# казан утлары

11
НОЯБРЬ-1974

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

11
НОЯБРЬ
1974

## Бу санда

**Ф. ЯРУЛЛИН. Экраннарда Павел Корчагин.** Шигырьләр . . . 3

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

**Я. ИГӘНӘЙ. Сөрелгән җир ята күпереп...** Шигырьләр . . . 7
**Г. ШӘМСЕТДИНОВ. Көз.** Шигырьләр . . . 8
**Р. НИЗАМИЕВ. Ил кайгысы — минем кайгым.** Шигырьләр . . . 9
**Н. ӘХМӘДИЕВ. Йөз чишмәнең суын эчеп карыйм.** Шигырь . . . 9
**Х. ХӘЙРУЛЛИН. Ургыл.** Роман . . . 10
**Р. СОЛНЦЕВ. Ул чакта.** Шигырьләр . . . 72
**А. МИФТАХЕТДИНОВ. Хан-Гәрәйнең сәер көннәре.** Хикәя . . . 74
**Р. КУТУЙ. Мамык оча...** Шигырьләр . . . 81
**Р. КУТУЙ. Яңгыр шавы.** Хикәя . . . 82
**К. БУЛАТОВА. Ана җыры.** Шигырьләр . . . 89
**Ш. МАННАПОВ. Китә чын Кеше дөньядан...** Шигырьләр . . . 92
**Е. УТКИН. Кырда күксел томан...** Шигырьләр . . . 94
**И. ТУКТАР. Җөмләләр** . . . 95

ОЧЕРКЛАР

**КамАЗ елъязмасы** . . . 96
**Э. КАСЫЙМОВ. Күршем Габделхәй буровоенда** . 98
**Р. ХИСМӘТУЛЛИН. Бәйрәм белән, дуслар!** . . 110

СӘНГАТЬ

**З. ШАҺИМОРАТОВ. Нөнәгәр кызы** . . . 121

ИСТӘЛЕКЛӘР

**А. ШАМОВ. Бер китапның тарихы** . . . 133

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ТӨРЛЕСЕННӘН

**М. ЕЛИЗАРОВА.** Пушкин Казанда . . . . . . 141
**Г. САТТАРОВ.** Исемнәр-атамалар сөйли: болгар-татар авыллары . . . . . . . . . . . . . 147

ПУБЛИЦИСТИКА

**Ш. ХАММАТОВ.** Матбугатта катнашу — язучының иҗтимагый вазифасы . . . . . . . . . . 156

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

**Ф. МУСИН.** Реализм юлыннан . . . . . . . . . 163

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Р. САЛИХОВ.** Тыйнак геройлар . . . . . . . . 173
**Ф. ХАТИПОВ.** Рафаил Төхфәтуллин повестьлары . 175

Н. Гайсинга 60 яшь . . . . . . . . . . . . . 181

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ

**Р. ИСАЕВ.** Үрнәкле кияү. Хикәя . . . . . . . . 182
Пудәш Патян хикмәтләре . . . . . . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 190



*Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 12.*

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-69.



Баш редактор: **Зәки Нури.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нафиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**



Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 1/VIII-1974 ел. Басарга кул куелды 11/IX-1974 ел. ПФ 09048. Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 87000 экз. Заказ Ю-206. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 12.



© «Казан утлары», 1974.

## Фәнис Яруллин

### Экраннарда Павел Корчагин

Ничә тапкыр инде укылган да
Ничә тапкыр инде каралган.
Ләкин һаман күңел тетрәтерлек
Вакыйгалар табам аңардан.
Ә бит үзе бер үк Павел сыман,
Юк шикелле һичбер яңарыш.
Һаман шул ук көрәш юлын уза,
Башкармый да кебек яңа эш.
Нәфрәте дә таныш, сөюе дә,
Батырлыгы таныш, язмышы.
Язмышына аның төзәтмәләр
Кертә алмый еллар агышы.
Төзәтмәләр ләкин кертмәсә дә,
Дәвам яза аңа замана!
Батырлыгы күпме буыннарда
Яңара да һаман яңара.
Аның кулларыннан төшкән каләм
Җирдә ятмый һич тә күгәреп.
Уннар аны бик тиз табып алды,
Уннар аны бара күтәреп.
Шуңа бугай һәр караган саен
Яңа батырлыгы күренә.
Корчагиннар яу кырында үлеп,
Йөрәкләрдә кабат терелә.

●

Алны-ялны белми эшлим мин —
Ташып тормый, юкса, көчем дә,
Тырышмыймын шөһрәт өчен дә,
Байлыкка да карыйм битараф,
Бары җитә — тора шул ярап.
Тик туктамыйм, эшлим һаман да:
Эч пошуны басар өчен дә,
Авырудан качар өчен дә,
Кешелегем раслар өчен дә,
Мәхәббәтем саклар өчен дә,
Яшәвемне аклар өчен дә —
Алны-ялны белми эшлим мин.

●

Ай-яй, көннәр озын инде,
Берсен буләрлек бишкә.
Иртән кырынган сакаллар
Кап-кара була кичкә.

Ай-яй, төннәр озын инде,
Таңнар атмый йөдәтә;
Мең төрле уй туа башта,
Мең төрле хис — йөрәктә.

Язлар озын, көзләр озын,
Чамасыз озын кыш та.
...Күренми үтә дә китә —
Гомер генә кып-кыска.

●

Шушы бик аз яшәү гомеремдә
Тормыш мине ничек үзгәртте:
Я суларга салып суытты ул,
Я утларга ташлап дөрләтте.
Үз төсемне калдырмаска теләп,
Маңгаемны еллар сырлады.
Чибәр чакта төшкән фотомны да
Альбомымнан кызлар урлады.
Үпкәли дип кызлар уйламасын,
Юк аларга минем һич үпкәм!
Ирләреннән яшереп альбомнарын
Карасалар, миңа шул җиткән.
Буем-сыным, төсем-кыяфәтем —
Бөтен яктан шундый үзгәрдем:
Элеккечә, үзгәрмәгән килеш
Калганнардыр калса — күзләрем.
Үзгәрмәде тагын турылыгым
Һәм дөньяга булган карашым!
Ак нәрсәне һаман — ак дидем мин,
Кара дидем — күрсәм карасын.
Күп күрсәм дә кара болытларны,
Күңел күзем, шөкер, яп-якты:
Мин һаман да яшь аралаш көлгән
Сабый бала кебек беркатлы.

## Нишләр идең?

Күп йөрдем быел кунакта,
Булмадым кай җирдә генә.
Кая гына барсам да мин,
Урыным булды түрдә генә.
Инде хәзер ял итәмен
Зәңгәр Балтик якларында.
Дулкыннарга серем сөйлим
Бик ямансу чакларымда.

...Беркем дә эш таләп итми,
Бар да әзер, бар да алда.
Ләкин җаным тыныч түгел,
Тормыш шавы җитми җанга.
Ярдәм итми көләч йөзләр,
Күңел күген каплый болыт.
Нишләр идең гомер буе
Яшәсәң гел кунак булып?

●

Мәхәббәт нәрсә икән?
Шуны белми Әминә.
Аңлатып бирми аны
Укытучы да, әни дә.
Сорап карый гөлләрдән,
Гөлләр кызара гына.
Кошлар да серләшәләр
Бары үзара гына.
Дулкыннар да сөюнең
Серләрен өйрәтмиләр.
Алсу таңнар да никтер
Йөрәкне дөрләтмиләр.
Көн артыннан көн үтә,
Кыз һаман җавап көтә.
Дөньяны гөлгә күмеп
Җылы як килеп җитә.
Болыннардан, кырлардан
Гөлләр өзә Әминә.
Сөю бик якын кебек,
Шуны сизә Әминә.
Көттерми мәхәббәт тә,
Килә яз эзләреннән.
Таба кыз үзенә җавапны
Яшь егет күзләреннән.

## Колын

Болында йөри колын,
Үзе уйнак, үзе шук.
Белми кая басканын,
Сулышы — ялкын, күзе — ут.
Я кинәт кешнәп куя,
Я үлән тешләп куя.
Я чәчәкләр елмаерлык
Шаянлык эшләп куя.
Я җиргә тып-тып баса,
Я әнкәсеннән кача.
Я сикереп чыга ул
Биек куаклар аша.

Болыннарның җаны ул,
Кемнең сабый чагы ул?

●

Игътибар! Игътибар!
Яз килгән дөньяга:
Күкләрдән моң тама,
Кояштан нур ява.
Һәркемгә елмаеп
Үтик бер урамнан.
Эчләргә җылылык
Йөгерсен шуңардан.
Карыйк һәр нәрсәгә
Сокланып, таң калып.
Уянсын күңелдә
Садәлек, балалык.
Гел җитди, гел олы
Булырга тырышмыйк.
Яшәсен сабыйлык,
Онытылсын кырыслык!

●

Яхшы атлар такыр юлда
Тырыша тигез атларга;
Адымын кызулый алар
Үргә менгән чакларда.
Үргә менүләре авыр,
Туктау ярамый ялга.
Кызулыйк әле адымны,
Таулар күренә алда.

●

Язмыш бит ул кәләш түгел,
Сайлап алып булмый:
Сайлап алган кәләштән дә
Һәр кеше дә уңмый.

●

Адашкан пуля тияме,
Атылганымы төзәп;
Бертигез яралый тәнне,
Бертигез өзелә үзәк.

●

Тормышым — авыр арба,
Йөгем гел артып бара.
Арбам күптән туктар иде,
Мәхәббәт тартып бара.

## Ямаш Игәнәй

●

Сөрелгән җир ята
күпереп...
Буразна эзендә
Саф бодай бөртеге,
шундый тук!
Күктәге кояшның
саф нуры
Гашыйк булды да аңа
шунда ук
Сикерде сөйгәне янына —
Яңгыр тамчысына
тотынып...
Һәм тиздән
Ямь-яшел нәни бер чаткы
Кояшка үрелде...

### Кырда

Этюд

Бер трактор кырда җир сөрә...
Әйтерсең ул
Әкияттәге көч-кодрәткә ия:
Буразнасы — аркан.
Шуның белән
Ураган да әйләнәсен җирнең
Гел кояшка таба тарта гүя...
...Офык чите. Тракторны кара:
Кояш уртасына кереп бара!..

●

Менә шушы якка таба
Барам мин, барасы бар:
Әнә шул офык ташыннан
Бер кала саласы бар!

Менə шушы якка таба
Барам мин, барасы бар:
Әнə шул яшен чаткысын
Үземə аласы бар!

Менə шушы якка таба
Барам мин, барасы бар:
Ул кыя — юлның өстендə,
Урталай ярасы бар!

Менə шушы якка таба
Барам мин, барасы бар:
Җыр язар өчен каләмне
Кояшка манасы бар!..

## Габделхак Шəмсетдинов

### Көз

Этюд

Юл буена тезелгəннəр
Шəмдəй нарат баганалар.
Үтеп киткəн юлчыларга
Моңсу гына карый алар.

Баганалар җитəклəшкəн
Тимер чыбык куллар белəн.
Суыктанмы калтыранып
Чыбыкларда Ай йөгерə...

### Гафу итмə

Оныт инде мине
мəңгелеккə,
Йөрəгеңнəн алып
ташла да...
Гафу итмə мине,
гафу итмə.
Алыштырдым сине
башкага...

Үкенсəм дə, хəзер
соң бит инде.
Кире кайтмас
безнең үткəннəр.
Гафу итмə мине,
гыйбрəт алсын
Мəхəббəтен
ташлап киткəннəр.

## Рашат Низамиев

●

Ил кайгысы — минем кайгым,
Мең кайгырам, мең янам.
Кайгыларны киметмичә
Китәсем юк дөньядан!

Ил шатлыгы — минем шатлык,
Мең шатланам, мең янам.
Илгә шатлык өстәмичә
Китәсем юк дөньядан!

### Чаган

Юл кырына төште орлык,
Үсеп чыкты яшь чаган.
Канат тәрткән кош кебек ул
Омтылды өскә табан.

Карлы-бозлы бураннарның
Килер әле ничәсе!
Күпме язны каршылыйсы,
Күпме җәйне кичәсе.

Күпме божра ишәйтәсе,
Күпме яфрак коясы, —
Каршында тора чаганның
Башланмаган дөньясы...

Юл буеннан үтеп тора
Җәяүлеләр, атлылар.
Чыбыркы сабына диеп
Яшь чаганны... чаптылар!

## Нур Әхмәдиев

●

Йөз чишмәнең суын эчеп карыйм,
Чын бәясен белер өчен бер чишмәнең.
Бер җимешнең тәмен белер өчен,
Ашап карыйм йөз агачның җимешләрен.

Йөз илдә мин йөрим сәяхәттә,
Чын кадерен белер өчен туган илнең.
Мин йөз төрле телдә җыр өйрәнәм,
Нәфислеген җырлар өчен үз телемнең.

**Хәким Хәйруллин**

# УРГЫЛ

РОМАН

*
* *



Уханов тагын көнозын шахтада йөрде. Бер штректән чыгып, икенчесенә керде, участоктагы барлык забойларны баштанаяк тикшерде. Өмете бөтенләй үк өзелмәсә дә, һәр җирдә эшнең өстерәлеп кенә баруын күреп, күңел юанычы тапмады. Бөтен шахтаның тәрәге дип саналган вентиляция штрегендә ике забойщик беренче тапкыр шартлатылган күмерне дә төяп озата алмаганнар. Шушы арада шурф белән тоташырга һәм ике участокка берьюлы саф һава өрдереп торырга тиешле штрек иде ул. Болай барса, эш атналар буена сузылачак һәм Беренче шахтада һава кытлыгы башланачак. Кайсы гына забойга кермәсен, әле дә тын алырлык түгел — зәп-зәңгәр төтен, шартлатканнан соң сәгатьләр буена забойдан китми тора.

Конвейерный штректә Шабанов дигән карт ярты күмерен дә төямәгән, ул эшләгән җирдә кичә үк ныгытыласы штрекләр әле бүген дә ныгытылмаган.

Баш штреккә төшүгә, кәефе тагын да кырылды Ухановның. Вагонетка этеп йөртүче малайлар, бишмәтләрен бөркәнеп, туңудан калтыранакалтырана, тәрәүлекләр өстендә ауныйлар. Коногон кайдадыр юлда, вагонетка тәгәрмәчләре рельстан ычкынган, батып ята, диделәр аңа. Малайларны төрткәләп торгызды да коногонны эзләргә чапты. Тиз тапты ул аны: вагонеткаларын рельска куярга азапланып ята иде. Икәүләшеп, тездән пычрак ярып, көчкә-көчкә куйдылар. Уханов бик озак барды коногон артыннан, юлны күзәтте, ә юл бөтенләй яраксыз диярлек иде, люк янына җитәрәк, яңадан берьюлы ике вагонетка юлдан төште. Бусында Уханов люкта торучы малайларны җилтерәтеп алып килде. Җыйнаулашып сәгать буе азапландылар. Забойщикларга эшне башлап җибәрергә дә мөмкин иде, әмма смена да беткән иде шул.

[1] Дәвамы. Башы 10 нчы санда.

Җен ачулары чыкты Ухановның, забойщиклар артыннан саженлы адымнар белән тышка, нарядныйга, ашыкты. Анда да күңелсезлекләр көтеп торасын ул яхшы белә: я берсе авырып эшкә чыкмаган, икенчесе фронтка киткән. Кайбер забойлар шартлатылмый калды. Ә бу инде яңа сменага эшләргә урын юк дигән сүз.

Шахтага җылы һава өрдереп торырга тиешле штректән аның каршына Хәертдин килеп чыкты, десятник булса да, ул анда үзе күмер төягән, Хәмзәгә булышкан.

— Харитонов, йөкләмә үтәмәгәннәрне минем янга! — диде Уханов, аны күрүгә үк.

— «Мунчаң» шифалы булсын! — дип җавап кайтарды Хәертдин. Ул яхшы белә: хәзер начальник йөкләмә үтәмәүчеләрне чакырып пешерәчәк, утлы табага бастырачак. Моны шахтерлар «Уханов мунча кертә» диләр.

Арган-алҗыган, тәмам әлсерәгән хәлдә Уханов нарядныйга кайтып керде дә күптән җыелып аны көткән яңа смена янына килде. Участоктагы хәлне инәсеннән җебенә чаклы сөйләп бирде, аннары наряд биреп чыгарып җибәрде. Шуннан соң гына үзенең бүлмәсенә аяк басты.

Җиде төн уртасы. Стена сәгате вакытны келт-келт чутка сала гына бара. Бүлмәдә шул келт-келттән башка тавыш ишетелми. Тик ара-тирә эстакадада вагонеткалар бушатканда гөрселдәп күмер коелганы ишетелә. Ухановның өч тәүлек инде өенә дә кайтып керә алганы юк. Өстәл читенә башын төртеп кенә бераз черем иткәли. Куелган срок якынлаша, ә бер генә участок та күмер чыгарырга әзер түгел. «Сивак»та хәл бүтәннәргә караганда да яманрак: егермеләп забой тезелешеп утырган күмер стенасы — лава кистерелсә дә, әлегә чаклы конвейер куелмаган, су түккеч насослар килеп җитмәгән, тимер юл төзелеше тоткарлана. Торбалар, рельслар, кабельләр һәм бүтән төрле җир асты җиһазлары әллә кайда сәяхәт итәләр. Штрекләр ераклаша, озыная, шуның белән бергә, куәтле вентиляторлар да куелырга тиешле, ә алар житешми. Исле һаваны суырып торачак шурфны тизрәк казырга лебедка кирәк, ә ул — участокта бер генә. Иң хәвефлесе: кыш көннәрендә су торбалары һәм канаулар катмасын өчен җылы өрдергеч штрек ярты юлда тукталган. Берәр айдан чатлама суыклар бөтен штольняне бозга күмәчәк, Беренче шахтада бөтен эш тукталачак...

Участокта шушындый зур эшләрне башкарып чыгарлык забойщиклар, ныгытучылар, күмер төяүчеләр һәм вагонетка йөртүчеләр бармак белән генә санарлык. Десятниклар курсына тәҗрибәле забойщикны җибәрергә, барлык штрекләрдә дә эшне кызулатырга кирәк. Кирәк, кирәк, кирәк... Ни генә кирәкми!

Бераздан бүлмәгә Якуп килеп керде. Уханов сүзне кыска тотты:

— Иртәгәдән башлап, эштән соң десятниклар курсына йөри башлыйсың!

Якуп чатлатып җавап кайтарды:

— Була, иптәш начальник! — Аның эштән кайтышы, ашханәдә тамак ялгап алган да чыгара башлаган стена газетасын төгәлләргә кергән. Ухановның тәкъдиме бераз күңелен үстереп җибәрсә дә, азрак шом да салып куйды. Ни әйтсәң дә, десятник сменада барысы өчен дә җаваплы, ни генә булмасын, аннан сорала, планны да аннан «таптыралар».

Бүлмәгә баш штрек терәүләре кебек озын буйлы карт керде, начальнигы каршына басты. Күзләре әйтә: «Я, картлач, арт сабагыңны укытам бит!» — ди берсе. Ә икенчесе җавап кайтара: «Һич тә исем китми, булган көч-куәтемне забойда калдырдым».

— Наприенко, сиңа җир бит дими ни дим! Яшьләрдән ояла белер идең! Сугыш вакытында аяк чалуың өчен ни кылырга белмиләр дисең-

ме? — Картлачның күзенә керердәй булып, һәр сүзен кадап әйтә Уханов. Наприенконың ялкаулыгы ташып чыкканын ул күптән белә. Участокта аннан да әйбәт ашаган-эчкән адәм юк: үз йорты, сугышка хәтле дөнья хәтле әйбер җыеп калган, хатыны зур шәһәрләргә барып алыш-биреш итеп йөри. Бу картның нык беләкле икәне әллә каян сизелеп тора. Тик нинди этәргеч табып кызурак кыймылдатырга аны?

Уханов Якуп янына килеп басты.

— Әхмәтҗанов! Наприенконы забой түрендә яткызып йоклат! Гырлата, гырлата. Аякларын күселәр кимерә, ә ул сизми дә. Газетаның урта бер җиренә сурәтен яса. Ямьсез иттереп. Хәзер үк, үз күз алдында.

Һәр вакыт балыктай телсез Наприенко корт чаккандай сискәнеп китте.

— Ассаң ас, киссәң кис, начальник, тереләтә суй, ә сурәтне ясатма да, элдертмә дә.

— Клубка элдертәм. Бөтен дөньяны синнән көлдертәм, Наприенко.

— Син мине фэошникларга тиңләмә, яме! Колга буе гәүдәмә бер утырып ашаганда бер мич ипи кирәк. Ач бәндә мин, тилмерәм, корсагым буп-буш. Олы кешене юкка рәнҗетәсең, гөнаһ җыясың...

Якуп көлемсерәп башын күтәрде. «Алдый картлач, тук ул. Ялкау тамыры бүрткән, үгез муен!..»

Аны уйларыннан Уханов бүлдерде:

— Әхмәтҗанов, эшеңдә бул! Җен кебек ямьсез итеп яса үзен! Менә, газетаның урта бер җиренә. Шушында.— Өстәлгә җәеп салган кәгазь уртасына төртеп күрсәтте.— Моннан ары да аяк чалсаң, милиция белән туп-туры юлың төрмәгә, Наприенко! Ишетсен колагың! Сугыш заманының законы каты!

Картның түгәрәкләнгән күзләре ишекле-түрле йөгерә. Хатын күрсә, егыл да үл. Уклау аркамнан төшәчәк түгел.

— Начальник, безләрнең олы атасы,— ди ул ыңгыраша-ыңгыраша,— яман атымны сатмасаң иде! Тәнемдә җан әсәре бар чакта, тагын тилпенеп карармын. Әгәр алдасам, телем корысын!

Уханов аңа ышанмый.

— Тукран тәүбәсе! — Аны бер читкә бастыра. Аннары ишекне ачып боера: — Барыгыз да керегез!

Бүлмә эче шыгрым. Хәлдән тайган малайлар да, таза күренгән картлар да бар. Хәмзә дә монда. Күз читләре белән генә газетага карап алалар.

Уханов үз каршына тәбәнәк буйлы, юан гәүдәле, күз төбенә «капчыклар» асылынган, шешенгән сымак битле, олы яшьләрдәге картны сайлап бастыра. Эченнән: «Туры кара, туры, Шабанов! Нигә йөзеңне яшерәсең! Оятың кайда?» — ди.

Ә гаеплесе: «Миннән план ала алмассың, болай да аякларым калтырана. Килешең ат белән чыпчык куган шикелле бит, тиңең белән тибеш»,— ди, шулай булса да башын читкә бора, әле бер аягында, әле икенчесендә генә басып тора.

Хәмзә бу адәмне күптән белә: бер палаткада торалар. Аның чуен өчаягы бар, шуны бер дә үзеннән калдырмый, һәр вакыт янында асып йөртә. Астына ягып су җылыта, чәй өчен үлеп тора ул. Анысы ярар иде әле, атлар алдыннан солы чәлдергәли. Ат ризыгын өчаякта киптерә дә төннәр буе киледә лап-лоп төя. Шул төйгене кайната-кайната да, иләктән сөзеп, кесәл пешереп ашый. Кайчакта Шабанов кесәлне малайларга да каптырып карый. Шабанов заманында Америкага да барып кайткан. «Йомырканы бәрәңге урынына ашадык»,— дип мактанып сөйләргә ярата. Малайлар ышанмый, икеләнә: аркасы тулы камчы эзе, тәм-том тәтеде микәнни?! Аларны анда кешегә дә санамауларын сөйләгәне бар ич. Йомыркаларын шул чакта битләренә атарга ие!..

— Я, кыяр карачкысы! Судка биримме үзеңне, әллә Априенко янына яткызыйммы? — Ухановның матур йөзе бик усал.

— Теләсәң нишләт! Терелэй тотып ашасаң да әйтерем юк.— Шабанов кулындагы өчаягын биленә кысыбрак тота, янәсе, тия күрмә, үземне ашасаң да, монысын миңа калдыр.

— Судка бирәм, Шабанов, пычагым да эшләргә теләмисең!

Шабановның шешенгән йөзендә аз гына да үзгәреш сизелми.

— Бир, бир. Карышыр гадәтем юк,— ди.

— Априенко янына яткызып көлкегә калдырырмын! — Уханов өстәлдәге газетага күрсәтә, сурәткә бармагын төртә,— менә шушылай итеп гырлый-гырлый ятарсың, аякларыңны күселәр кимереп китәр...

— Яткыр, яткыр, укам коелмас. Туйганчы бер йокпармын, ичмасам,— ди Шабанов.

Малайлар эчләре катып көлә.

— Көрәк хәтле кашык тоттырып иң уртага бастырырмын! — Уханов, картның килбәтенә түзә алмыйча, көлүен көчкә тыеп тора, авызын учы белән каплый.

Шабановның йөзе ачыла.

— Көн-төн рәхмәтләр укыр идем, начальник. Мәрхәмәтсез бәндә дип, ачу тотып йөрүчеләр әйтәдер, әүлиядер син.— Картның сүзләре бугазына утыра.

— Стена газетасына ямьсез итеп сурәтеңне ясарга ди бит ул синең. Ә син йокларга, тыгынырга,— ди Хәмзә Шабановка.

Картның гамендә дә юк, ник дөнья икегә ярылмый.

— Ясатсын. Үземнән дә нурсыз итеп барыбер сурәтли алмаслар. Априенко кордаш белән ни күрсәк бергә күрербез.— Эченнән: «Тизрәк җибәрсен иде, кесәмдәге бер уч солымны эшкәртәсем бар»,— ди. Ухановка: — Начальник, әйт әле, кайчан өшегән бәрәңге белән өшегән кәбестә өләшә башлыйсыз? Бүтән җирдә күптән өләштеләр бит инде,— ди.

— Хәрам аш җыйсаң, тешең коелыр. Төн узгач, төш күреп ятасың! — Уханов тавышыннан бүлмә стеналары калтырый.— Бар, үкчәңне күтәр! Иртәгә йөкләмәне үтәмәсәң, күземә күренәсе булма!

Ә Шабановка нәрсә, такылдый бирә:

— Үлгәч тә кырык көнлек эш кала. Рәхмәт, рәхмәт, рәхмәт! — Син күр дә мин күр, сыпырта гына тизрәк.

Бу юлы Уханов каршында таза гына гәүдәле ир. Урта яшьләрдә булыр, ни сәбәпледер сугышка алынмаган. Эшкә соңга калып килгән икән ул.

Уханов аның белән сүзне кыска тота:

— Суд хөкем итәр,— ди. Телефоннан милиция чакырта, дезертирны алып китәргә куша.

Бүлмәдә гүр тынлыгы. Кыймылдарга да куркалар. Уханов ахырда бәләкәй буйлы, ап-ак чырайлы, җәлпәк борынлы малай алдында туктала. Малайның өсте ләчмә су, битләре пычрак, күзләре дә тешләре генә елтырый. Икесенә карасаң, бозау белән фил басып торалар кебек.

— Я, йолкыш, шахтер буласың килмәсә, сине дә милициягә ияртеп җибәрә алам. Телисеңме?

Малай күзләрен челт-челт йомгалый, бертуктаусыз аяк алыштыра.

— Агай, авызны чөйгә элеп булмый ич.

— Алаймы? Орчык кадәр гәүдәңә дә, аттай эшләгән Әхмәтҗановка да, Алыптай гәүдәле миңа да берәр кило ипи бирәләр. Я, нигә эшләмисең?

— Эшлим лә.

— Нишләп йөкләмәңне үтәмисең?

Малай ярыйсы гына кыюлана төшә:

— Юрганыңа карап аяк сузасың аны, агай. Булдыра алмагач, нишлим? Бүген каты күмерле забойга эләктем. Кулбашым калмады. Астан да, өстән дә чиләкләп су коя. Һава җитми, тын бетә...

— Күмер каты булса, кәйләңне ешрак очлат! Ә тел озайтканыңны бүтән ишетмим! Утыр, аңлатма яз! — Уханов яңадан шундый ук йолкыш каршына килеп туктый. Бу малай моны көтмәгән иде бугай, куркудан йөрәк өзгеч тавыш белән:

— Әни! — дип, елый-елый ишектән чыгып йөгерде.

Бүлмәдә беркавым авыр тынлык урнашты.

Уханов үз-үзенә: «Забойщиклар кытлыгын җиде җирдән кырыпсебереп җыйсаң да киметерлек түгел, ә боларның һәммәсен бергә җыйсаң, бер иргә тормыйлар»,— ди. Хәмзә, үзенә чират җиткәнен көтеп, Якуп тирәсендәрәк чуала, начальнигының акыра башлавын көтә: «Миңа берәгәйле төшерер, бер дә йөкләмә үти алганым юк». Кыяркыймас кына үзе сүз башлады:

— Николай Иванович, буш вагонеткалар җитешми. Менә бүген дә... Атлаган саен тәгәрмәчләр рельстан ычкына, коногон азап чигә.— Тагын әлләниләр ачып салмакчы иде, көтмәгәндә бүлмә яңгырап китте:

— А ну, марш, вак балык! Икенче, йөкләмә үтәмәсәгез, колагыгызны борырмын. Сугыш вакыты, тел озайтыр чак түгел: эшләргә, фәкать эшләргә! Таш яуса да, план — закон! Кемгә әйтәләр? Марш!..

Бөтенесе берьюлы дәррәү кубып тайдылар.

Уханов Якупка таба борылды.

— Я, очына чыктыңмы? Ярый, бүгенгә җитәр. Газетаңны нарядныйга эл дә йөгер палаткаңа!

Ләкин Якупның чыгып йөгерергә исәбе юк иде. Аның үз кайгысы. Әле монда килгәнче үк бик күп сораулар әзерләп куйды ул Ухановка. Куллары кәгазь битенә сурәтләр төшерде, ә хыяллары башын катырып утырды. Менә хәзер барысы да ачылачак... Өметме бу, әллә коры бер теләк кенәме? Ничек булса да булыр, өметсез шайтан гына яши дөньяда. Һаман шул ата инде өмете, аның белән көрешү. Кайдадыр шушы тирәдә генә булып төшләренә керә. Ургылга килә торган тимер юлны салып йөридер кебек тоела.

— Иптәш начальник, кая хәтле килеп җиткән хәзер тимер юл? — Ул Ухановка һәр вакыт «иптәш начальник» дип дәшә, ә бүтәннәр фамилиясе белән яки Николай Иванович диләр. Якуп үзенчә әйтсә, Ухановны олылап, зурлап әйткән төсле.

— Моннан күренми,— диде дә Уханов идән буйлап йөреп китте. Тукталып калды. Йомшак кына әйтте:— Кара аны, юләрлек эшләп ташлама! Сиңа ышансаң, карап кайтам дип китәрсең дә барырсың.

— Миңа эшкә иртәгә кичкә генә бит.

— Беләм.— Уханов тагын бүлмәне иңли-буйлый башлады.

— Анда хәтле юл-мазар юкмыни?

— Ургылга килеп төшкәндә күрдең бит нинди сазлык, чытырманлык икәнен. Берничә урында елга кичәсе. Ара егерме чакрымлап. Стансага чаклы тәэминат складыннан көн саен тракторлар китеп тора.

Якупка шул гына кирәк иде. Бүген ул көндез эшләде, иртәгә төнге сменага чыгасы. Әллә тәвәккәлләп барып кайтыргамы?

...Менә Якуп тау итәгеннән кызу-кызу атлый, Уханов шикелле, җилгә каршы йөз белән, күкрәген киереп атларга тырыша, ә уйлары әллә кайларда. Әллә ниткән табышмак чиштерә бу Уханов. Сораган чакта тимер юл салучыларның кайда икәнлекләрен дә әйтмәде, ә хәзер үзе үк шунда бар ди. Әллә эти турында сизенгәнме?.. Алай дисәң, ул хакта авыз да ачканы юк Ургылда... Хәмзә дә ышанычлы малай. Каян белгән начальник бу турыда?

*
* *

Бәхетенә каршы, әле тракторлар китмәгән иде. Олы гына яшьлә-дәге бер тракторчы кисәү таягы белән дыңгычлый-дыңгычлый трактор-ның «мич»енә каен шакмагы тутыра, ул «мич»ен болгатып җибәргәндә, һавага соры төтен күтәрелә, очкыннар чәчри. Бу эшен бетергәч, уң аягын җирдән сөйри-сөйри, титаклый-титаклый, трактор чанасына шакмак тутырган капчыклар төяргә кереште. Якуп тракторларның күптән инде бензин урынына каен шакмагы ягып йөрүләрен белә иде һәм ул тракторчыга капчык төяргә житез генә булыша башлады, үзе-нең гозерен дә ачып салды. Тракторчы каршы килмәде. Икенче бер тракторда Якуптан шактый тәбәнәк буйлы, табак битле яшүсмер егет иде, анысы да «мич»ен кыздыра, тирләп-янып чыккан, тракторы паровоз шикелле «пых-пых» итеп тора, калтырана: бик тузган, искергән, ахры. Якуп аның да чанасына капчыклар төяргә өлгерде.

Көн ярыйсы гына җылы иде, ә хәзер шактый салкынайткан. Тирә-юньгә зәңгәр томан җәелгән, кешеләр дә, тракторлар да, каралты-кура-лар да, агачлар да карачкы кебек кенә булып диңгез уртасында чайка-лып утыралар шикелле. Юк, югарыдан төшкән томан түгел бу, мәңгелек туңлы сазлыктан күтәрелә ул, кеше буеннан да биегрәккә күтәрелми. Күктә тулган ай балкый, йолдызлар җемелди.

Кузгалып киттеләр. Якуп тракторның алдагысында, кабинада яшүсмер белән янәшә утыра. Ургыл артта калды. Ургыл елгасы аша салынган агач күпердән чыктылар, әйбәт кенә барганда, трактор тук-тады, тракторчы «мич»кә шакмак тутыргач һәм болгаткалагач, яңадан кузгалдылар. Берничә чакрымнан тагын шулай кабатланды. Бу юлы Якуп җиргә үзе сикереп төште, шакмакны да үзе тутырды, башын-күзен черки көтүе сарып алды.

Әнә, сызылып кына таң атып килә. Җәйрәп яткан сазлык уртасының әле теге, әле бу жирендә агач шәүләләре беленә. Тирә-як тып-тын. «Хәерле көн!» дип, берничә кат кычкырып куйды Якуп. Икесенең дә йөзләре бераз яктырып китте.

Трактор һаман алга таба сазлык ера. Сазлык ера дип, бер дә йөрелмәгән җир түгел бу үзе, шушы ук тракторлар бу төшләрне ничә тапкыр айкамаганнардыр, шуңа күрә юл дип атасаң да ялгыш булмас. Чокыр-чакырга кереп чуммасам, аяк асты боз ич, ә болай карасаң, трактор белән бу җиргә керергә үк котларың очар. Якуп тирә-якны күзәтеп бара. Инде ярыйсы гына яктырды. Үтереп тә йокысы килә башлады, башын тотар хәле дә калмады. Әллә тракторын сорап карарга инде. Йөртә белә бит ул, авылда чакта аз айкадымыни колхоз басуларын. Тик бу газогенераторлы тракторның серен белми шул әле.

Менә текә ярлы кечкенә генә инешне аркылы чыгасы бар. Бик яман урын, суы да тирәндер әле. Җайлап кына чыгар бу малай, остарып житкәнгә охшый. Әйе, шулай булып чыкты да, теге яктагы яр өстенә бик ансат күтәрелделәр... һәм күтәрелүләре булды, тимер чана ничектер трактор ыргагыннан ычкынды да шуыша-шуыша артка таба төшеп китте, суның нәкъ уртасында туктап калды. Тракторчы бу юлы да аптырап калмады, тракторын житез генә боргалады да чанасы янына төште. Бу юлы инде чананы тагу өчен Якупка тез тиңентен салкын су эченә керергә туры килде. Азаплана торгач, чананы тактылар да яр өстенә менделәр һәм берәр метр биеклегендәге түмгәкләр арасындагы суны ера-ера китеп бардылар. Артта тирән-тирән трактор эзләре яры-лып ята. Сазлыкның очы-кырые күренми. Якуп ыштырларын, чалбарын салып тракторның җылы «мич»енә элгән иде, алар да бераздан кибеп

өлгерде. Коры аякчу һәм чалбарын киеп җибәргәч, янадан йокы баса башлады.

Якуп күзләрен ачканда, трактор бар көченә үкерә, әле артка, әле алга сикерә, ләкин бер урында таптана иде. Йөрәге тагын да катырак дөпелдәргә кереште, җиргә сикереп төшүгә, тракторның чокырга төшеп утырганын абайлады. «Эх!» дип куйды ул тешләрен кысып, хәзер инде күргән төшен юрарга да күңеле бармады, ничек иттереп бу әсирлектән котылу турында уйлана башлады. Арттагы трактор да алга узып китәрлек урын түгел, ичмасам, бигрәк баткак җир икән... Нишләргә? Стансага тәпиләргәме? Ерак микән? Ерак микән дип көтеп ятаргамы? Юк! Көтәр гадәте юк аның. Әнә, тау артыннан кызарып чыккан кояшның алсу нурлары бу якларга ук үрмәли башлаган. Ашыгырга, анда берәр трактор-мазар табып...

Якуп, тез тиңентен сазлык суын ерып, трактор әзеннән алга атлады.

— Әй, шахтер, кем син? Исемеңне дә сорашмадык. Акылың бармы? Үпкәнә салкын тигезеп теге дөньяга китәсең киләмени?! Борыл! Ишетәсеңме? — дип кычкырды аксак тракторчы. Тик Якуп аны ишетми иде инде, аны хәзер тракторга аркан белән бәйләп тотсаң да туктатырлык түгел.

— Әй, егет, барсаң урман чыгаручылар янына бар, трактор булса аларда булыр,— дип кычкырды икенчесе.— Ай-һай, үзсүзле икән! Кем соң син?

Якуп артына борылды да:

— Әхмәтҗан малае,— дип җавап кайтарды. Ул ботинка эчләренә тулган суны пычтырдатып алга атлавын белде. Менә сазлыкның чиге дә бар икән, урманга барып чыкты. Монда юл коры, комлы, кояш та арканы җылыта хәзер. Аякчуын сыгып янадан урап киенде дә алда күренгән йортларга охшаш ниндидер корылмаларга таба ашкынды, бераз гына чырае да ачылып киткәндәй итте, эченә җылы да керде.

Ераклarga-еракларга сузылып тимер юл ята. Иртәнге кояш нурларыннан елтырап яткан рельсларга бик озак карап торды Якуп. Шунда ук ике-өч йөк вагоны да тора. Болардан көчкә аерылып киткәч, усаклар-карагайлар арасында берничә барак очратты, аннары аланлыкка килеп чыкты. Тирә-юньдә ник кенә бер җан иясе күренсен, кайда нәрсә барын сорашып барыр иде, ичмасам. Беренче чиратта ятьрәк трактор эзләргә, ярдәм җибәрергә кирәк... Әнә, әрдәнә-әрдәнә бүрәнәләр өелгән, шпаллар, тирәүлекләр... Урман кисүчеләре булгач, чыгаручылары да бардыр... Эзләргә, табарга...

Күп чуала торгач, баракларга юлыкты. Урман кырыенда газогенераторлы берничә трактор тора. Шунда ук ватык трактор детальләре, керосин мичкәләре аунап ята...

Якуп якындагы баракларның берсенә керде, коридор буйлап беренче бүлмәне шакыды, ачмадылар. Икенчесеннән «Кем кирәк?» дип сорадылар. Якуп тракторчы сорады, аңа күрше бүлмәне шакырга куштылар. Чыннан да, бу бүлмә ишеге төбендә майлы киемнәр, ботинкалар ята иде. Якуп кыю гына ишек шакыды. Ишектән ирләр башы күренде.

— Кем кирәк? — дип сорады ул баш.

— Бусага аша сөйләшмиләр,— диде аңа Якуп.

— Алайса, өйгә рәхим ит,— диде баш.— Мактап йөрисеңдер, яңа гына чәйләп утыра идем. Кер әйдә!

— Рәхмәт! Теге тракторларның берсе синеке булмый калмас,— дип, Якуп майлы киемнәргә күрсәтте.

Бүлмә хуҗасы, өстенә тужурка элеп, коридорга чыкты. Ябык кына, тәбәнәк кенә буйлы, сыңар күзле кеше иде бу. Якупны баштанаяк күзәткәннән соң, җайлап кына сорады:

— Минеке булды, ди. Шуннан?

— Син миңа менә болай хаҗәт! — Якуп бармагы белән муенын

сызып күрсәтте.— Ургылдан без. Башыбызга бәла төште. Анда батып калдылар.

— Ул төшләр минем башны да череткән җирләр, туган. Тик менә, мин бит гади тракторчы гына шул. Үз белдегем белән китә алмыйм. Начальство әле уянмагандыр...

— Алайса, бигрәк шәп. Алар торганчы әйләнеп тә кайтырсың. Тәвәккәл таш ярган...

— Кыю егет күренәсең... Миңа әләгәсен белеп торасың ич.

— Аның каравы, мең-мең рәхмәт ишетерсең, агай-эне.

— Һем. Рәхмәттән тун тектереп булмый...

— Тунмы?.. Ә анда ике трактор, беләсеңме, ике трактор. Алар бүген кичкә Ургылга әйләнеп кайтырга тиешләр. Шахтага җиһаз ташыйлар алар, анда аларны йөзләгән күз көтә. Иртәгә тагын шушында ук киләчәкләр. Ә син тун дисең!.. Кайда тора начальствогыз?

— Кызма, туган, мин үзем дә кызучан. Берәр нәрсә уйлап багарбыз бәлки. Иптәшләрне булса да уятыйм, белеп торсыннар.

— Ургыл юлы буйлап бара торгач күрерсең үзен. Моннан биш-алты чакрымнар гына булыр. Кеше икәнсең, кеше бул, егет бул, вөгъдәңне бозма...

Якуп, баскыч төбенә утырып, куен кесәсеннән йодрык хәтле ипи кисәге алды. Кичә төш вакытыннан бирле авызына ризык кергәне юк әле аның. Ипинең кадерен белә ул, нормасын төгәл өчкә бүлеп ашый.

Барактан теге тракторчы чыкты, бу юлы майлы киемнәрен дә киенеп алган иде.

— Туган, болай эш түгел бит әле бу! Корылай ашап утырасың, ашказаның кызганырга кирәк. Әйдә, чәйләп чыгарсың, самаварым өстәлдә җырлап утыра.

— Рәхмәт! Бүтән чакта.

— Үзең беләсең, алайса. Ә без тәвәккәлләргә булдык.

...Менә Якуп пропуск бүлмәсендә, кечкенә тәрәзә каршында басып тора. Берсен-берсе күрмичә генә сөйләшәләр.

Сораша торгач: «Монда сез кызыксынган кеше юк»,— диделәр аңа.

Аннан чыккач, аяклары кая атларга да белмәде. Шулай ук коры килеп буш кайтып китәрмени? Тагын кемнән сорап багарга? Әгәр дә олы начальникларына кереп караса?..

Күп бүлмәләрне үтте Якуп. Уханов исеменнән иң олы начальникка кадәр дә барып җитте. Ләкин җаваплар пропуск бүлмәсендә алганнан артмады.

Хәзер кая барырга? Кемнән сорарга? Шулай ук этисен таба алмыйча кайтып китәр микәнни?

Кояш инде шактый күтәрелгән иде. Көн матур, ләкин Якуп моны сизмәде, тирә-юне караңгы булып күренде кебек аңа.

Аннары ул тракторлар тавышы ишетелгән якка таба китеп барды. Кайтып төшүгә, өстен алышырга дип мунчага йөгерде. Эш сәгатьләре башланырга санаулы минутлар гына калып бара иде. Кайдандыр Хәмзә килеп чыкты. Сәерсенеп, ябыгып киткән дустына карап торды.

— Якупҗан, малай, төнозын, көнозын кайларда йөрдең? Мин, әй, борчылдым, әй, борчылдым, эзли-эзли кайларга гына бармадым да кемнән генә сорашмадым. Әйт инде?

— Поезд карарга бардым,— дип җавап кайтарды Якуп.

**БИШЕНЧЕ БҮЛЕК**

Баш штрекнең пычрагын тубыктан ярып, Уханов белән Степанов нарядныйга кайтып керделәр дә, манма су брезент тужуркаларын салып ишек түрендәге почмакка ыргыткач, уфылдашып өстәлнең ике

ягына килеп утырдылар. Икесенең дә кәефләренә кырау тигән. Газета ертып тәмәке төрделәр, икесенә бер шырпы сызып кабыздылар. Участокта кабынган бәхәс яңадан кызып китте.

— Теләсәң нәрсә әйт, тик мин, бер кеше сыныннан алла ясап, шуңа табынып ятарга риза түгел,— дип башлады Степанов. Ашыкмый гына дәвам итте:— Ә шахтерларны күптән табындыра алмассың, Коля.

Уханов тузгына, ачуын йота алмый, сүзен теш арасыннан гына чыгара, кызганнан-кыза бара:

— Җир асты эшләренең серләренә төшенгән, бөтен һөнәрне белгән кемне өйрәтеп җибәрдең ФЗОдан? Борын аслары да кипмәгән малайларың ни эш кыралар? Планны малайларга да олыларга биргән хәтле бирәләр миңа! Кеше саны бармы — бар. Җыенысы арасында әлегә Әхмәтҗановны гына күрәм.

Степанов үпкәләвен сиздерми, хәзергә рекорд куйдыру урынсыз, нык база юк диюендә тора иде. Җайлап кына әйтте:

— Ятлар бакчасына аткан ташың үзеңнең дә алмаңны коймасын, Николай Иванович.

Уханов бераз йомшара төште, еламсыраган булып:

— Моңарчы телле-тешле түгел идең, парторг итеп сайлагач, шактый үзгәрдең. Ярый, без икебез дә бер шахта бүреләре...— диде.

— Бер оядан да төрле төстәге казлар чыга.

Десятникның бу сүзеннән Ухановның яңадан ачуы кабарды.

— Конвейерный штрекнең артта калуы бугаздан буа минем, беләңме? Тизрәк чыбыркыларга, алга куарга кирәк. Күт тә тор: кызыл флаг «Сивак» өстендә җилфердәячәк! — Сүнгән лампасын кабызды, бүлмә эче яктырып киткәндәй булды, үзенең дә эчендә ялкын дөрли иде. Степанов аңа ихлас күңелдән күз төшерде: шул ук киң маңгай, шул ук матур йөз, бетмәс-төкәнмәс көч ташып тора. Юка иреннәр, куәтле җилне дә аямыйча барырлык алга омтылыш. Әйе, Әхмәтҗанов турында ул хаклы: забойның теләсә нинди авырын да ышанып тотырырга ярый. Яшьләргә хас чатлы-ботлы яклары бар икән, тормыш үзе тора-бара арындырыр.

Ә Ухановта бер уй: йодрык йомарланган икән, селтәнгәнсең икән — сукмый калма!

*
* *

Иртәгә рекорд куелачагын һәм ул Якупныкы булачагын бөтен участок бүген үк сөйли башлады. Хәер, сизмәскә мөмкин дә түгел: хәзерлек бик зурдан бара. Конвейерныйга юан-юан вентиляция торбалары сузылды, атлаган саен электр лампалары эленде. Көндәгедән артыграк күмер шартлатылды. Бүтән забойщикларның авызларыннан өзеп, житәрлек буш вагонеткалар ташылды. Тирәүлекләр өелеп тора. Икенче тапкыр шартлату өчен запас аммоналга тикле онытылмады. Барсы да әзер. Тик Якуп кына бераз шикләнә: элгәре бу штректә икешәр забойщик көчкә-көчкә бер тапкыр шартлатканны төяп озатырга өлгерсәләр, хәзер бер үзенә туры килә. Житмәсә, кабат шартлатасы. Хәер, вентиляция штрегендә икешәр көн шартлаткан көннәре дә булгалады, ләкин анда забой болай зур түгел иде. Иң мөһиме — анда рекорд дип синең авызыңа карап тормадылар.

Эшкә барганда, Якуп эченнән генә үз-үзенә кабатлап атлады: «Сыгылсаң сыгыл, әмма сынма».

...Бераз эшләүгә, ул үзенең манма тиргә батуын сизде. Житмәсә, күрәге әледән-әле эре күмер кантарларына төртелә... Ул арада, редакциядән килеп, аны фотога төшереп киттеләр. Ә көрәк һаман төртелгәли. Әллә күмер бүген артык эре микән?

Аннары аңлап алды. Артык кабаланып, ашыгып эшли бит. Болай ярамый. Иплэп, җайлап, эмма мулдан каерып алырга кирәк.

Күмер өеме күзгә күренеп кими башлады. Десятник Хәертдин килеп, аның җилкәсеннән сүзсез генә какты да ни арада юкка да чыкты. Шул җитә калды егеткә. Күңеленнән генә җырлый ук башлады. Өем кимегәннән-кими. Һәм кинәт... ут сүнде.

— Энергия давай! — дип кычкыра-кычкыра, Якуп «мич» буйлап чабып китте. Шул чак ныгытучылардан берәү аның артыннан кычкырып калды:

— Эй, Әхмәтҗанов! Абайлап йөгер, борының канар.

Ут кабынды, Якупның көрәге яңадан бик тиз уйный башлады. Ләкин нигәдер күңеле җырламый иде инде...

Бер кире китсә китә бит. «Мич»кә вагонеткасын бушаткан гына иде, люковойлар: «Бүтән бушатмаска!» — дип кычкырдылар. «Мич» тулы күмер, ә баш штректә буш вагонеткалар юк икән.

Якуп шунда йөгерде. Рельстән чыккан вагонетканы күтәреп азапланучы коногонны күрүгә, малайның якасыннан эләктереп алуын сизми дә калды.

— Вагонетка давай!

Коногон тыныч кына әйтте:

— Егет икәнсең! Иптәшеңә кул күтәрә башлагансың. Алай иткәнче, булышыр идең.

Якуп шунда гына абайлап алды: үзе белән бергә ФЗОда укыган, хәзер бер үк палаткада яшәүче Марченко икән ич бу.

Мыгырдана-мыгырдана коногонга вагонеткасын күтәрешергә булышты да тизрәк забоена ашыкты.

Өем төялеп бетте. Бораулап, яңадан шартлаттылар. Забойда төтен беткәнен көтеп торган арада, Хәертдин аның янына буфетчы Талиганы да ияртеп килде. Талига рекордсменга ашарга алып килгән икән — Уханов кушуы буенча.

— Тәлинкәләреңне забоең шикелле ялт иттереп куй. Батырны сыйлавы да җанга рәхәт,— дип, Талига алтын тешләрен елтыратып елмайды.

Якуп тәлинкә ялтыраткан арада, Талига тагын алтын тешен ялтыратып алды.

— Кичкә сый әзерләп торырга куштылар. Нәрсә ашарга телисең? Әйтеп кал.

— Күгәрчен сөте әзерлә, ап-ак муеның төслесен,— диде авызы колакларына җиткән Якуп.

Кабат шартлатылган күмерен төяп озатканда, Якупның күңеле тагын җырлый башлады. Дөрес, кулбашлары авырта, балтыр итләре сызлый, ләкин болар бераз эштән бүленеп торган арада гына сизелә иде. Аннары шунысы гаҗәп: Талиганың алтын тешен җемелдәтеп елмайганы күз алдына килсә, авырту-сызлаулары шунда ук онытыла, көрәге тагы да җитезрәк уйный иде.

Соңгы вагонетканы төяп бетерүгә, Уханов белән Хәертдин килеп җиттеләр. Рулетка тотып, забойның күпмегә алгарак киткәнен үлчәп алдылар.

Күңеле күтәренке Ухановның.

— Молодец! — дип, Якупның җилкәсеннән кочып куйды.— Мин синнән шуны көткән дә идем. Беләкләрең моннан ары да ару-талуны белмәсен! Синең эш үрнәгендә бүтәннәрне чыбыркылыйбыз. Мондый күрсәткеч бүген рекорд кына булса, иртәгә һәммәбезнең нормасына әйләнер.

Ләкин Хәертдин тавышы алай бик көр яңгырамады:

— Бер рәхәтнең бер михнәте була. Алдында рекордлар корбаны басып тора түгелме, начальник?

— Синеңчә нишләргә? Алма пеш, авызга төш дип ходайдан көтеп торыргамы?

— Талпынып кына очып китеп булмый, начальник. Аның өчен нык канат кирәк. Механизация дигән канат.

— Америка ачылганга биш былтыр, ә син «рекордлар корбаны!» белән авыз чайкыйсың. Бүген илгә күмер кирәк, күмер! Ә механизация әле кайчан була бит. Бәлки сугыш беткәч кенә...

Уханов аны күптән тыңламый инде: Әхмәтҗанов көндәлек норманы икеләтә тутырган! Көткәннән дә артыграк. Хәертдин ышанмый, тагын бер тапкыр үлчи, аннары әйтә:

— Тырышкан бушка китми, билгеле. Тик, бел аны, Якуп энем, бу хәтле эшкә иптәшләреңнең дә көче кергән, ә даны сиңа... Шуннан нәтиҗә ясa. Югыйсә, ике штрек арасында адашып йөрүең бар...

Уханов аны сүзеннән бүлдерде:

— Шахтерларны агач йортка күчерә башлыйбыз. Иң элек алдынгыларны. Бая карап йөргән бүлмәгә рекордсменны урнаштырырсың. Кирәкле кешеләр белән килешенгән. Караны, Харитон Харитонович, сыеңны мул әзерлә, үпкәләрлек итмә! Мине идарәгә чакыралар, бушасам килермен. Ә син, Әхмәтҗанов, иртәгә тагын шулай! Борыныңны күтәрмә! Бүлмәңә иптәш итеп кемне телисең — шуны кертерсең.

Уханов шулай дип әмер бирде дә китеп тә барды.

Хәертдин, куен кесәсеннән дәфтәр алып, үз-үзенә сөйләнә-сөйләнә, үлчәгәннәрен язарга кереште:

— Иөрәге ярсымаганның күмере мичтә дә пыскып кына яна. Бар иде безләрнең дә җир астын тетрәтеп забойда күмер чапкан, урамда сәлам кайтарырга өлгерә алмыйча йөргән чакларымыз. Яшь чагында яшьнәдем, яшьнәдем дә күкрәдем. Эх, энем! Менә шулай ул дөнья. Ярый, мунча чыккач, нарядныйда көтәрмен...

Ул салмак кына атлый-атлый күздән югалды.

Якупның исә чыгып китәргә аягы тартмый. Ахырда, штольня буйлап тышка юнәлде. Күгендә кояш, күңелендә яз, әмма чалт аяз түгел шикелле, ара-тирә болыт кисәкләре дә күренгәләп ала. Нилектән икән?

Штольня авызы каршында аны Хәмзә белән Оксана каршы алдылар. Оксана Якупның каршысына йөгереп килде.

— Яша! Яшенька! Батыр да икәнсең! Каяле, кая, карыйм әле үзеңә. Юкса, безнең ишеләрдән бөтенләй йөз чөерә башларсың. Сиңа ышансаң...

Хәмзә дә дусларча аның кулын кысты.

— Котлыйм, малай! Эх, әтиең белән әниең күрсеннәрие. Безнең палатка егетләрен агач йортка күчермәкчеләр. Тик... күченергә исәптә дә юк. Әнә, семьялылар күченсен. Син дә шулай диген, яме, Якуп. Бөтенебез беравыздан торыйк!

Оксана аларның икесен дә җитәкләп алды.

— Ә Яшага бүген үк тиешле. Аның турында бүгенге газетада да басканнар. Өй туеңа чакырырсың, яме, Яша?

— Ә үзең кияү туеңа чакырырсыңмы соң? — дип, Якуп бик матур иттереп кызга текәлде.

Хәмзә бераз кызарып китте, ә Оксана аларның кулларыннан ычкынды да сикерә-сикерә клуб ягына йөгерде.

— Мин кияүгә беркайчан да чыкмыйм, Яша.

Ул күздән югалгач, Якуп Хәмзәгә борылды.

— Әгәр дә икәү генә күчсәк?

— Иптәшләрне ташлап китәргә башыбызга тай типмәгән лә безнең. Әнә, балалы солдаткалар керсен.

— Кара, соңынтын үкенерсең.

— Синең сүзгә карап утка төшәр хәл юк.

Мунчада юынып, нарядныйга кергәч, Якупка күчмә вымпел тоттырдылар.

Палаткага кайтып кергәндә, Хәмзәсе, һаман авызын турсайткан килеш, игътибарсыз гына китап укый, дустына нибары күтәрелеп кенә карап алды. Әнә, Петя караватына менеп утырган да оекбаш ямый. Якупның караваты буш тора: көндез үк урын-җирен яңа йортка илтеп куйганнар. Якуп бераз сүзсез генә басып торгач, чөйдәге бишмәтенә үрелде.

— Сезне дә котәрмен, дуслар, озакламый килерсез,— дип, ишеккә юнәлде. Петя шунда гына башын күтәрде.

— Аякларың җинел булсын, Яша! Синнән башка безгә бик тә ямансу. Бәлки калырсың, ә?

Бүтәннәр дә шаулаша башлады.

— Әллә рекордны бер үзең генә куйдыңмы?!

— Караны, Яшка, иске ярлар яңаларның икесенә тора, диләр. Кире әйләнеп кайтмакчы булырсың... Үкенерсең...

Малайлар шаулаша калды, Якуп чыгып китте.

Урам буйлап атлый иде, Хәмзә куып җитеп янәшә бара башлады.

— Якуп дим! Рәхмәт әйтеп Ваняның кулын кысарга ие! Өстенә ишелмәсен дип, ул синең забойга терәүлек ташып түшәменңе ныгытып торган. Петя вагонетка китереп, йөклесен озата барган.

— Үзеңнең норманы тутырырга да тез буыннарың калтырый, акыл саткан буласың,— дип, Якуп адымнарын кызулатты.

— Көлке көлә килер, арттан куа килер, диләр, Якупҗан.

— Алдыңа кара да атыңны куала.

— Туры әйткән — туганына ярамаган, диләр. Хак икән...

Шуннан соң Хәмзә шактый ара ияреп барды да аннары, юньле сүз алып булмаячагына ышангач, палаткасына таба кире йөгерде.

*

* *

Якуп, яңа йортның баскычы төбендә тәмәке көйрәтеп торучылар белән «нихәл?» дип исәнләшкәч, комендант күрсәткән ишекне ачып эчкә үтте, ут кабызды. Стеналар ап-ак итеп буялган, матурлап җыештырылган дүрт тимер карават куелган. Йодрык-йодрык чәчәкләр төшкән тәрәзә пәрдәләре күзнең явын алырлык. Һәр карават янында ялтыратып буялган тумбочка, уртада ак җәймә җәелгән түгәрәк өстәл, аның тирәсендә күн тышлы урындыклар. Электр плитасы өстендә чәйнек тора. Хәтсез әйбер, ә утырырга урын тапмассың, кузгатырга кыймаслык затлы тоела Якупка. Көнозын аяк өсте булып, тагын иртәнгә чаклы басып тора алмый ич: бер стакан салкын су белән янган йөрәген баса төште дә, өстендәге тужуркасын җәеп, идәнгә сузылып ятты. Йокларга кирәк, иртәгә тагын эш күрсәтү көтә Уханов. Бүтәннәр дә. Менә як-ягында бар нәрсә дә бар, әмма иптәшләре юк. Ямансу. Кем аның шатлыгын уртаклашыр, кем? Җансыз стеналармы? Ефәк пәрдәләрме?..

Кемдер ишек шакыды. «Әллә Хәмзәме?» Авызы бераз ерылгандай итте. «Мөмкин» диюгә, кәрзиннәр, төенчекләр күтәреп Талига килеп керде. Керде дә як-ягына каранды: нишләп бүтән кеше заты юк, нибары — аптырашта калып, нишләргә белмичә идән уртасында катып калган Якуп кына.

Болытлы көнне кинәт калыккан кояштай, Талига килеп кергәч, Якуп бераз ачыла төште.

— Талига, килүеңә рәхмәт! — диде.— Ашы бәя түгел, чисы бәя.

— Инде икенче тапкырын килүем. Көттем, көттем, кайтмыйсың да кайтмыйсың. Палаткадагы малайлардан «Яша кайтмадымыни әле? —

дип сорагач, сәер генә итеп: «Кара син аны, рекордсменга кармак салмакчы бу солдатка»,— диделәр.

Талига шулай сөйләнә-сөйләнә өстәл әзерләде. Кыздырган балык, итле бәрәңге, тозлы кыяр куйды, аракы шешәләре бастырды. Бермәлгә икесе дә яңадан уңайсызланып калдылар.

— Бәлки берәрсе керер әле, Уханов та вәгъдә биргән иде,— диде бераздан Талига.

Якуп сиздермәскә тырышып кына аны күзәтә: ябыккан, агарган, әмма элекке матурлыгы сулмаган әле. Ачык якалы алсу күлмәге аша калкып торган күкрәге, йоп-йомры иңбашлары үзенә тарта. Сызылып киткән кара кашларын тагын да каралтып җибәргән. Бөтен гәүдәсе коеп куйгандай зифа. «Бу хатын сөйдерә дә, көйдерә дә беләдер,— ди Якуп үз-үзенә.— Эштә үзеңне күрсәтү хөрмәт белән бергә хур кызларын да китерә икән!»

— Тот, сәмруг кош баласы! Әйдә, кунак кызыдай ятсынып утырма! — Талига аракыдан авыз итеп Якупны кыстады. Үзенең бит алмалары тагы да алсуланып киткән, күзләре матур елтырый иде.

Ярты стаканны каплагач, Якупның да теле ачылды.

— Мин сине бу хәтле юмарт дип уйламаган идем. Алдан калганчы ризык! Бурычлы булып калмам, бел аны! — диде аннан бер, моннан бер капкалап.

— Кулында ут уйнаткан егет кайсы хатын-кызга ошамас?! Караны, күзләреңне алартма, яме!

— Сиңа ничә яшь? — дип сорады Якуп.

Талига, уймак авызындагы алтын тешен елтыратып:

— Хатын-кызга андый сорау бирмиләр,— диде.— Үзеңә?

— Көзгә унсигез тула.

— Миңа узган ел ук егерме иде. Син әле чебеш кенә.— Йомшак кулы белән Якупның битләрен иркәләп чәбәкләде.

«Урта бармагында алтын йөзеге дә бар икән, иренең бүләгедер»,— дип уйлады Якуп, хатынны беләгеннән әләктереп, үзенә таба тартты.

Ә Талига күз алдына ирен, Алешасын китереп бастырды: аның да битләре шушылай түгәрәк, тулы һәм шома иде. Тырпайган чәченә тикле анекына охшаган. Ачулануы да, үпкәләве дә, хәтта беләккә ябышуы да.

Ихтирамлы елмаю белән егеткә болай диде:

— Сиңа ОРС складында костюм сайлап куйдым. Тиешле язуым да бар. Иртәгә барып аласы булыр. Икәүләп карарбыз, яме?

Күзләр күзгә очрашты, кыенсынып бераз тын тордылар. Сүзләре ялганмады. Якупның йөрәге ярсына, күңеле ашкына. Талига анда моңарчы тоелмаган хис уята иде. Хәзер үк аның күкрәгенә сыеныр иде дә кысып-кысып кочар иде. Тиктомалга гына алай кылана башларга кыюлыгы сай шул.

— Иртәгә парлап барып кайтырбыз, алайса,— диде Якуп.— Минем өчен борчылмаска иде. Язусыз-нисез кулыма китереп тоттырырлык итәрмен әле мин аларны! Менә күрерсең!..

Аның соңгы сүзләре Талигага ошап бетмәде: чыраен сытты. Якуп, моны күреп:

— Әйдә, үз сыең белән сыйлан, Таня, тешең сызламас,— диде.— Ә мин бу хөрмәтеңне забойда ун итеп кайтара торган егет. Уханов белә кемгә ышанырга! Рекордка кайсын җибәрә алсын? Өчаяк асып йөрүче Шабановнымы? Ишәктәй үшән Наприенконымы? Юк шул...

Талига, күзләрен очлайтып, гаҗәпсенеп карап куйды. «Моның акылын тәтен капларга өлгергән. Монысы бөтенләй Алешаныкы түгел».

— Юлыңа ак җәймә! — диде җитди генә.— Мул уңыш казана барасың, тик бөтенесен дә отам икән дип уйлама: көн агышы агызып китүе бар! Бүгенгә сау бул!

Якуп дәртле шашу белән аның иңбашларыннан эләктерде, үзенә таба тартты, ә Талига ансат кына ычкынды да:

— Акыллы кылан, яме, Якуп, дус булып каласың килсә.

— Тагын кайчан көрәшербез? — диде егет.

Талига, көлүен яшереп, авызын учы белән каплады.

— Әйбәт кыланырлык булсаң, иртәгә үк. Ашханәнең теге башындагы бүлмәдә торам. Сөйләшеп кич утырырбыз. Чәй эчерермен. Патефоным бар, уйнатырбыз.— Үзе эчтән: «Гайбәт теле дилбегә буе, бик тиз чорнап алмагае»,— дип уйлады, аннары әйтеп куйды: — Килеп утыр! Әш беткәч.— Һәм, әйберләрен җыештырып, саубуллашып чыгып та китте.

Якуп аның артыннан тәрәзәдән карап калды.

Бернихәтле шулай көяләнгәч, игътибары тау итәгенә тезелешеп утырган йөзәрләгән палатка утларына юнәлде. Шуларның берсендә дуслары ята. Шушы минутларда алар кемнең ничә тонна күмер төягәнен, өеннәнниләр язганнарын, күргән-белгәннәрен куана-куана сөйләшеп яталардыр. Өстәлләрендә мондый сыйның гомер булганы юк. Ә күңел тынычсызлана.

Менә ул пәрдәләрне төшерми-нитми генә караватына сузылып ятты. Урын җәеп, чишенеп тормады, күлмәк изүләрен дә тартып кына чиште. Тыны бетә, һава җитми иде. Янадан Талиганың сылу гәүдәсе, чая карашлары күз алдына килде. «Иртәгә килергә кушып китте ич! Нигә иртәгә, нигә бүген түгел?»

Бераздан ул ихтыярсыз рәвештә ашханә башындагы кечкенә бүлмәгә таба атлый иде инде.

Ул якынлашканда, «хур кызы» баскыч төбендә утыра, күлмәк итәге белән тез башларын төргән дә шунда башын куйган иде.

— Килдеңме, Якуп? — дип, башын күтәрә төшеп сорап куйды.— Мин синең килереңне белеп киттем.

Якуп аның янына килеп утырды.

Тирә-як тын, салкынча. Хәтта шактый салкын. Шунлыктанмы, Талига егеткә елыша төште. Гүя алар баскыч төбендә утырмыйлар, ниндидер сихерле көймәдә йөзеп баралар, юк, йөзмиләр, биек-биекләргә очалар кебек иде. Бу кайнар тәнне кысып кочаклап алуын Якуп сизми дә калды. Талига, нәни кулларын аның күкрәгенә терәп, аны үзеннән этәргәндәй итә, Якуп моны бөтенләй сизми, хуш исле чәчләрне, гаҗәп татлы битләрне, иреннәрне үбә иде.

«Монысы да Алешка кебек. Аның да шушындый минутлары була иде»,— дип, Талиганың уенда чагылды.

— Якуп, шашма! Иртән забойга барасың бар. Кайт, ял ит,— дип пышылдады ул һәм, Якупның көчле кулларыннан ычкынып, аягүрә басты.

Якупның аяк тавышлары тынуга, Талига бүлмәсенә кереп бикләнде дә, ут кабызмыйча, мендәренә капланды:

— Алеша! Алешенькам! Синсез михнәтне белсәңие! Шахтага кояш ташучы кызың ялгышып йөрмәсә ярарие... Куркам мин, бик куркам. Нишләп син мине ялгыз калдырдың?

Тәрәзә аша җемелдәгән яңа йорт утларына күз ташлады: язмышы шушы егеттә түгел микән?

*

* *

Талига Алеша белән Кузбасс шахталарының берсендә танышты. Бу яшь-яшь кызны шахтерлар «җир астына кояш ташучы» дип йөртәләр иде. Ул забойлар саен кереп, утлы лампалар таратып йөри иде. Шул кәсебен исәпкә алсаң, чын мәгънәсендә шахтер өчен кояш таратучы иде ул. Тик аның өчен генә алай атамыйлар иде аны. Ягымлы, көләч йөзе ничектер нур чәчә, йомшак теле ничектер җанны эретеп җибәрә

иде. Вакыты чыкты дип кайтып китәргә ашыкмый, өстән агып-тамып торганына да, тубыктан баткагына да, фәкать шуышып үтәргә генә мөмкин булган кысрык штрекләргә дә үрмәли-үрмәли, кулларына, аркаларына асып бетергән лапмаларын өләшә. Һәр вакыт пөхтә, җыйнак киенгән булыр иде. Уч төбе хәтле генә түгәрәк көзгесенә күз салыр да, чәч бөртекләрен кызыл яулыгы астына кыстырып, брезент чалбар кесәсеннән яулыгын алып, битенә кунган корым-сөремне җентекләп сөртеп алыр иде. Бер тиен бакыр акча зурлыгындагы вазелин савытын һәм бик кечтеки ислемай шешәсен дә үзеннән калдырмас. Шуңа күрә аның җир астында икәнен бик ерак забойлардагы шахтерлар да сизенә, борын тутырып иснәргә керешәләр иде. Хушбуй исе шахтерга бик тә тансык: җир асты «пәрие» шул чакта якты дөньяны, чәчәкләргә күмелгән яшел болыннарны, каен җиләге тулы урманнарны, аланнарны исенә төшерә. Шахтер үз хезмәтен үлеп яратса да, кәйләсен һәм көрәген ничаклы гына дус күрсә дә, якты кояш нурына сусый. Менә ни өчен Талигага да «җир астына кояш ташучы» дигән кушамат тагылган иде.

Алешаның да яңарак кына курс тәмамлап, отбой чүкече белән күмер актара башлаган көннәре иде. Ачык изү, киң маңгай, бераз гына борчулы сыман йөз. Болары өстенә, әлерәк кенә сызыла башлаган кара мыек, бетмәс көч, яшьлек. Талига аны көн саен шушылай күрә. «Почет тактасы» яныннан узып барганда туктый да аның рәсеменә карап тора. Җыелышларда аның һәр сүзен йотардай булып тынлый.

Алеша забойда эшләгәндә җир асты яңгырый, терәүләр дерелди, тирә-як дөбердн. Ярты потлы отбой чүкечен кулларында уйната гына. Беләкләре йодрык-йодрык булып бүртенә, киң күкрәге бер калка, бер бата. Бик бирелеп күзәтә аны Талига. Килгән саен, лампасын яшереп, егетнең эшләгәнен озак кына карап тора. Шушылай куанып һәм янып яшәгән көннәрнең берендә Талиганың башына көтелмәгән кайгы төште. Җингәсе өйдән куалап чыгарды аны. Тәрәзәләрне кадаклап, «кияүгә чыгам» дигән булып, бер ак сакаллы картка ияреп каядыр китеп югалды.

Шулай лампасын качырмый-нитми терәүләр артында хәсрәткә чумып утырганда, аның янына искәрмәстән генә Алеша килеп басты. Лампасын күтәреп караса — кызның битендә яшь бөртекләре. Һәр вакыт көләч «кояш ташучының» күз яшьләрен күрү аңа гаҗәп тә, шомлы да иде. «Кемнең аны шулай кыерсытырга кыюлыгы житкән?» — диде, куллары йодрыкланды. Әмма коры әтәчләнүдән генә кызның юанмаячагын белә иде.

— Һем... Алай,— диде егет.— Танюша, син чылатып кына забойда тузанның басыласы юк. Аяз көнне яуган яңгыр ич бу! Битләрең тулы сөрем, чыраең көл күк. Кем әйтер безнең якты утыбыз дип? Ай-ай-ай... Кайсы утын авызы тел тидерде икән бу кечтеки кызга?

Талига бәләкәй көзгесе белән чиккән яулыгын чыгарды. Биттәге таплар сөртелгәч һәм керфекләр дә кипкәч, чыраена тагын нур йөгерде.

Алеша күңеленнән: «Эх, кызый, кызый, йөрәккә күптән ут салдың, үзенә сүндерергә туры килмәгәе»,— дисә дә, Талигага болай диде:

— Менә шулай һаман балкысаң гына безнең Таня, шахтер кояшы син. Ә хәзер сөйлә, нигә балавыз сыга иден?

Талига көлеп җибәрде, тик һаман бөтенләй тынычланып китәргә исәбе юк иде әле. Офтанмыйча гына әйтте:

— Болай гына, Алеша. Күз яше кызларга түгелергә бирелгәндер инде ул.

Алеша артык төпченеп тормады.

— Һем... Алай... Син түгәсең икән, юк өчен булмас. Әйтергә теләмәсәң — кыстамыйм.— Кесәсеннән сәгатен чыгарып, вакытны карап

алгач, сүзендә дәвам итте:— Смена вәссәлам. Бүген киногa барабызмы? Килеп алырмын.

Талига, сер тотмас үрдәк булмаса да, беркатлы кыз, әйтә куйды:

— Минем өем юк, Алеша.

— Һем... Аптырамыш! Ничек булып чыга соң әле бу?! — Алеша шулай дисә дә, үзе алай аптырап калмады. Брезент тужуркасын киеп, отбой чүкечен култык астына кыстырды да Талиганы җитәкләп китеп тә барды. Ә кыз тартыла-тартыла ычкынмакчы да итте, ләкин егет җибәрмәде. Штольня авызында кояш яктысы беленә башлагач, Алеша Талигага күтәрелеп карады: кыз манма тиргә баткан. Күзләре очрашуга, икесе берьюлы көлешәләр. Талига үзен хәзер шактый тынычлангандай сизә. Хәзер аңа Алеша тагын да якынрак иде. Якты җир йөзенә калкуга, ул үзе турында сөйләргә кереште.

Кыз Барнаул каласыннан ерак түгел бер авылдан килгән икән. Семьялары ишле булганга, тормышлары авыр, шулай да ата-ана һәм җиде бала тату яшәгәннәр. Иң олысы — нибары унҗиде яшьлек Талига. Әнисе кызларын яшьләй чигү чигәргә, бәйләргә, кул эшләренә, киндер сугарга, аш-су әзерләргә, кыскасы, хатын-кыз башкарырга тиешле бөтен эшкә өйрәтә. Олы балалар үсә барган саен кечеләрен карый, булдыра алган тиңентен кечеләре олыларына булыша. Бу йортка хезмәт тәме яшьли үтә. Җиденчене тәмамлауга, Талига фермада әнисенә булыша башлый. Кызлары комсомол путевкасы белән шахтага китәргә язылып кайткач, ата-ананың кулыннан эш төшә, буй җиткән кызларын җибәрәселәре килми: артык кашык түгел иде. Нишләсеннәр: үзе атлыгып тора, кызлар — күрше тавыгы, катыбызда озак ятмас, җибәрми булмас, дигән карар кылалар. Анда дәү әтисе дә күз-колак булыр, китсен, диләр.

Шулай итеп, Талига шахтада кояш ташый башлый, дәү әтисендә яши. Дәү әтисе бөтен гомерен дип әйтерлек җир астында күмер чокып кулбашларын имгәткән, билен кузгатып бетергән карт икән. Авыр туфрагы җиңел булсын, озакламый ул вафат була. Моңарчы да үз итеп тормаган җиңгәсе каен сеңелесенә көн күрсәтми башлый: тирги-тирги акыл сата, бер кая чыгармый, урлап сатар дип бөтен әйберне яшерә. Каен сеңелесе китап укырга утырса: «Сезнең нәселдән профессор чыгасы юк! — дип, утны сүндерә.— Надан килеш тә дәү әтиең кебек шахтада чана өстерәп була»,— ди. Ә Талига, тешен кыса-кыса булса да, түзә, ата-ана сүзеннән чыкмаска тырыша...

Шулай дип, Талига сөйләп бетерде, күтәрелеп Алешага карады, бермәлгә алар туктап калдылар.

— Һем... Алай икән...— диде Алеша.— Хәерле каза булсын җиңгән!

Җитәкләшеп урамга чыктылар. Кызның күзләренә текәлеп, Алеша:

— Өегез еракмы? — дип сорады.

Талига бераз шикләнә калды: агач атка атландырмагае бу! Керсез яшьлегенә тап төшермәгәе. Шулай дип уйлады да алдан йөгереп китте. Алеша куа китте, куып җитте һәм җитәкләшеп яңадан урам буйлап атладылар. Аннан тыкрыкка, тыкрыктан тагын да таррак чат башына кадәр килгәч, зәңгәргә буялган урыс капка каршында басып торганнарын Талига үзе дә сизми калды.

Биек койма эчендә калай түбәле алты почмаклы йорт, янында мунча. Ике арада тактадан корылган төз лапас. Өй артында шомырт агачлары җәелеп үсеп утыра. Капка эчтән бикле иде. Алеша Талиганы җайлап кына биленнән кысып тотты да койма баганасына күтәреп утыртты. Һәм шундук үзе эчке якка сикереп төште, кызны баганадан алып, җиргә аяк та бастырмыйча күкрәгенә кысты, үбә-үбә иркәләргә кереште. Ике яшь йөрәк леп-леп типте. Алеша чаманы белә торган егет: сөйгәнен аякларына бастырды да бүрәнәләр өстендәге яшел сандыкны күрсәтте: синекеме? Ул гына түгел икән. Талига лапастан төенчек

күтәреп чыкты һәм: «Менә бөтен барлыгым шушы»,— диде. Бәхеткә каршы, лапаста кечкенә арба да табылды. Әйберләрне шуңа салып бәйләделәр. Ягымлы гына итеп бер-берсенә карашып алдылар һәм, Алеша, бахбай булып җигелеп, тар чат башына таба юл алды. «Хәерле юл!» дигәндәй, капка үзеннән-үзе ябылып калды. «Кирәкми, Алеша, кирәкми!» диюенә карамастан, егет сөйгәнен чырылдата-чырылдата сандык өстенә күтәреп утыртты да урам буйлатып чаптырып китте, арттан тузан тузгып калды. Алеша узган-барганга елмаеп сәлам бирде, сәлам кайтарды, үзенең күзләре куанычлы масайган иде: «Күрәсезме абзагызны, бәхетен тартып кайта», янәсе.

Тулай торакның тар гына бүлмәсе аларга чиксез киң булып күренде, иптәшләре якты йөз белән каршы алды аларны. Талига һаман ятсынды, өнемме бу, төшемме дип гаҗәпләнде.

— Егетләр, мин бәхетемне таптым. Мәхәббәтебез ташып ашкан. Тагын ни кирәк безгә! Дәшмисез, димәк, безнең яклы,— дип, Алеша шаярырга тотынды, Талигага йомшак кына тавыш белән: — Гөлбикәм,— диде,— мин сиңа ташпулатлар салып бирергә, үзеңне ефәккә күмеп, күктән йолдыз чүпләп тоттырырга вәгъдә бирмим. Әмма йөрәгем тибүдән туктаганчы сөюдән талчыгасым юк!..

Әнә шулай бергә яшәп киттеләр алар.

Сугыш чыгар алдыннан, комсомол чакыруы буенча Ерак Көнчыгышка киттеләр. Монда шахталар да Кузбасстагыча түгел: күмер катламы сөзәк, калынлыгы да үзгә — бер участокта өч-дүрт метрга җитсә, икенчесендә мүкәләп кенә йөрерлек иде.

Алеша «Чаланык» участогына күмер кистерү машинасына машинист, ә Талига буфетчица булып эшкә керде. Монда әлегә газ-мазар да юк, забойщик кайчан кирәк шул вакытны шырпы сызып лампасын кабыза, шуңа күрә дә җир астына лампа ташып йөрүчеләр дә кирәкми иде. Ә барыбер Алеша күңелендә һәм телендә «шахтага кояш ташучы кыз» һаман саклана, хатынын үзенчәрәк итеп, «йөрәккә кояш ташучы» дип атарга керешә иде. Фронттан хатларын да «йөрәккә җылы җибәр!» дип яза башлаган иде. Әмма санаулы гына килеп өлгерде шул аның хатлары...

*

* *

Төн уртасы. Уханов — бүлмәсендә ялгызы. Уйлары һаман да бер тирәдә чуала. «Гайкалар тарттырып», авыздан ут чәчә-чәчә «мунча кертүләр»дән кайчан котылыр ул? Мондый «чара»ның әллә ни бирмәсен ул үзе дә яхшы белә дә бит. Нихәл итәсең... Рекорд куюлар да шәһәр каршында бер ялтырап алу гына булды. Көч җитсә, бөтен забойларны рекорд тизлегенә күчерер иде дә, итәк кисеп кенә җиң озайтып булмый икән шул. Кичә партия җыелышында да әләкте үзенә. Степанов тәки үзенекен итте. Без борын салындыра торганнардан түгел, иптәш Степанов, бер рекорд урынына унны куярбыз. Шул рекордларга таянып, меңнәрне күтәрербез. Хәзергә бу коры теләк кенә. Уйны бар итәргә теләк янында олы терәк тә кирәк. Ул терәк — кешеләр. Көчле, аңлы, ихтыярлы кешеләр. Тик аларны кайдан табарга? Иртәгә үк. Бүген үк. Хәзер үк... Бер резерв бар барын...

Телефоннан өенә шалтыратты.

— Зоя, синме бу? — Кайта алмасын әйтте дә, хәзер үк шушында килергә кушып, трубканы шалт итеп куйды. Өстәл читенә башын төртеп күпме черем иткәндер, бүлмәгә хатыны Зоя килеп керде. Бик шыпырт кына атлый, ирен уятырга теләми. Ләкин Уханов ялт сикереп торды. Зояның аякларында резин итек, өстендә көзге пальто, кулында шахта лампасы иде. Ире белән кул биреп күреште.

— Килдеңме, Зоечка? — диде Уханов, үзе уйлана калды: «Ничек кенә сөйләп китәргә? Бик сак кыланырга, бик сак. Аңлашырлар микән?»

Зоя өстәлгә ипи кисәге белән бер шешә чәй куйды, иренең чәчләреннән сыйпап алды.

— Я, нигә чакырттың, Коля?

Уханов җайлап кына сүз башлады:

— Зоечка, әгәр дә мин акылдан шашкан кешеләр генә сөйли торган сүзләр ычкындырсам, син ышанма, яме! Ничаклы шаккатсаң да, ирем шаша башлаган икән, дип тик утыр. Ник дисәң, мин әйтәсе сүзләрне баш мие зәгыйфь булмаган ир заты берниндн хатынга да авыз ачып әйтмәс.— Ул бик озак, яңа өйләнгәндәй, хатынына карап торды. Шул ук кара күзләр, уртасы батып торган ияк, олыгая барган тулы йөз. Аңлар микән? Нәрсә дияр?

— Тыңлыйм, Коля.

— Ярый. Белгәнеңчә, Гитлер башкалабыз Мәскәүне быел көзгә, дөресрәге, шушы арада алу өчен бөтен көчен туплый. Дошман безнең йөрәгебезгә омтыла. Котың очмасын, Зоя, ул аны үзенең җилкә чокырын күрә алмаган кебек күрә алмас.

— Әллә үзең теләп фронтка китмәкче буласыңмы? — дип бүлдерде хатыны.— Ә монда кем эшләр?

— Минем сүзем нәкъ әнә шул «кем эшләр» турында, Зоя. Эшләргә кеше юк. Шул турыда киңәшергә кирәк безгә.— Ул участокның кышка күмер чыгара башларга тиешлеге турында, кеше кытлыгы хакында сөйләп бирде.— Хатын-кызларны шахтага эшкә чакырсак ничек булыр? — дип сорады.

Юк, уйламаган иде бу турыда хатыны, төшенә дә кермәгән иде. «Чыннан да, берәр шөребе ычкынды микәнни?»

— Ниләр уйлаганыңны беләм,— дип дәвам итте ире.— Әйт әле, җир астындагы эшләргә түзәрсеңме?

Зоя дәшмәде.

— Авыр эштә җәфа чиктереп, ирләрен мәңгегә күрә алмаслык итмәбезме? — диде Уханов, һәр сүзен каушап әйтте.— Бала табу сәләтләрен югалттырмабызмы? Монысы гафу ителмәслек хатабыз булыр иде.

Берьюлы дөнья хәтле сорауга ничек җавап биреп өлгерсен хатыны, һаман да исен җыя алмый утыра бирде. Коляның акылдан язмаганына ышана хәзер: киңәшә авыр минутларында. Горурлыгын бер читкә куеп торып, ир башы белән хатын-кыздан ярдәм көтә. Шушы көнгә калгач, хәлләре мөшкелдер. Ил өстенә афәт төшмәсә, дивана сөйләмәстәйне сөйләп утырмас иде...

Шулай уйлаганнан соң хатын болай диде:

— Иң элек үзең нык фикер тупла, Коля. Минем шахтага карарга гына кереп чыкканым бар. Кайлә-көрәк тотканым да юк.

— Тотмасаң — тотарсың. Белмәсәң — өйрәтербез. Мәсьәләне хәл кылырга булыш миңа: хатыннар белән сөйләш, киңәш. Дошманны үз өненә куа киткәч, фронттан шахтерларыбызны кайтара да башларлар. Еллар буе җир астында ятмассыз, чыгарсыз.— Уханов кискен җавап көтә иде.

Зоя дәшмәде, ни дияргә дә белмәде: риза булучылар табылыр, ник табылмасын. Азмыни хәзер ирләр эшендәгеләр. Ә менә шахтада эшли алмыйча йөзләренә кызыллык китермәсләрме? Имгәнеп, ватылып бетмәсләрме? Монысына ничек кисеп җавап кайтарасың? Ә матурлыкларын җуймаска тырышуларында шик тә юк...

— Бераз уйларга ирек бир, Коля! Иртәгә чаклы.

— Ә мин райкомда һәм шахта идарәсендә Михайлов белән хәл итә торырмын. Ә хәзер — марш өйгә, ярыймы? Ә мин — участокка.

— Көн-төн шунда ятмасаң, ишелер дисеңме? Малайларыңны тагын «мунча» керттеңме? — Зоя сүзләрендә үпкәләү катыш борчылу сизелә иде.

Уханов лампасын кабыза-кабыза сөйләнде:

— Безнең калтыраганны кемнең күргәне бар? Забойдагы терәүләр калтырасын, Ухановлар түгел! Караңгыда башны бәреп борын канатсаң да, һаман алга ыргыл! Сер бирмә! Көчле жил нигә исә дип беләсең? Күкрәк киерә-киерә, Ухановлар алга барсын өчен, белдеңме? Һәм барырбыз да!..

## АЛТЫНЧЫ БҮЛЕК

Беренче шахтада хатын-кызларның ярдәме кирәклеге турында район газетасында басылды. Бу мәсьәлә хакында парторг Степанов район партия комитетына барып киңәште, югары оешмалар белән килеште. Менә ул Уханов бүлмәсендә газеталар караштырып утыра. «Икенче шахтада забойщик Кузнецов егерме тонна төягән, шулай итеп ике норма тутыра язган...»

«Өченче шахтада коногон Зинченко, эштән бушаган арада, юлларны тәртипкә китереп, төзәтеп, көн саен забойларны буш вагонеткалар белән тәэмин итеп торган...» «Бораулаучы Сенибабнов өч кеше урынына эшләп, баш штректә берүзе йөздән артык шпур бораулаган...»

Болар турында участокта әңгәмәләр үткәрергә кирәк, дип утырганда, бүлмәгә Оксана килеп керде. Кәрә-керешкә ярып салды:

— Федор Иванович, минем дә шахтада эшлисем килә.

Степанов баштанаяк күз йөртеп алды: өрсәң, күбәлектәй очып китәргә торган җиңел гәүдә, беләкләре нәп-нәзек, әле сабыйлыктан да чыкмаган кыз бала...

— Әти-әниеңнән сорадыңмы соң?

— Уйлап та карамадым. Әтинең шахта карарга да төшергәне юк.

— Һем... Ә син үтенеп кара, кызым! Әтиеңә ялын башта, ул үзе сезнең ярдәмгә мохтаҗ. Иптәш кызларың ни уйлый?

— Минем кебек. Кайберләре генә...

— Башта әти-әниең белән киңәш тә, шахтага яраклымы-түгелме икәнлеккә врачлардан язу алыгыз. Аннары килерсез, карап карарбыз...

Оксана ничек керсә шулай сикергәләп чыгып та китте.

Степанов үзалдына елмаеп куйды. Менә әкәмәт! Әтисе башлаган эшкә иң беренче булып кызы атлыгып тора. Ә үзе әтисе-әнисе белән киңәшеп тә карамаган. Менә сиңа Ухановлар!..

Язгалап утырган чакта, моңарчы күренмәгән бер ят хатын килеп керде. Кулындагы бияләйләрен салып почмакка ыргытты да автомашина тәгәрмәчләреннән ясалган зур галошларыннан эре-эре эз калдырып, туп-туры өстәл янына узды. Гәүдәгә Ухановтан ким түгел. Өстендә таушалган кара комбинезон, башында яшел одеялдан тегелгән бүрек. Кулындагы газетасын селки-селки, калын тавыш белән сүз башлады:

— Начальник, язып куй мине забойга! — Кесәсеннән бер уч кәгазь чыгарып өстәлгә салды.

Степанов аңа җентекләбрәк карап алды. Олы гәүдәсе, ирләрчә киеме, җилдә-суыкта өшәнгән йөзе генә шактый өлкән күрсәтә икән ич моны. Әнә бит, аяз күктәй зәп-зәңгәр күзләре бөтенләй сабыйларныкыча саф, япь-яшь. Затлы, матур итеп киенеп-ясанып җибәрсә, карап туйгысыз чибәр буласы.

— Кем син? Кайдан килдең, җанкисәгем?

— Болар ни өчен ята соң, җанкисәгем! Укы! Күзләрең күрәдер бит.

— Ә мин үз авызыңнан ишетергә телим, бәбчегем.

— Үзсүзле карт икәнсең, бәбчегем. Фамилиям Варварина, исемем Варвара, Варя дип йөртәләр. Әтием Варвар булган. Димәк, Варварина

Варвара Варваровна. Канәгатьме? Элгәре тагын өч-дүрт фамилиям бар иде. Берсе — Харитонова. Калганнарын да санап чыгаргамы?

Степанов ык-мык килеп утыра, күзләрен чекерәйтеп хатынга карый, болай дип уйлый: колониядән, ахры, срогын тутырып чыкты микән, әллә шылганмы? Кәгазьләрен алып тикшерә. Варя сөйләвендә дәвам итә, кабарып беткән уч төпләрен күрсәтә:

— Моңарчы тимер юлда тачка белән таш-ком ташыдым. Аңарчы шушы йортны штукатурладым, буядым. Җиттеме, әллә биографиямне бөтенләй сөйләп чыгыйммы?

— Бар да мәгълүм. — Степанов кәгазьләрне кире сузды. — Нигә килдең, җанкисәгем? Ни йомышың төште?

— Сугыш вакыты, шуны да белмисеңмени, абзыкаем? — Хатын куен кесәсеннән газета чыгарып Степановка күрсәтте.— Укымаган булсаң укы, илгә күмер күп кирәк дип язганнар монда. Моңарчы тимер юл салуда эшли идем, газетаны укыдым да шахтер булырга кызыгып киттем. Язып куй мине ятьрәк, чыгып киткәнче. Юкса, бүтән начальникка барып язылам.

Степанов бер бу хатынга, бер алдындагы кәгазьләргә карап-карап алды да яза башлады. Варяның авызы ерылып ук китте.

— Ә син чыннан да җанкисәгем икәнсең. Озак яшә! Торырга миңа палатка табарсың бит?

Степанов аяк какты: булыр, янәсе. Иртәгә килергә кушып чыгарып җибәрде. Киләләр бит, җанкисәкләрем, киләләр. Без ялынганга гына түгел, вөҗданнары кушканга, үзләренең кирәклекләрен сизеп киләләр.

Яңадан бер атна вакыт узды. Берәм-сәрәм килгәләп торалар. Күбесе Оксанадай яшүсмерләр. Чын-чынлап забойга куярлыклары гына бик күренми иде.

*
* *

Зоя ярты төнгә хәтле ирен көтте, ә Колясы телефоннан: «Су түктерү коесында яңа насосны җибәрәбез, кайта алмыйм», — дип шалтыратты. Йокысы аңарчы ук качкан иде Зояның. Атна узып китте, әле һаман кыюлыгы җитеп хатыннар белән киңәшә алганы юк. Үзе дә нинди карарга килергә дә белми. «Бүтәннәргә тәкъдим ясасам, үземә дә шахтага төшәргә кирәк, ә минем үз гомеремдә кара эш тотканым юк», — дип өзгәләнә. Мин Коляның иң якын киңәшчесе дә булып яшәдем. Ә хәзер киңәшче булып кына кала алмыйм, уникешәр сәгать көрәк тотып тир түгәргә туры киләчәк. Үзенә-үзе: «Гафу ит, Коленька, мин андый авыр эшкә түзә алмам, сыгылып төшәрмен»,— ди. Ә ничек моны күзенә карап әйтергә? Әнә, ашханә тәрәзәсендә ут күренә — иртәнге ашка әзерләнәләр. Әллә иң башлап шуларга әйтеп караргамы?

Шунда китте. Керсә, казаннар белән бергә кызу эш тә кайный. Пешекчеләр, аш ташучылар, савыт-саба юучылар, җыештыручылар һәммәсе ыгы-зыгы килә.

— Талига җаным, кем анда таң тишегеннән ачыгып килгән? — Бусы — Фатыйма тавышы, кухня тәрәзәсеннән, ашым әзер түгел бит дип, башын тыга.

— Үлә язып ашыйсым килә, — ди Зоя шаярып. Аннары өсти: — Эшкә ашыгам, белмисезмени?

— Ә-ә, Ивановнамыни әле бу? Исәнме, Зоя! Сөбханалла, күз тия күрмәсен! Тфу, тфу! Тазарып, матурланып киткәнсең. Ниләр җимереп йөрү болай? — Фатыйманың теле телгә йокмый, ашыгып килеп күреште.

— Эшкә ашыгам, Фатыйма, — дигән булды Зоя.

— Кит аннан! Конторның төнлә эшләгәнен кем күргән!

— Мин хәзер, кадрлар бүлегеннән чыгып, забойга кердем.

Фатыйма ышанмады, башын чайкады, юан гәүдәсе калтыранып куйды, кулларын алъяпкыч итәгенә сөртеп алды.

Бу сөйләшүгә башкалар да колак салды. Берсе дә ышанып җитмәде: алдыйдыр, юләрмени начальник хатыны. Гомер булмаганны.

— Чын, хатыннар, чын, — ди аларга Зоя. — Ышанмасагыз, шалтыратып Ухановның үзеннән сорагыз.

«Үзеннән» дигәч, ышанмый кая барасың! Шулай да шикләнәләр, икеләнәләр.

— Сез дә язылсагыз, бергә-бергә эшләр идек, күңеллерәк булыр иде, — ди Зоя.

Аш ташучы кечтеки генә кыз телгә килә:

— Минем әти белән ике тапкыр шахтага кергәнем бар. Бер дә куркыныч җире юк. Мин инде Степановка барып шахтага язылып та кайттым.

Батырга караган шикелле, һәммәсе аңа кызыксынып карады.

— Әнә, Талига берничә ел эшләгән шахтада. Әле һаман чәчәк аткан гөл кебек.— Зоя буфет артында ипи талоннары санап торган Талигага күрсәтүгә, бөтенесе аңа таба борылды. Ә Талига барлык сүзләрне колагына сала барган икән:

— Ашханәгә ябышып ятадыр дип белдегезме? Язып куй мине, Зоя Ивановна. Кая җибәрсәгез — шунда риза. — Газета алып күрсәтте.— Менә, биш-алты кат укып чыктым. Егет сүзе бер булыр.

Һәммәсе аңа төбәлде: чынлап әйтәме? Дөрескә охшаган, шахтада кайгысын юмакчыдыр.

— Ә мин шахта мәгарәсеннән иманнан качкан шайтан кебек куркам, — ди Фатыйма, хатыннарның кыюлыгына шакката. Кайсысыныңдыр: «Ашың ташый» диюенә, үрдәк шикелле алпан-тилпән килеп, кухнясына йөгерде.

«Ашың ташый» диюче Нәфисә әби икән, ул да хатыннар янына килеп чыкты.

Сүз уңаенда Талига әйтеп куйды:

— Әбекәй, забойга языласыңмы?

Нәфисә әби кеткелдәп көлде:

— Акча күп төшәме?

— Селтәгән саен тәңкә ярым.

— Алай икән! Картым мәрхүм исәнкәйләр булса, ризалык сорап карар идем, җаны оҗмахта яткыры. Хәзер Фатыйма килен мәгарә янына якын да җибәрмәс. Үзе күк мине дә куркак куян дип уйлыйдыр.— Нәфисә әби Фатыймага карады, ә тегесе кухня тәрәзәсеннән аңа бармак янады.

Зоя ни өчен килгәнен бик җитди итеп сөйләп бирде. Залда беркавымга тынлык урнашты, берсе дә эчендәгесен ачып салырга ашыкмады. Фатыйма яңадан болар янына килде, ул үткәндә бөтен өстәл аяклары калтыранып, дерелдәп калды.

Нәфисә карчык, башын Зояга таба изәп, килененнән сорагандай итте: бу ниләр кылмакчы?

— Кәндә [1] эшлим дип әйтә, әнкәй, — диде Фатыйма. — Тел сөяксез, ни тели — шуны лыгырдый.

Әнкәсе бик озак гаҗәпләнеп Зояга карап торды.

— Мәслихәт, бик мәслихәт. Изге сәгатьләрдә, изге минутларда башын исән-сау алып чыгарга насыйп иткән булсын, ходаем!

— Авызыңа бал да май, әбекәй! — диде Талига.

— Гөлбикә, бәгърем парәсе, — диде Нәфисә әби Талигага, — илнең фәрманы икән, зиһенең җый, хатыннарга башлык бул! Син кәндә буйсын җиткергән кыз.

Талига үзенең шахтага керәчәген сөйләп биргәч, Нәфисә карчык тагын сүз башлады:

---

[1] Кән — шахта, рудник.

— Мәслихәт, бик мәслихәт, кызым. Мәшһүр кәнче[1] яуларга язсын! Үзләремез биредә булса да, барчамызның күзе мәгърибтә. Шахтер мөкатдәс адәмдер, мөхтәрәмдер, дип йөртерие мәрхүм картым.— Фатыймага карап: — Ә син, килен, үтә мәэюс. Беленеңне белеп из, яме. Сабан туенда атлар да алдан килергә омтыла. Габделмалигыбыз кәйләкөрәген күгәртмәскә кушып китте. Өстәл өстендә өебезне балкытып аның лампасы янып тора лабаса, килен. Ай-ай, кайда минем утыз-кырык чакларым, — дип сөйләнде.

Ә килененең коты очкан: шахтага керү түгел, баздан бәрәңгене дә Малигы алып менеп бирә торган иде. Теләмәүдән түгел, таракан-мазар күрсә дә йөрәге ярылырга гына тора шул. Ахырда, батыраеп киткәндәй булып әйтте:

— Һәркем үз казанында кайнап пешә, әнкәй. Бик хаҗәт икәнбез, без дә төшеп калганнардан түгел, әлегә учагыбызда ут бар кебек.

— Май кап, килен! Алла мадәт бирсен! Шахтерга дивар да тәрәзә, нәҗип вә дәрәҗә. Кәсафәтсез галип улып калкырга язсын! Казанның янында үзем чуалырмын. Аллага шөкер, әлегә тез буыннарым калтырамый, тәндә дә сихәткә зарланганымны ишеткәнең юк, махы бирмәбез, ашларың тәмле булыр...

— Тәкъдир кушканча кылырбыз. — Фатыйма уйлап карарга сүз биреп Талигага карады, аннары Зояга: — Иртәгә төгәлен әйтермен, — диде.

— Иш янына куш җыела, хатыннар, — диде Зоя куанып.

Шул ук көнне Зоя төрле идарәләргә һәм тегендә-монда йөрүче хатыннар белән сөйләште. Яңадан берәр көн узгач, хатын-кызлар кыяркыймас кына, берәм-сәрәм дә, төркемләп тә шахта идарәсенә, участокларга, парткомнарга килә, сораша, белешә башладылар. Тик әле һаман икеләнәләр, шикләнәләр, иртәгә үк эшли башларга сүз бирмиләр иде.

Тагын берәр атнадан гына медицина комиссиясе байтагын җир астында эшләргә яраклы дип тапты, шактыен кире борды. Чыннан да, кайберәүләрне, тазалыклары ташка үлчим генә булса да, шахтерга бирелә торган бер кило ипи кызыктыра иде. Бәлки шау-шулы агымга ияручеләр дә булгандыр.

Зояның хәле мөшкел: үз урынына калдырырга кеше таба алмый. Башына капылт кына «кызым Оксананы куярга» дигән уй килеп төште. Әле ул кайтмаган. Олысы Марина — кибетче, тиздән кайтырга тиеш. Анысы үз эшенә ябышып ята, гомер ташлыйсы юк.

Аш-су әзерләп бетергәч, янарак кына салып ыргыткан брезент киемнәрен киде дә көзге каршына басты, төймәләрен карады, якаларын рәтләде, килешәме, фигурамны бозып бетермиме, дип борчыла иде. Таманча шикелле, кысып та тормый, буш та түгел. Идәнгә утырып, аякларына чүпрәк урап, шахта резинкасын киде, аяктан төшеп калмасын дип, бау белән бәйләп куйды. Башына каты түбәле касканы да элгәч, яңадан көзге каршына килде, менә бит: бөтенләй малайларга охшап калган. Озын чәч толымнарын түшенә асылындырып карады, яңадан хатын-кызга әйләнәмме, янәсе. Билен каеш белән кысып буды, бераз нечкәрәсе килә иде аның, күкрәк турыларын тагын да кабартарак төште. Алай да күңеле булмагач, кашларын каралтты, битләренә гомер сөртмәгән иннек ягынды, иреннәрен алсулатты. Ахырда толымнарын аркасына асылындырды. Иңбашына кәйләсе белән көрәген җайлап кына куйды да, алдын-артын карый-карый елмайгандай итте: менә хәзер малайлардан бераз аерыла, матурлыгы да ярыйсы әлегә...

— Әнием, бик килешә,— дигән тавышка сискәнеп китте, борылып карады: Оксана икән, аның кайтып кергәнен сизми дә калган. Тик кы-

[1] Кәнче — шахтер.

зы анасының куанычына кырау тидерде: чоланнан аныкы шикеллерәк брезент киемнәр алып керде дә киенеп тә куйды. Җитмәсә: «Килешәме, әни?» — дип сорый әле.

Кичен олы кызы Марина белән дә шушы турыда сөйләшү булды.

— Әни, кадрлар бүлеге мөдире булсаң да, минем синнән эш сораганым юк бит әле, — дип кенә куйды Марина.

Зоя бераз ни дияргә белми торды.

— Кызым, бөтен җирдә хатыннар купты, этиләре, абыйлары, туганнары урынына бастылар. Алардан артта калсаң, соңыннан үкенерлек булмасын, кара аны!

— Минем кем урынына басар кешем юк. Үкенсәм, сезгә түгел. Һәркемнең үз акылы. Сугыш беткәч, сәүдә техникумына керәм дигән вәгъдәм бар.

— Анысы мәгълүм, техникум качмас, керерсең. Ә бүген безнең кулда винтовка түгел икән, кәйлә белән көрәк булырга тиеш. Әнә сеңелең Оксана үзе башлап йөри.

— Кем дан артыннан куа — керә торсын, пожалуйста. Миңа газетада басылу кирәкми әлегә, — диде дә өйдән үк чыгып китте.

— Әтиеңә ни диярмен, балам? — дип калды анның артыннан Зоя.

Уханов өйгә төн уртасында гына кайтып керде. Оксана белән Марина йоклыйлар иде инде. Ата белән ана арасында бик озак сөйләшү барды. Уханов Мариnaның шахтадан баш тартуын һич тә өнәмәде.

— Ана булгач, кызың күңеленә син ачкыч табарга иде, һич аңламыйм, — диде ул, канәгатьсезлек белдереп.

— Маринада синең катылыгың, синең килеш-килбәтең, Коля. Шахтага керәсе килми икән, көчләмик. Ул бит үз эшен үлеп ярата. Бәлки тора-бара...

— Орчык буе Оксаналар шахтага ашкынып торганда, ат чаклы Маринаң, ак халат киеп, җылыда кибетче булып ятсын инде, ә! Аңламыйм. Ухановлар семьясымы бу? Кеше күзенә ничек күтәрелеп карарбыз? Кайда Ухановлар горурлыгы?! Кайда дип сорыйм, Зоя?

— Кызма, Коля. Марина үз хәлен синнән-миннән ким белмидер. Соңгы көннәрдә сырхаулап та йөри.

— Сырхауга сылтау табыла. Уят! Ныклап сөйләшәм. Үзем. Күндерми калмам. Ухановлар семьясына беркемнең дә тап төшерергә хакы юк.

— Уятмыйк. Иртәгә дә көн бетмәгән...

Икенче көнне Марина әтисе алдында да үз эшен ташлыйсы юклыгын әйтеп кырт кисте. Чыннан да, сәүдә эшен ярата иде ул, техникумга да керергә әзерләнгән иде, шушы якларга күченеп килү сәбәпле, имтиханга барырга туры килмәде.

Әти-әнисе алдында кырыс кыланса да, бик йомшак күңелле кыз иде Марина. Сугыш чыгуга ук, кибетләрдә һәм ашханәләрдә ашау-эчү каты нормага калдырылды. Эшләмәүчеләргә һәм балаларга ипи бик чамалап бирелә иде. Ялынуларына түзә алмыйча, Марина талонсыз гына да ипи биргәләп чыгара башлады, ишеткән рәхмәтләрдән күңеле тулып китә торган булды. Акчалар белән бергә ипи талоннарына да көн саен отчет бирергә кирәк бит, җитмәгән талоннарны үз нормасын ашамыйча капларга мәҗбүр иде. Зоя бу хәлне сизенеп йөрде. Марина өйгә кайткач ашарга да тартына башлады, сөйләшмәс булды.

Әй, ана! Сизенүләреңне кичекмичә генә уртага салган булсаңчы...

*
* *

Бүген шәһәрдә яңалык: җир астына «яулыклылар» гвардиясе керәчәк. Бу көнне хатын-кызлар хафаланып та, көяләнебрәк тә һәм бераз куаныбрак та көттеләр. Степанов аларга атна буе конторда сабак бир-

де, берничә тапкыр участокны күрсәтеп чыкты. Десятник итеп аны билгеләгез безгә дип, бик үтенгәннәр иде, Уханов кырт кисте:

— Харитон Харитонович, рәхим итеп гвардияне кабул ит. Шартламасаң, ярыл, әмма плансыз чыгасы булма! — Шулай дип ул бу бригаданы Хәертдингә тоттырды да икенче бригада җыярга кереште.

Эшкә килгәч, Зоя Хәертдиннән сорап куйды:

— Я, иптәш Харитонов, безне исән-сау алып чыгарсызмы шахтадан?

Хәертдин каш астыннан гына ямьсез караш ташлады.

— Я үләрсез, я калырсыз,—диде дә штольняга юнәлде.

Заманында бөтен Донбасста дан тоткан зимагур Харитоновны хатыннарга көтүче итеп куйдылар бит, гарьлегеннән егылып үләрсең! Бар икән күрәселәре бу фани дөньяда. Ничек йөрәгең сызламасын. Донбасста бит Уханов белән бер забой төтенен суладылар, моннан ары дус дип йөр инде аны! Элекке күк забойда күмер чапкан булсам, шуңа ни җиткәние? Ярый, бер-ике көн чамасы өйрәтеп карыйм әле, аннан күз күрер...

«Гвардиячеләр» Хәертдин артыннан, су буена тып-тын гына төшеп барган каз бәбкәләре кебек тезелешеп, абына-сөртенә штольня буйлап атлый. Степанов ни кисәтте: җир астында каскагызны башыгыздан беркайчан да салып йөрмәгез, диде, ә боларның бер колакларыннан кереп, икенчесеннән чыга барган. Һәммәсе кызыл яулыктан, каскалары кулларындагы сумкаларында ята.

— Бу мөсафир телен йоткан, ахры? — ди Талига Фатыймага.

— Мин аны безгә үтә мәгъкуль күрәм, Талига сеңелем. Ни әйтсәң дә, укымышлы, мулла малае. Ифратлар да тәүфыйклы бәндә диләр аны. Ул сиңа күз сирпеп тә карап алачак түгел.

— Хатын-кыз сөймәс җан да булыр икән! — дип чыркылдый Талига. — Көлсәң дә вай, көлмәсәң дә вай.

— Хәсрәт богаулаган аны, шуны берәүгә дә сөйләми, — ди Фатыйма шыпырт кына. — Ә болай күмер маһиры ул, Габделмалигым белән гел бергә эшләделәр. Донбасста ук кәндә фәхер казанган ул. Җанны фида кылырлык аның өчен, син алай авызыңны бик ерма.

— Чыкмаган җаны гына...

— Чыкмаган җанда өмет бар, Талига. Ике терәү арасына сеңеп бет, сеңелем! Степан ат-мазар килгәндә шулай итәргә кушты. Әнә килә, электермәсен. — Фатыйма көчкә-көчкә ике терәү арасына кысылды, бүтәннәр дә вагонеткалар белән ат узып киткәнче шулай иттеләр. Узган-барган «Сәлам гвардиягә!» дип көлеп уза һәм шундук туктыйтуктый исәнәнергә керешә иде: бөтен баш штреккә Талиганың ислемай исе таралган иде. Әнә өчаягы белән көрәген шалтырата-шалтырата, Шабанов узып бара. «Саумысыз, Талига апа!» — дип, Хәмзә үтеп китте. Якуп узганда, Талига туктап кул биреп күреште, шатлыклы йөзе, гүя «күрәсеңме кояш ташучы апаңны?» ди иде.

Алда, шактый еракта, бик каты шартлау яңгырауга, һәммәсе, көтүчесез кәҗәләр кебек, төрле якка сибелделәр.

— Лә хәүлә вә лә куатә! — Фатыйманың кулыннан лампасы төшеп китте. Җир тетрәп, күк күкрәп торган җиргә ничек үз аякларың белән атлап керерсең?!

— Хатыннар патшасы! Ата казмыни — кеше турында уйлап та карамый, бара да бара. Ник бер тапкыр борылып карасын,— дип кычкырды Варя ачу белән.

Икенчесе аны тыеп: «Әкренрәк! Юкса, тотып ашар», — диде.

Хәертдингә кире борылмый булмый: бөтенесе баскан да каткан, бүредән курыккан сыерлар кебек бер урынга укмашканнар. Аңа ияреп киттеләр тагы үзләре. Тик әле һаман куркуларыннан айнып җитә ал-

мыйлар, аяк асты шытырдаудан да дәррәү кубарга гына торалар. Алар арасында Талига гына үзен бик кыю тота, уйлап та бирми.

— Фатыйма апа, котың ботыңа төштеме? — дип ирештерә Талига. Бөтенесе шаркылдап көлә.

— Әле дә калтыранам, җаным. Әгәр дә мәгәр бүген хәвеф-хәтәрсез өйгә кайтып керсәм, Хәертдин Гали җәнабләренә сәдака бирер идем. — Фатыйма куркуын аңлатырга теләп сөйләнә бирде: — Мин юри генә, сезне сынар өчен генә курыкканга салышам. Ә сез чынлап укты әле...

— Иптәш Харитонов, син каңгылдый-каңгылдый бар! Ата каз каңкаң-каң итә бит ул! — Варя шулай диюгә, бертавыштан көлеш купты, тавыш китте.

— Әй, кызлар, шушы бабай кара мыегы астыннан гына үптерсә дә, җаным үкчәмә җитәр иде.

— Әгәр дә шушы атна эчендә үземнеке итмәсәм, исемем... — Варя соңгы сүзен бетергәнне көтмичә, Хәертдин туктап калды, күзләрен әле берсенә, әле икенчесенә ташлап уртәүчене эзләде, чамалый алмагач, яңадан юлын дәвам иттерде.

Шартлатучы Прошка карт узып бара иде. Ул да, юри ачуны кабартырга теләп, көлгән була:

— Харитоша туган, берүзеңә бер көтү саулык! Берәрсен сатмассыңмы?

Алар забойга якынлашканда, әле төтен таралмаса да, тын алып булырлык иде. Каршыларында, егермеләп тонна булыр, күмер өеме. Хәертдин бик җентекләп түшәмне һәм терәүләрне тикшереп чыкты, асылынып торган күмер кисәкләрен бәргәләп төшерде. Аннары, менә карап торыгыз ничек эшләргә кирәклеген дигәндәй, күкрәк турысына лампасын элде дә забойның түренә тикле буш вагонетка этеп китерде. Лампасын түшеннән алып, бөтен тирә-якны бер чамада яктыртырлык урын тапкач, лампаның ыргагын терәүгә кадап куйды. Аннан соң көрәген җирлеккә салып, нык микән дигәндәй, баскалап карады, өстеннән майкасына чаклы салып ыргытты да күмер төяргә кереште.

Беренче булып Фатыйма кычкырып җибәрде:

— Әбәү! Әстәгъфирулла! Гомердә алай чишенәсем юк!

— Сөбханалла! Беләкләренә генә карасана!

Монысы Талига тавышы. Ә бүтәннәр ныклап күзәтә иде: үзләренә дә шулай эшләргә туры киләчәк бит.

Әнә, Хәертдин башта олы-олы кисәкләрне вагонеткага сала, алар беткәч кенә, көрәген тутырып-тутырып ала, иплән кенә төяргә керешә. Кулын уйната гына! Бу хәтле ярсып эшләрен башларына да китермәгәннәр иде. Вагонетканы тутыргач, аякларын шпалларга терәп алып та китә, арттан иярергә куша. Бераздан җыйнаулашып буш вагонетка китерәләр.

— Кәндә азау ярган, тешен койган икән бу мулла малае,— ди Фатыйма.

Әмма аны берәү дә тынламый.

— Нәрсә катып калдыгыз? Ябышыгыз эшкә! — ди Хәертдин, киенә дә, терәүлекләр ташый торырга дип, караңгыга кереп югала. Биш-алтылап бүрәнә китергәч, битләрен тужурка чабуына сөрткәли, болай да чалгы кебек үткен балтасын кайрарга керешә. Әле хатыннар эшкә дә тотынмаган, кайсы кайда әйләнә: көрәкләренә күмер ала алмый йөдиләр. Шулай азаплана торгач, берәр уч чамасы гына әләктереп алалар да вагонеткага салганда, көрәкләрен түшәмгә бәреп, аны да түгеп бетерәләр. Варя белән Талига эчке кулмәктән генә калганнар, көчәнәкөчәнә, ат башы кадәрле кисәкне салырга азапланалар. Менә кайчан вагонетка дөберди икән!

— Өемнең башына менмә, Фатыйма апа! Син этәч түгел, күмер эскерт түгел. Берәрсенең башына кирәк читең белән кундыруың бар. Җайлап кына, астан төя. Башта җирлеккә хәтле казып төш,— ди Талига. Үзе бик җитез төйи, җаен тапкан, күрәсең.

— Варя, син дә әмәлен бик ансат таптың,— ди Зоя, сокланып, аның төягәнен күзәтә. Беркавымнан үзенең дә эше җайлана, көрәге шома гына шуып йөри башлый.

Фатыйма шыпырт кына Талигага дәшә, ияге белән Хәертдингә ымлый:

— Теге нишләп утыра инде, чукынмыш? Күзләрен акайткан, гыйбрәтсез! Аның күз алдында ничек чишенмәк кирәк?!

— Бер мактыйсың, бер каргыйсың, — дип җавап кайтара Талига.

— Минем акыл үзе белән, сеңелем. Минә эшнең ибе-җәбе юк. Үзең ансат кына әмәлен таптың. Һәр нәрсәнең җае бар, ботканың да мае бар, диләр. Минем Малигым янында да чишенгәнем булмады.

— Тәмуг газапларына да түзә барабыз ич, боларына гына күнәрбез.

Бер килсә килеп кенә тора бит ул. Өем өстендә Фатыйма, гәүдәмне турайтыйм, билемә капты дип, үрә каткан иде — «шап» иттереп башын түшәмгә бәрде, күзеннән утлар чәчелде.

— Әнием! Үләм! Үләм... Муеным сынды, муеным! Әҗәлем шушында икән! — дип кычкырып, артына мәтәлде. Аңа игътибар-мазар юк. Үзләренең дә кулбашлары өзелеп төшәргә җиткән, күтәрер хәлләре юк. Маңгайдан тир агып күзләрне әчеттерә. Өсләреннән пар, тузан күтәрелә. Кайсыдыр: «Һич тә яктыртмый бит, каһәр», дип, лампасын тирги. Икенчесе күрәген орыша: артык олыны тоттырып җибәргәннәр, янәсе.

Түшәмне ныгытыр өчен, Хәертдин «тук та тук» бүрәнә юна, чөйләр әзерли. Җитди генә әйтә:

— Лампаларыгызны саклап тотыгыз! Тимерче күмергә, шахтер яктыга туймас. Шахтер өчен яктылык — ярты гомер ул.

Вагонетка тулгач, Зоя белән Оксана җиңел генә этеп китмәкчеләр иде, — кая ул! — урыныннан да кузгата алмадылар.

— Ботканы аз ашагансыз, — ди Фатыйма һәм батыраеп килә дә вагонетканы этеп лаптыр-лоптыр китеп тә бара. Ә үзе, күлмәгем күтәрелмәгәе дип, чалбар артын кармалый.

— Көч тә соң! Моннан бик ару гына вагонетка этеп йөрүче чыгачак. Бәлки забойщик та, — дип мыгырдана Хәертдин.

Биш-алты вагонетка төягәч, Зояның ике уч төбе дә кабарып чыкты, көрәк тота алмас хәлгә килде. Оксана, аяк бармагына күмер кисәге төшереп, тырнагын кубарды. Нибары Талига белән Варя гына кулларында көрәкләрен уйнатыр хәлдә. Бүтәннәре вагонеткалар этеп йөрергә генә яраклы. Забойны Хәертдиннең үзенә чистартырга туры килде. Соңыннан, күмер төяләп, җирлек ялтырап калгач, үз янына хатыннарны чакырып алды да кәйләләү әмәлен күрсәтә башлады. Талигага тикле бер-ике суккалап карады да, бүтән булмый дип, кәйләсен җиргә ыргытты. Ә Зояга хәзер каләм сабы да тота алмас кебек тоела. Кәйлә күтәреп бер-бер артлы барысы да суккалап карый, нибары борчак-борчак кына кыйпылчыклар чәчрәтә. Хәзер инде берсенең дә шаярасы килми. Тик Варя гына кәйлә сабын нык тоткан: йодрык-йодрык кубарып төшерә.

— Сүрелдегезме? — дип көлемсерәп сорый Хәертдин.

Ә Талига көлә дә, чалбар кесәсеннән кечтеки көзгесен алып, чиккән яулык читенә битендәге төтен-тузан сөремнәрен сөртә. Үрнәкчедән күрмәкче дигәндәй, көзге кулдан-кулга күчеп йөри.

Уйга чума Хәертдин: бичараларның атлар хәлләре дә юк, ә һаман бизәнү дә ясану. Кем өчен? Әлбәттә, аның өчен түгелдер. Шундук үзенең хатыннарга сокланып карап торганына офтана да башлый: «Бәхетсез итте алар мине, башымны ашады. Гомер буе диярлек ялгыз яшим.

Үлгәндә авызыма су салырга, каберемә туфрак ташларга да кешем юк»...

Штольня буйлап кайтырга чыккач, Хәертдин тагын алда, үз-үзенә мыгырдана, уйлана: «Ничек тә өйрәтергә, аякка бастырырга кирәк боларны. Көнегә-көнегә эшләрләр, файдалары булмый калмас»...

Шахтадан чыгуга, хатын-кызлар бер-берсенең киемнәрен кагыша, чәчләрен рәтли, битләрен сөртешә. Шаркылдап та алалар. Шул арада өскә чыгып килгән икенче гвардия күренә, анысын өйрәтүне Уханов үз өстенә алган булган. Анда бигрәк яшь кызлар. Ике төркем кушылгач, сорашу китә, кулбашлары, уч төпләре авырта, бил сызлый дип зарланышалар. Шулай да, пышылдап кына, читкәрәк китеп, ирләр затына сер бирмәскә тырышалар.

— Сохари сөттә йомшара. Әйләнербез-тулганырбыз, барыбер үзебезнекен итми калмабыз,— ди Фатыйма, үзенең өстеннән пар күтәрелә, сулуы капкан. Әйе, ул элгәре чыпчык җиленнән дә өркүчән иде. Ә хәзер шахтер кисәге.

Ухановның чырае бу юлы йөзе килгән күмәч кебек. Эченнән: «Карт бүре көрт ера тәки»,— ди, ә Хәертдиннең үзенә:

— Берәр ун елга яшәрергә дип офтана идең. Я, хатын-кызлар арасында яшәреп буламы? — дип елмая.

Хәертдин аңа усал караш ташлый, дуамал гына әйтеп куя:

— Яңадан ун елга картайтырлар алар, үлмәс борын кабергә кертерләр үзеңне дә...

Уханов хатыны белән кызы янына килде. Оксана кабарган уч төбен күрсәтте, бераз чатанлый да иде.

— Туйга кадәр барысы да төзәлер, кызым,— диде әтисе.

Икенче көнне Оксана иртән:

— Әни, мин бара алмыйм. Бөтен гәүдәм сулкылдап сызлый,— дип еларга ук кереште. Әнисенең дә сызламаган җире юк, әмма: «Җигелгәнсез икән, тартырга да кирәк»,— дип, кызын юата-юата, үгетли-үгетли киенергә мәҗбүр итте.

## ҖИДЕНЧЕ БҮЛЕК

Хәмзә тагын забоен «ялап алгандай» итә алмады. Тиздән хатын-кызлар киләчәк, бәлки Оксана да килер, оятыңнан җир тишегенә кереп чумарсың, билләһи. Аты салынкының үзе дә салынкы диләр, тәгаен ул миндер. Кайдан алмак кирәк унбишәр тонна күмер төярлек куәтне? Буыннар талдай сыек, бил катмаган, беләкләрдәге көч ташка үлчим генә...

Шулай үз-үзе белән сөйләшеп, баш штрек буйлап кайтып бара Хәмзә. Янәшә генә вагонеткаларын дөбердәтеп, аргамагын куып, коногон уза. «Эх, аның урынында булсам иде!» ди, бик озак артыннан карап кала, аннары кычкырып «Шахта» көенә җырлап суза.

> Шахталарда күп эшләдем, булалмадым коногон.
> Булыр идем мин коногон, күтәрәлмәдем вагон.

Җир өстенә чыккач, лампасын сүндерде дә тау итәгенә күз салды: анда ямь-яшел чирәм. Эх, рәхәтләнеп сузылып ятарга иде!

Карагай төпләрендәге яшел чирәмне умырып-умырып йолкый башлады. Бер кочак җыйгач, коногонның кире әйләнеп килгәнен көтеп, чирәм өстенә сузылып ятты. Рәхәт тә соң табигать кочагында җәелеп ятулары! Бил авыртканы да басыла, башны бәрәм дип тә котың очмый. Һавасы да һавасы!

Штольня авызында бахбай башы күренүгә, сикереп торып, җыйган чирәмен эләктерде дә, эстакада янында коногон вагонеткаларын ычкын-

дырып икенчеләрен таккалаганчы, малкайны сыйларга кереште. «Аша, малкай, аша, көч җый! Минем дә авылда синең шикелле дускаем калды, нишләп ятадыр?». Шул чакта башына келт итеп бер уй килеп төште. Аякларының җиргә дә тигәнен сизмичә, Ухановны эзләргә йөгерде. Гомергә үзе теләп аның бүлмәсенә кергәне юк иде әле. Тик бу юлы теләкне тормышка ашырасы бар, тотып ашаса да, каршысына басмыйча булмый. «Атны аллага тапшыр, үзең дилбегә тот», — дип әйтер иде әбисе мәрхүмә. «Ятып калганчы атып калырга кирәк, куян йөрәк!..»

Ул баш штрек буйлап чапты: иртән Уханов яңа вентиляторны көйгә салып йөри иде. Әйе, слесарьлар һәм Хәертдин белән хәзер дә вентилятор куеп маташалар икән.

Хәмзә Уханов каршына басты да кыю гына әйтте:

— Минем коногон буласым килә.

Уханов белән Хәертдин, эшләреннән бүленеп, бер-берсенә караштылар.

— Комсомолмы? — дип сорады Уханов.

— Авылда чакта ук.

— Синең ише батырларны забойдан кубара башласак, кем шахта төзер?

— Мин ат яратам.

— Нишлибез, десятник? — дип, Уханов Хәертдингә таба борылды.

— Булмаса булган икән, аллага тапшырыйк! Минем сменага куярсыз үзен,— диде Хәертдин, җитди генә итеп мыегын бөтереп алды.

— Иртәгә хәл кылырбыз. Марш эшеңә!..

Хәмзә, яңадан өскә чыккач, якты кояшка елмаеп карап торды: бүген начальнигы холыксызланмады, кычкырмады. Каефле чагына туры килде, бәлки коногон итеп тә куяр.

Ул мунчага килгәндә, юынучылар берәм-сәрәм генә иде әле. Суы саркып торган брезент киемнәрен салып төрде дә, тимер чыбык белән бәйләп, киптерүчегә тапшырды. Кабыргалары әллә кайдан санарлык, ап-ачык беленеп тора. Куллары, битләре пычракка манчып алгандай булган, иреннәре ярылып каралган, чәчләре тузгыган, тешләре дә күзләре генә утлы күмердәй ялтырый. Иң ахырдан, аякларыннан төшеп калмаслык итеп тимер чыбык белән бәйләгән резинкаларын салып, ыштырларын сыкты да бөтенесен бергә бәйләп мунчачыга тоттырды. Хәзер ул үзенең эш киемнәре турында борчыла: тужурка-чалбары тузып, тетелеп беткән, аркалары умырылган, әле кию срогы туларга ярты ел бар... Ничек җиткезер?

Кирпеч хәтле кер сабыны белән мунчаланы тәмам күбеккә батырып, тәнен ышкый-ышкый юынгач, кеше төсе кереп китте үзенә. Коры һәм чиста киемнәрен дә кигәч, арулары да онытылды кебек. Әмма мунчадан чыгып өй алдындагы эскәмиягә утыруга ук, күзләр йомыла башлый. Гәүдәсен селкетүе дә авыр, кузгалып китүләре дә бәла. Ябылып куймагае дип, ашханәгә йөгерде. Буфетчы булып эшләүче яшь кенә кыз, ашарга биргәнче, ярты литрлы пыяла банка белән кайнатылган ылыс суы чүмерергә куша, эчмәсәң, ашарга бирми. Чырайларын сыта-сыта булса да, сагыз исе аңкыган шул суны голт-голт итеп йотарга мәҗбүр. Бу сыекчаны монда тукланган һәркем көн саен эчәргә тиеш. Әйтүләренә караганда, аннан зәңгелә авыруы кача.

Буфетчы кыз Хәмзәнең ашханә карточкасыннан «иртәнге аш» дигән бармак очы тикле талонын кайчы белән киркып алды да, биш тиен бакыр акча кадәр булыр, ике калай кисәге тоттырды, аннары ике йөз грамм ипи үлчәде. Хәмзә калайларны кухня тәрәзәсендә ике тәлинкә ашка алыштырды. Шуларны өстәлгә китереп утырткач, чалбар кесәсеннән сабы яртылаш кисеп ташланган агач кашык алып, бишмәт итәгенә сөрткәләде дә, тамчысын да чәчрәтмәскә тырышып, ашны болгатып карады. Тәмле дә соң борынга бөркелгән кайнар ашның булары! Бер-

ике кисәк бәрәңге дә эләккән. Бүген тозы да таманча. Ничек булса да, бик шома шуа. Икенче тәлинкә бигрәк тә сай, тирәнрәк итеп ясый алмадылар микәнни дип, Хәмзә савыт-саба ясаучыга да тел тидерде. Төбенә генә тары боткасы салынган, бер кисәк тозланган яшел помидор да бар. Ярыйсы гына ялганды тамагы. Хәзер үк идәнгә сузылып ятар иде дә каткан билләрен язар иде, аннары изрәп йокыга китәр иде. Юк, монда ятып булмый. Кайткач рәхәтләнеп йомшак урын-җирдә йоклар. Урыныннан кузгалгач, келт итеп, бүген хәрби өйрәнүләр көне икәнлеге исенә төште: йоклау тәтемәячәк. Китим дигәндә генә, чабуыннан Якуп тотып калды.

— Я, малай, ничек? Бүген тагын бирелгән йөкләмәне үтәмәдеңме?

— Ун тонна төяп озаттым, малай. Моңарчы ул хәтле төягәнем юк иде әле.

Якуп тиз генә ашарга алып килде, аныкы бер тәлинкәгә артыграк. Бирелгән йөкләмәсен арттырып үтәгәнгә өстәмә паек биргәннәр.

— Утыр, бергә китәрбез, — диде ул Хәмзәгә, ике каба, бер йота ашарга кереште. Өстәмә паекка талон сузды: — Мә, алып аша, бер түләрсең. Мин көн саен алам хәзер. Мә инде, мә!

Бик кызыкса да, Хәмзә алмады: дусты аттай эшли, күбрәк ашарга да тиеш, гәүдәгә дә зур.

— Рәхмәт, Якуп! Әле генә ашадым. Гарык, — дигән булды ул. Тәлинкәләрен ялтыратып куйгач, Якуп дустына хөрмәт белән кул бирде:

— Кичә ничектер янына килә алмадым, малай. Рәхмәт!

— Комсомолга керүең белән котлыйм! — диде Хәмзә.

— Җыелышта ишеттең бит мине мактаганнарын. Артык макталудан да йөз кызара икән. — Якупның авызы колагына җиткән. Хәзер ул да комсомол, авылда алмаганнар иде, монда мактый-мактый алдылар.

Икәүләп урамга чыктылар. Караңгы төшеп беткән. Кичке суык күптән сагалап торган, ахры: бишмәт ертыкларыннан куенга, аркага үтеп керә, кинәт-кинәт биткә үрелә, гүя ул, хәзер кирәгегезне бирәм, дип кисәтте.

Хәмзә берни булмагандай:

— Почет тактасында синең фотоң эленеп тора, Якуп. Янында минеке дә булса!.. — дип офтанып алды. Шулай бара торгач, үзенең коногон булып эшләргә кызыгуын ачып салды. Иртән почтага кереп чыккан икән, авылдан хат килгән. Сөйләп китте: Якупның Гарәфи абыйсы култык таягы белән, күкрәгенә бик күп медаль тагып кайткан. Әни сиңа да бик күп сәлам әйткән, Якуп...

Шактый ара узгач, Якуп болай дип әйтеп куйды:

— Коногон эшмени ул! Һәркем сиңа акыра да бакыра. Җилкәләрең умырылганчы рельсәдән төшкән вагонеткаларны күтәреп газап чигәсең, ә кадерең бер тиен. Ургылга тимер юл килеп җиткәч тә, шахтага электровозлар, врубмашиналар, тагын әллә нәрсәләр кайтачак, диләр. Ул чакта сине атың-ниең белән бергә выжт тышка! Забойщик булуга ни җиткән!

— Минем коногон буласым килә. Җырлый-җырлый ат белән йөрергә телим, аңлыйсыңмы? Бер генә кешене дә буш вагонетка җитмәүдән зарландырмас идем кебек...

Тыңламый аны Якуп, борчулы уйларына чумган килеш, башын аска иеп, янәшә атлавын гына белә. Әйе, әтисенең ябылуда икәнен моңарчы ул берәүгә дә әйтмәде, серен һаман яшереп яткыра. Кичә комсомол җыелышында да бу хакта авыз да ачмады. Сораулар яудырырлар, нигә яптылар дип төпченеп азаплыйлар дип коты очып утырды. Бу тарафта Хәмзә дә сүз кузгатмады, сорау да бирмәде. Ул ни уйлый икән? Ялганын кайчан да булса бер тотармын дип йөрмиме? Җыелышта дөресен әйткән булсам, нишләткән булырлар иде икән?

Якуп икеләнеп кенә сүз кузгатты:

— Кара әле, малай, нигә син кичә җыелышта минем әти турында бер сүз дә әйтмәдең?
— Бу да комсомол булсын дигәнгә.
— Хәзер инде менә икебез дә алдакчы. Нишләдек без, ә, Хәмзә?
— Аның каравы, икебез дә комсомол. Мин шуның өчен куанып бетә алмыйм.
— Моннан ары да әтине сер итәрсеңме?
— Син нәрсә?! Әллә мине әләкче дип белдеңме? — Хәмзә күрсенеп дустына карады.— Барысы да Әхмәтҗан абзый шикелле әйбәт кеше булсын иде әле...
— Белә торып әйтми йөргәнең өчен сиңа бик каты эләгәчәк бит!
— Син бар чакта, мин бернәрсәдән дә курыкмыйм. Син ни күрсәң, миңа да шул булыр...
Якуп, дус итеп, Хәмзәнең иңбашыннан кысып куйды.

*
* *

Мәңгелек туң өстенә җәелеп, зәп-зәңгәр томан төшкән. Диңгез уртасыннан су ерып барган төсле хис итә үзен Хәмзә. Тау итәге буйлап сузылган тар сукмактан мәктәпкә хәрби укуга бара. Шушы тауның астында меңләгән кеше тир түгә, күмер чабып шахтерлар көн күрә, балалар тәрбияли, гомерен уздыра. Хәмзә дә хәзер шахтерлыкны бүтән эшкә алыштырмас иде, аның да канына күмер тузаны «сеңә» башлаган, күңеленә хуш килде бу авыр эш. Шушы томанлы сазлык тынлыгын бозып, әкрен генә җырлап та ала...
Тар сукмактан таеп сазлыкка чуммас өчен вак-вак атлый Хәмзә, һаман бара да бара ул. Мәктәпкә килеп җиткәндә, армиягә чакырылырга тиешле яшьләр һәм шахтада махсус эшкә дип калдырылган олы ирләр парталарга утырган иде инде. Хәмзә дә арткы рәттәге буш урынга кысыла-кысыла урнаша һәм уйлый: менә хәзер парта арасына да көчкә сыям, шактый үстем инде!
Класс тып-тын. Арыган сөякләр йөктән бушап калгач, үзеннән-үзе йокыга талдыра. Һәммә кешенең дә башында кайгы-хәсрәтле, борчулы уйлар. Кайсының әтисе яисә абыйсы, яки бүтән туганы фронтта. Донбасстан килгәннәренең күбесенең якыннары дошман кул астында калган. Кайчан фашистлар үкчә ялтырата башлар? Бүген дә астан да, өстән дә су агып яткан забойга эләктем, күмере дә каты: суккан саен икеләтә көч сорый. Бораулыйм дисәң, борау үтми, утлар чәчри...
Һәркемнең башында шушындый уйлар. «Смоленск ычкынган», дип борчылып куя берсе. Икенчесе: «Аннан да ары уздылар», — ди. Кайсыдыр, башын калкытып, тукмак хәтле йодрыгын күрсәтә: «Менә аларга Мәскәү!» Биленә таккан агач гранаталарын капшый.
Тышта Уханов командасы яңгырый:
— Сафка!
Һәркем үз урынына чыгып баса. Уртага, саф алдына, батальон командиры Уханов чыга.
— Сугышчы иптәшләр! Без сезнең белән пулемет һәм винтовканың материаль частьләрен өйрәнүне тәгәлләдек. Бүген батальонга яңа приказ: Ургыл таулары артында «япон самурайлары», төн уртасына анда барып җитәргә, шул дошманны юк итәргә һәм иртәнге эшкә әйләнеп кайтырга! — дип, сафны ике минутка тарата.
Әле тегендә, әле монда отделение командирларының: «Кызурак! Тизрәк!» дигән боерыклары яңгырап ала. Киемнәрен, аякчуларын караштыргалап, яңадан тезеләләр. Аркаларында авыр капчык, индә агач мылтык, билләрендә граната сыманы, кирәк һәм противогаз. «Солдатлары» тынычлангач, гәүдәсен үрә катырып, уртага тагын Уханов

баса. Биленә сары киң каеш буган, өстенә соры шинелен, башына гражданнар сугышыннан бирле саклап тоткан кызыл йолдызлы шлемын кигән.

— Сугышчы иптәшләр!

— На плечо! Шагом марш! Айт-два, айт-два, три...

Батальон шәһәр читендәге Ургыл буйлап атлый. Якуп, озынрак булганлыктан, Хәмзәдән алгы рәтләрдә. Сазлыкның төнге тынлыгын бозып, «Катюша» яңгырый. Вак каенлык арасына керәләр, монда бер аяктан атлап булмый. Сазлык һәм вак каенлык арасында озын-озын түмгәкләр: үзләре нәзек, үзләре биек, өсләренә аяк басуга, мәтәлеп суга төшәсең. Шуның өчен дә түмгәкләргә басмаска тырышалар, араларыннан атлыйлар. Билдән су ерып бара торгач, яңадан коры җиргә чыктылар. Монда кеше юанлыгы усаклар патшалыгы. Төнлә түгел, көндез дә шомлы караңгылык хөкем сөрә. Усак араларында кешедән дә биегрәк абагалар үсә. Тегендә-монда лаштыр-лоштыр аяк тавышлары, сүгенүләр ишетелгәли. Абайламаганнары усакларга килеп бәреләләр.

— Ятарга! Шуышырга! — Уханов бик житез жиргә сузылып ята да, аякларын күкрәк астына тартып, кулларын алга сузып шуышып китә. Хәмзә дә бүтәннәрдән калмаска тырыша, ботак-сатакка, абага яфракларына битләре сыдырыла, арудан бөтен гәүдәсе ватылып сызлый. Аз гына хәл җыеп алыйм дип, тирә-юньгә карый: һәммәсе кара нокта булып җирдә ята, әллә шуышалар, әллә юк инде.

— Атакага! — дип кычкыра Уханов.

Мылтыкларын алга сузып, «ура» кычкырып, батальон алга ыргыла.

— Ятарга! Шуышырга! Гранаталарны әзерлә!

Солдат солдат инде ул: Хәмзә дә приказны үтәргә тырыша, инде түше авыртса да, һаман алга шуыша.

Шул арада икенче команда янгырый:

— Шагом марш! Тик Хәмзә монысын ишетми иде инде. Аркасындагы капчыгыннан кемдер күтәреп торгызгач, ул күзләрен ачты.

Бу Якуп иде. Отряд тәмәке тартып алырга дип туктауга, ул иптәшләре арасында Хәмзәне күрмәде. Борчылудан нишләргә белмичә, ары сугылды, бире сугылды, әле берсеннән, әле икенчесеннән сорашты, тәгәл әйтеп бирүче булмагач, шыпырт кына килгән юл белән кире атлады. Сазлыкка бата-чума шактый баргач, ахырда, тукталган җирдән илле-алтмыш адымда гына «мескенне» тапты. Күтәреп торгызды, аның капчыгын үз җилкәсенә салды, Хәмзәне күтәреп дигәндәй отряд янына алып килде дә яңадан җиргә куйды. Шактый ара мышный-мышный икәүләшеп ятып тордылар. Бераздан Хәмзә күзләрен ачты, үзе янында дусты икәнен күреп, шатлыклы елмайды: «Рәхмәт, Якупҗан!» — дип куйды.

Ул арада яңадан сафка басарга команда бирелде.

Кеше биеклеге абагаларны икегә аера-аера, ега-ега, сугышчылар алга бара. Дөм караңгы төндә. Хәмзә уйга чумган: «Хәзер нинди команда бирерләр икән?»

— Батальон, окоп казырга! — Уханов үзе дә олы көрәге белән эшкә башлады. Тирә-якта көрәкләр зыңлады, өскә таш-ком сибелде. Командирлар ашыктыра, тизрәк казыган чокырга кереп ятарга куша.

Бераздан Уханов:

— Батальон! Тукта! — командасы бирде.

— Иптәш сугышчылар! Командованиенең боерыгы төгәл һәм «югалтуларсыз» үтәлде. Тауны штурмлау тәмамланды. Димәк, без, шахтерлар, Ватан боерса, Ерак Көнчыгышны японнардан саклый алабыз...

Аннары ул фронттагы хәлләр турында сөйләп китте. Дошманның Мәскәүгә ыргылуын әйтте, шахтерны тагын да зуррак уңышларга өндәде. «Сивак»ның тормышына тукталды. «Сивак» торгызылды, күкрәк

киереп, кин сулап алга атлый, план үти, диде. Азакта ярты сәгатьлек ял рөхсәт итте.

Сугышчыларның кайберләре шундук сузылып җиргә ятты. Кайсылары, вагонетка кадәрле таш кисәкләренә сөялеп, тәмәке пыскытты.

Хәмзә иң читтә ялгызы гына абагалар арасында мөшкелләнеп утыра, өсте-башы манма су. Кыл кыймылдатырлык та хәле юк. Уйлана: «Менә шушындый куе абага урманнарыннан ташкүмер барлыкка килгәндер. Борынгы ата-бабаларыбыз шушында абына-сөртенә җәнлек аулаганнардыр... Менә шушы куаклар арасыннан галәмәт тә озын муенлы, ифрат олы гәүдәле сәер җәнлекләр килеп чыгар шикелле тоела. Тәлгәш-тәлгәш яфракларны аударып, сузылып ята. Күзләрен күккә юнәлтә. Әнә, янәшәдәге биек-биек тау артыннан, тегәрҗеп сыман сузылып, озын-озын нурлар сузыла. Еракта, әллә кайларда, әле калка гына башлаган кояшның нурлары алар. Тиздән монда да таң беленер, аннары шахтерның җан теләге кояш — үзе дә тау башына менәр дә кешеләр өстенә кызыл нурларын сибәр, җылы өрер. Шахтер ул җир асты җене булса да, аның иң яратканы — якты җир йөзе, кояш, ай һәм йолдызлар.

Кинәт таулар яңгырап, сугышчылар калтырап китә. Уханов команда бирә:

— Батальон, сафка! — Гәүдәләрен көч-хәл белән җыеп, ашыга-ашыга тезеләләр.

— Шагом марш!..

Кайтып җиткәндә, кояш чыккан, иртәнге сменага чыгарга вакыт җиткән иде инде.



## СИГЕЗЕНЧЕ БҮЛЕК

Шартлатканнан соң чыга торган аммонал төтене забойдан әле дә таралып бетмәгән. Хатын-кызлар, төтеннең таралып беткәнен көтеп, саф һавалы баш штректә сафсата сатып утыралар.

— Карагыз әле, кызлар, — дип сүз башлады олы гына яшьләрдәге бер хатын. — Ухановны да сугышка алалар икән. Димәк, бездән һәм шахтадан котыла. Ул киткәч, утлы табага бастырып пешерүче булмас, шахтерлар иркенләп сулу ала башларлар, ичмасам.

— Синең ишеләрне утлы табада кыздыру гына түгел, янып торган утка ыргытсаң да артык булмас, — дип, Талига кысылып куйды.

— Анда да янмабыз, алла боерса, янмабыз. Анысы да монысы, Зоябызның сөекле кызы Маринаның да эшләре кыекка кереп киткән бит әле. Кибетендә ипи талоннары белән мутланып яткан икән дә, таладылар дип әйтеп, үз кулын үзе җәрәхәтләгән, ди. Оялмыйча шул турыда милициягә хәбәр итүен әйт әле син аның.

Беразга тынлык урнашты. Уңайсызланып кына, барысы да Оксанага текәлде, аннан дөреслекне көттеләр, әмма ул бу хатын сөйләгәннәрнең мыскалын да белми иде, сикереп урыныннан торды да теге хатынның каршысына килеп басты.

— Кайдан белдең боларны, кайдан? Чынмы, ялганмы? Яшермә.

— Миңа ышанмасаң, әнә милициягә шалтырат. Ипигә дип кибеткә барсам, ни күзем белән күрим, ике милиционер һәм тагын берничә кеше кибет ишегенә ат башы хәтле йозак элеп маташалар. Көпә-көндез Маринагызны нйртеп алып та киттеләр.

Бу сүзләрне ишетүгә, Оксана әнисен эзләп йөгереп китеп барды. Теге хатын әле һаман теш кайрый иде.

— Безнең кебек тир түгеп, хәләл ипи ашыйсың килмәсә, шулай була ул! Шахтага да шуның өчен кертмәгән Уханов ул кызын. Хәзер инде менә үзе дә Ургылдан китә.

— Әле син һаман, кара елан, телеңне тыймыйсыңмы?! — дип, Варя кәйләсен кулына алды.

Теге хатынның моңар да исе китмәде.

— Үзеңне бел, үзеңне. Төрмәң артыңнан елап калгандыр әле... — Варя кизәнеп килә башлагач, бик ансат кына аның кулыннан кәйләсен тартып алды да читкә ыргытты.

— Әле син алаймы?! — Варя бу юлы аның биленнән эләктереп алды. Гауга, тавыш купты, чыр-чу итәргә тотындылар.

Ничек кирәк алай тегеләрне тынычландырдылар.

Тик Фатыйма гына берәүне дә тыңламады, гаугага тыгылмады. Аның үз кайгысы кайгы иде. Әле шушы арада гына олы малае: «Марина апа бер сынык ипи биреп җибәрде», — дигән иде. Аңарчы да уртанчысы: «Марина апа бер сынык ипи ашатты, безне бик кызганам диде», — дип әйткән иде. Ничек булып чыга соң әле бу? «Сыныклап-сыныклап таратсаң да үлчәүле ипи бит ул. Башсыз кыз, ахры, утыртмагайлары бичараны».

Бик тә менә ачуы килде Фатыйманың теге хатынга. Ухановларга өепме-өеп яла яга. Зоя бит шахтага керергә и үгетләде Маринасын, и үгетләде. Ә тегесе теләмәде. Ә инде Уханов шахтадан качып китә дию-ләре чеп-чи нахак. «Мин офицер кеше, урыным фронтта», — дип ничә тапкырлар әйткәне бар.

Шул арада Хәертдин килеп җитте һәм лампасын баш очына күтәреп, забой түрен күзәтеп чыкты, әле һаман төтен таралып бетмәгән иде. Кисәтеп әйтте:

— Мин әйләнеп килгәнче забойга кирәсе булсагыз, һәммәгезне бер бау белән әнә теге терәүгә асып куярмын! — дип, асат кына «мич» буйлап үрмәли-үрмәли менеп тә китте.

Хатыннар янына Прошка килеп утырды, тәмәке төреп пыскытырга керешге.

Хатыннар аны сырып алдылар.

— Прокопий Ильич, хәтерлисеңме, теге көнне Харитонов турында сөйли башлаган идең дә, очына чыга алмадың? — диде Талига. Бүтәннәр дә ялына, кыстый башладылар, бик беләселәре килә: Хәертдин кемгә өйләнгән дә ничек яшәгән?

Көнен ничек уздырырга белми аптыраган карт, җан биргәнгә юнь бирде дигәндәй, кызу-кызу сөйләргә керешге.

— Мин Донбасста чакта яшь идем, чибәр идем. Забойщик кеше бит! Кесәм тулы акча, әйләнәм тулы, менә хәзерге кебек, матур-матур кызлар. Алар мине үлеп тә ярата, мин аларны, нәкъ әлеге шикелле...

— Син Харитонов турында сөйлә, — диде Варя, ашыктырып.

— Шулай бер заман, — диде Прошка, дәвам итеп, — трах-бах, забойны дөбердәттем дә, шул матурлар хакында уйга батып утырганда, Харитоныч килеп чыкмасмы... Аның Донбасста бөтен шахтаны данга күмеп ташлаган чагы...

— Синең белән бергәме? — дип бүлдерде кайсыдыр.

— Түгел. Үзе генә. Үгездәй таза иде ул чакта. Алексей Стахановның тәмам койрыгына басты бит шул: аннан ун тапкыр артык күмер чабып ташлады. Кесәләре тулы акча, әйләнәсе тулы сезнең төсле матур кызлар, җаның кайсысын тели — шунысын кочакла да үп. Юк, алай итми егет. Өйләнми дә өйләнми бит бу. Минем яңарак кына вагонеткалар этеп йөрүче Марусягә йортка кергән вакыт. Безгә көн дә килә бу, килә дә китә, ә чибәркәйләрнең берсен генә дә ияртми, ичмасам. «Кайсысын димлим үзеңә?» — дип сорыйм. Җавапны кызык һәм бик кыска кайтара: «Сагындым, кайтасым килә», — ди. Мин әйтәм: «Йөрмә кайтып, үкенерсең, Харитоша», — дим. Кыңгыраулы гармунын култык астына кыстыра да бу, капка төбенә чыгып, тотына чәрелдәтергә — колагыңны томаламасаң, чыдый гына күр. Үзе уйный, үзе җырлый. Русча да, та-

тарча да. Әйләнәсе тулы халык — карты да, яше дә. Ирлесе дә, ирсезе дә. «Кайтам булгач, кайтам»,— дип җенләнеп кермәсме бер заман өйгә. Мин түгел, Фатыйма кебек таза Марусям дә тота алмады үзен. Иртәгесен шалт-шолт и расчет! Сызды бу Донбасстан. Ә мин һаман бер урында трах-бах җир шары селкетәм. Менә бервакыт сыер теле хәтле хаты килеп төшмәсме! «Сагындым, Донбасска кайтасым килә», — дип язган. Ә мин шатыр-шотыр кәгазь ал да, трах-бах иттереп кайтырга кушып язам...

— Күп шартлаттың бит инде, төтенгә чыдар әмәл юк, Прокопий Ильич.

— ...Прошка абзагыз күпме кирәген үзе белер. Исәпкә алып торучы булса, җир шарының аръягына тишеп үткәнем беленер иде инде. Шулай. Менә бер заман минем ничәнчедер хат артыннан Харитоныч үзе дә кошлар кебек әйләнеп кайтмасынмы! Сорыйм: «Я, туган, үз якларында ничек яшиләр?» Җавабы: «Әйбәт!» — ди. Тагын сорыйм: «Алайса, монда нигә кайттың?» «Сагындым», — ди бу. «Кемне?» — мин әйтәм. Дәшми генә бит. Ашамый, эчми бу, ябыкты, кипте, чыкмаган җаны гына бар. Авызыннан сүз дә тартып алыр хәл юк. Көннәр агыла тора, атналар үтә тора, ә Харитоныч, дивана кешедәй, ишегалдында моңаеп утыра. Аптырап беттек Марусякәй белән. Бер заман, трах-бах, теле ачылмасмы моның...

— Һаман кичәгене кабатлыйсың бит, Прошка агай,— дип, кайсыдыр аны сүзеннән бүлдерә.

— Боларны сөйләдең ич инде.

— Сабыр иткән — морадына җиткән, кызлар,— дип дәвам итә карт.— Эшкә керде бер заман. Утырабыз, сөйләшәбез, ә аның серен ачарга исәбендә дә юк...

— Теле ачылды диден ич!

— Ә-ә, ачылды шул, ачылды. Әй, белсәгез иде! Үзенең туган авылында бәйләнгәннәр икән! «Мулла токымы, Себер кötә сине!» — дигәннәр. Сорыйм: «Алайса, нигә анда кайттың?» — дим. Әйтә бу: «Сагындым».— ди. «Алай булгач, нигә монда килдең?» дигәч, җавабы: — «Качтым».

— Кайчан, кайчан өйләнде? Кемгә? Хатыны матур идеме? — дип ялына Талига.

Прошка тәмәке төреп кабыза, җайлабрак утыра. «Иң кызык җиренә җиттем, бик теләсәгез, көтәрсез әле», — ди, ашыкмый.

— Бетер инде сөйләп үзе килгәнче, төтен иснәп туймагансың икән, — диләр хатыннар түземсезләнеп.

Прошка сөйләргә дип авызын гына ачуга, аңа «мич»тән Хәертдин кычкырды:

— Прокопий Ильич, конвейерныйга марш тизрәк! Трах-бах итәргә.

Прошка житез генә сикереп торды да лампасын эләктереп китеп тә барды.

Хәертдин килеп җитүгә, Фатыйма аның каршына басты:

— Карале, начальник, хәлләр яман! Май булса ботка пешерер идек тә, ярма юк. Тик ятабыз, суган сатабыз. Ни күмерең шартлатылмаган, ни төтен кудырылмаган.

— Сафсата сатканчы шурфтан такта ташый торырлар! Төтен бетүгә, забойга ябышыр идегез.

«Ох, өшетте», — дигәләп, һәммәсе такта ташырга киттеләр.

Баш штрек беркавымга тынып калды. Бераздан ике метр озынлыгындагы, баш бармактан аз гына юанрак булыр, бораулар күтәреп, бораулаучы малай килеп туктады. Кайда ничә тишек борауларга икәнен чамалагач, бораулый башлады. Аның янына давыл кебек дулап, Хәертдин килеп басты.

— Сез... хәчтерүшләр! Алла каргаган бәндәләр! Петя кайда? Кайда дим Петя Киреев? Кая качтылар? Әйт тизрәк, малай актыгы!

Бораулаучы аптырап калды, ык-мык килде, белмим, диде.

Гөнаһ шомлыгына каршы, алар янына Хәмзә килеп чыкты, десятниктән нидер сорамакчы иде, авызын да ачарга өлгермәде, шундук Хәертдин аның якасыннан эләктерде.

— Әһә! Эләктеңме! Әйт, хөрәсәннәр кайда?

Хәмзә ничаклы ычкынырга тыпырчынса да, Хәертдин аны җибәрмәде.

— Алар... Алар... Качтылар, — дип әйтергә мәҗбүр Хәмзә.

— Җәһәннәм артынамы? Ә син карга санап калдыңмы? Нигә тыймадың? Комсомол үзе, җитмәсә...

— Комсомол шул...

Хәертдин һич уйламаган җирдән «Уф, йөрәгем» дип күмер өстенә чүгәләде. Бераз яткач, исенә нәрсәдер төшергәндәй торып утырды да үз-үзенә сөйләнде: «Эх, малайлар, малайлар. Борын астыгызда чатнаган кыш тора бит. Качып кайларга китмәкче буласыз? Катып үләчәксез ич. Ә тотсалар? Яшьлек горурлыгыгыз кайда сезнең?» — Кинәт каты гына итеп әйтте:

— Бар, Ибраев, чаптыр! Җиде кат җир тишегеннән эзлә, тапмый кайтма! Бар, син дә! — Бораулаучы белән Хәмзәне шулай җибәрде дә үзе бораулый башлады. Бераздан янып-пешеп бораулап та ташлады. Малайлар инде күптән табан ялтыраткан. Хәзер менә үзенә шартлатучы килгәнне көтәргә кала...

Сабыйларга җикеренүенә Хәертдин үкенеп бетә алмый. Җитмәсә, комсомол егеткә дә тел тидерде. Бер дә гаепсезгә бит. Ә яшь чагында бер дә юкка үзенең дә күз яшен түктермәделәрмени? Нахакка бәйләнделәр, бәхетсез иттеләр ич. Һәм кинодагы шикелле күз алдына шул көннәре килеп басты...

Әтисе Хәертдинне, янарак кына мыек төртә башлаган унҗиде яшьлек яшүсмерне, Донбасска озатты. Анда аның олы абзыйсы яши иде. Шуның янына эшкә урнашты егет. Әтисенең бәлки гаебе дә булгандыр, ләкин ул вакытта аны-моны аңламады Хәертдин. Үзе шахтада булса да, күңеле авылда, иркен басуларда, ямьле болыннарда, шаулы урманнарда, су буйларында чыр-чу килеп йөргән иптәшләре янында иде. Эшли торгач, күмер чабуга да ияләште, яңа дус-ишләр тапты, әмма күңел дигәне һаман кытыклап кына тора иде: игенче эшенең тәме, авылның яме үзенә тартты аны. Яшьли крестьян хезмәтен татып үсте бит ул. Тырмасын да тырмалады, чабагач тотып арыш сукты, чалгы белән печән чапты. Әтисе мулла Себергә озатылганын иптәшләре әйтеп язды. Ә барыбер туган туфрагы тартты. Юк, кирәкми аңа мәчете дә, әтисенең каралты-курасы да. Ашкынып, туган авылына кайтып керде, ерактан, бик ерактан сәлам бирде. Тик... тик сәламне алучы да, кайтаручы да булмады. Тиешле кешеләрдән: «Урман кистерегез, урын бирегез, йорт салам, эш тоттырыгыз», — дип үтенеп карады. Кая ул!.. Тотарга да сызарга иде тизрәк Донбассына. Юк, китмәде, үз авылында яшәргә теләде. Үзе китә белмәгәч, бер төнне Хәмзә ише бертөркем яшүсмер аны районга озатырга чыктылар. Галәмәт таза иде ул чакта Хәертдин, ике малайны бәргәләп ташлады да якындагы урманга шылды. Аннан — Донбасска. Яңадан көн-төн күмер чабу башланды, тик бу озакка сузылмады, забойдан алып киттеләр: имеш, авылда комсомолларны кыйнап качкан. Шуның өчен еракка: Уралга, яңа төзелеп килә торган Магнитогорскига җибәрелде. Туганнарын эзләп тапты. Әтисе күптән вафат булган, энесе әйбәт кенә эшли, укый, завод сала, шәһәр төзи, яңа тормыш кора иде. Хәертдиннең үзенә дә ошап китте монда. Әмма күп тора алмады, забойлары үтереп сагындыра башлады, иптәшләрен юксынды, канына диярлек сеңгән күмер тартты. Түзмәде, алай итте, болай итте, ялынды-ял-

варды, расчет алып янадан Донбассына, йөрәгенә якын Прошкасы, Степановлары, Ухановлары янына ашкынып кайтты. Тормышы әйбәтләнде, эшләгән эше күңеленә рәхәтлек, җанына азык биреп торды. Буй-сын да, төс-бит тә сокланмаслык түгел иде. Күңеленә якын кызлар да очратты, ләкин өйләнми яшәде. Хатын алганда яше утызга җитә иде инде. Һәм шул көннәрдән башлап, аның тормышы тагын артлы-киреле агарга тотынды. Ухановлар белән Ургылга килеп тә... Боларны хәтта уйлап торуы да бик авыр...

Менә конвейерныйда бер-бер артлы шартлау ишетелде. Хатыннар да җыелып өлгерде. «Күз алдымнан югала торсагызчы!» дияргә тели Хәертдин, сабыр холкы гына тотып кала.

— Забоегыз трах-бах ителгән, ни көтәсез тагы?! — диде ул каты тавыш белән.

«Дөнья хәтле вакыт заяга үтте»,— дигәләп, бригада эш урынына таралды.

— Чыннан да, ни тикле күмер чыгарыр идек инде, вакытында шартлатып, һаваларны чистартып торгыза алсак,— дип офтанды Хәертдин һәм, бер забойны үзе эшкәртмәкче булып, Хәмзә эшләгән забойга юнәлде. Ул якынлашканда, Хәмзә күмер төяп маташа иде, десятнигын күргәч, кулыннан көрәге төшеп китә язды.

— Я, таптыгызмы? — дип, Хәертдин йомшак тавыш белән сорады.

— Миңа хәтле Якуп өлгергән. Мунча чормасыннан сөйрәп төшергән үзләрен.

— Сезденме? Тырышкан — табар, ташка кадак кагар, диләр. Шулаймы, агай-эне? — Ул Хәмзәнең кулыннан көрәген сорап алды. — Бир әле монда? Мин төярмен, син тачка йөртерсең. Икәүләп забойны бик тиз «ялап» алырбыз.— Ике-өч көрәк тутырып салуга, тачка тулды да. Хәмзә тачканы штрек буенча сузылган тактадан тәгәрәтеп алып китте.

*

* *

Уханов, гадәтенчә, җиде төн уртасында тагын бүлмәсендә утыра. Күзләре стенадагы участок картасына текәлгән: тиздән «Сивак»ны да файдалануга тапшырып булачак. Лавалар әзерләнеп бетә, конвейерный штрек күмер озатып торырлык дәрәҗәдә диярлек. Гөрләтеп күмер чыгара башларга да булыр иде, тимер юлның Ургылга тикле килеп җитмәве генә тоткарлый. Анысы да килеп җитәр, күмер дә агыла башлар, тик ул көннәрне үзенә күрергә насыйп булмаган икән. Бер атнадан китәргә дигән повестка кесәсендә инде... «Ә шахтерлар арасында аны искә алып сөйләрлек нинди ямьле һәм яхшы эшләре кала? Ниләр эшләнмәгән? Кайларда хаталар ясады?..» Өстәвенә, Марина...

Ишек шакыдылар. Хатыны Зоя белән кызы Марина керде. Маринаның уң кулы терсәктән югары бәйләүле. Ябыгып, саргаеп киткән. Нинди таза, янып торган кыз иде. «Ярый, тиресе белән сөяге калса, ите үсәр. Ә менә намус дигән нәрсә!»

— Без, Коля, синең янга, ата янына килдек.Синең хөкемеңә мохтаҗ булдык.

Уханов бүлмә буйлап йөренергә керешә, бераз гына «Сивак» картасы каршында басып торды, аннары Марина янына килеп утырды.

— Мин түгел, кызым, суд хөкем итәчәк. Барыбызның да йөзебезгә кызыллык төште. Мин фронтка китәм. Сугышта синең дә гаебеңне юарга тырышырмын. Ә менә үзең... Үзең ничек юар идең соң? Юатып тормыйм, соң инде. Теләгем шул: нык бул! Җебеп торма! Язмышыңа хуҗа була бел! Тагын ни әйтим.

Марина нәрсә дияргә дә белми утыра: гаепле, гаебе зур туганнары каршында. Карточкасыз ипи таратып, җинаять ясады. Сугышның мон-

дый мәрхәмәтсез яклары да булуын башына да китермәгән иде. Тормыштан гел яхшылык, шәфкать кенә көтеп яшәгән иде. Сыныклап ипи өләшеп, кешеләргә изгелек кылам дип уйлады. Өстенә чыкканын сизгәч, бер караңгы төнне кибетен бикләп бик соң гына кайтырга чыкты һәм ипи пычагының очы белән терсәгеннән түбәнрәк җирдә җәрәхәт ясады да көндез сатылган ипи өчен җыелган талоннарны җиргә сипте, аннары үз-үзен онытып: «Каравыл, талыйлар!» — дип кычкырырга тотынды. Шулай талану вакыйгасы ясап, җиңел генә котылу иде исәбе. Бәлки ахыр чиктә нишләргә белмәүдән шулай артыгын кыланып җибәргәндер. Ничек кенә булмасын, аның гаебе ачылды. Беләк җәрәхәте әкренләп төзәлер, ә менә йөрәк ярасы һаман ачыта.

Зоя килеп кергәннән бирле елавыннан туктый алмыйча утыра, ә Маринаның инде елаудан күзләре шешенеп беткән.

— Кызым, гаебеңне маңгай тирең белән юарсың. Барыбер шахтада эшләтәчәкләр, — дип куйды Зоя, кызын юаткан булып.

— Юатма! — диде Уханов коры гына. — Ни чәчсәң — шуны урырсың. Суд кайчан була?

— Иртәгә.

Зоя белән Марина чыгып киткәч, Уханов яңадан стенадагы «Сивак» картасы каршына килеп басты.

## ТУГЫЗЫНЧЫ БҮЛЕК

Гасырлар буе ташкүмер асрап яткырган таудан алып, җәйге эссе көннәрдә дә аяк баса алмаслык сазлык буйлап Ургыл елгасына хәтле басма җәелгән. Шушы басма янына урта яшьләрдәге бер хатын белән Якуп яшьләрендәге бер егет килеп туктады. Чемодан һәм төенчекләрен җиргә куйдылар да берәр кешенең юл күрсәтүен көтә башладылар. Үч иткәндәй, шактый вакыт килүче-китүче күренмәде. Салкын. Эңгер-меңгер чак. Көн саен төшә торган зәңгәр томан җир өстен каплаган.

— Әни, карале, диңгез! Диңгез җәелә түгелме? — диде егет, бармагы белән елга ягына күрсәтеп.

Әнисе нидер мыгырдап чукынып алды.

— Алла саклый күрсен! Әҗәлдән котылдык дигәндә генә, килеп житкәч, батып үләргә язмасын!

Әкрен генә, курка-курка гына басма буйлап киттеләр. Чакрым чамасы үткәч, каршыларына яшь кенә кызлар һәм үсмер малайлар очрады. Алар туктадылар да ят кешеләрне сырып алдылар, берсеннән-берсе уздырып сорый башладылар:

— Исәнмесез! Кайдан килдегез?

— ФЗОгамы? Шахтагамы?

Егет үзләренең Донбасстан Свердловскига, аннары монда, Уханов-ларга килүләрен әйтте.

Хәмзә аның Якупныкы шикелле таза гәүдәсенә күз йөртеп алды.

— Безнең «Сивак»ка сора, яме? Шахтада иң алдынгы участок ул.

— Рәсем ясый белмисенме? — диде икенче малай. — «Чаланык»ка керсәң, стена газетына сурәтләр ясар идең. Безгә художник бик кирәк.

— Мин музыкант. Рояльдә уйныйм. Кайсы участокта бар ул? — диде егет.

— Бездә рояль юк, сугыш беткәч булачак. Шахтада вагонеткалар белән уйнарсың, кәйлә-көрәк тотып юанырсың. — Моны әйткән кызның төркем арасыннан башы да күренми иде.

Малайлар өерелешеп китә башлагач, хатын Хәмзәнең чабуыннан эләктереп туктатты.

— Карале, кечкенәм, безнең әйберләрне Ухановларга кадәр илтсәгез, колбаса ашатыр идем.

Хәмзә башын чайкады: юк, колбасаң үзеңә булсын, шуны вәгъдә итмәсәң, бәлки ярдәм йөзеннән илтеп куяр идем.

...Бара-бара Ургылга килеп терәлгәч, юан-юан бүрәнәләрдән салынган алты почмаклы йорт каршында туктап калдылар. Әйтүләренә карағанда, Зоялар өе шушы булырга охшый. Тәрәзәдән күреп калган Марина каршыларына йөгереп чыкты: күптән көтә иде ул кадерле кунакларларны.

— Исән-сау килдегезме, Настасья Петровна? Андрей? Исәнмесез! — Шулай дигәч, әйберләрен күтәрешеп өйгә алып керде.

— Юл газабы — гүр газабы инде ул. Шулай да без алай ук газап чикмәдек, поездларда тыгын булса да, акча барысын хәл итте.

Марина кабалана-кабалана чәй әзерләргә кереште, янып торган мичкә күмер өстәде.

— Зоя Ивановна кайда? Оксана? — дип сорады Настя.

— Яңарак кына төнге сменага киттеләр. Забойда эшлиләр. Мин дә шунда эшли башладым.

Шаккатты Настя: ничек инде хатын-кыз җир астында эшләсен! Гомер булмаганны! Николай Иванович, начальник башы белән.. Настя зур күзләрен тутырып өй эчен күзәтте. Бөтен стенага, түшәмгә дәү-дәү кыпкызыл роза чәчәкләре төшкән чуар обой ябыштырылган. Бер кырыйда — тимер караватп, икенче кырыйда — агачы. Уртада — клеенка җәелгән өстәл. Түрдә — китап шкафы. Күрше бүлмәгә чыга торган ишеккә чаршау корылган. Тәрәзә пәрдәләре дә ак ситсыдан гына. Бөтен нәрсә гади, бер дә начальник йорты димәссең.

— Әтине озатканга айдан артык инде. Япон чигендә хезмәт итә. Мәскәү янына күчерүләрен сорап рапорт язган. Шушы арада гына хаты килде, — дип сөйләп китте. Монда үзләренә ошавын, сугыш чыкмаган булса, бик зур матур гына шәһәр калкып чыгарын әйтте.

Настя, чемодан актарып, урындыкка киемнәр элә башлады: өстен алыштырмакчы.

Марина чаршауны шыпырт кына икегә аерып күрше бүлмәгә шылды, аның артыннан Андрей да иярде.

— Марина, үлә язып сагындым сине, — диде егет.

— Үзем дә... Әкрен, әниең ишетер... Көттем... Көттем.

Настя олы якта иде, аларның үбешкәннәрен күрмәде, тавышларын гына ишетте. Улының бу кызга мәхәббәте барлыгын Донбасста чакта ук яхшы белә иде ул, моңа чаклы хат алышып тордылар. Свердловскидан китүләре дә улы шушында каерудан иде, фатир булмау — сылтау гына.

Кече якта яшьләр һаман серләшәләр әле.

— Синең янда булгач, таш кисәргә дә әзер, күмер нәрсә ул! Забойта керәм, файдам күбрәк тияр.

Егетнең анасы куанып утыра, менә бит: аркылыны буйга алып салмаган иркә бер малай иде, хәзер әнә ничек кылана, әтисе шикелле, монысына да шахта җене кагыла.

Андрей, уч төпләрен кашып:

— Кулларым кычыта, аякларым синең янга атлыга, — диде, кызны үпмәкче булды.

— Я, җитәр! — дип, кыз аны җиңелчә генә этеп җибәрде. — Әнә чәйнек быгырдый, кайнады бугай, — дип, олы якка чәйнек чыгарды. Аның артыннан Андрей да иярде.

Өстәл тулы ризык: берничә телем юка гына колбаса, соя кабартмасы, мүк җиләге вареньесе, ярты бөтен чамасы ипи. Марина, чынаякларга чәй сала-сала, кунакларны кыстады:

— Настасья Петровна, әчегез! Җылынып китәрсез. Аннан соң ял итәрсез. Иртәгә әни кайткач, эш юлларбыз.

Настя куанып бетә алмый: сау-сәламәт килеп җиттеләр ич. Эшкә дә керерләр, икмәк карточкасы да алырлар, тормышлары яңадан көйләнер..

— Василий Федоровичның хәбәре бармы соң? — дип сорады Марина Андрейның әтисе турында.

— Юк шул... Бәлки ул партизандыр. Иптәшләре шулайрак әйттеләр.

— Миңа монда ошый, — диде Андрей, туеп урыныннан кузгалгач. — Ап-ак йортларыгыз күңелгә бер ямь өсти. Коры җирдә диңгез җәелеп ята. Шуны ерып әкияттәге кебек алга барасың. Ошый, бик ошый...

— Әйтерең бармы! — дип куйды әнисе. Эченнән: «Беләбез кем ошаганын»,— дип уйлады. Маринага күз төшерде: әтисе кебек олы гәүдәле таза кыз. Төскә-биткә дә ярыйсы. Тик бик ябыккан. Забойда эшләү җинел түгелдер, күрәсең.

Икенче көнне Настя белән Андрейга баракта аерым бүлмә бирделәр. Настяны, үз теләге белән, мунчада кием киптерүче, ә Андрейны эстакадада күмер арасыннан таш чүпләп торучы итеп куйдылар.

* * *

Менә Хәмзә атна буе инде коногон булып эшли. Моңарчы олылар фзочыларны «матрос» яки «кавалер» дип йөртәләр иде. Хәзер аңа «кавалерист»диләр. Куана егет: теләгенә ирешге, исеме генә дә ни тора — ка-ва-ле-рист! Җир өстендә шулай диләр. Ә шахтада һәммәсе: «Коногон! Вагон давай!» дип кенә акыра. Исем-фамилиясе бөтенләй юк диярсең. Ничаклы акырсалар да, үпкәләми ул, җәберсенми, әлегә хәтере калырлык урыны да юк. Йөкне һаман вакытында чыгарып, шахтерларга буш вагонетка төткәзә алмый. Хәер, бүтән смена коногоннары да баш штрек тулы йөк калдырып кайтып китәләр. «Эх, Казанга бара торган шикелле туп-туры төзек тимер юл булсын иде!» — ди Хәмзә үзүзенә. Менә бүген дә ашханәдә ашын тәлинкә читеннән генә күтәреп чүмерде дә, йодрык хәтле арыш ипиен куенына кыстырып, Акбүзе янына элдертте. Килүгә үк аргамагы алдына нормага тиешле бер кочак печән салды, бүтән юк, нормаң шушы гына, диде аңа. Атлар караучыдан бер бүрек солы алып китереп салды. Әнә, бахбай иреннәрен селкетә-селкетә солы чәйни, ә хуҗасы куенындагы ипиен алып, бик тәмләп кенә, валчыгын да төшермичә, тагарак башына артын төртеп ашап утыра. Малкай, ипи исен сизеп, иясенең кулына үрелә, йомшак иреннәре белән уч төбен ялый: ипи сорый. Хуҗасы бармак башы хәтле генә өзеп каптыра: ипи минем үземә кирәк, әнә, печән күшә, су чүмер!

Штреккә яңа чапкан тәмле печән исе таралган. Хәмзә күңеле белән күптән шул печәнне чапкан ямьле болыннарга кайтып киткән. Әтисе белән әнисе дә, сеңелләре дә шунда: кайсы печән чаба, кайсы тырма белән әлек чапканны кабарта. Баш очында ук кояш кыздыра, маңгайдан тир ага, әрәмәдә кошлар сайраша. Бик күңелле. Бөтен кеше болында. Арба астындагы әбәт чиләгеннән салкын әйрән эчәсең дә арганнар әллә кая китә дә югала. Үзенең арбага төяп стансага олау-олау печән ташыганы бар. Вагоннарга төяп менә кайларга китерәләр икән аны. Акбүз ише шахтер атларны туйдыру өчен икән...

Икесенең дә ризыгы кече телләренә дә йокмый, шулай да күңелләре күрәйгән шикелле.

Акыллы малкаен җитәкләп, Хәмзә абзардан баш штреккә чыга, юлдашына бертуктаусыз такылдый: «Сиңа монда рәхәт, — ди. — Ә Донбасста атлар, бичаралар, җир астында җан бирәләр. Аларны өскә чыгарырга ярамый, шундук сукыраялар». Акбүз, аңлаган сыман, башын чайкап бара, ә иясе уйга баткан. Бүген без шахтерларны «Вагон давай!» дип акыртмаска тиеш. Әмәлен таптым, ахры. Син аяк өсте булса да

черем иткәндә, кичә мин гамәлдән чыккан юлны караштыргалап йөрдем. Эштән бушаган иптәшләрем юл төзәтергә килербез дип калдылар. Бүген, аргамагым, эш синнән тора. Әмәлем гамәлгә ашса, тагын ипи каптырырмын...»

Олы юлга чыксалар, бөтен штрек йөкле вагонеткалар белән тулган. Люковойлар, гадәттәгечә, тамак ярып акыра. Ә бүген Хәмзәнең аларга исе китми, иптәшләренең юл төзәтергә килгәннәрен күрә, шул яктан күзләрен алмый. Әнә кайләләре шалтырый, утлары җемелди, малайлар икәнлеген шаяра-шаяра һавага чүкеч чөюләре үк әйтеп тора.

Килеп житәр-житмәс үк берсе:

— Кайдан башлыйк, Хәмзушка? — дип сорады.

— Иртән сөйләшкәнчә, стрелкадан тотыныгыз, баткакка тикле. Аннан күз күрер.

— Тәки юк. Килмәстер, ахры, — диде берсе, кемнедер булса көтә иде, ахры.

— Петя кайда? — дип сорады Хәмзә.

— Яшь хатын кочагында, — диде кайсыдыр.

— Яшь сиңа! Ир кеше булса, ул хатынның сакалы биленә җиткән булыр иде инде...

Малайлар шаркылдарга кереште, Петяның үзеннән шактый олы хатынга йортка керүен ошатып бетермиләр иде. Кызып-кызып кайсыдыр сөйли:

— Өйләнмәс иде, хатыны ашханәдә пешекче бит. Тамак ул янган утка да кертер.

Бераздан йөгерә-йөгерә Петя үзе килеп житте, мышный-мышный эшкә тотынды. Малайлар аны ирештерә башладылар.

— Петя! Яшь кияү...

— Яшь кияү! Балагыз ничәү?..

Һәммәсе бирелеп юл төзәтә: чүкечләре шак-шок, шак-шок итә. Ломнары лап-лоп, топ-топ итә. Аяклары су эчендә лаштыр-лоштыр, лоштыр-лаштыр. Ә Хәмзә, гадәттәгечә, биш вагонеткасын тагып, арткысының буферына баса да Акбүзен куалап китеп бара. Кулында дилбегәсе дә, чыбыркысы да юк: кирәкми алар, мал да җылы сүзне аңлый лабаса. Вагонеткалар шыгырдый, дөберди, рельслар калтырана, дер-дер селкенә. Тәгәрмәчләр, рельстан менә ычкынам, менә ычкынам дип, кылдыйбылдый киләләр. Кызулыкны тырнак очы хәтле генә арттырсаң да, бишесе берьюлы пычракка кереп батар кебек. Болай таракан шикелле кыймылдасаң, шахтада мәңгегә вагонетка кытлыгы бетәчәк түгел. «Әллә унны тагып карыйбызмы, бахбай?» — ди Хәмзә, атының ялыннан иркәләп. — Юкса, эшләр хөрти безнең, коры хыялый булып кына калырбыз».

Тышта йөкләләрен калдырды да, бушларын тагып, люк янына китетереп куйды. Люковойлар сукраналар: «Коногон итеп куйдылар бер корчаңгыны. Коногон! Вагон давай!»

Менә Хәмзә хыялыннан шашып берьюлы унны тага: «Акбүз бирешмәс, — ди. — Ә юл түзәрме? Рельслар? Ни булса булыр, сынап карарга кирәк. Ятып калганчы атып калырга... Шундук икенче уй килә: таш урынына баш ярсаң? Үр төшкәндә унысын берьюлы аударып, бөтен баш штрекне томаласаң? Ул чагында участокта эш тукталачак. Каш ясыйм дип күз чыгару була түгелме, ахмак!..»

— Чаптырдык, дөлдел, биш белән! — Ә колак төбендә кемдер тукый кебек: «Кыюрак кылан, егет икәнсең егет бул, батыр бул!»

Менә хәзер бахбай унны өстери. Көчәнә, тырмаша, әмма тарта. «Өстерә, җанкаем, тарта күр! Азга гына түз, тиздән үр төшәсе». Менә үр өсте, йоклап калырга ярамый, атны куаларга, үрдән барлык көчкә чаптырып төшәргә кирәк тә очынып каршыдагы үргә дә менеп китәргә!..

Хәмзә җилкәсе белән алгы вагонетка читеннән этеп бара, атына булыша, ә үзенең тез буыннары калтырый. Аяклары чыптыр-чыптыр пычрак ера, аны сизми дә ул хәзер. Әмәле акланса, бөтенесе оныталачак, эчкә җылы керәчәк, кайгыны шатлык күмеп китәчәк. Менә шушылар хакына гына да теләккә омтылырга ярый.

Соңгы үрне менгәч, эчләр җиңеләеп китте, хәзер Акбүз ярыйсы гына юртып бара, ә Хәмзә нәтиҗә ясый: үрне чаптырып төшәргә дә икенчесенә хуттан менеп тә китәргә кирәк икән.

Малайлар терәүләр арасына посып состав узганын көтәләр, берсе вагонеткалар саный: берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү... «Әле тагын бар!»

— Эй, Хәмзушка, ялгыш такկансың ич.

— Нишләвең бу?!

— Башың ике мәллә?

Берсен-берсе узыша-узыша, ат артыннан чабалар. Хәмзәнең чабуыннан тарталар.

— Ычкындыр яхшы чакта! Десятник күргәнче...

— Юри таккан ул, юри.

— Юаштан юан чыга. Сазлыкка мәтәлеп төшмәсә генә ярар иде.

Хәмзә атын туктатты. Бу төштә һәр вакыт рельслар пычрак астында ята, су тонып тора. Ничаклы гына ком-таш тутырмасыннар, шпалларынниләре белән рельслар калтырана, рельсның берсе бата, икенчесе күтәрелә, шушында кайчакларда вагонеткалар да ауганый. Шушы калтыравык җирдән курыккан иде барысы да. Ничек итеп составны уздырып җибәрергә моннан? Малайлар катып калган. Хәмзәнең нишләрен күзәтәләр иде.

— Әйдә, тәвәккәллә! — диде Петя.

— Бик акрын гына кузгат. Ни күрсәк бергә күрербез.

— Егет булсаң, дегет булма!

Хәмзә яңадан бу калтыравыкны карап килде, нибары ун-унбиш адымлап кына үзе, ә ничаклы котны очыра. «Бишәрләп ике тапкыр чыгарырга кирәк булыр».

Составны урталай бүлеп, атны куалап кереп китте. Әкрен, бик әкрен. Шулай да бер вагонетка рельстан төшеп, тәгәрмәчләре пычракка батты. Азаплана-азаплана, җыйнаулашып күтәреп куйдылар.

Составны икегә бүлеп чыгарып бетергәч, яңадан унны бергә такты да тышка таба чаптыртты гына. Малайлар аның артыннан йөгерәләр, кычкыралар: «Менә ул кем коногон! Күптән куясы булган!» — диләр.

Хәмзәнең маңгаена тир бәреп чыккан, шатлык тире. Кысан штрекләр иркенәеп киткән кебек, баш штректә кинәт кояш балкый башлаган сыман тоела.

Хәертдин, һаман яңа лава тирәсендә чуалганлыктан, баш штреккә төшеп йөри алмаган иде. Ярты смена беткәндә генә люк янына төште: коногон йөк көтеп утыра. Аннан да ерак түгел малайлар юл төзәтә иде. Хәертдин шаккатты: «Менә сиңа кавалерист! Ахыр заман галәмәтедәр бу! Юк, болар чынлап торып эшләргә килмәгән». Бераз карап торгач:

— Тиздән үз сменагызга киләсе. Кайчан ял итәрсез? А ну, марш! — дип боерды.

*

* *

Тау итәкләрендә таш кыя ярыкларына кәкре-бөкре тамырларын батырып үскән карагай агачларының ылыслары саргайды, шулай да әле һаман коелмый. Ургыл буендагы таллар, усаклар да яшел киемнәрен күптән салдылар, фәкать чыршы гына ямь-яшел килеш утыра бирә. Ә кыш дигәне бер караңгы төнне әллә кайдан шатырдап килеп чыкты да таң атканчы бөтен җир өстен ак җәймәсе белән каплап алды. Һәм

сугыш авырлыклары өстенә үзенең мәрхәмәтсез суыгын кешеләр өстенә китереп аударды. Ә кешеләр, түзә генә түгел, аяк басмаслык сазлыклар, җәнлек тә үрмәләп менә алмаслык текә таулар һәм чытырманнар аркылы олы шәһәрдән бирегә хәтле тимер юл салып китерде. Урман һәм таулар яңгыратып ыргылган поезд белән бергә бу якларга, кышкы салкын дип тормыйча, илнең йөрәк җылысы килеп җитте. Шушы җылыны тоеп, шахтерлар, Мәскәү яныннан фашистларны куып китү көненә багышлап, Беренче шахтаны файдалануга тапшырдылар. Хәзер вагоннарга төялеп илнең төрле завод-фабрикаларына, калаларына, йортларына, электр станцияләренә шахтерның йөрәк җылысы — ташкүмер озатыла.

Степанов бер сменага десятник итеп яңарак кына курста укып кайткан Якупны куйды. Десятник ул — җир астында тау эшләре остасы, хәвеф-хәтәрсез күмер чыгаруда да, кешеләр белән мөнәсәбәтендә дә һәм әйбәт оештыручы буларак та барысына үрнәк күрсәтергә тиеш. Якуп шахта эшләрен ярыйсы гына белә, курста бераз чарлап та җибәргәннәр үзен, һәм ул мондый авыр эшне теләп диярлек алды. Хәзер ул Степановның уң кулы.

Зоя бригадасын Степанов Якупка тапшырды. Менә ул айга якын инде шул бригада белән ярыйсы гына эшләп килә.

Соңгы вакытларда аның бигрәк тә алны-артны карамыйча алга ыргылган көннәре. Степановны бөтен Ургыл шахтерлары исеменнән өлкә үзәгенә җибәргәннәр иде. Ул, «Беренче шахта»ның парторгы һәм иң өлкән шахтер буларак, шәһәрдә бик зур эш башкарып чыкты. Фронтка җылы киемнәр җыю башлангач, аны шул комиссиянең председателе итеп куйдылар. Җылы киемгә мондагы шахтерлар үзләре дә мохтаҗ булганлыктан, Степанов танк колоннасына акча җыеп тапшыру тәкъдиме кертте һәм тиз арада шактый акча да җыеп өлгерде. Якуп белән Хәмзә дә өйләренә җибәрергә дигән акчаларын шул фондка тапшырдылар. Менә шул фондны илтү өчен дип китте анда Степанов.

Шахта начальнигы Михайлов үзе килеп Якуп белән «Сивак»тагы бөтен забойларны айкап чыкты. Механизмнар төзек, забойларда шактый күмер шартлатылган иде. Михайлов күзенә төшеп торган куе кара кашларын өскә таба күтәрде дә:

— Бернигә карамастан план үтәлгән булсын! — дип, шахтадан чыгып китте.

Боерык бирүе җиңел, ләкин каян алырга соң ул планны? Әллә бүген бөтен забойщикларны да лавага гына куяргамы? Аннан күмер күбрәк бирелә. Ә штрекләр әзерләргә бер-ике генә забойщик куеп торырга да ярый. Хәер, Степанов соңыннан сизенәчәк, колакны борачак, тик ул берәр атнасыз кайтмас әле. Ул барында тыныч иде күңеле, таяныр кешесе бар иде, аның белән күзгә-күз карап сөйләшеп була иде. Ә Михайлов усал, артык җәелеп китми, таләп итә генә белә. Бүген йөкләмәне үти алмаса, аның каршысында калтырана-калтырана басып торырга туры киләчәк. Якуп Михайловның әле өскә чыгып китмәгәнен яхшы белә, ярты төнгә хәтле диярлек шахтаның башка участокларын да урап чыгачак. Ник дисәң, алардан күмер «Сивак»ка караганда күп тапкыр артыграк чыгарыла, анда катлам биек, күбрәк ирләр эшли. Эх, хәерле төн булсын иде дә, бөтен теләкләре тормышка ашсын иде Якупның, йөкләмәсе арттырып үтәлсен иде...

*

* *

Иң башта Якуп Марина забоена тукталды.

Шахтада баш штрекне олы юл дияргә була. Шушыннан төрле якка эреле-ваклы штрекләр кереп китә, шул юллар белән бөтен шахта эче челтәрләнеп беткән. Баш штрек буйлап шахтерлар бергәләп барырга

чыгалар, бара-бара кайсы кая үз юлы белән тарала. Штрекләрдә икәүләшеп яки берәмләп кенә эшлиләр. Төрле штрекләрдә һәм лавадан чыгарылган барлык күмер һәм таш-ком шушында җыйнала. Баш штреккә тимер юл салына һәм шул юл буйлатып вагонеткалар дөбердәтә-дөбердәтә атлар йөри.

«Сивак»та иң яман җир бүгенге көндә кай төштә дип сорасалар, икеләнмичә, Марина эшләгән шушы забойны күрсәтергә була. Баш штрек иң озын гәүдәле кешеләрдән дә биегрәк булырга тиеш. Күмер катламы бүтән штрекләрдәге хәтле генә, әмма монда күмер катламын гына алу җитми, аның астында яткан метр ярым калынлыгындагы таш катламын да шартлатып, вагонеткаларга төяп өскә чыгарып түгәргә туры килә. Күмерне бер смена төясә, икенчесе шул таш белән иза чигә. Шушы баш штрекнең соңгы ун-унбиш метры диңгез төбенә туры килгән диярсең, бертуктаусыз өстеңә чиләкләп яңгыр коя, аяк асты тубыктан пычрак. Йодрык кадәрле генә таш кисәкләре дә чуендай авыр. Көрәк тотып төяргә генә керешәсең, беләкләрең буйлап бөтен тәнеңә суык су ага башлый. Барыннан да яманы — шартлатканнан соң сәгатьләр буе зәпзәңгәр төтен забойдан бик озак китмичә тора, иртәрәк килеп керсәң, тыныңны буа.

Якуп килеп туктады, забойга күз салды, тетрәнеп китте. Марина эчке күлмәктән генә калган, өстеннән пар күтәрелә, зәп-зәңгәр төтен, пар эченнән нишләгәне дә күренми, аркасыннан ике толым чәче асылынып төшкән дә очлары су өстендә йөзә. Көчәнә-көчәнә олы гына бер таш кисәген вагонеткага салырга азаплана икән. Тирән итеп сулады да тиргә, пычракка манчылган битен юеш кул сырты белән сөртеп алды, бернәрсәгә дә игътибар итмичә, яңадан шул ук ташка ябышты. Якупның күзләре эчетә башлады, тыны буылды, ютәлләп тә куйды.

— Тукта дим! Шушында аяктан егылырга телисеңме әллә?! — Якуп ярыйсы гына каты итеп әйтте.— Бар, саф һавага чыгып, бераз хәл ал!

Марина иелгән җиреннән әкрен генә күтәрелеп, чыраен сыта-сыта, сыңар кулы белән билен тотты, икенчесе белән вагонетканы капшады. Вагонетка туп-тулы иде. Шунда гына ул Якупка күтәрелеп карады. Чырае яктыра төште, әмма бу Якупны күрүдән түгел, вагонеткасын тутырудан иде.

Килеп-китеп йөргән кешегә игътибар итми Марина, йөрәге яралы аның. Ул ярага тияргә, аны яңартырга ярамый. Шулай да бар бит әле дөньяда кайбер телчән бәндәләр, теләпме-теләмичәме, шул җәрәхәткә кагылгалыйлар да тоз сибеп әчеттерәләр. Шундыйлардан читкә, бик читкә качып котылмакчы Марина. Әмма Якуп мондый нечкәлекләргә төшенми, аны кызгана гына. Мариналың шахтага беренче килеп кергәч көннәрен исенә төшерде. Әтисе шикелле күкрәк киереп, бераз гына усалрак чырай белән керер иде ул нарядныйга, шулай да йомшак холыклы икәнлеген бик тиз сиздерде. Шулай беркөнне иртән наряд биргәндә чираты буенча Фатыйма шушы забойга барырга тиеш иде. Марина: «Мин үзем генә барам анда», — диде. Степанов та, Хәертдин дә аптырашта калдылар. Чөнки монда барырга һич тә атлыгып торучы юк, барысы да җәза алган шикелле генә риза булалар иде. «Чиратың җиткәч, сеңелем, чиратың»,— диде Хәертдин. Марина бик кыю гына: «Әгәр дә мин бүген теләсәм?» — диде. «Ай, җанкисәгем, бәбчегем, барсаң барырсың, тик ярдәмгә кемне бирик?» — диде. Степанов Мариналың усал телләрдән, аларның күзләреннән котылырга теләгәнен белми иде. «Бирәү дә кирәкми, үзем генә», — диде Марина. Шулай итеп ул теләгенә ирешге.

Үзен шушы авыр эшкә корбан итеп, олы хатыннарны авыр эштән коткарырга теләгәндер ул бәлки. Тик монысын берәү дә төпченеп тормады, шулай да Фатыйма ишеләр аны ихтирам итә башладылар. Мактапып десятниклар теленә дә керде.

Якупка Марина ошый иде. Гомумән, ул эшкә булганнарны, ныкларны ярата. Менә айга якын инде Марина шушы забойда. Ничә килмә аның янына, гел эшләвен белер. Менә бүген дә забойның җиллләп беткәнен көтеп тормаган, төтен эченә барып кергән дә көрәгенә ябышкан.

Якуп каршында инәсеннән-җебенә тикле чыланган, манма тиргә баткан, эчке күлмәк итәген брезент чалбар эченә кыстырган, калку күкрәкле, нык беләкле яшь кыз басып тора. Үзе еш-еш тын ала, битләре кап-кара, маңгаеннан, кашларыннан тамчылар тәгәри. Су тамчыларымы, әллә күз яшьләреме? Дәшмәде ул Якупка, күз сирпеп карап алды да аякларын шпалларга терәп, көчәнә-көчәнә, вагонетканы урыныннан кузгатты. Аякларын пычрактан кубарып алыр хәле юк, күренеп тора: тез буыннары бераз калтырый. Якуп әле һаман аны аңламыйча сәерсенеп карап тора иде, тик вагонетка урыныннан кузгалгач кына, икәүләп этеп киттеләр. Илле метрлап ара узгач, вагонетка икенчеләренә доңгылдап килеп бәрелде. Монда, икенче юлда, бушлары да бар. Марина шундук бушына ябышты, этеп кире китәргә керешге.

— Марина, саф һавада утырып бераз ял итсәңче,— диде Якуп чын күңелдән.— Җитешерсең әле, лавада яңа гына эшкә керештеләр.

Ап-ак тешләрен елтыратып, Марина берничә генә сүз әйтте.

— Үземнекен бетерсәм, Оксанага булышасым бар, Яша.

— Марина, тукта әле!

— Нәрсә тагы?

— Иртәгә лавага чыгарсың, бригадага, әниең янына. Инде бит бер ай монда интегәсең.

— Анысын үзем белермен, — дип, Марина китеп тә барды.

Менә аңла инде син аны, егет. Бер караганда, горур кебек, ә бәлки гөнаһысын тир белән юмакчыдыр. Бәлки забой түренә вагонеткасын китереп җиткерер дә терәүгә йөзе белән капланып үкси-үкси еларга керешер, эчендәге барлык хәсрәтләрен шулай күз яше белән түгеп забойда ялгызы гына коенадыр, әле төзәлеп җитә алмаган җәрәхәтенә җиңелрәк булып китәдер... Монда аны елый-елый шешенеп бетсә дә күрүче юк, янына килеп сорашучы, үгетләүче-юатучы юк. Барыннан да бигрәк, әнисе йөрәгенә тоз сипми.

«Иртәгә үк, Степанов кайтса, моны лавага алырга кирәк», — дип куйды Якуп.

*
* *

Якуп, бер забойдан чыгып икенчесенә керә-керә, Оксана забоена якынлашты. Күңеле төшенке түгел аның: колашалар тулы күмер агыла, люк астында вагонетка артыннан вагонетка куела тора. Әнә, Хәмзә икенче составны алып китеп бара. Болай булгач, шәп! Менә Оксана эшли торган забой. Монда астан да, өстән дә су саркый, күмер юеш, таштай авыр, көрәккә элеп вагонеткага сала башлауга, лачкылдап өстеңә апара коела. Моңарчы бу штректә икешәр забойщик эшләп килде, ә бүген шуларның берсен лавага җибәрде Якуп, күмер агыла торган җиргә. Ул килгәндә, Оксана резинкасына тулган суны түгеп утыра иде, бөтенләй ялан аяк калган.

— Ну, иптәш Уханова, ничәнчесен төйисең?

Оксана дәшмәде, су түгүендә дәвам итте. Башын кыйгач салган, каскасы астыннан чәч толымнары асылынган. Үзенең өстеннән пар күтәрелә, бөтен өсте манып алгандай юеш.

«Бик кәперәйсәң шулай була ул», — диде Якуп үз-үзенә һәм моннан ике атна чамасы булган хәлне исенә төшерде.

Шулай, шәһәргә беренче поезд килгән көн иде. Шул ук көнне Беренче шахта файдаланууга тапшырылды. Ә кичен клубта тантаналы җыелыш булды, кайберәүләргә бүләкләр, Мактау кәгазьләре бирелде, рәх-

мәтләр әйтелде. Андыйлар арасында Якуп та бар иде. Тантана өлеше тәмамлангач, кайсы утырып концерт башланганны көтә, берәүләре буфетта соя кумәченә чират тора, икенчеләре өстәлдә газета-журнал актара. Тантаналы кичәдә катнашучыларга икешәр йөз грамм кәгазьле конфет та бирелде. Оксана конфетка дип буфет алдында чиратка баскан, матурлыгы белән Ургыл буйлап баржага утырып менгән чагын хәтерләтә иде. Якуп талонга тигән костюмын, аягына кызыл төстәге ботинка кигән иде. Оксана чиратыннан чыгып залга атлауга, Якуп аңа конфет төргәге тоттырды, концерт башланганчы клуб әйләнәли йөреп килергә тәкъдим итте. Урамга чыктылар. Бөтен эскәмияләрне яшьләр биләп бетергән. Яфрак-яфрак кар ява. Клуб эченнән оркестр моңы сибелә. Култыклашып, берничә тапкыр клуб әйләнәсен уратып килгәч, Якуп дуамал гына:

— Мин синең белән гел бергә булыр идем, Оксана, — диде.

Тегесе күзләрен зур ачып, егеткә күтәрелеп карады.

— Миннән башкаларың да җитәсе, Яша.

Эчкә керергә өндәп кыңгырау шалтырый башлауга, Якуп Оксананы кинәт кочып алды да шашынып үбәргә кереште, ә Оксана, аның кочагыннан оста гына ычкынып, конфет төргәген Якупның аяк астына ыргытты һәм йөгереп китеп тә барды. Шул чакта аның: «Иптәш Әхмәтҗанов, мин сезне мондый тупас дип уйламаган идем, бөтенләй Хәмзушкага охшамагансыз. Конфетыгыз да, үзегез дә хаҗәт түгел!» — дигән сүзләре әле дә колак төбендә генә янгырый кебек...

Менә кайчаннан бирле Якуп аңлый алмый, үзен түгел, Оксананы гаепли: «Ярый, кызый, карарбыз кемнең кирәкмәгәнен, минем кул астында эшләячәксең»,— ди ул үзенә. Шул көннән башлап, Оксананы ялгызын гына әһәмияте кимрәк булган забойларга җибәрә...

— Бүген кич айны күзәтергә чыгабызмы? — диде ул, Оксана янына килеп җитүгә, авыз чите белән генә көлемсерәп.

Оксана, аңа житен чәчәгедәй зәңгәр күзләрен күтәреп, мыскыллап карап куйды, үзе бер сүз дә дәшмәде.

— Мин сиңа чынлап әйткән идем, нигә аңламыйсың икән?

— Әллә егетләрне без Мактау тактасында эленеп торулары өчен генә яратабызмы, Яша? Кучмә кызыл флаг җилфердәтеп йөрүләре хакынамы? Берне түгел, унны җилфердәтсәң дә, бу дорфа килешең белән яраттыра алмассың, Яша.

— Оксаночка, мин бит гел сине генә уйлыйм...

— Таняның иреннән хат килгән. Алешасы исән икән.

Өстенә кайнар су сипкәндәй, Якуп дерелдәп китте.

Оксана кабатлап әйтте:

— Әйе, әйе. Кичә генә хат алды. Бик тә авыр аңа хәзер. Тәмам диваналанып беткән.— Бераздан пышылдап өстәде: — Синең дә гөнаһың юк түгел...

— Үлгәннәр беркайчан да кайтмыйлар, — диде Якуп, һаман ышанмыйча, әкрен генә атлап баш штреккә чыкты, лавага таба юнәлде.

Колашалар дөберди, лава гөрләп эшли, күмер агыла. Шәп бара ич эшләр.

Әй, яшь десятник! Биредә сезне нинди хәвеф сагалап ятканын белмисең шул әле син...

*

* *

Якуп күздән югалгач, Оксана ат башы хәтле күмер кисәген кәйлә белән вакларга тотынды. Аннары маңгаена төшкән чәчләрен сыпырып, битендәге тир тамчыларын күлмәк итәгенә сөртте дә вагонетка кырыена сөялде. Күз алдына тантаналы кичә көне, клуб яны килеп басты. Әйе, Яша ул чакта барлык егетләр арасында тазалыгы, матурлыгы белән

аерылып тора иде. Карашлары ягымлы, сөенече йөзенә чыккан иде: Мактау кәгазе бирделәр бит аңа. Ул көнне бөтен халык шат иде. Авыр сугыш елларында да туган ил шахтерларны онытмый, олылап хөрмәтли. Урамнар да матур итеп бизәлгән, бөтен Ургыл чын бәйрәм төсен алган иде. Боларның тәэсире генә түгел, ниндидер бүтән ягымлылык бөркелә иде ул көнне Яшадан. Конфет төргәген дә бәлки йөрәге кушканга сузгандыр, ә үзе йөрәккә үтеп керә алмады. Нишләп алай? Хәзергә белми Оксана. Хәзер ул сызлана гына: кем дип уйлый мине? Танясы шикелле, мине дә кочып үбәргә ярый ди микән? Кимсетә дисәң, бүген азрак оялган да кебек тоела. Әллә яратамы? Яратса, нишләп болай гөрбиян?..

Оксана яңадан кәйләсен алып, күмер кисәген чит-читләп киткәләп төшерергә тотынды. Шул чак йодрык кадәрле кыйпылчык уң аягының баш бармагына килеп бәрелде дә, Оксана куркудан чырылдап куйды. Бармак башы уелган, тырнагы купкан, кан саркый иде. Моңарчы аңа бер ялгызы гына ябылуда яткан шикелле азаплы иде, ә хәзер бөтенләй үк шомлы тоелды. Чатанлый-чатанлый, баш штреккә таба китте...

*

* *

Ә бу вакытта фаҗига куерганнан-куера бара иде. Прошка начальникка шалтыратасы урында, күмер өеме өстенә утырып, десятник килгәнен көтә бирде. Шартламый калган детонаторны бергәләп эзләмәкче иде. Күңелендә һаман: «Ходаем үзен сакла! Детонаторны эзләп тапмасам, карт көнемдә моннан ычкынам...» дигән уй гына булды. Үзалдына шулай мыгырдана-мыгырдана, әҗәле сагалап яткан урынга үрмәләде, десятникны көтмичә, үзе эзләп табарга карар кылды. Бөтен гомерен хәвефле эштә уздырган җир асты карты шомлы җиргә отыры якынлаша барды. Аның бөтен буыннары калтырана иде. Эзләргә йөрәге җитмичә, ул яңадан десятникны көтәргә булып, шомлы урыннан байтак читкәрәк китеп утырды.

Прошка шулай утырган арада, Варя, детонаторны эзләргә дип, шыпырт кына забойга шылды. Берәү дә аның анда кергәнен күрми калды. Соңгы минутларымдыр дип, ул узган гомерен башыннан үткәрә башлады. «Минем бу дөньяда беркемем дә юк, ә теге дөньяда әби-бабаларым, әти-әниләрем бар, җанымны фида итсәм, шулар янына барырмын. Ә Прошканың өендә чукрак сеңелесе бар, аны тәрбияләргә кирәк...»

Һәр күмер кисәген җентекләп карый-карый читкә ыргыта барды. Кисәкле күмер беткәч, бөрешкән бармаклары белән өемне актара башлады, тырнакларын кубарып канга батырды, үзе һаман эзли дә эзли. Менә кулына кирәк алды, казырга тотынды. Кирәкне тотырып алды да читкә ыргытты, алды да ыргытты, нәрсә эшләгәнен дә онытып җибәрде. Шул чакта коточкыч шартлау дулкыны аны читкә атып бәрде, күмер кисәкләре әллә кайларга чәчрәде, берничә терәү дә җиргә авып төште.

Участокта ыгы-зыгы башланды. Шул арада йөгереп Якуп та килеп житте.

*

* *

Мондый хат килере төшенә дә кермәгән иде Талиганың. Хатны тотуга ук, иренең кулын таныды ул һәм стенадагы фотога карап бер елады, бер көлде. Баштарак бу турыда берәүгә дә авыз ачмады. Кабат хат килгәч, иренең терелегенә тәмам ышангач кына, хәлне Фатыймага сөйләде. Алеша яраланганнан соң бик озак госпитальдә яткан икән. Хат язарга кул-аягы селкенмәгән, бик озак аңын югалтып яткан. Хәле ях-

шыруга ук, беренче хәбәрен «йөрәккә кояш ташучы» хатынына язып җибәргән.

«Үзеңне сакла», дигән Алеша хатында. Менә шушысы Талиганы көн-төн борчый. Саклый алдымы соң ул? Саклавын саклады, әмма күңеле, бөтен омтылышы чит иргә, Якупка ошарга тырышып яшәүгә әйләнеп китте түгелме? Якупны үзенең бүлмәсенә кертте, түренә утыртты хатын. Шуларны уйлап кыйнала, төннәр буе йокламый ята. «Кайбер хатыннар ирләре үлгәч тә гомерләре буена аларга тугры булып калалар, ә мин кала алмадым»,— ди. Һәм ул кала да алмас иде. Әмма үз хәлең белән килешмичә булмый. Ире аның алтын бәясе кеше иде, үлеп яратты һәм яраттырды да. Ә яраткан кеше гафу да итә белә. Әнә шундый өмет баглап, ул өзелеп ирен көтә башлады. Алешасының фотосын табып, сәгатьләр буе күзен алмыйча утыра, эче тулы сагыш, моң, юксыну һәм оялу да. Иреннәре кыймылдый: «Алеша, бәгърем, кайларда югалып йөрдең син елга якын? Исән икәнсең ич син, нигә мине алдадылар? Нигә үлгән дип кәгазь тоттырдылар? Хәзер бөтенләй югалып калам түгелме? Тәмам болганып беттем ич, зиһенем чуалды бит...»

Әнә шушындый хәлдә, кулына Алешасының рәсемен тотып утырганда, кинәт ишек шакыдылар. Талига сискәнеп китте.

— Кем бар? — дип каушап сорады.

— Талига!.. Мин бу.

Талиганың тез буыннары калтырап китте, ул, кулындагы фотоны күкрәгенә кысып, караватына килеп утырды.

Тагын шакыдылар. Тагын, тагын.

— Талига, зинһар ач... Нишлим, кайгымны бушатырлык беркемем юк. Кая барыйм... Талига!..

Талига тораташ шикелле утыра бирде. Шакучының кем икәнен тавышыннан гына түгел, шаку рәвешеннән үк танып алды ул. Ләкин кузгалырга, һич югында, тел әйләндереп берәр сүз әйтергә үзендә көч таба алмады.

Шаку бүтән кабатланмады.

Әйе, «Сивак»тагы фаҗигадән тәмам миңгерәүләнеп калган Якуп, чыннан да, кайгыларын бушатырга, биредә юаныч табарга дип килгән иде. Аннары... Алеша турындагы хәбәр дөрес микән — шуны да ачыкларга иде исәбе.

Ләкин ишек ачылмады.

## УНЫНЧЫ БҮЛЕК

Михайлов белән Степанов контора бүлмәсендә утыралар, бер-берсеннән күзләрен яшерергә тырышалар. Утыралар-утыралар да, торып, яңадан йөренергә тотыналар. Ник берсе-бер сүз катсын, телләрен йотканнар икән диярсең.

Михайловның үз гомерендә болай коелып төшкәне юк иде әле. Үзен Степанов каршында да, Якуп каршында да гаепле саный ул. Яшь десятникка ярдәм итәсе, аның эшен күзәтеп һәм искәртеп торасы урында, гел план гына давайлады. «Планны кысып чыгара беләбез, ә менә үз канатың астындагы яшьләргә якын итеп карауны, игътибарлы булуны кайчакта оештыра белмибез. Күбрәк үзебезне акыллы башларга санап яшибез. Юк, билләһи, кирәк хәтле җылы бөркеп тормый башлады бездән. Сугыш мәшәкатьләренә сылтап, отыры суына барабыз, ахры. Ә Степанов нилэр уйлап дәшми йөренә? Аның кайтышына нинди зур бүләк әзерләп куйдым. Минем аркада диярлек Прошка белән Варвара Харитонова больниста яталар. Бөтен Ургылга яман атыбызны чыгардык. Менә хәзер Әхмәтҗановның гаебен ачыклап бетерәсе бар, гаепле икән — җәзасыз калмас. Ә үзебезне? Читтә торып бөтен гаепне яшь

егет өстенә аударырга вөжданым житәрме? Нишләргә? Ничегрәк дөрес нәтиҗә чыгарырга?» Шулай уйланып йөри торгач, Степанов каршына килеп туктады ул һәм салмак кына сүз башлады:

— Федор Иванович, бөтен гаеп тик миндә генә. Мин гаепле. Болай дип бөтен «Сивак» каршында әйтә алам. Мин, карт бүре, сезне фаҗига алдына куйдым, дияргә телим. Теләсәгез өскә үк куып чыгара аласыз, диярмен...

Степанов аңа туры карады: сынап та түгел, кызганып та түгел, ә сәерсенеп карады. Михайловның сүзләре чын йөрәктән әйтелгәнен яхшы аңлый иде ул. Шулай да арттырып җибәргәне дә сизелеп тора, монысы ошамый олы урындагы кешегә. «Нишләп ул гына гаепле булсын? Нинди горур кеше дә шушылай артыгын кыланып икән! Хәер, үзәгенә үтмәгән булса, бу сүзләрне әйтә алмас иде. Әйе, фаҗига ул җитәкчелек иткән чорда ясалган, мин бөтенләй читтә чакта, өлкә үзәгенә киткән көннәрдә. Шулай дип әйтеп, теләсә кем алдында акланырга булдырыр идем. Ә намусым алдында шулай дип әйтеп кенә котылып буламыни?» Әгәр беренннән-беренә гаеп аударуда гына эш торса, бөтенесен үз өстенә алыр иде ул. Әйе, Ургылга куанып, дәртләнеп кайтып кергән иде Степанов абзагыз. Өлкә үзәгендә танк колоннасы өчен бик күп рәхмәтләр әйттеләр, барлык шахтерларны олыладылар. Стансага килеп җиткәнче үк вагон тәрәзәсеннән күзләрен алмады. Беренче шахта өстендәге балкып янган кызыл йолдызны күзәтте. Бу йолдыз алдынгы шахталар өстендә генә кабызыла. «Сивагы» өчен сөенде ул, ФЗО мәктәбендә үзе тәрбияләгән малайлар өчен куанып бетә алмады. Боларыннан да бигрәк, яңа фикер кереп оялады аның башына. Хәер, күптән уйлап йөргән иде бу хакта, тик төпле нәтиҗәгә генә килә алмады. Ә поездда карар кылды. Яшь һәм кыю егет Якуп, ошый иде ул аңа. Бүгенге көндә картның уллары фронтта, карчыгы белән икәүләп кенә яшиләр. Бүтән картлар янына күптән ФЗО малайлары килгәләп йөри. Малайларга да, картларга да болай аралашып яшәү бик рәхәт, күңелләре шуны тели. Якуп белән бергә-бергә күңеллерәк булыр иде. Аның өстенә, җитеп килә торган кызы да бар. Ул әле укый гына, техникумда. Аны тәмамлауга шушында кайтачак ич... Монысын үзләре карарлар иде әле. Карчык та бик сөенер иде... Менә шул хакта, Якупны ияртеп кайткалау һәм иркенләп утыру иде аның уенда. Ә монда нәрсә килеп чыккан.

Чыннан да, Степанов бу фаҗигадә үзен Михайловка караганда гаеплерәк тоя башлады. Ни генә әйтмә, «Сивак» — аның участогы, кая гына китсәләр дә, малайлар һәм хатын-кызлар аныкы булып калалар, ул аларны тәрбияләргә тиеш. Ә Әхмәтҗанов Степановның уң кулы, төпчек улы иде. Шуны ничек кисеп ташлый аласың? Ә шулай да гел башыннан гына сыйпап торырга ярыймы соң? Буш та калдырмаска, канатын да кисеп ташламаска. Менә дөрес карар.

Михайловка Степанов болай диде:

— Хөрмәтле иптәш Михайлов, без икебез дә бер арбаның ике тәртәсен тартып барабыз. Тик аерма шунда гына: сине комбат буш калдырмас, син шахта начальнигы. Ә мин парторг буларак һәм әлгәрерге малайлар остазы дисбрәк җавап бирергә тиеш. Әмма таякның юан башы Әхмәтҗанов өстенә төшәчәк.

— Нишләтмәкче буласың син Әхмәтҗановны?

— Белеп тор, җанкисәгем, ул сыгылса сыгылачак, тик беркайчан да сынмаячак! Ул безгә караганда да көчлерәк. Менә Степанов җүләр әйткән иде диярсең, абынып алыр да яңадан торып китәр ул, олы сафка басар.

— Ә без читтә торып калырбызмы?

— Әйттем бит инде, бабчегем, безне дә җәзадан мәхрүм итмәсләр.

— Шулай да нишләтмәкче буласың төпчек улыңны, уң кулыңны?

— Бер айга шахтадан өстәге эшләргә күчереп торырга.

— Ничек?! Шахтадан куарга?

— Дөрес аңлагансыз. Югыйсә, ул безне дөрес төшенеп житкермәс, һаман борын чөюен дәвам иттерер. Иң куркынычы — үзен һәр вакыт хаклы дип эш итәчәк. Өстә эшләп тору аңа бик зур сабак булыр.

— Ярый ла, ул безне дөрес аңласа. Әгәр дә аңламаса, тагын да каты йөрәкле яки усалның да усалы булып китсә? Менә кай якларын да искә алырга кирәк.

— Боларын искә төшереп тору минем өстә. Аңлатуны да бурычым дип саныйм. Күз алдымнан җибәрмәскә тырышырмын. Эш анда гына да түгел. Бүтәннәргә дә игътибарны көчәйтергә кирәк. Үкенечле, бик үкенечле хәл! Әх, ничек килеп чыкты соң әле бу?!

Телефон шалтырады. Михайлов бик бирелеп тыңларга кереште. Бик озак тыңлады, «әй, әйе, аңлашыла, карарбыз» дигән сүзләр кыстыргалады. Трубканы куйгач, шалтыратучының Варя икәнен әйтте. Хәле әйбәтләнә икән. Һаман да шул элгәреге сүзләрен, детонатор эзләргә аны Әхмәтҗанов кертмәвен, үзе теләп кергәнен тукыган. Прошка агай да йөри башлаган икән.

Шул арада эш киемендә, утлы лампа тоткан Якуп килеп керде. Йончыганы һәм борчылганы йөзенә чыккан булса да, үзен кыю тотарга тырышып, өстәл янына килеп басты, начальникларның әле берсенә, әле икенчесенә карап алды.

— Иптәш начальниклар, күпмегә кадәр мине караңгылыкта яткырырсыз? — диде шактый батыр тавыш белән.

— Борчылып килүең урынлы, иптәш Әхмәтҗанов, — диде Михайлов, башын күтәрми генә. Ул приказ язып утыра иде.

Бүлмәгә Зоя белән Фатыйма килеп керделәр, аларның кергәнен Якуп күрми дә калды. Бүлмә эче тулы кеше булса да, берсе-бер башлап сүз катмады.

Ниһаять, Михайлов урыныннан торды, Якупка бер бит кәгазь сузды.

— Кара аны, иптәш Әхмәтҗанов, төшенкелеккә биреләсе булма! — диде боеру тавышы белән.

Якуп приказны тиз-тиз укып чыкты, бер агарды, бер кызарды. Иң каты җәзаны көтте ул, тик шахтадан куып чыгаруларын түгел иде.

— Бу... бу... чынлапмы? — дип кенә әйтә алды егет.

— Приказлар үтәлер өчен языла, иптәш Әхмәтҗанов, — диде Михайлов каты гына. — Иртәдән башлап, ат белән шахтага агач ташырсың. Бер айда үзеңне акласаң, күз күрер. Әгәр егет булып кала алсаң, арабызга кире кайтырсың.

Фатыйма белән Зоя да пышылдап сөйләшә башладылар. Ахырда Зоя:

— Федор Иванович, артыграк булмас микән? — дип куйды. — Без аның гөнаһларын кичергән идек инде.

— Әйе, әйе, әстәгъфирулла! Бигрәк кансыз кыланасыз инде! — дип өстәде Фатыйма һәм Якупның колагына пышылдарга кереште: — Якупҗан, энем, кичерәм синең тупаслыгыңны. Алар да гафу итәрләр аллаһына тезләнсәң. Тезлән дим ич, тезлән! Үтен, ялынып бак! Үзсүзләнеп катмансың, нарасый.

Степанов та Якупка үгет-нәсихәтләр тукырга тотынды.

Якуп боларның берсен дә ишетмәде.

— Эх, лутчы җанымны алган булсагыз! — диде дә ишекне дә ябып тормыйча чыгып китте. Бу минутта аның күзләреннән яшь бөртекләре мөлдерәп битләреннән тәгәрәгәнен берсе дә күрмәде.

* * *

Җир асты эшләрен җаны-тәне белән яраткан, уннарча чакрымнарга сузылган караңгы штрекләрдә күз йомып үз өендә шикелле йөргә өйрәнгән шахтерга шулай өскә куып чыгарылу — каты җәза.

Якупка да шахта җене кагылып өлгергән иде инде. Һәрбер терәү, рельсларның һәр ялганышы, баткак шпал аралары, аунап яткан бүрәнә башлары, таш кисәкләренә хәтле таныш һәм кадерле аңа. Ә шуны берәү дә аңларга теләми. Бөтен теләге йөкләмә үтәү иде ич. Хатын-кызларны лава җиллләп бетмәс борын куалап кертүе дә йөкләмә үтәсеннәр өчен һәм өстәмә талон алсыннар өчен иде... Авылда бригадир атлаган саен: «Артыгыздан куып йөдәтмәсәң, сезнең эшлисегез юк», — дия иде. Мондый сүзләрне тәпи йөри башлагач ук ишетә башлады. Әле «Сивакта», ФЗО мәктәбендә чакта да, Уханов күренүгә үк, утырып тәмәке тартучылар торып басалар иде дә тизрәк кәйләләренә ябышалар иде. Степанов та юаш түгел, тотса кара көйдерә торганнардан. Якуп та әнә шулар шикелле каты булырга тырышты.

Сәер дә соң бу тормыш! Иртәгәдән башлап, типсә тимер өзәрдәй яшь егет, гарип-горабаларга ияреп, шахта янына агач ташырга тиеш. Аның куллары дилбегә тоту түгел, кәйлә-көрәк сабыннан да нәзегрәк нәрсә тота алмас шикелле. Атка утырып йөрү өчен Ерак Көнчыгышка килеп тә йөрисе юк. Бу беләкләр дилбегә учларга түгел, кәйлә сабына җайлашкан. Әнә дилбегәне Хәмзә ише мәми авызлар тотсын. Мин җиңел эш сорамыйм, су тонып яткан тәбәнәк һәм тар забойга куйсыннар иде, ичмасам.

Шунда күз алдына Оксана килде...

Әнә, талдай зифа буйлы, моңарчы токмач та кисмәгән япь-яшь кыз, өстән бертуктаусыз су тамып торган штректә кәйлә күтәреп таш вата. Вагонеткасы тулгач, этеп чыгара алмыйча азаплана, көче җитми, гарьлегеннән йөзен каплап еларга керешә һәм яңадан таш ватмакчы... Канга баткан аягын күреп чырылдап ала... Бу көннәрдә ул забойда эшкә яраксыз. Кем гаепле? Гамьсезлек, усаллык түгелмени? Ничек булса да егетлек түгел бу...

Кая барырга, кемгә моң-зарыңны ачып салырга? Кем аңлар?

Аңласа, бары тик Талига гына аңлар кебек иде. Ләкин ул да... Кичә ишегең ачмады. Алешасы турындагы хәбәр дөрес микәнни?

Якуп, кайтып, бүлмәсенә бикләнде. Ишек шакыдылар. Хәмзә икән. Якуп, су капкандай, дәшми утыра да утыра. Эт итеп сүксен иде, ичмасам. Болай азаплаганчы, акланып маташыр идем.

— Якуп, малай, Варяның хәле ничек?

— Палата бетереп йөри. Башы-күзе бәйләүле.

Икесе дә тагын сүзсез калдылар. Бераздан Якуп сүз башлады:

— Мин түгел, Варя үзе гаепле. Комиссия дә шулай дип раслады.

— Гаепсез булганга тез астыңа суктылармыни? — Хәмзә шундук үкенә дә башлады: егылганны кыйнамыйлар ич, ә ул тукмарга да керешә.

— Мине түгел, җибәргән Прошканы өскә чыгарып атасы иде.

— Ә син шуны аңла, Варя ятасы караватта син ятасы идең. Десятник буларак детонаторны үзең эзләп табарга тиеш идең. Минемчә, бик ансат котылдың.

Якупның төсе үзгәреп китте:

— Күзгә кергән чүп кебек, гел мине куралмыйсыз. Юлыгызга киртә булып аркылы яттым, ахры.

— Һаман уңай гына сыпырмыйлар, белеп тор! Ярый, бүтән авыз да ачмам, башы-ахыры шул булыр. Килсәң-китсәң кергәләп йөр. Әни «Совет әдәбияты» журналы салган, укырга алып китәрсең. Күтәрмен. Ә

син, малай, әүвәлгечә нык бул. Муеның исән, камытын кидерерләр. Сау бул! — дип, Хәмзә чыгып та китте.

Якуп тагын ялгызы калды. Дусын ул тыңламады. Үз кайгысы кайгы, үз кырыгы кырык аның. Мең бәлагә бер җавап: яңабаштан көч-куәтең һәм маңгай тирең белән таныт үзеңне. Танытырсың монда, тышта, дилбегә белән. Талигасына тикле... Нишләргә хәзер? Әлегә бер юл бар, хәер. Үзем теләп фронтка китәм...

Утырып гариза язды. Тиздән таң атачак. Атлар абзарына китәр вакыт якынлаша. Анда түгел, хәрби комиссариатка юл алды ул. Анда аны озак тотмадылар. Урамга чыкты. «Монда да минем хаҗәтем бер тиен икән!» Комиссарның әйткән сүзләре һаман колак төбендә яңгырый: «Син, иптәш Әхмәтҗанов, шахтаны яратмыйсың, эшеңне сөймисең икән, күмереңне яккан оборона заводларына, бергә эшләгән иптәшләреңнең йөзенә төкерәсең. Комсомол алай итми. Бар, кайт та күмер чыгар! Безнең монда да фронт». Шулай дип чыгардылар аны ишектән.

Якупның эче яна. «Эх, эти, эти! Янымда киңәшче булсаң иде. Хәзер улыңа нишләргә?!» — Якуп кызу-кызу атлап бүлмәсенә кайтты да чемоданга әйберләр тутыра башлады.

— Качарга! Китәргә моннан!

Шундук бераз җиңеләеп тә киткән кебек булды.

*
* *

Хәмзә эстакадада вагонеткалар эләктереп маташа иде.

— Сиңа, бәбчегем, бөркет баласы ияртеп килдем,— дигән тавышка сискәнеп китте. Степанов тавышы икән. Янында Андрей басып тора иде.

— Иптәш Ибраев, син бу егетне үз эшеңә өйрәт. Тәмам төшенеп житкәч, олы көрәк тоттырып забойга җибәрермен.

Шулай диде дә Степанов китеп тә барды.

«Бу егет белән эшләргә була, вагонетка забурить итсә, кешегә ялынып ятмабыз», — диде Хәмзә эченнән. Горурлыгы да ни тора: начальник аңа шушындый Алып батырдай егетне өйрәтергә кушсын әле!

— Коногон, әйдә, эшкә тотыныйк! — Шулай дип, Андрей житез генә бер вагонетканы этеп китерде дә икенчесенә ялгап та куйды.

— Минем кулдан дилбегәне тартып аласың түгелме? — Хәмзә аның өйрәтмичә дә эшли белүенә сөенеп куйды. «Моннан Якуп шикелле менә дигән забойщик чыгачак», дип уйлады. Атын тарттырып китеп тә барды. Әйләнеп килүенә, Андрей тагын бер состав әзерләп куйган иде. Шулай ярты көн үтте, әйбәт кенә эшләделәр, манма тиргә баттылар.

— Бүген күмер агыла гына,— диде Хәмзә. Куанычы йөзенә нур булып кунган иде.

Тора-бара Андрей составларны әзерләп торырга өлгерә алмый башлады.

— Әллә авырыйсыңмы, Андрюша?

Тегесе аңа ямьсез итеп карап куйды.

— Һәр нәрсәнең чиге бар. Туйдым! Гарык. Ул күмерне мин төямәдем һәм бүтән бу арбаларны этеп тә йөртмим.

Хәмзә гаҗәпләнә калды: ул да төями ич, ә куана-куана атын чаптырып кына йөртә. Забойщиклар да күмерне үзләре ясап җиде кат җир астына тыкмаган. Мин төямәдем, этеп тә йөртмим, имеш. Ничек булып чыга инде бу?! Андрейга аңлатмакчы булып:

— Әнә ул биек таулар нигә яралган дисең? Шахтер казып керсенгә, белдеңме? Шуннан күмер чыгарып ятсынга, ишетәсеңме? — диде.

— Мин ат түгел арбалар тартып йөрергә!.. Паровоз да...

— Шахтада вагонеткалар этеп йөрү иң җиңел эшләрдән санала.

— Җинел эш эчне пошыра минем. Эстакадада күмер арасыннан таш чүплэтеп үземнән бер көлделәр инде, монда тагын...

Андрей янәшә генә үтеп барган кәйлә һәм көрәкләр күтәргән забойщикларга сокланып карап торды. Авыр гына сулап куйды.

Менә шулар шикелле горурланып, «Мин шахтер!» дип әйтерлек эш эшләсәң иде!

Хәмзәнең кәефе бөтенләй кырылды, үзенең дә кәйлә күтәреп забойга йөгерәсе, һәммәсен гаҗәпкә калдырасы килә дә бит. Ярар, Акбүзем исән булса, без дә күрсәтербез әле, барысының да борыннарына чиртербез.

— Әйдә, дөлдөл, әйдә, бахбай! Күмер агыла бүген, су урынына ташый, — дип, атының ялыннан сыйпаштырды да вагонеткаларын дөбердәтеп китеп тә барды.

Кичкә, Степанов әйтмешли, «җиңү фондына» тагын бер эшелон күмер озатылды. Туплар залпын хәтерләтеп, шахтада икенче смена өчен забойларда күмер шартлатылды.

*
* *

Андрей, аякларын көч-хәл белән өстерәп, мунчага да кереп тормыйча, туп-туры өенә кайтты. Әнисе өйдә юк иде. Пычракка баткан киемнәрен салып идәнгә ыргытты, юынмый-нитми генә караватка сузылып ятты, күзләрен түшәмгә төбәде, бераздан үз-үзенә зарланырга керешә. Вагонетка этеп йөрүдән дә авыр эш юктыр, исән чакта тизрәк забойга эләгәсе иде. Анда, малай-шалай, кыз-кыркын янында, мин дә эшли алмаммыни? Тырышырмын. Ничек булса да монда коногон хезмәтчесе булып йөрисем юк...

Уйлары аның Донбасска алып кайтып китте. Рәхәт иде анда, оҗмахта яшәгән икән. Җаның ни тели аша, эч, киен. Туйганчы уйна, кайчан кайтып керәсең килә, шул чакта кайт, типтер, күнел ач, һичкем бер сүз әйтми, тиргәми. Бар иде рәхәт заманнар...

Сукрана-сукрана Настя кайтып керде.

— Чукынсын дөньясы! Башыңа төшсә башмакчы булырсың диләр, дөрес икән. Кесә ягы такырайгач, актык шәлемне кыстырып базарга киттем. Әйләнеп тә караучы юк. Нибары бер аксак абзый гына карады да, чыраен сытып, икенче килермен дип, адресны сорап китеп тә барды. Биллаһи менә, көнбагышның стаканы егерме биш тәнкә... Син дә ятасың урам себереп шул эстакадаңда. Колга буе гәүдәң белән ояла да белмисең. Җир асты гөрләтеп забойда эшләр чагың. Ипие дә бер кило, өстәмә паегы да эләгә.

— Шушы атнамны гына ат койрыгы борам да, котыла башым. Забойга китәм. Берәр нәрсә капкаларга иде, әни?

— Үзеңнең ипи нормаңны кичә үк суктың. Шул хәтле бәрәкәтсез икән ул норма белән ашау... Фил хәтле гәүдәңне кешеләр кебек солы төеп туендырыр хәлем юк. Базарда анысының да стаканы ун сум. Үз көнеңне үзең күрә башларга вакыт!

— Әни, элгәре болай сөйләшми иден ич! Минем карын ач.

— Түшәмгә төкереп ятма! Тор да, әнә, күмер алып кайт! Мичкә ягып җибәр! Су китер дә чәй кайнатып эч!

— Мин синең шикелле мунчада кергән-чыккан кешене генә күзәтеп ятмыйм, әни. Адәм күтәрә алмаслык вагонеткаларны рельска күтәреп куярга туры килә. Әни дим! Берәр нәрсә эмәллә инде! Бик арып кайттым бит бүген.

— Карточкаларыңны ал да ашханәгә элдерт! Кастрюль онытма, миңа да алып кайтырсың.

— Ни йөзем белән урам буенча савыт-саба күтәреп йөрим?.. Табаннарым уттай яна, җилкәләр кымырҗып сызлана. Әни дим!..

Ана урыныннан кузгалды: туйдырмый нишләсен, үз баласын әнисе дә кызганмаса, кем кызганыр. Савыт тотып ашханәгә китте, ә егет, татлы уйларына чумып, караватында ятып калды.

Әтисе музыка мәктәбенә хәтле җинел машина белән илтеп куя, алып кайта иде. Ашау кайгысы түгел, уку кайгысы да булмады. Өф-өф итеп кенә үстерделәр. Чирли-нитә күрмәсен дип, җылы киемнәргә генә төреп йөрттеләр. Үч иткәндәй, я тамагына шеш чыгар иде, я борыныннан агар иде. Ә хәзер шайтаным да ябышмый, берәр атнага врачлардан язу алып эшкә чыкмаска булыр иде, ичмаса...

— Тор, Андрюша, эшкә соңга каласың! — дигән тавышка ул сискәнеп уянды. Күзен ачса, каршында Марина басып тора иде.

— Я, яңа эшкә күнегеп буламы? — Ул шулай килгән саен сораша, ә Андрей иңбашларын гына җыера. Ә бу юлы зарланырга тотынды:

— Эш димәсәң хәтере калыр. Бала-чага уены шунда. Җыен малайшалай кулында кәйлә дә көрәк, ә миндә ат койрыгы... Коногон ялчысына әйләндерделәр. Тфу! Забойга китәм, тик забойга гына!

Марина куана: сөйгән егете алга ыргыла ич. Бераз борчыла да: сыгылып төшмәс микән?! Андрейның маңгаеннан үбеп алды да: «Эшкә барышым, кичен күрешербез», — дип чыгып китте.

«Шапырынуын шапырындым, ә забойда эшләргә кулымнан килерме? Көрәкне, кәйләне тотып та караган юк бит», дип уйлады Андрей, аннары икенче бер уй өстенлек алды: шахта тулы яшь кызлар, малайлар, алар да кәйлә тотканнар дисеңмени моңарчы? Сугыш чыкмаса, олылар әле дә тоттырмаслар иде. Ә хәзер, башларына төшкәч, көн саен эшелон-эшелон күмер озаталар, җир астын янгыратып көлешәләр, шаяралар...

Ул өстәлдәге кастрюльне ачып карады. Ашка охшаган, ләкин боз кебек суык. Җылытып торса, мичкә ягарга кирәк. Ягыйм дисәң, тыштан күмер алып керәсе. Карынын ач бүренекедәй булса, салкын килеш тә бик шәп шуа икән.

Чыгарга дип ишек тоткасына ябышкач, ишек шакыдылар. Йоклап яткан әнисе уянды. Бүлмәгә, култык таякларына таянып, солдат киемендә ят бер ир кеше килеп керде. Өчәүләшеп бер-берсенә караштылар. Аннары ят кеше Настяга карап елмайды һәм тегесе дә, нидер исенә төшергәндәй, көлемсерәп җавап кайтарды.

— Узыгыз, уз түрдән!..

Бу кешенең түшендә яраланып кайткан фронтовиклар йөртә торган тасмалар да бар, кулына ярыйсы гына зур капчык тоткан иде.

Андрей дәшмичә генә, бу кешегә карый-карый, акрын гына чыгып китте. Кем булыр бу? Нишләп әни янына килгән? Әллә эти яныннан кайтканмы? Алай дисәң, әни күптән әйтер иде. Кайчан танышып өлгергәннәр болар? Шушы сорауларга җавап эзли-эзли, ул нарядныйга юл алды.

* * *

Яшьлек! Дөньяда беркемгә дә кире әйләнеп кайтмый торган кадерле яшьлек! Бик рәхәт яки артык михнәтле узса да, бертигез сагындыра ул, олыгая барган саен искә төшә.

Менә Варя да больница палатасында бала чакларын исенә төшереп һәм бүгенге хәле турында уйланып ята. Куллары һәм башы бәйләүле. Колаклары ишетми. Бөтен гәүдәсе хәлсез. Әхмәтҗановның кан бирүе турында да әле бүген генә белде. Хәзер анда Яша каны да бар, димәк, алар туганнар булып чыга. Эш канда гына да түгел. Хезмәт лагерендагы Әхмәтҗан абзый Яшаның әтисе түгел иде микән? Шул шиген Яшага әйтсә? Әтиең түгел иде микән дип сораса? Ул да укытучы иде, күпләр-

не укырга-язарга өйрәтте. Варяны да. Хәзер анда түгелдер шул инде ул. Әгәр идарәгә хат язып, кайдалыгын белешсә?...

Варя бүген генә торып йөри башлады. Хәзер ул тәрәзә аша якты дөньяга карап куана, фаҗигадән соң исән калуына аптырый.

Аның әтисе тимер юлда стрелочник булып эшләгән. Кечкенә генә бер стансада торганнар алар. Атасы бар тапканын эчеп бетерә барган, атналар буе өйгә кайтмаган чаклары булган. Сеңелләре белән Варя аны эзләп табып култыклап алып кайта торган булган. Әнисе кешегә кер юып, ирен дә, балаларын да туйдырып торган. Ә аннары үзе бер яз көне чирләп дөнья куйган. Әтисе дә үлгәч исә, өч бала ятим кала. Олысы Варяга — ун яшь, кечесенә — биш. Аларга үзләренә көн күрә башларга туры килгән. Сеңелләренең күз яше Варяның бәгырьләрен кисә. Нишләсен, чара калмагач, ул базар прилавкалары алдында сату итүче вак нэпманчыларның сумсаларын, пешкән берәнгеләрен чәлдергәләргә тотына. Һәм... балалар колониясенә элгә. Көннәре, төннәре сеңелләрен сагынып үтә. Кайткач, аларны, күпме эзләсә дә, таба алмый. Дөрес, колониягә икенче кат китерелгәч, тәрбиячеләр ярдәмендә олы сеңелесен таба ул, ниһаять. Ләкин ул апасын танырга да, белергә дә теләми. Ә кече сеңелесенең язмышы бүгенгә тикле билгеле түгел. Колониядә Варя буяу эшләренә өйрәнде. Бик зур матур-матур йортлар салдылар, шул чакта ул үз эшен күреп беренче тапкыр чынчыннан куануның нәрсә икәнен белә башлады.

Аннары Ерак Көнчыгышка язылып китте, анда тимер юл салуда эшләде... Шахтага күчте... һәм менә шушы фаҗига килеп чыкты...

«И, юләр,— дип уйлый Варя,— ярый әле, ансат котылдың, гариплә-неп, гомерлеккә кеше кулында яшәр хәлгә калган булсаң? Үзең бер хәл, Яшаны тилмертәсең...»

Эх, шунысы үзәкне өзмәсен иде, ичмасам! Яша бит миңа әҗәл эзләргә кушмады. Хәзер аңа кем дип дәшәргә? Мине терелтү өчен канын биргән... Туганым дияргәдер. Шахтада ачуга тиеп йөрсә дә, бигрәк сөйкемле шул Яша. Варяның үзенең дә тимер юлда эшләгән чагында ярatып йөргән егете бар иде, Яша кай җире беләндер аны хәтерләтә: тынгысызлыгы белән, ахры. Бәхет дигән нәрсә бер күренмәгән кешегә гел күренми икән, Николаен икенче урынга күчерделәр дә, аралары өзелде. Кайларда йөри икән?..

Варя Якупны ярты көнгә хәтле көтте, ә ул килмәде дә килмәде.

Икенче көнне Варя иртүк тәрәзә катында басып тора иде инде. Күктә чалт иткән кояш балкый, урам тулы кеше, тракторлар, атлар йөреп тора. Әнә якында гына Беренче шахта идарәсе, анда Яшаның язмышын хәл итәләр. Инде менә кич тә житте, Яша һаман юк. Тышта әле караңгы булса да, Михайлов тәрәзәләрендә ут бар... Менә шунда йөгереп кенә барып керергә дә бөтенесен сөйләп бирергә...

Варя ничәмә тапкыр коридорның тынычлыгын тикшереп йөрде, күнеле һаман җилкенгәннән-җилкенә барды һәм ахырда тәвәккәлләде.

Аның җәймә белән одеялга төренгәнен, чатнап торган суыкта чыгып таярга ниятләвен бүлмәдәшләре яхшы сизенеп яттылар... Юк, тыңлыйм-мы соң ул хатыннарны, колакларына да элми. Һәм коридорда кеше-фәлән очрар дип тә уйламыйча, урамга атылды. Шундук аны томанлы салкын бөтереп алды, ә ул һаман урам буйлап Михайлов тәрәзәсендәге утка таба атлады...

* * *

Улы Андрей чыгып киткәч, Настя әлеге кешене җентекләбрәк карарга кереште: өстендә соры шинель, башында колакчын бүрек, аягында кирза итек. Битендә әле җыерчыклар да юк, сакал-мыегы шома итеп кырылган, коңгырт күзләре һаман өй эчен күзәтәләр.

— Кем кирәк сезгә? — дип кыюсыз гына сорады Настя.

Тегесе чатан-чотан түргә таба атлады, кулындагы капчыгын идәнгә куйды.

— Базарда шәл сатып йөри идегез, адресыгыз буенча шуны карарга дип килдем.

— Әйе, әйе, хәтерлим. Утырыгыз. Азык-төлеккә алыштырмакчы идем.

Ят кеше капчыгыннан берничә банка итле борчак, аш тәлинкәсе кадәр түгәрәк ипи чыгарып куйды.

— Мине Михаил дип йөртәләр. Ә сез? Настямы? Исемегез дә бик матур икән, җисеменә туры килә.

— Сез инде бигрәк. — Настя өстәлдәге банкаларга карашгыргалады. Аның өстендә ак якалы зәңгәр күлмәк, аягында биек үкчәле кара туфли. Коңгырт чәчен матурлап баш түбәсенә өеп куйган. Киеме дә, төсе-бите белән дә көзен сулырга өлгерми калган чәчәккә охшаган. Гәүдәгә дә бик килешле. Йөргәндә биеп кенә йөри.

— Әни карчыкка шәлең бик хуш килер. Ә үзеңә — җаның ни тели. Капчыкта һәм өстәлдә нәрсә бар, барысы да сиңа,— диде Михаил.

— Сез боларны кайдан аласыз бу хәтле?

— Йөргән аякка йон ияргә диләр бит! Безнең базарда мондагы кебек кытлык юк, кирәк нәрсәне табарга була. Кием-салымыңны гына кыстырып бар. — Михаил өстәлгә ярты литр аракы да чыгарып куйды. — Магарыч миннән, товар синнән.

Настя, мич артына ыргыткан төенчеген сүтеп, ак ефәк шәлен күрсәтте, чит-читләре чачаклы, бик нәфис күренә, карчыкларга бигрәк тә хуш килер.

Михаил ике стаканга аракы салды.

— Андый-мондый өлкә үзәгенә барырга туры килсә, туп-туры үзебезгә рәхим итәрсез, — дип, адресын сузды.

Әнисе белән икәү генә яшиләр икән. Хатыны былтыр ук вафат булган. Шуннан соң әле өйләнергә вакыт та, бикәч тә тапмаган, әмма эзли икән. Хәзер төрле якка командировкага җибәрәләр, ди. Шунда кирәк нәрсәләрен дә юллый икән. Кешегә ничек тә яшәргә кирәк ич кыен чакта. «Кирәк-ярагың булса, килгәләп йөр, табарга үзем булышырмын», ди.

Шушы сүзләре белән ул Настяның дөрләп кабынырга торган уйларына утлы күмер салды. Донбасста бал-майда йөзүен, иренең өрмәгән җиргә дә утыртмавын, эшләтмәвен, җаны ни теләсә, шуны киюен сөйләп бирде, хәзерге тормышыннан зарланды, стакан читеннән генә аракыны авыз итеп куйды.

— Әйдә, тагын берәрне өстик, Настенька, кайгыларны юып җибәрик! Безгә шатлык, дошманга үлем булсын!

Михаил, үткен пәкесен батырып, консерва банкасын ачарга керешге. Башта консерваны мактады, аннары Настяны мактарга кереште:

— Бөтен Донбасска таратасы матурлыкны ходай ялгызыңа биргән. Ирләр тормышын шушындый чибәрләр матурлый да инде! Әйдә, Зөһрә йолдызы!..

Шешә бушады. Телләр тәмам чишелде. Настя иренең үзенә ошамаган якларын саламнан бүрәнә кадәрле итеп күпертә-күпертә сөйләп китте. Янәсе, бер генә бала таптырган да бүтән теләмәгән. Имеш, ятлар артыннан чапкан. Теләсә, шахта начальнигы булып эшли алырлык белгеч, участок механигыннан ары уза алмаган. Күптән инде хәбәр-хәтере дә юк. Бәлки инде исән дә түгелдер... Донбасста бөтен йорт-җире талангандыр... Сугыш бетсә, кая кайтып керер?..

Күптән гудок гүли. Эшкә китәр вакыты узып бара. Янәшә генә дөнья күрерлек, көн итәрлек тап-таза ир заты бар лабаса, аны калдырып ничек китсен. Аннары, алыш-биреш тә бетмәгән.

— Мин синең сөттәй ак беләкләреңә гомер буе эш тоттырмас идем, күбәләккәй, — ди Михаил. — Ирең әллә исән, әллә юк. Син дә ялгыз, мин дә... Тормыш иптәшем булсаң иде, Настенька. Җавапны ашыктырмыйм, көтәргә риза.— Шулай дигәч, ул урыныннан торып шәлне капчыгына салды да өстәлгә бер төргәк акча, ит консервалары куйды, бер кисәк дуңгыз мае чыгарды, тагын әллә нәрсәләр тезде.

Ә Настя сөенеп бетә алмый: ун көнлек ризык ич болар!

— Белмим, белмим, Миша. Зиһенемне чуалттың, башым әйләнә... — дип кенә сөйләнде ул...

*
* *

Сызылып кына таң атып килгәндә, бер яшь егет, песи шикелле йомшак кына баса-баса, бүлмәсеннән коридорга чыкты да, куллары белән стенаны капшый-капшый, тышкы ишеккә таба атлады. Конвейер штреге сыман кысан-озын коридорда күзгә төртсәң күренмәслек караңгы, шомлы иде.

Шушы коточкыч җирдән үтеп китә алса, аның дүрт ягы кыйбла. Иң әһәмиятлесе: артыннан берәү дә, бармак төртеп: «Әнә, хәчтерүш Яша качып китеп бара», — дип кычкырып калмас. «Ни булса булыр — хурлыктан котылырга!.. Мин бирегә күмер чабарга килдем, куып чыгарырга түгел. Я уңам, я туңам. Мин киткәнгә карап кояш та тотылмас, җир дә тетрәмәс».

Якуп кинәт нәрсәгәдер абынды да дөбердәп идәнгә ауды. Чүп савыты булды, ахры, дөбер-шатыр тәгәрәп китте. Дежур хатын кисәк ут кабызды. Берничә малай, күзләрен угалап, бүлмә ишекләреннән башларын тыктылар. Якуп сукрана-сукрана торып басты. Иң элек күзенә стенадагы төрле-төрле плакатлар чалынды. Шуларның берсендәге дошман өстенә атакага ташланган яшь кенә совет солдатының штыгы Якупның да маңгаена кадалган шикелле тоелды. «Әһә, каптыңмы, дезертир?» — дия кебек иде солдат. Шундук икенче кәгазьгә күзе төште: «Җиңү көнен якынайту исәбенә, шахтер, син нинди өлеш кертәсең?» Стенада шундый плакатлар санаусыз икән. Көн саен кереп-чыгып йөрсә дә, йөрәгенә бу хәтле кадалганнары юк иде.

Якуп бүлмәсенә йөгереп кереп китте. Караватына авып, башын мендәр астына яшерде. Гүя аны ниндидер аждаһа куа, аннан, сабый баладай, менә шулай мендәр астына качып котылып булыр кебек иде.

Дөп-дөп иткән йөрәк тибешен тыңлап күпмедер яткач, каяндыр бик ерактан җыр тавышы ишетелгәндәй булды.

...Салкын чишмәләрдән су алдың,
Салкын чишмәләрдән су алдың да
Еракларга китеп югалдың.

Әнисенең җыры ич бу... Йөгерек хәтер еракларга очты. Менә авылда сабан туе гөрли. Җыр, гармун, кунаклар. Бәйге, уеннар. Якуп та көрәшә. Үз иптәшләреннән берәүгә дә бил бирми ул, каршына өлкәнрәк егетләр чыга башлагач кына егыла. Аннары Якупны җырларга чакыралар. Нәкъ әнә шул җырны, әнисенең яраткан җырын җырлый ул. Соңыннан, мәзәк такмак әйтеп, халыкны көлдереп тә ала.

Мин баһадир, миндә көч күп,
Миндә көчләр патшасы.
Курка миннән төлке, тычкан
Һәм куяннар барчасы.
Уйласам, мин бер шырпыны
Бер сызуда ут итәм.
Уйласам, мин мең чебенне
Бер сугуда юк итәм.

Шунда тамагына төер утыргандай була. Кешеләрне этә-төртә мәйданнан чыгып китә. Әнисе нигә күренми соң? Ялгызы гына өйдә моңаеп

утыра микәнни? Дөрес сизенгән икән бала күңеле. Якуп кайтканда, әнисе, чыннан да, ялгызы гына каба читенә утырып йон эрли, авыз читеннән генә шыңшып, үзенең әлеге «Салкын чишмә»сен көйли иде.

Нишләпләр ята икән хәзер әнисе? Әтисе кайларда икән?

Якуп кинәт сикереп торды. Коридорда очраган малайларның бирсенә дә күтәрелеп карамыйча, сәламнәрен дә алмыйча, юынып керде. Ашыгып чыгып китте...

Куенында күмер хәзинәсе яткан таныш тау артыннан кояш күтәрелеп килә иде. Җир өстенә сөттәй ак томан җәелгән. Ике адымнан да алда берни күренми. Мәрхәмәтсез суык Якупның борын очын, колак яфракларын чеметтереп алды. Аның башы һәм муены урын-җир җәймәсенә төрелгән, күзләре генә елтырап күренеп тора. Өстендә сырган бишмәт, бер кат брезент чалбар гына. Аякларында табаннары кубарга торган эш ботинкалары. Кулында брезент бияләйләр.

Кая бара Якуп? Башында нинди уй кайный? Сорасаң, ул моны үзе дә әйтеп бирә алмас иде.

Ат абзарына килеп җиткәч кенә, ул кинәт айнып киткәндәй булды.

Кыр казлары кебек тезелешеп, Ургыл буенча бахбайлар атлый. Боз өстендәге каты карда чана шыгырдап алга шуа. Ян-якта усак агачлары шарт-шорт итеп кала. Моннан ике ел чамасы элек бу төшләрдән бөтен иптәшләре белән, матур хыялларга чумып, иң алдан барган иде ул. Хәзер иң арттан гына тып-тын гына, агач складына атын куалый. Шәһәрдән ун-унбиш чакрымдагы урманда агач кисәләр. Шушында ук кул белән такта да ярыла. Менә шушы терәүлекләрне, такталарны шахта янына ташып тора ул. Урманны яңгыратып кычкыра-кычкыра поезд үтеп бара. Күмер эшелоны. Кул болгап кала аңа Якуп, сәлам әйтә олы калага. «А ну, малкай, кызурак атла! Анда иптәшләр күмер куа, ә мин сине куам». Терәүлекләр әрдәнәсе янына китереп атын туктатты. Бүтән атлылар төяп бетереп кузгала да башлаганнар инде.

*

* *

Кичен Якуп больницага Варя янына китте. Палатасына керәм дип кенә торганда, Варя үзе коридорга килеп чыкты.

— Яша!.. Син бит бу?! Ә мин сине көттем, бик көттем. Сине минем аркада җәзалыйлар, кичер мине, Яша! — диде ул, зәңгәр күзләре белән ялынып караган кебек.

— Минем сиңа үпкәләргә хакым да юк. Мин ятасы караватта син ятасың.— Якуп кесәсеннән шырпы тартмасы чыгарды да, иплэп кенә ачып, брошка алды, аны Варяның түшенә кадап куйды. — Туганым итеп алсаң, бик тә сөенер идем.

Варя башын аска иеп, аптырап, бик озак карап торды.

— Рәхмәт, Яша!.. Туганым. Үз гомеремдә миңа беренче тапкыр бүләк бирәләр. — Шулай диде дә, һич көтмәгәндә, башын Якупның җилкәсенә куеп, үксергә кереште.

— Нигә инде, Варя, күз яше? — Бүтән ни диярге дә белмәде Якуп.

Варя, бераз тынычлана төшкәч, кызу-кызу сөйләп китте:

— Моңарчы: «Варенька, давай, жир казы! Варенька, монда йөгер, тегене китер! Нигә моны болай иттең, тегене алай итмәдең?» дигәннән бүтәнне ишеткәнем юк иде минем. Ә бүләкне? Бәйрәмнәрдә төшләремдә генә күрә идем...

Ул беразга сүздән калды. Күзләрен зур ачып, бик сәерсенеп нидер тыңлап торды, аннары колакларын каплаган бәйләүне тарта-йолка тәрәзә янына юнәлде.

— Чү! Күк күкри. Яша, күк күкри!..

Бу күкрәүнең яңа шахта төзелешендә икәнен Якуп әйтеп тормады. Шартлау тавышын унбишкә тикле санадылар.

— Син ишетәсең, Варя, ишетәсең!

Икесенең дә йөзләрендә нур уйный, икесе дә бер кеше хакында авыз ачмакчылар, тик һаман шикләнәләр. Ахырда Якуп сорап куйды:

— Варя, син тимер юл салган җирдә татарлар бар идеме?

Варя бераз уйга калды, аннары тагын Якупка карап торды.

Әйе, бар иде Варяның моңа охшаган кешене күргәне. Олы, таза гәүдәле, кара чәчле, кара күзле сөйкемле бер агайны. Күңелгә кермәслек тә түгел иде шул. Ул чакларда укый-яза белмәүчеләр күп иде хатын-кызлар арасында. Менә шул агай, баракларга килеп, аларны укырга-язарга, хисапка өйрәтеп йөрде. «Ахмет абый» дип, кадерле кунак шикелле күтәреп ала торган булганнар аны хатыннар. Көндез Ахмет тимер юл түзелешендә мотовоз белән шпаллар, рельслар ташый, ә кичләрен Варяның да кулына карандаш тоттырып, язарга өйрәтә, авазлап-авазлап, иҗекләп-иҗекләп китап тыңлата...

— Кайда ул Ахмет абый хәзер, Варя? — Якуп сабырсызланып Варяның авызына текәлде.

— Безнең белән елга якын гына эшләде ул, аннары күренмәс булды. Әйтүләренчә, еракка, ниндидер заводка алганнар. Бар белгәнем шушы гына.

— Эх, Варя, беләсеңдер дигән идем...

Сүз шунда өзелде. Варя, Якупның кулында китап күреп:

— Яша, иртәгә миңа да китап китер әле, яме? — диде.

Якуп кулындагы китабын калдырды да, иртәгә тагын килерен әйтеп, саубуллашып чыгып китте. Баскычтан төшүенә, каршысына Зоя очрады, бераз күтәргә кушып, Варя янына кереп китте. Якуп күтә аны, бик теләп күтә: сорашасы сүзләр күп. Күмер чыгару йөкләмәсе көн дә үтәләме, рекордлар куярга җыенмыйлармы, кемгә тапшырмакчылар? Хәер, йөкләмә үтәлүне шахта маңгаенда янып торган кызыл йолдызга карап белә. Рекорд-мазар куючы булса, бөтен Ургыл шау-шу килер иде. Ә менә баш штректә кем эшли, лава кытлыгы һаман бармы, яңа шурфны казып бетерделәрме, су артмыймы, метан газы чыкмадымы? Боларын участокка кермичә яки кешедән сорашмыйча белер җир юк. Ә кереп карап йөрергә йөрәге җитми.

Менә алар урам буйлап баралар. Борын очлары да елтыраган күзләре генә ачык, башлары төрелгән. Кинәт-кинәт көчле җил китереп бәрә, атларга ирек бирми. Зоя кайтып җиткәнче бер генә сүз әйтте, анысы да забойлар турында түгел. «Ничаклы бугаз киерсәң дә, син үзебезнең егет идең, — ди. — Без синең килгәнеңне, белмәгәнне өйрәткәнеңне көтә идек».

Күккә ашардай булып утырган эстакада баганаларына бәрелеп, җил бүре кебек улый. Үз гәүдәсе белән каплап, Якуп Зоя апасын җилдән ышыклый. Аркаларын куеп һаман алга баралар. Җилне шулай җиңә-җиңә, Ухановлар йорты каршына кайтып җиттеләр.

— Караны, Яков, тәрәүлекләр җиткезеп тормасаң, колагыңны борырмын! Борыныңны салындырма,— дип, Зоя ишегалдына кереп тә китте.

## УНБЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

Хәмзә, көндәгечә, унике вагонеткасын тагып, Акбүзен баш штрек буйлап чаптыра. Бүген күңеле көр аның: юллар адәм рәтенә кертелде хәзер, яңа рельслар салынды, шпаллар алышынды. Тиздән электровозлар кайтачак. Эштән соң электровоз машинистлары курсына укырга йөри Хәмзә. Шулай да җаны нигәдер тынычсызлана аның, әллә ни булды аңа бу арада... Баш штректән узган саен, Оксана аның я чабуыннан тарта, я каскасын битенә хәтле төшереп куя. Кайчакта «крестьян, кавалерист» дип ирештерә-ирештерә, аркасына бармак башы хәтле

күмер кыйпылчыгы ата да караңгыга китеп югала. Ну, тотса бирер иде кирәген! Юк, аркасын авырттырганы өчен түгел, һич тә авыртмый. Йодрык хәтлесен атса да сүз әйтмәс. Тик, нигә алай итә ул? Ыргыткан икән, качмасын! Эзли аны Хәмзә, таба алмый. Әле анда, әле монда чырылдап көлгән тавышын гына ишетеп тора. Әнә, кошчык оясы — бу үрне төшеп, тегесенә менеп җиткәч кенә. Ул анда, насосныйда, мотористка булып эшли хәзер. Насосныйдан баш штрекка чыгып, нинди дә булса берәр шуклык кылырга терәү артына посып торадыр әле. Юк, нигәдер уты күренми бүген, үзе дә.

Вагонетка тәгәрмәчләре шыгырдап бер көйгә генә алга тәгәри, коногон җырлап ала:

> Инде мин күптән коногон,
> Ирештем теләкләргә.
> Кабынды ут, яна, дөрли,
> Ни булды йөрәкләргә?

Чү! Нәрсә бу?! Каршысына диңгез булып шахта суы җәелгән. Насоска нидер булган! Әллә мотористканың үзенәме? Әллә торбалар ярылып, бөтен су штрекка агып ятамы?!

Эстакадада йөкне калдырып, буш вагонеткалар белән кергәндә болай ук түгел иде әле, ә хәзер тезгә җитә язган. Су өстендә йомычка, такта кисәкләре, бүрәнә башлары йөзеп йөри. Суны ерып үтәргә җыенсаң, шул нәрсәләр тәгәрмәчләр астына эләгеп вагонеткаларны рельстан төшерүләре бар. Акбүз тез тиңентен су эченә керде дә шып туктады. Шпал башлары да калыккан бугай.

Бу ни хәл?! Шахтаны су баса ич! Нишләргә? Тышка хәзер узып китәрлек түгел. Десятникны, механикны эзләргә керешсәң, ничаклы вакыт үтәчәк.

— Мотористка! Оксана! Уханова! Эй, шахтерлар, шахтаны су баса! — дип кычкырды да Хәмзә, учларын җилпуч сыман итеп колакларына куеп тыңлап торды: җавап юк. Аптырагач, терәүләргә беркетелгән су торбаларына күмер кисәге белән суккалап, доңгылдатырга тотынды: бәлки берәрсе ишетер дә ярдәмгә килер. Әһә! Торбалар зыңгылдый, кемдер җавап кайтара. Бик ерактан тоныкы кына булып «Ярдәм итегез!» дигән тавыш та ишетелде. Оксана тавышы бу, су түккеч баздан. Таныш тавыш, йөрәк өздергеч тавыш.

Хәмзә атын калдырды да, чаптыр-чаптыр су ерып, насосныйга бара торган штрекка атлады, дөресрәге, йөзеп үк диярлек китте. Су салкыны җелекләргә үтеп керә, алга узу авырайганнан-авырая бара. Менә насос янына керә торган тәбәнәк штрек. «Әгәр дә алда су түшәмгә хәтле килеп җиткән булса! Ул чакта су астыннан бака шикелле уза алмам ич... Алга, тик алга! Анда күз күрер».

Хәзер актык чара — кычкырыр чамасы да юк, авызын ачуга ук су тулачак. «Тизрәк, тизрәк, коногон! Алга ыргыл да насосны эшләтә башла!» Келт итеп икенче уй килде башына: «Әгәр күптән су басып киткән булса?!» Былбылының да, үзенең дә әҗәле шушында икән! «Алга, тик алга! Әлегә тәндә җан бар. Син шахтер егет, комсомол, шахтаны коткарып калырга бурычлысың, булдыра да аласың». Су өстендә йөзгән бүрәнә кисәгенә атланды да, «на, бахбай!» дип, куллары белән ишә башлады. Бүрәнә башы катыга килеп терәлде. Кап-караңгы. Җитмәсә, җан ачысы белән кычкырган тавыш колак төбендә генә: «Коткарыгыз! Коткарыгыз!» Эх, шунысы үзәкне өзмәсен иде, ичмасам! Килә бит инде, коткарырга ашыга.

Электр яктысы күзләрне чагылдыра: килеп җиткән икән ич. Үрмәләп чоңгылдан чыкты да бер-ике адым югарырак күтәрелде. Каршында насос, аның тирә-ягында бик тирән баз-чокыр, бөтен су шушында җыела, моннан торбалар буйлап тышка түгелә. Су түккеч насосның биек нигездәге өрлекләргә куелганын Хәмзә яхшы белә. Ике адым гына си-

кирәсе... Калтыранган куллары үзеннән-үзе рубильникка үрелде. Бөтен көчен җыеп рубильникны югарыга таба этүгә, насоска җан керде, гөжелдәп эшли башлады. Монысы булды. Хәзер, кайда соң Оксана? Тавышы-тыны юк. Әллә аяклары таеп чоңгылга чумганмы? Шундук маңгаена тир бөрчекләре бәреп чыкты, арыганнары онытылды Хәмзәнең.

Әнә кайда икән: түшәм астына тактадан ясалган сәндерәгә менеп кунаклаган да балавыз сыгып утыра. Аяклары асылынган, бармак очлары суга тиеп тора.

— Син нәрсә, карга баласы кебек анда менеп кунакладың? Синең аркада бөтен шахтаны су баса язды бит! Эх, син!

Оксана һаман калтырана, ни дияргә дә белми. Үзенең гаепле икәнен тоя ул, җәзага тартачакларын да сизә. Бәлки, Яшаны очырганнары кебек, аны да өскә куып чыгарырлар. Әле генә су астында калу куркынычы бар иде, шушы коногон егет килеп коткармаса, тончыгып харап булыр иде. Бу бәладән соң кеше күзенә ничек күренерсең...

Хәмзә дә дерелди, тик ул өркүдән түгел, ә үзәкләренә үткән су салкыныннан. Бармакларын көзән җыера, тешләре тешкә тими, колаклары чыңлый, бөтен җиреннән шыбырдап су ага, тирә-ягы чайкала-әйләнә сыман тоела. Ә Оксана, ачуны китереп, үкси дә үкси.

— Җүләр! Үкермә! Ишетмисеңмени, гөрелдәп эшли насосың. Елама дим! Тукта!

— Гафу ит мине, Хәмзушка. Бүген тоташтан икенче сменага калуым. Нишләптер миңа алмаш кыз килмәде. Бераз гына моторны суытып алыйм дип туктатып торган арада йокыга киткәнмен. Күзләремне ачсам, бөтен штректә су.

Мотор һаман жылына, гөрли-гөрли су түктерә, торбалар күңелле генә зыңгылдап тора, «диңгез дә» азрак кайткан кебек. Бер-ике сәгатьтән, бәлки иртәрәк тә, бу баздан чыгып китәргә мөмкин булыр. Хәмзә жылынган мотор өстенә менеп атланды, аңа күкрәге белән ятты, кулларын, аякларын жылытмакчы булды, ләкин әле һаман эченә жылы керми иде.

— Миңа нинди җәза бирерләр икән? Комсомолдан кумаслармы? — ди Оксана пошынып. — Кусалар, син кул күтәрерсеңме?

Хәмзә аптырап калды: тәүлекләр буе йокламаска үзе түзәр идеме соң? Кыз башы белән япа-ялгызы, дөм-караңгы җир астында түзгән, бичара.

— Юк, күтәрмәс идем, гаделлек андый булмый, — диде Хәмзә кискен һәм җитди итеп.

Көтмәгәндә Оксана җан ачысы белән әйтеп куйды:

— Әни! Җен килә, җен! — Сәндерәсеннән сикереп төште дә Хәмзәгә елышты. Икесенең дә күзләре — шаптыр-шоптыр аларга таба килүче табак хәтле ике утлы шарда. Бөтен штрек быгыр-быгыр килә. Менә дулкыннар ярга ук килеп бәрелде, битләргә тамчылар чәчрәде...

— Әнкәем!.. — дип, Оксана Хәмзәнең муенына сарылганын үзе дә сизми калды. — Нәрсә бу?!

Шунда Акбүз, алгы аякларын ярга куеп, судан сикереп чыкты. Бөтен гәүдәсен калтыратып өстендәге суны койгач, хуҗасының кулын иснәргә кереште.

Хәмзә белән Оксана шаркылдап көлделәр.

— Рәхмәт, дустым, рәхмәт! Артымнан килгәнсең.

— Акыллы икән. Мал иясенә охшар, диләр, бик дөрес сүз.

Хәмзә атының сыртына сузылып ятты да караңгылыкка кереп чумды.

— Алмаш җибәрсеннәр миңа! — дип кычкырып калды Оксана.

Менә ул яңадан ялгызы. Идән астында күселәр кыштырдый. Шомлы төннән дә шомлырак кыз балага. Иптәшкә насос булмаса, тәүлекләр буе монда ятып акылыңнан язарсың. Күрәсең, алмаш җибәрергә кеше

булмагандыр, теге кыз авырып калгандыр. Утырма, кызый, утырма, сөялмә дә, беразга түзә күр, юкса, йоклап китәрсең! Әнә мотор көенә «Гопак»ны бие.

*

* *

Хәертдин, Хәмзә авырып яткан карават читенә утырган да, врач калдырып киткән даруны аның аркасына сөртә-сөртә, шыпырт кына сөйләнә:

— Әй, бала, бала. Болай булгач, шахтер чыга синнән, билләһи чыга. Терелерсең, терелми калмассың, шахтер сулырга тиеш түгел. Нигә дисәң, ул үз җылысын кешеләргә өләшә, ә кешеләр аны терелтә. Шахтерның бите шахтада кара булса да, намусы чиста, күңеле саф.

Хәмзә күзләрен ача, үзе һаман саташа: «Әти, әти! Килдеңмени? Нишләп моңарчы бер дә күренмәдең? Мин сине и көттем, и көттем. Бүтән китмә, яме...»

Хәертдин нишләргә белми, аны юаткандай итә, аннан да бигрәк, Хәмзәне юата-юата, үзе дә юана:

— Мин бу, улым, әтиең. Китмәм бүтән, китмәм, улым.

Хәмзә янадан күзләрен йома. Ә Хәертдин, офтанып, үзенекен тукый:

— Керфекләрең баш штректәй озын, гомерең генә кыска булмагае!.. — дип офтанып куя.

Әкрен генә Якуп килеп керде, урындыкка утырды, авыруның маңгаен тотып карагач кына Хәертдин белән исәнләште.

Хәертдин, сүзсез генә киенеп, эшкә китеп барды.

Шулай Хәертдин, Оксана һәм Якуп алмаш-тилмәш Хәмзә янында атна буе утырып чыктылар.

Беркөнне Хәмзә күзләрен ачса, караваты читендә Оксана утыра иде.

— Мин кайда? — дип, ул яткан җирен танымый торды. — Су бирегез, — дип акрын гына урыныннан торып утырды. Су эчеп, бераз аш шулпасы да капкач, авыруга хәл кергән кебек булды. Оксананың талчыккан йөзенә карап торды.

— Оксана, син бик йончыгансың, бар кайт, яме. Яша таза-саумы?

— Һаман агач ташый. Яңарак кына моннан китте. Мин югында синең янда ул утыра. Харитоныч төнге сменада.

Берәр көннән Хәмзә аякка басты.

Хәертдин абыйсына тәмам ияләште ул хәзер, аның тизрәк кайтып гармун уйный башлавын зарыгып көтеп ала. Ул бик матур итеп уйный да, сөйли дә белә. Кайчакларда чөйдә эленеп торган балалайкасын алып «Коногон»ны яки «Зимагур»ны сиптерә, җырлап туйгач, «Син игътибар итмә, шахтер икәнсең, шахтер бул!» — ди.

Хәмзә беркөнне иртән уянса, өйдә япа-ялгызы гына калган иде. Өй эче тулы кояш. Мичтән җылы бәреп тора. Аның күзе өстәлдәге альбомга төште. Моңарчы күргәне юк иде әле аның бу альбомны. Миңа карарга юри калдыргандыр дип, битләп-битләп актарырга тотынды. Беренчә биттән соң, мөлаем гына йөзле бер кыз рәсеменә туктала. Зур гына күзле, кыйгач кара кашлы, чәч толымнарын күкрәгенә асылындырып төшергән. Альбомның икенче битендә шушы кыз белән янәшә Хәертдин абыйсы басып тора. Үзе әйткәндәй, яшьнәп һәм күкрәп яшәгән чагы, арысландай көчле көннәре булса кирәк. Хәзерге шикелле кырыс күренми: нурлы йөз, ягымлы караш, елмайган авыз. Башка битләрдә дә шул кыз белән парлап төшкән фотолар очрый. Менә Хәертдин абыйсы үзе кебек шахтерлар арасында. Мондыйлар ике-өч урында очрый. Иң соңгы рәсеме үзенә җәлеп итә. Тимер юл буе. Вагон кырыенда теге матур хатын белән Хәертдин саубуллаша. Яннарында биш-алты яшьләрендәге бер малай тора.

«Хәзер кайда икән алар?» Хәмзә альбомын урынына куйды да өй эченә күз йөртеп чыкты. Моңарчы да бөтен әйберне күргәне бар иде

барын, әмма бу хәтле үк серле тоелганы юк иде. Йорт юан-юан карагай бүрәнәләреннән салынган. Идәндә һәм түшәм такталары арасында инә сыярлык та ярык тапмассың. Бер читтә — агач карават, янәшәсендә — ике кечкенә сандык. Бөтен әйбер үз урынында, һәммәсе чиста, ялтырап тора. Шкаф тулы китап. Русчасы да, татарчасы да, гарәп хәрефлесе дә бар. Шкаф өстендә — тальян гармун. Плитә өстендәге кастрюлдә — аш, чәйнектә — чәй. Өстәлдә — бер көнлек ипи. Ашны Оксана китереп киткәнен Хәмзә яхшы белә.

Урындык аркасына элеп, абыйсы ак күлмәк белән соры төстәге костюм калдырып киткән. Ул бу киемне өченче көн үк кияргә кушып киткән иде. Хәмзә, уңайсызланып, моңарчы кими йөрде. Хәзер киенеп алгач, көзге каршына килеп басты, килешле, ятышлы күренә. Шуннан соң китап алып укырга утырды.

Оксана керүгә, өйгә кояш өстәлгәндәй булды. Салкындыр, ахры, тышта, кызның керфекләренә тикле бәсләнгән.

— Гафу ит, Хәмзушка,— дип, пальтосын салып әлде дә чәй җылыта башлады.

— Мин сине гомер буе асрарга тиешмен, Оксана. Бәхетсезлек аркасында бәхет кошы тоттым, ахры.

— Сиңа көлке. Кичә җыелышта ялварганга күрә генә комсомолдан чыгармадылар.

— Сине чыгарсалар, дөреслектән бер чите кителеп төшәр иде.

— Ә син бигрәк күпне беләсең! Шахтада барыбыз да йоклап йөрсәк, нәрсә булып чыгар?

— Белмим, белмим. Синең урыныңда мин булсам да тәүлек буе йокысыз түзмәс идем.

— Барыбер юата алмадың. Беләсеңме, әни үзебезгә кайтырга куша, «бездә торсын», ди.

Хәмзә башын гына чайкады.

— Иптәшләрне сагынып беттем, палатага кайтам. Терелеп кенә җитим. Синең белән бер дә аерылып торасым килми хәзер, күрешеп йөрербез, яме?

Оксана, кызара төшеп, ияк какты.

— Беләсеңме, Оксана, сугыш беткәч, җыелышып безнең якларга кайтып килербез, яме? Әнигә син бик ошарсың. Хатыма күптән мактап яздым.

— Эх, белсәң иде! Минем ак күмәч белән кәҗә сөте ашыйсым килә.

— Сугыш беткәч, мин сиңа күгәрчен сөте дә табып китерермен. Парлап сигезенче класска йөрербез. Аннары шахта техникумына керербез. Аннан институтка... — Хәмзә авылда чакта Казан ветеринария техникумына керергә баргач, төнлә вокзалда кунып ятканда аягыннан галошларын салдырып китүләре, русча белмәгәнлектән, техникумга керә алмый кайтуы турында сөйләп алды.

— Эх, син, Казан ятиме! — Оксананың йөзе янадан җитди төс алды. — Минем монда бик зур шәһәр төзисем килә. Шушы мәңгелек тунлыкта гөрләп заводлар эшләсен, халкы шат яшәсен... Нигәдер минем бүген гел ашыйсым гына килә... Тәмле әйберләр генә. Донбасста чакта әни чия пилмәне пешерә иде, шуны сөт өстенә манып ашый идек. Эх, хәзер шул булса! Ярып пешергән бәрәңге булса да ярап куяр иде. Ә син авызыңны ерып утырма, яме!

— Юк, көлмим. Киләсе язда сезнең өй артындагы усакларны төплибез дә бәрәңге утыртабыз, кишер, суган чәчәбез, ярыймы?

— Бергәләп эшләрбез, яме? Син казырсың, мин утыртырмын, чүпләрен утармын, су сибәрмен.

Тәмам терелеп җиткәч, Хәмзә үзенең палаткасына күчеп китте.

*Ахыры бар*

## Роман Солнцев

### Ул чакта

Бала чактан
омтылабыз еракларга,
дөнья күрергә.
Диңгезләр өстеннән
уза юлларыбыз,
уза гомер дә.
Өлкәнәйгән маңгаебызга
диңгезләр рәсеме сызыла,
Тик ул чакта
күңелебездә
җир генә була...

### Язу машинасы янында

Утыз өч йодрык
кагалар бикле ишекне.
Кагалар бикле ишекне
утыз өч йодрык,
Кыйныйлар, кыйныйлар ишекне
утыз өч йодрык.
Уйлардан, тәмәке төтененнән
Баш ката,
арып йокыга китәм
туным өстенә егылып.

Төш күрәм:
Янымда ак ишек,
Әз генә ачык, куркыныч зур ишек,
имеш, эчтә — теге якта
чигәсе чаларган
Маяковский ята...

## Әнкәм әкияте

Имеш, төпсез серле күл булган.
Чуртан күле икән исеме.
Бик күпләрнең котын алган ул:
йоткан
бихисап кешене...
Кинәт күлнең төбе ачылган:
Су югалган,
кипкән.
Карасалар: төптә берни юк:
бары тик
ком гына икән...

РӨСТӘМ МИНГАЛИМОВ тәрҗемәләре.

●

Чык тамчысы кызыл төскә керә...
Шәфәкъ нуры бии офыкта.
Малайларның кырга ат куганы
Ишетелә кичке тынлыкта.

Торам ярда... Дөнья киң һәм серле...
Тып-тын инде авыл урамы.
Аргы ярда гүя сөт яңгыры —
Ай нурында каен урманы.

ГОСМАН САДӘ тәрҗемәсе.

## Альберт Мифтахетдинов

# ХАН-ГӘРӘЙНЕҢ СӘЕР КӨННӘРЕ

хикәя



Кырым татары егете Илдар Гәрәев төньякка акча эшләргә дип килгән иде.

Әти-әнисе аны гомерләре буена ата-аналарга гына хас чын ярату белән яратып яшәделәр.

Илдар тир түгеп эшләп тапкан акчаларына әти-әнисе өчен яңа йорт салып бирде, тик картлар бу өйдә озак яши алмадылар, үлеп киттеләр. Әҗәл капыл килде аларга, ике көн дигәндә бер-бер артлы җан бирделәр. Үлгәндә икесенең дә телендә Илдар исеме булды. Илдар аларны табутка салып күмде, аннары йорт-җирне сатты да, очраклы рәвештә генә күреп калган сабыр холыклы чибәр бер рус хатынына өйләнергә карар кылып, яңадан Чукоткага китеп барды.

Ләкин бу хатынның менә инде бишенче ел кияүдә икәнлеге, ике баласы барлыгы беленгәч, Илдарның тәмам сөмсере коелды...

Үкенү, көнләшү корты аның йөрәк итен кимерде, кешеләр арасында да үз-үзен кулга ала алмады Илдар, кайгысына сабышып йөри бирде.

— Нәрсә син тундра кисәве төсле кара көеп йөрисең әле, Хан-Гәрәй?— дип сорады аннан бер көнне баш бухгалтер Козлов.

Хан-Гәрәй дәшмәде. Һай, көнләшү корты, йөрәк итен кимермәсәнә шул кадәр!

Ләкин Хан-Гәрәйнең «мәхәббәт газаплары» икенче көнне ничектер юып ташлангандай юкка чыкты. Мондый чакта Илдар өчен иң шәп дәва — әйбәт эш икәнен яхшы белә иде Козлов һәм сүзне дә шуңа таба борды:

— Мейнываамга барырсың,— диде Илдарга,— балыкчыларга бригадир кирәк.

Бүген эшне Козлов бирә, чөнки ул председатель урынына калды.

— Кайчан? — дип сорады Илдар һәм башы белән тәрәзәгә таба ымлады. Ә тышта күз ачкысыз буран котыра иде.

— Иртәгә: бүген төнлә буран туктаячак.

Козлов төньякта күптән яши иде инде, ул көньяктан килгән кешеләрнең бу тирәләрдә өч көннән артык тормавын яхшы белә.

— Беренче нарта белән миңа бер капчык шәп балык җибәрерсең. Кыздырган балык ашамаганга йөз ел тула бугай инде.

— Анысы булыр,— диде Илдар,— ә кыздырган балык янына?

— Складтан сиңа да, егетләргә дә яздырып алдым.

— Җитәрлекме?

— Юк, әлегә аеруча салкын көннәр өчен ярты ящик кенә биреп торабыз.

Акча исе килгән җирдә Илдар җәһәннәмнең үзенә дә бара инде. Козлов моны бик яхшы белә, шуңа күрә Илдарга ышана, товарны да кызганмый,— бигрәк тә боз астыннан балык тотучыларга кирәк товарларны. Үз чиратында Илдар да беркемне дә кыерсытмас — үзен дә, егетләрне дә, Козловка да өлеш чыгарыр. Акча өчен дә, спирт өчен дә эш белән, аяк-буыннарның ару-талуы белән, буранлы төннәрдәге ялгызлык һәм сагыш белән түләрләр балыкчы егетләр. Баш бухгалтер боларның барысын да белә, шуңа күрә юмарт та ул бүген.

Илдарның алты эте бар. Авылда өй борынча йөреп тагын дүртне тапты. Аларын, чылбырга бәйләп, барысын ашатты да җыена башлады — иртәгә иртүк ерак юлга чыгасы.

Чукоткада гадәт шундый: әгәр сиңа «иртәгә» диләр икән, димәк, берсекөнгә барысы да әзер булачак. Гадәттә Чукотка кешеләре «кайчан?» дигән сорауга кинаясез-нисез: «Хәзер, хәзер, төштән соң ук»,— дип җавап бирәләр.

Шул гадәт буенча Илдар да бик ашыкмады, ләкин ашыкмавына бик үкенде.

— Менә нәрсә, Хан-Гәрәй,— диде аңа Козлов,— Күнче бригадасына кадәр бер кеше утыртып барырсың.

— Күнче янында ни калган аңа?

— Сиңа барыбер түгелмени? Илтәсе бар. Менә шул...

— Кеше төяп йөрисем килми әле.

— Хатын-кыз ул...

— Аһ, аллам! Хатын-кыз булгач бигрәк тә!.. Ничегрәк соң тәскәбиткә диюем?..

— Ансын үзең карарсың инде... Яңа кеше әле.

— Ни эш майтарып йөри?

— Кызыл ярангадан, укытучы.

— Соңрак илтеп булмыймы соң үзен?

— Белеп торасың ич, — дип авыр сулады Козлов,— вездеход сүтеп ташлаган көе ята, тракторны суга батырдык, вертолет чакырсаң, аяз көн көтеп ятасы бар, берничә тиен көмеш өчен җибәрмәүләре дә бик ихтимал, ә нарталарның барысы да тундрада... Кыскасы, бөтен өмет синдә. Ерак җир түгел, юл уңаенда калдырып китәрсең... Тфу, шайтан, ниемә дип кодалап торам соң әле мин сине, әйтерсең Хан-Гәрәй шуны да аңламый.

Козлов кырт кына борылды да, муеныннан эше бар кеше кебек, җәлт-җәлт атлап китеп тә барды.

Күп тә үтмәде, тиредән тегелгән кием-салымнар төргәге күтәреп, укытучы кыз да килеп җитте.

— Исәнмесез, миңа сезнең белән барырга дип әйттеләр.

— Дөрес әйткәннәр,— дип мыгырданды Илдар.

Икесе дә тынып калды.

Кызый көрсенеп куйды:

— Ә кайчан юлга чыгабыз?

— Мин иртәгә дип торам...

Кыз, Илдар өенең болдырына утырды да, тегенең нарта белән мәш килүен күзәтә башлады. Аның күзләрендә шул кадәр кызыксыну, самимилек, балаларга гына хас гөнаһсызлык бар иде,— моны күргәч, Илдар бик мавыгып башлаган эшен ташлап нартага утырырга һәм тәмәке кабызып җибәрергә мәҗбүр булды.

— Минем исемем — Илдар. Хан-Гәрәй дисәң дә ярый, монысы Козлов таккан исем. Ә сезне кем дип белик?

— Света... Светлана мин, Иванова.

— Тәк, менә нәрсә, Света Иванова, мин бер үзем генә булсам, сезгә кирәк җиргә, ягъни Күнче янына иртәгә үк барып җиткән булыр идем... — Илдар шунда ук «син»гә күчте: — Ә синең белән ике көндә барып җитүе дә шикле.

— Нигә?

— Чөнки кар йомшак, этләргә авыр булачак. Җитмәсә, юл уңаенда авыл да юк, юлда безгә ялгыз йорт кына очраячак. Без бүген анда барып җитә алмыйбыз, соңга калдык, ә синең әле палаткада бер мәртәбә дә кунып караганың юктыр?..

— Ю-ук... — дип сузып куйды Светлана.

— Әллә тундрада да беренче мәртәбәме?

— Беренче. Беркайчан да булганым юк. Күпме хыялланып...

— Нигә?

— Нәрсә — нигә?

Илдарның ачуы чыга башлады:

— Нигә хыялландың дим?

— Белми-и-им... — дип сузды Светлана тагын.

Илдар авыр сулап куйды.

— Иртәгә иртәрәк кил. Таңда кузгалырга кирәк. Ә бүгенгә яңа туныңны киеп кара,— таманмы. Киеп карамадыңмы әле?.. Юк?.. Менә сиңа мә, үзең тундрага чыгам дисең. Ә киемеңнең берәр җирен төзәтәсе, сүтеп тегәсе урыны булса? Давай, тире эченә керергә өйрән... Күнеккәнне ярата ул тире... Э-э-эх...

Илдар тагын бер тапкыр көрсенде дә өенә кереп китте. Чәй куйгач, бер көйрәтеп җибәрде. «Ниемә дип шундыйларны тундрага җибәрәләрдер?!— дип уйлады ул. — Җан көеге булырга гына ярыйлар, адәм көлкеләре».

Тәмам ачуы чыгып йокларга ятты, йоклап китә алмыйча озак азапланды, ә Светаның юлдаш булуына күңелендә ни сөенеч, ни көенеч юк иде. Нишлисең инде, илтергә кирәк икән, илтергә, Күнче янында калдырырга да бетте-китте. Әйдә, бездән булсын яхшылык, тундрадан кире сыпыртканда юлы уң булсын.

Иртән иртүк, әле кояш салкын чакта ук кузгалдылар. Илдарның инде Козловка ачуы басылды — юлаучы зыянлы күренми.

Озын итәкле өр-яңа тун кигән кызый шөкәтсез аю баласына охшап калган иде. Кызның бу кыяфәте Илдарга кызык булып тоелды, шул ук вакытта ул тунның башлыгы алыштырылганын, башлыкның киндерә бавы урынына ефәк бау тагылганын да күрмичә калмады.

«Монысы юкка,— дип уйлады Илдар,— ефәк бауның төене тиз чишелә».

Этләр әйбәт кенә бара.

Эт ул кеше кәефен сизә белә. Күршеләрдән алган теге дүрт эт тә, бу җигүдә чит булуларына да карамастан, тыныч кына теркелди бирәләр. Илдар этләре аларны борчымый, Илдар да аларга кычкырмый, тынгысызламый. Ул кояшка битен куйды да Светланага запас кара күзлекләрен сузды. Гомумән, Илдарның кәефе әйбәт. «Гаҗәпкә каршы,

юлаучы юньле кеше булып чыкты, берни дә сорашмый»,— дип уйлады эчтән генә.

Илдар һәр вакыт аз сүзлелекне, тынлыкны ярата, юлда өч тиенгә ярамаган сүз сөйләп тинтерәткән кешеләрне җене сөйми аның. Шушы тып-тын карларны, тыныч кына юрткан этләрне күзәтеп, җылы мартның нечкә моңын тыңлап барудан да ләззәтлерәк нәрсә бармы икән дөньяда?!.

Илдар этләрне туктатты.

— Чәй эчәбезме?— дип сорады ул.

— Эчә-ә-бе-е-з,— дип сузды Светлана.

Кыз малахай бүреген салып ташлады. Һәм кинәт Илдар кызның шактый ягымлы, хәтта чибәр, кояш нурлары төшкән кар шикелле очкынланып торган күзләренең, шат йөзенең, озын сары чәчләренең бик тә матур икәнлеген күреп алды. «Бу чәчләрдән, мөгаен, кар һәм кояш исе киләдер»,— дип уйлады Илдар.

Кызый бер уч кар йомарлап Илдарга ыргытты. Тегесе көлеп җибәрде. Кар Илдарның колагы яныннан гына үтеп китте дә бер эткә барып тиде. Ә этнең моңа бер дә исе китмәде — салмак кына борылып карады да нарта буена сузылып ятты. Аның танавы һәм күзләре мөлаем, ягымлы иде. Этләр дә, кешеләр кебек, яз шатлыгы белән шатлана беләләр.

Көн кичкә авышкач, нарта юл буендагы ялгыз йорт янына килеп җитте.

— Шушында кунарбыз,— диде Илдар. — Арымадыңмы?

Кыз баш какты.

Илдар аңа урын-җир рәтләде, мичкә ягып җибәрде, шәмнәрне кабызды, чәй куйды. Света тире капчык эченә кереп ятты. Илдар аның баш астына тун салды, тегесе, рәхмәт йөзеннән, ягымлы итеп елмаеп куйды.

— Арыдыңмы, Света?

— Бераз гына баш авыртып тора... Чәй эчкәч, узар әле.

— Әйе... юл шактый ерак шул...

Илдар этләрне ашатырга чыгып китте.

Башта ул аларны туарды, аннары иң алдан баручы ике эттән башкаларын бәйләп куйды. Эт саен берәр кисәк ит ташлады. Шуннан соң бераз уйланып торды да, кулын селтәп, тагын берәр кисәк нерпа мае кисеп бирде. Этләр, һәр вакыттагыча, ашар алдыннан чинашып алдылар.

Илдар бәйләмәгән этләрнең берсен өйгә алып керде. Эт ишектән керүгә түргә узмады, бусага буена гына сузылып ятты.

Чәй кайнап чыкты. Илдар иелеп Светлананың йөзенә карады. Кыз йоклый иде инде. Илдар чәйнекне читкәрәк алып куйды, аның урынына утка котелок утыртып кичке аш әзерли башлады.

Ул табак-савытны шалтыратмыйча, тавышланмыйча гына эшләп йөрде: кешене беркайчан да юкка уятырга ярамый, ач килеш йоклап китсә дә...

Илдар тамак ялгап алды, термоска яңа чәй салды, уянып ашап алмасмы дип, Светлананың баш астын рәтләгән булды, ләкин кыз инде тирән йокыга талган иде. Илдар көрсенеп куйды, бер генә шәм калдырып, бүтәннәрен өреп сүндерде, бер почмакка барып тире капчыгын җәйде, ләкин капчык эченә кермәде, өстенә генә менеп ятты. Өй инде шактый җылынып җиткән иде. Илдар уйга чумды. Менә хәзер ул йоклап китәчәк, матур төшләр күрәчәк. Бүген ул эт булып арыды, ә Вутильхинның муенчагын рәтлисе бар, бөтенләй чәйнәп бетергән — яшь

шул әле, җигүгә күнекмәгән. Иртәгә иртәрәк торырга кирәк, кояш салкын чакта юлга... Ә кызый болай ярыйсы гына... тик бер генә җитешсезлеге бар — артык чибәр, тундрага төс түгел... һәм чәче дә мондагыча түгел... ул чәчтән, мөгаен, кар һәм кояш исе киләдер...

Илдар торды да Светлана янына килде, аның таралып төшкән чәчен рәтләп куйды, иреннәре белән тияр-тимәс кенә кызның бит очына кагылды һәм кинәт елмаеп куйды — юл шактый арытса да, яшьлек үзенекен итә шул.

Светлана тын гына йоклый бирде.

Илдар борылып үз урынына китте. Йоклар алдыннан тартылган сигарет — иң татлысы! Соңгы сигарет белән күңелгә тынгылык яки иң вәсвәсәле уйлар килә. Соңгы сигарет күп нәрсәгә төшендерә... «Гаҗәп,— дип уйлый Илдар,— бу кызның миңа мөнәсәбәте мине һич кенә дә кызыксындырмый. Мине үземнең аңа мөнәсәбәтем ныграк кызыксындыра. Гаҗәп...»

Көлешә-көлешә, иртәнге ашны ашадылар. Юлга кузгалгач, Илдар оялып кына кызга тундрада озак барачакларын, шулай булгач, әгәр Светлананың андый-мондый йомышы булса, оялып тормыйча әйтергә һәм Илдарга нартаны туктатып читкә карап торырга кушарга тиешлеген аңлатты. Боларны аңлатканда ул оялуыннан кып-кызыл булды, ләкин тегесе:

— Ярар, ярар, Хан-Гәрәй, ярар, аның ни ояты булсын,— дип кырт кисте.

Кызның бу кыен хәлдән Илдардан алдарак чыгуы егетне тәмам тынычландырды.

— Тагам![1] — дип кычкырды ул этләргә һәм чиелдый-чиелдый зарланып барган Вутильхинга берне сыдырып алды. Нарта дәррәү алга омтылды.

Көнче туплавына алар төнлә генә килеп җиттеләр. Ләкин монда аларны буш консерв савытлары, учак урыннары гына каршы алды. Тирә-яктагы кар өстен болан һәм кеше эзләре чуарлап бетергән иде. Илдар учак урынындагы көлне һәм болан тизәкләрен тотып карады да Светланага:

— Алар кичә генә кузгалып киткәннәр,— диде.

— Ә хәзер нишлибез инде?

— Этләр арыды... Кунарга туры килә. Иртәгә куа чыгарбыз.

Илдар нартадан кирәк-яракларны бушата башлады.

— Алар язгы туплауга киткәннәр. Моннан ике көнлек юл. Ә син бер дә кайгырма, без аларны куып җитәрбез... Әйдә, миңа палатка куярга булыш.

Агач терәкләр юк иде, алар урынына Илдар карабинын һәм мылтыгын утыртып куйды... Мылтык аңа кыр тавыклары атарга кирәк, ә карабин... Янында карабин булуы һәр вакыт ярап тора. Палатка итәгенең бер ягын нартага бәйләделәр, ә икенче ягына учак әйләнәсенә тезелгән ташларны бастырып куйдылар. Шулай итеп ике урынлы кеч-кенә генә палатка корылды.

Аннары Илдар этләрне ашата башлады, ә Светланага учак тергезергә кушты. Света ботак-сатак җыеп килде, ярты кап шырпы яндырып бетерде, ләкин учак кабынмады. Илдар аңа шәм төбе бирде, ничек итеп тундрада учак кабызырга икәнен өйрәтте.

Егет палатка идәненә нарта төбендәге болан тиресен җәйде, аннан тире капчыкларны алып керде һәм Светланага палатка эченә урнашырга кушты, әгәр теләсә чәйне дә монда гына алып керергә булды.

---

[1] Этләрне кызурак барырга өнди торган сүз.

Светлана каршы килмәде.

Ике сәгать тә үтмәгәндер, буран күтәрелде. Ул капыл гына башланып китте, ләкин палатка эчендә рәхәт иде — тире капчыклар җылы, кул астында гына кайнар чәй белән термос, тагын ни кирәк. Палатка эче гаять җайлы, Светланага рәхәт, Илдарга сәер иде. Ул күңелендәниләр барлыгын аңларга тырышып карады. Ләкин уйларының очын-очка ялгый алмады. Ул һаман саен көрсенде, тәмәке тартты.

Элек Илдар гомере буе үзен һәм эти-әнисе исән чакта аларны гына кайгырта иде. Ул үз шәхесенә бик нык иялэшкән, үз-үзен яхшы беләм дип уйлый иде. Ләкин аның күңеленә бернинди рөхсәтсез-нисез менә бу кызый кереп килә бит. Илдар кинәт шуны аңлап алды: бүгенге мәшәкатьләр аңа бер рәхәт кенә, менә бу хатын-кызга җылымы яки салкынмы булуы, аның ачмы яки тукмы булуы, ул бүген төшләр күрәчәкме һәм нинди төшләр күрәчәге Илдар өчен һич кенә дә барыбер түгел иде...

Илдар ике көн буе куган этләргә азык бетте, аннары алты кыр тавыгын ун эткә бүлеп бирергә туры килде. Дөресрәге, биш кыр тавыгын бүлде ул, чөнки алтынчысын Светлана белән бүлешеп ашадылар. Ниһаять, бишенче көнне алар Күнчене куып җиттеләр. Күнче кадерле кунаклар килүгә бик шатланды — ул көнне көтүчеләр бәйрәм ясадылар...

Ләкин бәйрәм алдыннан әле шактый сәер хәлләр булып алды.

Күнчегә килеп җиткәч, Илдар Светлананың талчыккан, сулган йөзенә карады да:

«Аһ, аллам,— дип уйлады,— соң бит ул бер атна буе чишенмичә тире капчык эчендә йоклаган кеше. Ни уйлап йөри бу минем баш тартмасы! Әлбәттә, кызый авырый. Ахмак, дивана!» — дип ачуланды ул үзен.

Илдар Күнче белән пышылдашып кына сөйләшеп алды, карчыклар тирмәгә олы бер казан асып ут ягып җибәрделәр, казанга боз һәм кар тутырдылар. Светлана талчыккан кыяфәттә учак янында утыра бирде.

Су җылынды. Бөтенесе дә тирмәдән чыгып киттеләр.

Илдар ишекне ябып, таш белән терәтеп куйды, учак янына иске болан тиресе ташлады да Светланага кырыс кына:

— Чишен! — диде.

Кыз берни дә аңламыйча, күзләрен челт-челт йомгалап, аңа текәлде.

— Чишен,— дип кабатлады Илдар. — Монда юынырга салкын түгел, мин сиңа булышырмын.

— Юк, юк... — Светлана куркып тирмә почмагына сеңде,— юк!

— Аһ, аллам,— дип көрсенде Илдар. — Мин синең белән сүз көрәштерергә килмәдем монда. Һәм синең сылу гәүдәң дә кирәкми миңа. Мин арыдым, йокым килә. Ләкин син тундрада чакта мине тыңларга тиеш булырсың. Хәзер карт Күнче кереп чишендергәнне телисеңдер бит? Шунысы да бар: мин юынганда син миңа булышырга тиеш булырсың. Башка баш! Мин җәмәгать эше тәртибендә бер эш тә эшләмим,— дип ялганлады Хан-Гәрәй.

...Кружкалар бик кечкенә иде, Илдар кызны зур алюмин табак белән коендырды. Светлана чүгәләп утырган, болан тиресе юеш һәм җылы, кызның аякларына җылы пар бөркеп тора. Караңгы тирмәдә учак күмерләре генә җемелдәшә.

Илдар Светлананың эчке киемнәрен җыеп алды да учак өстенә элеп куйды, ә кызга зур сөлге тоттырды. Светлана сөлгегә төренде. Илдар капчыгыннан үзенең җылы эчке киемнәрен алып кызга бирде, тизрәк киенергә кушты.

Светлана киенгәч, Илдар аны сәкегә утыртты, янына керосин лампасы кабызып куйды, тарак, көзге һәм кызның сумкасындагы башка кирәк-яракны алып биргәч, тирмәдән чыгып китте. Ир кеше беркайчан да хатын-кызның ничек итеп яңадан үз гүзәллегенә кайтуын карап торырга тиеш түгел.

Чәй эчкәч, йокларга әзерләнделәр.

Илдар Светлананың үзе белән тагын кемнеңдер арасында ятуын теләмәде, аңа иң кырыйга ятарга кушты. Үзе Светлана белән Күнче арасына ятты, ә Күнченең теге ягына кечкенә малае, малайның теге ягына анадан тума чишенеп ташлаган карт — Күнченең әтисе урнашты. Карт, оялып, өстенә тире ябынды.

Ике карчык башка урынга яттылар, өсләрендә җылы киемнәр булганга алар туңмыйлар иде. Җитмәсә, иртән иртүк торып учак тергезәселәре һәм иртәнге чәй әзерлиселәре дә бар.

Биш кеше яткан кечкенә сәкедә озакламый эссе дә була башлады.

— Башны чыгарып ятсаң әйбәтрәк. Ә баш астына мендәр урынына малахай бүрек сал,— дип пышылдады Илдар Светланага. Һәм моны ничек эшләргә икәнен күрсәтеп тә бирде.

Илдар тәмәке көйрәтеп җибәрде. Светлана караңгы тирмәдә Илдарның тәмәке утлары җемелдәвен күзәтеп ятты. Аннары песи кебек йомарланды да тынып калды. Ә Хан-Гәрәй тарта да тарта иде.

Бераздан Светлана як-ягына әйләнгәли башлады — күнегелмәгән урында җайсыз иде аңа. Шуннан соң ул Илдарның колагына: «Тыныч йокы!» — дип пышылдады һәм егетнең колак очыннан гына үбеп алды. Аннары ул малахай бүрекнең яртысына Илдарның башын салды. Бу — аларның беренче уртак мендәрләре иде. Светлана Илдарның таза беләгенә башын куйды да егетнең тыгыз тәненә сыенып йоклап та китте.

Кызның коп-коры сары чәчләре Илдарның беләге өстендә таралып ята. Егет ул чәчләрне битенә каплады. Бу чәчтән хәзер чыннан да кар һәм кояш исе, тагын бераз гына учак төтене исе дә килә иде.

«Кызык, ул бүген нинди төш күрер икән?»— дип уйлады Илдар.

Русчадан ГӘРӘЙ РӘХИМ тәрҗемәсе.

## Рөстәм Кутуй

●

Мамык оча! Мамык оча!
Дөнья — җиңел, ап-ак!
Кыз баланың чәч үргечен
алган аклык каплап.

Дөньяда аклык кына,
юк төрмәләр, чират...
Җир йөзендә сугыш барын
оныткан ди ир-ат.

Шәһәр өстенә, ис китеп,
туктап карый халык.
Аклык сарып, пакьлек сарып
оча мамык, мамык!

...Юк тол калган солдаткалар,
төтен, дары исе.
Юк йозак-бик! Һәркемгә
ачык бөтен ишек.

Әнием шат. Күңеле — күктә!
Яшьлегенә кайткан.
Сукырның күзе ачылган,
кояшны тәүге күргәндәй,
зәңгәр күккә баккан.

Ятимлек юк. Барыбыз тигез.
Әтиебез өйдә.
Кара пичәтле язу юк,
Шинель генә чөйдә...

Оча мамык! Оча мамык!
Аклык — күктә, юлда.
Бу дөньяда кирәк кайчак
матур алдану да!

Оча мамык! Оча мамык...

Шат чагымда елый алмыйм,
Сагышлы чакта көлмим...
Башкалар күк булдыралмыйм,
Күрәсең, уйный белмим.

Уйда — бер, эштә — бүтәнчә
дөньямны коралмадым.
Бар булганны мул чәчсәм дә,
көз — буш булды амбарым.

Әмма биегәйде күгем,
чүп-чардан ерагайдым.
Дөнья йөзе ачыла төште.
Үзем дә шул... чалардым.

Р. ФӘЙЗУЛЛИН тәрҗемәләре.

# ЯҢГЫР ШАВЫ

*Әниемә багышлыйм*



Менә... безне каршы алучы да булмады,— диде әни.

— Бәлки алар вагонны ялгыштырганнардыр.

— Алай булуы да бар.

Вокзал шау-гөр килә, килүче-китүче халык ишекләрдән ташкындай агылып тора. Йөк ташучылар арбалары белән бер-берсенә бәреләләр, гадәтләренчә, ачуланып кычкыралар. Беркемнең дә бездә эше юк, икебезне дә почмакка китереп кыстылар, аннары тагын үзләре белән ияртеп алып чыктылар. Һәм соңга таба әнием бөтенләй югалып калды: менә-менә хәле бетәр дә чемодан өстенә утырыр төсле иде. Ул бер мизгелдә картаеп та киткән кебек булды. Халык арасына килеп кергәч кечерәеп калды, иңбашлары салынып төште. Тамчыга охшаган колак алкалары калтыранып куйды.

— Киттек. Ни дә булса уйларга кирәк. Монда торып булмый бит инде,— дидем мин.

Аннары кулга чемоданны алдым дә гәүдәм белән әнине ышыкладым. Әгәр берәрсе катырак бәрелсә, әни бөтенләй хәлсезләнер, яулыгы иңбашына шуып төшәр, һәм барысы да әниемнең чал чәчен күрерләр дип уйладым мин.

Поезд вокзалга килеп җитәр алдыннан әни, тешләренә чәч каптырмаларын кыскан килеш, купедагы көзге каршында озак кына басып торганнан соң:

— Яулыгымны кысыбрак бәйләрмен. Шулай итсәм, чал чәчләремне берәү дә күрмәс,— дигән иде.

Моңа кадәр анның картлыктан оялганын күргәнем юк иде. Яулыгын башына бәйләгәннән соң, ул тәрәзә янына утырып, шактый вакыт сүзсез торды. Бик авыр, серле тынлык иде бу. Әйтерсең әни, миңа күренергә теләмичә, шул тынлыкка кереп яшеренде.

— И аллам, кая бара бу халык!..

— Син кабаланма,— дидем мин, канатларым белән саклагандай, кулларымны анның өстенә күтәреп. — Атла, әни. Әнә теге мәйданга чыккач ял итәрбез. Мин тәмәке тартып алырмын. Атла инде, күп калмады бит.

Минем ирләрчә каты тавышым халык шау-шуы эчендә бөтенләй көчсезләнеп калды, тик шулай да әни кайбер сүзләрне ишетә иде. Мин, уңга да, сулга да борылып, елмая-елмая бертуктаусыз гафу үтендем, ләкин моңа игътибар итүче дә булмады. Чемоданнар һаман саен кулларымны аска тартты. Мин булдыра алган кадәр әнине сакларга тырыштым, битемнән аккан тир күлмәк якасын юешләп бетерде. Күз алдымда бары тик әнинең юка яулыгы гына күренә. Калган бар нәрсә яңгыр яуганда юеш тәрәзә аша күренгән сыман иде.

Ниһаять, без кечкенә генә мәйданга килеп чыктык. Чемоданнарны стена буена куеп, алар өстенә әнине утырттым. Тыгынлыктан котылуыбызга сөенеп, бер-беребезгә карап куйдык. Әни яулыгын чишеп миңа сузды.

— Бөтенләй тиргә баткансың. Мә, битеңне сөрт. Тәмәке тартып ал,— диде.

— Барысы да җайланыр. Кабаланма гына. Ашыгыр җиребез юк,— дидем мин.

— Әле байтак юл үтәсе бар бит.

— Барып җитәрбез,— дидем мин.

— Чәчәкләр бөтенләй сулып бетте. Суын да алыштырган идек, югыйсә: барыбер шиңделәр.

— Ике көн үтте бит. Кыр чәчәкләре...

Башларын салындырган ромашкалар әниемнең тезләре өстендә ята иде.

Әниемнең чәчләрен җил тузгыта. Йөзе дә яктырыбрак китте. Әнием елмаеп куйды, һәм ике җыерчыгы бите буйлап аска, муенына таба сузылып төште. Ул вокзал шау-шуыннан арынгач тынычланган кебек булды.

— Яңгыр гына ява күрмәсен инде,— диде әни. — Беләсеңме, монда яңгырлар бик еш була бит, бездәге шикелле түгел. Әтиең язган иде. Аннары юллар яхшы дип язган иде. Ява-нитә калса, узып киткәнен күтәрбез. Мин анның хатларын тагын бер кат укып чыктым.

— Казаннан киткән чакта ничек койды!.. — дип куйдым мин.

— Хәрефләрне эре итеп яза иде ул,— диде әни.

— Плащларны хәзер үк алып куйык. Бер авырлыгы да юк бит анның.

— Энҗе килгән иде, хатларны анның белән укыдык. Нигә яратмыйсыңдыр син аны, аңламыйм. Елап та алды хәтта. Син каядыр чыгып киттең, ә без анның белән бик озак укып утырдык.

— Тәмәке тарта ул,— дидем мин.

— Аңа тартса да ярый, ул артистка. Бер ялгызы яши, шул ялгызлыктан тарта инде... Мин дә сугыш вакытында «Казбек» тарттым. Операциядән соң кабинетка керәм дә яшереп тартам. Энҗе апаң чибәр иде, аннан бераз көнләшә дә идем. Хәзер онытылды инде. Көнләшмим...

Әтинең онытып калдырган куен дәфтәрендә берничә сүз бар: «Энҗе сөйкемлем, аерылабыз. Озата барма...» дигән. Әти бу кәгазьне иясенә тапшырмаган. Онытакан. Бәлки шулай кирәк булгандыр.

— Хатын-кыз тартканны яратмыйм. Сугыш вакытында... — аны-сы башка эш,— дидем мин.

— Аның да...

Әни сүзен әйтеп бетермәде. Күк буйлап таралган болыт җәймәсе кара-кучкыл төстәге яңгырны үзенә җыя иде кебек. Өй түбәләре тонык кына ялтырый иде.

— Ә син полякча белмисеңме? Билет белешерлек кенә булса да. Кайсы кассада саталар икән. Аларча сорашырга кирәк бит.

Әни минем полякча сөйләшә алуыма ышанмый, гадәтенчә, мине һаман да кечкенә малайга саный һәм шуңа күрә бары тик үзенә генә исәп тота иде. Әнә, тезләренә таянып, инде нишләргә? дигәндәй, тын калды. Ян-яктан җил искәнгә, мин әнине гәүдәм белән ышыкладым. Аңа карагач, күз алдыма ап-ачык булып Россиядәге бер станция вокзалы килеп басты. Шундагы көтелмәгән бер хәлдән соң, ни өчендер, дөнья кинәт гаҗәеп буш һәм кайгы баскан кебек тоелды, хәтта бугазым кысылып куйды. Әйтерсең менә хәзер әни, каршыма килеп баскан да дымлы күзләрен миңа төбәп, тотлыга-тотлыга әйтә: «Аңла улым, сугыш бит, аңла,— ди. — Ела инде, аз гына булса да ела. Шулай итсәң, бәлкем поездга билет бирерләр...» — ди. Ул минем муеныма мамык шәлен урый, ә мин уратмаска тырышам: фонарь утларыдай, каршымда әнием күзләре чайкала. «Ела инде, нәнием. Ни авырлыгы бар аның сиңа? Ела, инде зинһар өчен», ди. Минем күңелем болгана башлады, баш очымда, шөпшә өередәй, меңләгән тавыш чыңлый, алар бернинди кызганусыз-нисез мине чагалар һәм күз алдымда саргылт түгәрәкләр хасил була. Мин соңгы чиккә җитеп сусадым, кычкырасым килә башлады, ләкин суыктан, ачлыктан, җилкәләренә капчыклар аскан коточкыч кешеләрдән, винтовкалы хәрбиләрдән куркып, тын тордым. Һәм кычкырмый калдым. Идәннән күтәрелгән әшәке ис борыннарга бәреп керә иде. Әни шунда: «И аллам, үлә бит!» — диде дә башымны күкрәгенә кысты, һәм мин төпсез бер упкынга төшеп киткәндәй булдым.

Менә инде хәзер, ничә еллар үткәннән соң, шушы чит шәһәрдә, шау-шу, ыгы-зыгы эчендә кечерәеп калган әниемнең зәгыйфь тавышын ишеттем. Халыкны аралап чыгарга хәленнән килмәсен күргәч, ул авыр сулап куйды. Һәм шул вакыт мин аңа сирәк, хәтта бик сирәк «әни» дип эндәшкәнемне искә төшердем.

— Хәл алдыңмы?— дип сорадым әнидән.

— Әйе. Минем арганым да юк әле, болай каушап кына калдым. Яулыкны бәйләп тормам инде. Бик тирлисең син, тиреңне сөртерсең. Үзебезгә кайткач, рентгенга барып килербез... Болай булгач, килеп җиттек инде.

— Килеп җиттек,— дидем мин дәртлерәк тавыш белән. — Югалып калмадык.

— Гел егет булып җиттең бит,— диде әни. — Сине тапкач, әтиең ялан аяк йөгереп килеп җиткән иде. Малай туса иде дип бик көткән иде...

— Сумканы тот. Чәчәкләрне кәгазьгә төр,— дидем мин.

— Борчылма. Тик менә бераз шиңгәннәр. Җае шулай туры килде бит...

— Барыбер болын исе килә алардан.

— Болын исе,— диде әни. — Сиңа ике чемодан белән авыр түгелме?

— Алга уз, югыйсә, тагын китереп кысарлар. Тизрәк буш урынга утыр. Уйлап торма. Аптыраган синең белән. Әйдә, кузгалдык.

Ул, аз гына алга таба иелә төшеп, җиргә катырак, ныграк басарга тырыша-тырыша, вак адымнар белән атлап китте. Чәчләре костюм

якасына төшеп таралды. Аннары, артка борылып, баш кагып куйды. Мине нәрсәдер сорады дип уйлады, ахрысы. Ишек пыяласында аның шәүләсе чагылып китте. Әни йодрыклары белән ишекне этүгә, без төтен тулган биек залга килеп чыктык.

Кешеләр, тәмәке тарта-тарта, ашый-ашый, билет кассасы белән сыра буфеты арасында йөриләр. Шушы ыгы-зыгы өстендә, бөтенләй башка дөнья авазыдай булып, репродукторның «пш-ш»лап, «дз-з»лап торган коры тавышы яңгырый. Радио кешеләргә ниндидер күрсәтмәләр бирә, нәрсәдер искәртә, ә алар аны бөтенләй ишетмиләр, я ишетмәгәнгә салышалар иде. Вокзалда һәр вакыт шулай: анда һәркем бары тик үзе турында гына уйлый.

— Шушында утырып тор. Мин хәзер белешеп килəм,— дидем энигә.

— Берүзем генәме? Ә чемоданнарны урласалар?

— Башта сиңа мороженое алам.

— Акылдан яздыңмы әллә? Тапкансың кирәк нәрсә... Мороженое...

Ләкин мин сатучы янына килеп бер бармакны күрсәткән идем инде. Ул, аңлагандай, башын селкеде. Учымда злоталар чыңлады.

— Менә,— дидем мин, әнине шаккатырып.

— Моңа кадәр башыңа килгәне юк иде. Һе... мороженое.

— Моңа кадәр... — дидем мин.

— Чирләгән вакытта балаларны «терелгәч, үзеңә мороженое алып бирермен» дип алдыйлар.

— Ашый тор. Мин монда гына булырмын,— дидем мин.

— Тик озак йөри күрмә. Күз алларым томаланып тора. Җитмәсә, менә мороженое... Берүземә генә күп бу, әллә инде йөз ел ашаганым юк иде. Кирәк бит, ә. Бөтенесенең авызында тәмәке, ә мин мороженое ашыйм. Йөгер,— диде әни.

Ул, үзе дә сизмәстән, күзләрен каядыр төбәде, кулларын чемодан өстенә куйды да нидер көтеп, сагаеп, һәр авазга колак салып, тын калды. Чал чәчләреннән төшкән яктылык аның йөзен тагын да аграк күрсәтә иде.

Касса тәрәзәсеннән, кабыгы эчендәге әкәм-төкәмнеке кебек, билет сатучы кызның башы күренде. Мин, кулларымны болгый-болгый, ашыгып сөйләргә тотындым, ә ул кыска чәчләрен сыпырып куйды.

— Аңлыйсызмы, Згеж. Варшава—Згеж поезды... Ике билет. Әнием белән мин. Булышыгыз инде. Пани... Бигрәк сөйкемле кеше сез. Варшава—Згеж. Сез аңлыйсыз бит, әйеме?

Кассир кыз башын чайкады да утыргычына чумып көлеп җибәрде. Шул кадәр тырышып сөйләвем кызык тоелды, ахрысы. Мин тагын аңлатырга тотындым, ләкин ул көлүеннән туктамады. Үзем күз кырыем белән генә әнине күзәтәм. Ул, мороженое тотып, мине көтеп утыра иде.

Яныма мәһабәт кыяфәтле, чиста йөзле бер кеше килеп басты.

— Сез русмы?

— Әйе,— дидем мин.

— Мин кассирга аңлатырмын... Кабатламагыз, барысын да ишетеп тордым. Добже, добже...

— Дзенькую, пан,— дидем мин.

— Нинди пан булыйм, рус мин,— диде ул, кулларын җәеп. — Әниегезме ул?

— Әйе,— дидем.

Һәм шул вакыт әнинең ашыга-ашыга ниндидер хәрәкәтләр ясавын күрдем. Кәкре каенга терәп калдыралар бит инде, и аллам, чемоданнарны кая куйым, дип борчылып, коты очып калган иде ул.

Мин әнигә карап:

— Эш пеште,— дидем.

Һәм шатланганымны сиздермәскә тырышып елмаеп куйдым. Билгеле, ул берни дә ишетмәде, ләкин минем ишарәне күреп, бераз тынычланды бугай. Жакет төймәләрен ычкындырып, зәңгәр блузкасының якасын рәтләп куйды. Мороженое ашаганнан соң, сулышы да бераз иркенәеп китте бугай... Бигрәк кызык итеп әйтте инде: — Әллә йөз ел ашаганым юк,— диде. Ә аңа мороженое алу минем башыма да килгәне булмады. Күптән, инде бик күптән без аның белән бер кечкенә генә кафеда утырган идек. Кафе стеналары кызыл таш белән бизәлгән, өстәлләре дә көзгедәй ялтырап тора. Әни шул көнне ике мороженое алган иде. Күптән, бик күптән булган хәл инде ул... Әлеге таныш булмаган кеше мине култыклап алды да мина кыры аша үткәндәй сак кына атлап касса янына алып килде. Бала чактан бирле борынымны кытыклый торган яңа карандаш исеме, әллә вареньесы исеме—нииндидер тәмле ис аңкып тора иде аннан.

— Россиядәнме?— дип сорады ул.

— Россиядән.

— Озаккамы монда?

— Юк. Берничә көнгә генә,— дидем мин.

— Саратов гимназиясендә укыдым мин. Ә аннары... әтиләр шулай кирәк тапты. Ә гомер үтте дә китте. Синнән сорап тормый икән ул.

— Аңлыйм,— дидем мин. — Саратовта хәзер эссе, тузан.

— Юньләп хәтерләмим дә инде ул шәһәрне. Ничектер, бөтенесе буталып бетте. Ә менә яңгыр шавын ишетәм. Без киткәндә, шаулап яңгыр явып калды. Су өстендә яңгыр тавышы аерата каты ишетелә бит. Идел һәм яңгыр. Ә сез ничек монда килеп чыгасы иттегез?

— Шырпыгыз юкмы? Минем беткән икән,— дидем.

— Ярый, ярый,— дип кабалана башлады ул. — Хәзер билет алам. Тартмыйм мин.

Ул кечкенә тәрәзә янына җитез генә үтеп керде. Һәм мин шунда кисәк кенә уйлап куйдым: «Әгәр дә ул минем әтием булса. Юк, юк, ул түгел...» Мин аның һәр хәрәкәтен, иелеп сөйләшүен, ничек итеп акча санавын карап тордым. Терсәк янына эленгән аксыл тәстәге таягы, сорау билгесенә охшап, селкенеп тора иде. Мин әнигә кул селтәдем, җавап итеп ул да ым какты.

— Менә билетлар. Егерме минуттан поезд китә. Әниең белән танышасым килә минем. Мөмкиндер бит?— диде ул.

— Рәхмәт сезгә... әлбәттә, мөмкин,— дидем мин.

Без әйләнеп килгәч, әни җиңел сулап куйды һәм таныш булмаган кешегә үзенең кечкенә кулын сузды. Әлеге кеше иелеп әнинең кулын үбеп алды. Әни кинәт җыелып, бөрешеп калды.

— Нигә инде?— диде әни.

— Пани Польшада беренче тапкыр... Улыгыз бик шәп сезнең. Мин көчемнән килгәнчә булыштым. Гафу итегез, миңа вакыт... Ни әйтсәң дә бер җир өстендә яшәүче туганнар бит без.

— Рәхмәт. Бик зур рәхмәт... — диде әни каушап.

— Соңга калам,— диде ул. — Беләсезме, һәр вакыт соңга калам мин. Рус кешесен күрүемә шатмын. Бик шатмын.

— Мин татар,— диде әни ашыгып.

— Күзләрегез якты сезнең... Барыбер бик шатмын.

Һәм ул тагын әнинең кулын үпте. Аннары, ераклашкан саен әкренләп гәүдәсен турайта-турайта, таягына нәзакәтле итеп таяна-таяна, китеп барды. Бәлки яңгыр эзләп киткәндер ул...

— Каушап беттем,— диде әни.

— Синең яшьтәшең ул. Саратовтан. Эмигрант, ахрысы. Әйдә, платформага чыгабыз.

«Ул Саратовтагы яңгыр шавын ишетә,— дип уйладым мин. — Менә инде ничә ел... Йоклаганда да ишетә. Яңгырга чыланганын күреп, ләззәт таба. Россия күге астында зонтиксыз-нисез басып тора. Яңгыр шавы. Йокыдан уянгач, күңелсез буладыр аңа. Хәер, бәлки миңа гына шулай тоеладыр. Ул бит гади генә итеп: «Идел һәм яңгыр»,— диде. Һәм шул вакыт күзләрендә әллә нинди чиксез бер бушлык чагылып китте. Бушлык читендә, комлы яр буенда бер малай утыра. Аякларына юеш балчык ябышкан аның. Ә еракта-еракта, җир читендә тавышсыз пароход узып бара. Кеше гомере...»

Әни:

— Ни уйлыйсың син?— диде дә миңа күтәрелеп карады.

— Аның турында.

— Поезд китәр вакыт җитә. Катлаулы нәрсәләр күп ул дөньяда. Уйланыр чакларың да булыр.

— Мороженое тәмле булдымы?

— Бездә яхшырак,— диде әни.

Поездда ул тын гына утырды. Алма ашый-ашый, тирә-ягындагы кешеләрне күзләде. Әнинең йөзе — әле генә шатлык кичергәндәй, якты һәм уйчан. Өйдә дә шундый чаклары була иде — өстәл артына утыра да башын иеп, керфек тә какмыйча, күзләрен бер ноктага текәп онытылып тора. Шундый вакытларда нәрсә күрә икән ул? Бервакыт без аның белән көймәдә йөрдек. Иртәнге вакытлар иде. Тик торганда әни кулларын җәеп сорап куйды: «Нишләп син бер дә көймәдә йөртмисең мине? Көне нинди бит, улым, көне. Ишкәкләр ал. Мин койрыкта утырырга яратам»,— диде. Билләһи, күзләренең ничек кабынганын күрсәгез иде, ул бөтенләй җиңеләеп китте — туфлиләрен кулына тотып, яулыгын иң өстенә ташлады да тар сукмак буйлап, бер таштан икенче ташка сикерә-сикерә баргандай, йөгереп китте. Эзләре аермачык булып ком өстендә ятып калды. Аның кәефен һич тә бозасым килми иде. Шуңа бернәрсәне дә күрмәгәнгә салыштым, әйтерсең барысы да: аның шатлыгы да, кояшлы көн дә, аяк астында кыштырдаган җылы ком да һәр вакыт булган һәм моннан соң да булачак. Көймә койрыгына утырганда әни чайкалып китте. «Башым әйләнде»,— диде дә кинәт тынып калды. Суда чагылган кояш нуры аның куллары, йөзе буйлап йөгереп үтте. Ул, менә хәзер тын торган кебек сүзсез калды, аның күңелен миңа таныш булмаган хис—яктылык хисе биләгән иде.

Вагон каты селкетә. Борынгы дилижанска охшаган состав иде бу. Күрше купеда шау-гөр килеп кәрт сугалар. Каршыда бер карчык тыныч кына оек бәйләп утыра. Әни уйга чумган. Кулындагы алмасын да оныткан. Алма төшеп китәр дә әни сискәнеп куяр төсле. Күзләремне аның кулыннан ала алмыйм.

Станциядә безне чәчәкләр тотып каршы алдылар. Кечкенә генә кызыл гөләпләр... Алардан иртәнге бакча исе аңкып тора иде әле. Әни, чәчәкләрне күкрәгенә кысып, таныш булмаган телдә сөйләшүче кешене башын селки-селки тыңлап тора. Башын шул кадәр тырышып селки иде ул, хәтта, моны күреп, кешеләр елмаеша ук башладылар. Җитез генә бер яшь егет фотоаппаратын туктаусыз чыртлата. Без кечкенә шәһәрнең тыныч перронында басып торабыз. Көн болытлы. Рельслар, тоныкялтырап, чиксез киңлеккә — яңгыр якынлашып килгән якка таба сузылганнар. Каршылаучылар төркеме эчендә калган әни, кызыл гөләпләр белән кыр чәчәкләрен бергә кушып, зур бәйләм ясады. Аның чәчләре яшь каен тузы кебек ап-ак иде.

— Хәзер юлдан соң бераз ял итеп алырсыз. Барысы да әзер,— диделәр әнигә.

— Юк, юк... Арымадык без. Шулай бит, улым?

— Арымадык без, аз гына да арымадык,— дидем мин дә. Әни дә:

— Хәзер үк барыйк... Ял итеп тормыйк... Ял итәргә өлгерербез әле,— диде.

Бөтен җире ялтырап торган, утыргычларына йомшак келәм җәелгән машинага утырганда ул никтер каушап калды: яңакларына алсулык йөгерде. Аннары тезләрен җыеп, гәүдәсен туры тотып, утыргычның аргы башына утырды. Машина, җил этеп җибәргәндәй, салмак кына кузгалып китте.

Әни күзләренә төшкән чәчен бер читкә сыпырып куйды.

— Бик ерак түгел. Бездә бар нәрсә дә якын,— диделәр аңа.

— Әйе, әйе...

— Өч урам үтәсе.

— Өч урам,— дип кабатлады әни. Якын. Ә яңгыр һаман килеп җитми.

Ләкин күз алдымда яңгыр күрә башлаган идем инде мин... Яңгыр шавы. Бәлки машина тигез юл буйлап бер дә селкетмичә, кыштырдап торган яфракларга бәрелә-бәрелә, тын гына барганга шулай тоелгандыр ул.

— Ачуланмассыңмы, мин бер тапкыр гына. Кеше күрмәгәндә,— диде әни.

Ул, күзләрен йомып, иреннәренә тидерер-тидермәс итеп, сигарет капты. Аннары утыргыч аркасына сөялде. Зәңгәрсу төтен югарыга күтәрелде.

— Искә төште,— диде әни. — Монда юллар яхшы дип язган иде шул. Әй, әйткән идем бугай инде. Ни булды соң миңа...

Мин, әнинең терсәген тотып, бармакларым белән әкрен генә беләгеннән кыстым.

— Менә килеп тә җиттек, әни, — дидем. — Тәрәзәгә кара. Күрәсеңме, нинди кызык йорт. Балалар рәсемендәге кебек. Киоск янында туктыйк, су эчәрсең. Эчәсең килмиме?! Ә-әнә анда...

— Анда койма. Анда койма башлана,— диде әни ашыгып һәм йөзен минем битемә якын китерде. — Әйт әле аларга. Әйт инде. Башта без үзебез генә. Үзебез генә...

Ул чәчәкләрне кулына алды да утыргычтан аз гына күтәрелә төште. Машинаны балалар урап алды.

...Әни буш аллея буйлап, тавышсыз-тынсыз, минем алдан бара. Кабер ташына таба атлый иде...

Русчадан РАЗИЛ ВӘЛИЕВ тәрҗемәсе.

## Клара Булатова

### Ана җыры

Бакча гөле микән бу?
Таң былбылы микән бу?
Бер елмайса, көн җылына,
Кояш улы микән бу?

«Үчти-үчти» дигәндә,
«Үчтеки»ләп сөйгәндә,
Күгәрченнәр көнләшерлек
Минем улым көлгәндә.

Дөньядагы зиннәтләрнең
Иң затлысы шушыдыр.
Табындагы нигъмәтләрнең
Иң татлысы шушыдыр,
Һавадагы йолдызларның
Иң яктысы шушыдыр.

Ал тирәктер, гөл тирәктер,
Чәчәкләрдер, гөлләрдер,
Сандугачтыр, карлыгачтыр...
Тагын әллә кемнәрдер.

Алма болай ал булмас,
Хөрмә болай бал булмас.
Шушы матур малаемның
Илдә тиңе табылмас.

Алышмам бер гөлгә дә,
Алыштырмам унга да.
Шушыннан да матурлары
Булмас инде дөньяда.

«Үчти-үчти» дигәндә,
«Үчтеки»ләп сөйгәндә,
Кояш үзе таң каладыр
Минем улым көлгәндә.

Эрбетемнең чикләвеге,
Өрегемнең җимеше.
Буй үстергән ил-җиремә
Бүләгемдер бу кеше.

## Каеннар яшь иде

Каеннар яшь иде,
алар да яшь иде
Авылдан хушлашып киткәндә.
Кайтмаска киткәнне
белделәр микәнни?
Каеннар сыкранды үткәндә.

Озата бардылар,
кул болгап калдылар,
«Онытма!»
«Исән кайт!»
«Җиңеп кайт!»
Җилләрдә җилфердәп
тибрәлде каеннар.
Кызларның иңрәвен кабатлап.

Каеннар яшь иде,
алар да яшь иде...
Каеннар картайган, саргайган.
Ап-ак бәс түгел дә,
сыкылар күренә,
Чигәләр сизелеп агарган.

Яз арты яз үтә,
яз арты яз үтә.
Җәй җитә, җәй китә аннары.
Бу күңел ни көтә?
Бу күңел ник көтә?
Кайтмаска киткән бит ярлары.

Каеннар саргайган,
чигәләр агарган.
Күңелләр, әйтерсең, япь-яшьләр.
Һаман да сөяләр,
һаман да көтәләр
Ярлары кайтмаган кәләшләр.

## Июнь ае

Арыш кыры яшькелт-сары,
Серкәләрнең очкан чагы.
Ашыкма әле, үтмә әле.
Чуак чагым — июнь ае.

Юл буйлары яшел тары,
Саргаерга иртә әле.
Чуак чагым — июнь ае.
Ашыкма әле, китмә әле.

Кыр читендә кояш байый,
Кыр өстендә ашлык тәме.
Чуак чагым — июнь ае,
Китмә әле, ашыкма әле!

•

Әни, сиңа ак чәчләрем күрсәтмим мин,
Алар өчен оят миңа синең алда:
Тик үземнең шәхси борчу-уемнан тыш
Ни кагылган, ни чагыла соң аларда?

Синекендә —
буыныңа туры килгән
Чор өлеше никадәре,
ил өлеше...
Й газизем!
син бит сугыш елларының
Сынауларын сынмый үткән әни кеше.

И әнием!
Изге күңел, олы җаным,
Гомереңдә күп күргәнсең,
кичергәнсең...
Безне кеше иткәнсең дә,
инде хәзер
Безнең иркә балаларны үстергәнсең.

Кайтып керсәм, өем җылы,
бүлмәм нурлы,
Табыным тулы, ашым тәмле,
син булганга.
Чыгып китсәм —
эшем уңыш,
күңелем тыныч,
Юлым якты, көнем ямьле,
син булганга.

Бу тормышны бәяләргә өйрәттең син,
Акыл бирдең гади генә, тыйнак кына.

Әни, сиңа ак чәчләрем күрсәтмим мин,
Алар өчен синең алда оят миңа...

▪▪▪▪▪▪▪▪▪▪▪▪

## Шамил Маннапов

### Китә чын Кеше дөньядан...

*Әти истәлегенә*

Кем уйлап чыгарган сүздер:
Ризыгы беткән, имеш.
Бакчы, калды бакчалары
Шау чәчәк аткан килеш.

Ризыгы беткән чаклары
Күп булган, беләм, ансы.
Походларда йөргән чакта
Ни күрми солдат башы.

Ризыгы булмаганда да
Үлемне җиңә белгән,
Ризыгы беткәнгә актык
Кисәген бүлеп биргән.

Кеше турында кем әйтә;
Ризыгы беткән, диеп?!
Аңа соңгы сулышыңны
Бирергә иде бүлеп.

Бирергә иде бүлеп тә,
Барыбер алмас иде.
Кеше өлешенә кермәс,
Ул гадел солдат иде.

Актык сыныгын бирсә дә,
Сатмады ул намусын.
Саклады иле алдында
Иманын-ышанычын.

Кем уйлап чыгарган сүздер:
Ризыгы беткән, имеш.
Бакчы, калды бакчалары
Шау чәчәк аткан килеш.

Ризыгын бетереп түгел,
Башкаларга калдырып
Китә чын Кеше дөньядан,
Яшәргә сагындырып...

## Төрбә

Елизавета патша Чиләбедә табылган көмеш рудасыннан 90 потлы гробница-төрбә койдырган. Төрбә Ленинград Эрмитажында саклана.

Мәңгегә килмәгән патшалар:
Көннәре санаулы, —
Тойганнар.
Рәсәйдә табылган металлдан
Иң әүвәл төрбәләр койганнар.
Юк, алар үзләре коймаган,
Камчылап халыкны эшләткән,
Хаклык дип талпынса кешеләр,
Тупларга, төрбәгә күрсәткән...
Бәлки ул үз данын үлемнән
Калмакчы булгандыр йолып та.
Я ирек теләгән Рәсәйне
Салмакчы булгандыр гробка.
Мәңгегә килгәннәр эшчеләр,
Патшадан акыллы булганнар,
Тиранны күмгәннәр төрбәсез...
Үзләре ясаган төрбәне
Кадерләп музейга куйганнар.

## Егор Уткин

### Кырда куксел томан...

Нинди бөркү
Бу көн.
Кырда күксел төтен.
Җилләр,
Кошлар,
Иген —
Тып-тын.
Бу чакларда
Орлык
Авырая, тула...
Тургай булып
Тургай
Җырдан туктап тора,
Җырдан туктап тора,
Тынлык саклый сыман...
Кырда күксел томан,
Кырда күксел томан...

●

Булган, диләр,
Гаҗәп шундый заман,
Юк, әкият түгел, чын бар да...
Ык суларын иңләп
Аккош йөзгән,
Камышларда бала чыгарган.

Без — кешеләр,
Табигатькә хуҗа,
Хуҗа гынамы соң,
Түрә без...
Ык буйлары тып-тын.
Аккошларны
Киноларда гына күрәбез.

## Идрис Туктар

### Җөмләләр

●

Чын мәхәббәт — әйтеп-сөйләп, язып-кейләп, тоеп-туеп бетергесез бөек шатлык ул.

●

Ул, ай саен 1 апрель булмавын авыр кичерсә дә, еллар буе рәхәтләнеп алдауларын дәвам итә.

●

Шатланганда теләсә кем — оптимист, син менә кайгырганда оптимист бул.

●

Эчкечеләр: «Эчкечелеккә каршы» дигән китапны без эчсәк тә укымыйбыз»; эчмәүчеләр! «Ул китапны без укымасак та эчмибез»,— диләр.

●

Мәхәббәтле — иң бәхетле, мәхәббәтсез — иң бәхетсез.

●

— Минем мөгеземнән беркем дә тота алмый, — дип мактанган ди бер мүкләк сыер.

●

Ала каргага бирәчәгең булмасын.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

## НОЯБРЬ, 1973 ел

Кама автомобиль комплексын төзүчеләр 15 ноябрьда зур җиңүгә ирештеләр: тимерчелек заводының өч корпусы — штамповка, автоматлаштырылган һәм механикалаштырылган линияләр, ярдәмчел цехлар корпусы төзелеп бетте. Кама автогигантының тимерчелек заводы Европада иң зур завод.

15 ноябрьда Чаллыда КамАЗ төзүчеләрнең культура сарае ачылды. Анда симфоник концертлар, кинофильмнар күрсәтү, биюләр һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр өчен махсус заллар бар.

Якын арада биредә кинотеатрлары, китапханәләре булган район культура үзәкләре сафка баса, шулай ук гомум шәһәр культура үзәге дә салыначак. Анда драма һәм курчак театры, яшь тамашачылар театры, цирк булачак. Аннан тагын культура сарае, кинотеатр, Халык иҗаты йорты.

«Литературная газета», Мәскәү.

Ульяновск машина төзү фәнни-тикшерену һәм проект-технология институты белгечләре ярдәмче заводлардан аерым комплектларны Чаллыга китерүне оештыру проектын эшләделәр.

Илебезнең сиксәннән артык предприятиеләре Кама автогиганты өчен ике меңнән артык төрле автомобиль узеллары һәм агрегатлары әзерләячәк. Аларны китерүне ничек җайлырак итеп оештырырга?

Моның өчен 20 шәр тонналы контейнерларны файдалану планлаштырыла. Ульяновск институтында Кама автозаводы өчен илебездә иң зур контейнер мәйданы планлаштырылды. Ул автомат белән идарә итә торган иң камил күтәрү-транспорт җайланмалары белән җиһазландырылачак.

«Советская Россия», Мәскәү.

ЗЯБ поселогының «Строитель» клубында комсомол комитеты инициативасы белән «Смена» исемле эшче театры оештырылды. Бәйрәм алды көннәрендә театр сәхнәгә «Тагын бер Америка» дигән феерия куйды. (Авторы — монтер Павел Юлаев.) Спектакль тамашачыларга ошады.

«Советская Татария», Казан.

ТЭЦның 250 метрлы торбасы очыннан төтен бөркелде, беренче теплоэнергетика агрегаты эшкә керешә. Ул сәгатенә 420 тонна пар һәм 60 мегаватт электр энергиясе эшләп чыгарачак.

«Труд», Мәскәү.

Комплексның төп заводлары төзелеп беткәнче үк бирегә «КамАЗ» маркалы зур йөк күтәрешле 50 автомобиль җыелачак. Алар өчен детальләр һәм узеллар ремонт-инструменталь заводында — комплексның беренче промышленность объектында эшләнә.

«Труд», Мәскәү.

Чаллы шәһәренең төньяк-көнчыгыш өлеше һәм автомобиль комплексы төзелеше мәйданы арасында, район чистарту корылмалары белән бергә, төп коллектор эксплуатациягә бирелде.

Унҗиде километрга сузылган ике ярым метр диаметрлы җир асты торбалары буйлап көнкүрештә һәм промышленностьта файдаланылган су механик һәм биологик чистарту объектларына ага.

«Труд», Мәскәү.

Чаллы шәһәре янында Түбән Кама гидроэлектростанциясе өчен плотина салу эшләре бара. Моңа кадәр бетон эшләре булачак ГЭС бинасының нигез плиталарында һәм шлюзларда барды, плотинаның үз нигезен кору башланды. Плотина өстеннән тимер юл үтәчәк. Ул тимер юл Идел — Бөгелмә линияләре белән төп Себер магистрален һәм Казан — Свердловск, Киров — Пермь магистральләрен тоташтырачак.

«Труд», Мәскәү.

Чаллы шәһәрендә яңа сөт заводының беренче технологик линиясе эшли башлады. Бу предприятие һәр көнне 50 тонна сөт эшкәртеп чыгарачак, уннарча төрдәге сөт продукциясе җитештерәчәк. Сөт заводы янында гына азык индустриясенең куәтле предприятиеләре: икмәк заводы, ит комбинаты төзелде. Алар инде эшли.

«Труд», Мәскәү.

Ленинград «Электроаппарат» фәнни-производство берләшмәсе коллективы бишьеллыкның өченче елында КамАЗга җибәрелергә тиеш булган 12 һәм 20 мең вольт көчәнешле 28 трансформаторның соңгысын озатты.

Бу заказны вакытыннан элек үтәү предприятиенең социалистик йөкләмәсендә әйтелгән иде.

Ленинград энерготөзүчеләренең бу трансформаторлары быел дәүләт Сыйфат билгесенә лаек булды.

ТАСС, Ленинград.

КамАЗда художниклар еш була. Гигант төзелеш бик күп сынлы сәнгать осталарын үзенә тарта. Күптән түгел Чаллыда Петрос Оганесович Малаян булып китте. Ул Ереван художество-театр институтын тәмамлаган. Ул иҗат иткән әсәрләрнең темасы — совет кешеләренең фидакарь хезмәте. Газетада художникның КамАЗ альбомыннан кайбер үрнәкләр дә басылып чыккан.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

Казагыстандагы Состобинск цемент заводы коллективы Чаллыга унбер айлык заданиедә билгеләнгәнгә караганда артыграк — ике мең тоннадан артык ак, сары, кызыл һәм яшел цемент озатты.

ТАСС, Алма-Ата.

Чаллы шәһәренең яңа салынган өлешендә «Орфей» әдәби берләшмәсе «Шигъри атналык» оештырды. Җиде көн эчендә КамАЗдагы яшь шагыйрьләр унҗиде тулай торакта чыгыш ясадылар.

«Советская Татария», Казан.

Бөек Октябрь социалистик революциясенең 56 еллыгы алдыннан ВЛКСМ Үзәк Комитеты бюросының «Фән, техника һәм производство өлкәсендә Ленин комсомолы премияләре бирү турында» карары басылып чыкты.

Халык хуҗалыгындагы башка белгечләр белән бергә, 1973 ел өчен Ленин комсомолы премиясе «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсенең комсомол-яшьләр бригадасы җитәкчесе Рәис Ганиевкә дә бирелде.

Яшь белгеч бу югары бүләккә бөтен союз удар комсомол төзелешендә производство куәтләрен вакытыннан элек эксплуатациягә тапшыруда ирешкән уңышлар, иҗади инициативасы өчен лаек булды.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

Кама автогиганты өчен махсус заказ буенча Хабаровск станок төзү заводы эшләгән станокта ике мең ярымнан артык детальне эшкәртергә мөмкин. Мондый агрегатларның беренче партиясе ясалды инде. Алар теге яки бу детальне эшкәртү өчен махсус җайлаштырылган. Дәүләт комиссиясе бу станокларның сыйфатына яхшы бәя бирде.

ТАСС, Хабаровск.

Яңа салынган «Энергетик» культура сараенда Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе артистлары концерты булды. Бөтенроссия конкурсы лауреаты, җырчы Гали Ильясов, эстрада артистларының бөтенсоюз конкурсы дипломанты Нурмөхәммәтов җырлары, Эльба Закирова биюләре һәм башка чыгышлар КамАЗ төзүчеләрендә җылы тәэсир калдырды.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

## Эдуард Касыймов

# КҮРШЕМ ГАБДЕЛХӘЙ БУРОВОЕНДА

### Карар күзгә бары да гадәти иде...

Мастер Габделхәй Шәйморатов, мине күрүгә, авызын колагына тикле ерды һәм кулымны кыса-кыса бәрхет тавышы белән:

— Килдем, дисең? Бик әйбәт!.. Әйдүк, әйдүк,— дип тәкърарлый башлады. — Балыккадыр инде ният, жумбага...

— Белмим әле. Бәлки тотып маташмам да...

— Ярар, хәйләләмә. Беләм мин сине! Әле кайчан гына әнә Сельсков буровоенда кунып та яткансың.— Мастер дамба буйлап еракка күз ташлап алды: анда, ике-өч чакрымнарда, икенче буровой шыңгырдап азаплана иде.— Ул чагында ничәләп жумба тартып чыгардың? Унлап түгелме? Җитмәсә, һәр кайсы килолы... Хәйран кылангансың, имеш! Шулай да үпкә бар сиңа: буровойда уха пешереп сыйламадың.

— Төн уртасындамы? Аннары кем белән пешерергә иде аны? — дип акланырга тотындым мин.— Иван Сельсков төнге вахта белән өенә тайды, калган егетләр эштә — инструмент күтәреп яталар иде. Аларны ничек аерасың? Соң, Габделхәй, син үзең дә, Фәизәңне яман да сагынып, Алабугага сызган идең бугай ла...

— Э-э, юк. Атна буе инде мин монда ябышкандай ятам. Скважина авыш. Күз-колак булып тормыйча ярамый. Ахырга таба бигрәк тә... Иртәнге якта хәбәр иткән булсаң иде, ичмаса, уханы монда да пешерә белер идек.

Ачык һәм киң күңелле кеше ул Габделхәй, һәм миңа аңардан шук сүз белән генә котылу уңайсызрак тоелды. Җитдирәк тавышка күчеп, аңлатырга керештем:

— Синең монда калганлыгыңны белгән булсам икән! Әмма иртәнге якта мин бәлага эләгә яздым шул: ярдан атлавыма ук бил тиңентен бозлы суга төштем. Кая анда балык кайгысы! Культбудкада бераз кибендем дә вахта белән тизрәк Алабугага кайтып киттем. Кама аша да көчкә чыктык: боз күбенеп, ярдан чигенә башлаган иде инде. Куркыныч...

— Анысы хак. Шулай да безнең егетләр монда насосный тирәсендә матавыкланалар әле. Бозга такта салып керәләр. Ә проран Сельсков янындагыдан начар түгел: земснаряд казыган. Бәкеләр дә җитәрлек. Кышын да, язын да камазчылар өзелмәде. Әле дә проранда Чаллы

халкы байтак утыра. Әмма тотканнары вак-төяк... камырга, кортка. Кая инде аларга жумба!

Мин җилкә тартып көлемсерәдем. Ә Шәйморатов күзләре белән мине бораулагандай итә:

Жумба кичке эңгердә каба башлый бугай, иеме?

— Әйе, кояш баю белән. Аннары, ара-тирә тукталгалап, төн ката. Көне, һавасы ничек була бит тагы...— Бу хакта мин, әлбәттә, бик озаклап, тәмләп сайрый алган булыр идем, ләкин ул мине шундук бүлдерде:

— Алайса, болай: миндә балыкчылар чутсыз. Кичке эңгердә вахтадан бушаган теләсә кем синең белән боз өстендә йөри алырдыр. Коралларың үзең беләнме? Блеснаң шәпме?

— Коралны алуын алдым. Елдырма да шәп, суалчан да...— Мин кулымдагы бәләкәй генә чемоданны бер мәл селеккәләп торгач, мастерга турысын ярып салырга исәп иттем: — Әмма бу юлы балык тотарга ният юк минем. Болай гына килдем. Хәл-әхвәлләрегез белән танышырга дигәндәй...

— Бик әйбәт. Анысы да эш... Ярар, буровойда син беренче тапкырың түгел, бары да таныш, әйдә, үзеңчә кылан. Әмма иң башта культбудкага кереп, тамак ялгап ал. Ризык өстәлдә, ә чәйне кайнарларсың. Ә без монда, күрәсең, колонна төшерәбез.

Һәм буровой хуҗасы ашыкмыйча, аз гына чайкалгалап, күперчеккә таба юнәлде. Шактый гына калку, калын гәүдәле ул. Мондыйлар, гадәттә, мәйданга чыгып, батыр кала.

Чәйдәмени кайгы? Иң әүвәл бераз «иснәнергә» кирәк. Мин чемоданны койка астына тыктым да культбудкадан чыктым.

Буровойда Харис Фазлыев вахтасы. Үзе ул юка, тыгыз гәүдәле, үтә кырыс кыяфәт белән бар игътибарын тормоз рычагына һәм индикатор угына биргән — янына якын килерең юк. Аның ярдәмчеләре күз иярмәслек тизлектә элеватор, автоматик ачкыч, трос ише нәрсәләр белән эш итә, һәм корыч колонна торбалары, теш камаштырырдай каты һәм ачы шыгырдап, берсе икенчесенә ялганып куя. Нык берегә, мәңгелеккә! Әйе, алар үзара күз карашлары белән генә аңлаша, эшне гаҗәп гаярь һәм оста башкара иде. Карап торулары ук күңелле. Һәм галәмәт озын корыч колонна, әнә шулай югарыдан өстәлә барып, җир куенына тирәнгә акрынлап кертелә-сеңдерелә бара... Егерменче йөзнең киләчәк гасырларга чираттагы күзгә күренмәс һәйкәле!

Шәйморатов бораулау идарәсенең производство бүлеге башлыгы Попов белән бергә — бусы бездән чак кына алданрак махсус рәвештә колонна төшерергә килгән икән — күперчек кырыенда торган эстакададагы торбаларның озынлыгын үлчәп маташа. Һәр торба-шәмнең озынлыгы төрлечә, моны анык белмичә, исәпкә алмыйча һич ярамый. Хәзер буровойда иң җаваплы вакытларның берсе: колонна скважинаның проект тирәнлегенә төп-төгәл төшеп урнашырга, ягъни забойга җитеп төртелергә тиеш. Югыйсә...

Бер читтә, дамбаның шушы киңәйтелгән мәйданы кырыенда ук, ике вагон тора. Берсендә — тулай торак. Икенчесендә — күчмә ашханә. Бу соңгысының болдыры төбендә, агач тумранга утырып, пумала башлы бер егет бәрәңге чистартып азаплана. Үзе солдат гимнастеркасыннан. Эшенә шул тикле чумган, хәтта дөньясын онытканн дияр идем. Бүтәнчә булмый да торгандыр, ахры: бәләкәй генә ашханәдә бөтен дамба диярлек тамагын туйдыра, һәм ризыкны әләй-вәләй генә пешереп табынга бирсәң, ай-яй, бораулаучылар, монтажчылар һәм төрле механизаторлар үзеңне утлы табага бастырып биетүләре бик ихтимал! Ә миңа шушы контраст сәер, хәтта беркадәр көлке тоелды: янәшәдә бүтәннәр чамасыз авыр, чын ирләр эше белән мәшгуль, ә монда исә үзенә күрә «чираттан тыш наряд» сыманрак... Бераздан, сораш-

калый торгач, аңладым. Армиядә чагында ук әле кухня тирәсен якын күргән, яраткан. Инде хәзер буровойда үзенә күрә стажировка уза. Казандагы сменадашы белән унбиш тәүлек саен алмашыналар икән. Сизелеп тора, егет җәядәге угын еракка төбәгән: буровойда кулын шомартып, осталыгын үстерә төшкәч, Казан каласының үзендә берәр ресторан яисә юньлерәк ашханәдә пешекче булырга чамалый. Бер генә дә кырын эш түгел. Кем әйтмешли: «Җаны теләгән — җылан ите ашаган» ләбаса...

Ә тулай торак дигәнебез вакытлыча гына оештырылган, бер-ике атнага: Кама аша әлегә юл ябык бит. Вахталар берничә тәүлеккә командировкада. Вертолет өчен иң ыгы-зыгылы, иң мәшәкатьле чак. Аннары, Камада су юлы ачылгач, чират катерларга.

Вагонда җанлана төштеләр: тиздән вахтага чыгасы. Билгеле инде, гәүдәсен кырын салган җиреннән беренче булып бораулаучы Шәрхмулла абый Шакиров үзе кузгалды һәм эш киемнәренә тотынды. Ачык, мөлаем чырайлы, арпа мыеклы бу абзый бөтен Союзда ук булмаса да, һич югы, Татарстанның үзендә, мөгаен, иң өлкән, күрәсен күргән бораулаучыдыр: аның сугыштан соңгы бар язмышы бораулау эшенә бәйләнгән. Данлы Бакуда башлап җибәргән, тәҗрибә туплаган, аннары ерак Сахалинга китеп җир тишкән, моның соңында кире туган ягына — чиксез бай Тимәш мәйданына кайтып маңгай тирләрен агызган. Инде хәзер берничә ел рәттән Кама буйларын бораулый. Аңа бригадада, үз һәм якын итеп: «бабай» дип эндәшәләр. Дөрестән дә, бабай инде... Кайчагында чаярак усалрак егетләр, юри шаяртклап, «бабайның» күңел кылларында уйнап алгалыйлар. Әмма эшкә килгәндә, әлбәттә, берсүзсез буйсыналар, тыңлыйлар.

Минем игътибарны колгадай озын, элеп киптергәндәй юка буйлы Виктор исемле егет җәлеп итте. Өстенә йон свитерын, башына җептән бәйләгән башлыгын киеп өлгергән дә, ишек яңагына сөялгән хәлдә, бүтәннәрне көтеп тора иде. Буровойда бу кадәр үк колга гәүдәлене гадәттә очратмыйсың. Фамилиясе дә кызык кына: Чипиус. Латыш егете икән. Күр, кайлардан килеп чыккан!

— Мондый буй белән баскетбол мәйданчыгына басасы иде сезгә! Бит сезнең якташлар...

Виктор миңа әйтеп бетерергә бирмәде, кырт кисте:

— Мин дә заманасында уйнаган идем. Армиягә тикле дә, армиядә чагымда да...— Аннары ялкау гына кул селтәде.— Ә монда ул хакта уйларга да вакыт тими...

— Дөп-дөрес: тими. Алай-болай вышка ава башласа, ул бит монда иң төп терәк,— дип чәнчеп алды кайсыдыр, шаяртып. Помбур Володя Калабушкин булдымы, әллә Рәшит Ширәев идеме?

Моңа Чипиус хәтта кашын да селкетмәде, күрәсең, шундыйрак вактөяк үртәшүләргә ул инде күнегеп беткән. Ләкин электрик Геннадий Аникин кичен бушрак вакыт тисә боз өстендә бергәләп йөрергә нияте барлыгын миңа сиздереп куйгач, Чипиус мыскыллап авызын кыйшайтты:

— Эх, сезне, хәсрәт балыкчылар! Соң бит бүген безнекеләр чехлар белән мөгезгә мөгез... Безгә вахтага чыгасы... җәл...— һәм ул дамба комыннан беренче булып озын аякларын кыштырдатты.

Мин уч төбем белән маңгаемны шапылдаттым: менә сиңа мә! Ничек онытканмын икән? Әмма «бабай» мине тынычландырырга ашыкты:

— Телевизорыбыз юк югын, ләкин, аның каравы, культбудкада радиоалгычның тавышы шәп. Тиккә ухылдама, энекәш!

Вахта халкы, скважина тамагы төбендә кайнар тирләрен түккән иптәшләрен алыштыру өчен, бердәм кубып һәм шаулашып, буровойга таба атлады.

Мин чәй кайнатып өлгертүгә, культбудкага Шәйморатов килеп керде һәм күкрәк тавышы белән гүләп тә җибәрде:

— Шәп, шәп! Егет икәнсең!

Ләкин тәмләп чәй эчәргә керешкәнче, ул рация аша диспетчер белән элемтәгә кереп монда колонна төшерүнең әлегә шома гына баруын әйтте, аннары Әлмәттән цемент койдыру агрегатының чыгуы-чыкмавы хакында белеште. Ә чәй чынлап гаҗәеп хуш исле булып пешкән иде. Бер-беребезне узарга теләгәндәй, «өф-өф» итәргә тотындык.

— Шома дисең. Алай да бу авыш скважинаның мәшәкате аз булмагандыр, ә? — дип сорадым мин һәм күз карашым белән стенага ябыштырылган «миллиметровка»га ым кактым. Зур кәгазь битенә проходканың бар үткән юлы төшерелгән иде.— Әнә бит нинди: кыек-мыек...

— Шулай инде. Нервы дигәнеңне шәп сыный. Азимутны төгәл алсаң, авышлыгы какшый, бусын төзәтсәң, азимут читкә тайпылгандай... Бит илле метр радиустагы түгәрәккә эләгергә кирәк. Ноктасына! Ә ул куенында мең дә сигез йөз метрлар тирәнлектә, җитмәсә тагы, вертикальдән алты йөз утыз метрдан да артык читтәрәк... Кыскасы, скважина еландай бөтерелеп төшә, өстән караганда, спираль сыман... Ә-әнә, күрәсеңме, теге күл артындагы куаклар астында, җәһәннәм тирәнлегендә, безнең забой...

— Димәк, «нокта»сына эләктегезме? Ә синең берәр кайчан ул түгәрәктән читкә тайпылганың булмадымы?

— Төрле хәлләр килеп чыккалый. Юкка гына буровойдагы эшне «кәртә уены сыман» дип әйтмәгәннәрдер... Ләкин минем үземнең әле беркайчан да брак ясаганым юк... Моның соңында да авыш скважина. Әмма анысы бөтенләй икенче якка кыегая. Безгә шушы мәйданчыктан дүртне тишәсе.

— Иван Сельсковта бишәү бугай.

— Бишәү.

Комнан өелгән биек дамба... Аңарда бер-берсеннән шактый ара калдырып махсус киңәйтелгән бүсенте-мәйданчыклар. Русча «пятачок»... Җир маен ипләп суырту өчен, һәр мәйданчыктан дүртәр-бишәр скважина-тамыр төшә. Әйләнә-тирәне су баскач та, ул скважиналар тирән җир куенын имеп торачаклар...

— Анысы да уңышлы булырдыр. Инде хәзер шактый ук остардыгыз шикелле. Биш-алты ел элгәредәге кебек түгел. Ул чагында авыш скважиналар белән, һай, иза чигәләр иде.

— Әйбәт буласына өмет юк түгел үзе. Тик, күрше, андый-мондый хәл генә чыкмасын. Үзең беләсең...

Мастер авыр кымшанып миңа таба тартыла төште, һәм читкә караган көенчә, дустанә-серле пышылдауга күчте:

— Әлмәттән заливка агрегаты, бәлкем, соңга калыр. Ул чагында кичке эңгердә синең белән боз өстендә йөрергә миңа да җай туар иде. Блеснага бик тотып карыйсы килә. Минем моңарчы әле бер кайчан жумба эләктергәнем юк бит... Аннары бераз онытылып йөрү дә зыян итмәс иде...

Мин җилкә тарттым һәм сәбәбен аңлаттым.

— Чехлар белән алайсам... Анысы да кызык!

Ләкин бу минутта без — ни ул, ни мин — кичен эшләрнең кискен борылыш ясап, яман үзгәреп китәсен тамчы да абайламый идек.

Башта барысы да әйбәт барды. Колоннаны, Габделхәй үзе әйтмешли, бик тә «шома» төшереп бетерделәр. Бу вакытта кичке эңгер тәмам куерган иде инде. Ул да түгел, Әлмәт җибәргән зур ярдәм дә килеп

җитте. Өч агрегатны бергә тоташтырып, үзенә күрә «төен» бәйләргә керештеләр. Нык һәм ышанычлы итеп! Шул чагында, күктән иңеп төшкәндәй, әллә каян гына геолог Василий Алексеев та килеп чыкты. Ул, колонна төшергәндә Попов катнашкан шикелле ук, скважинаны, дөресе, колоннаның тышкы аралыгын, цемент измәсе белән «коендыру»ны үз күзләре белән карап, тикшереп торырга тиешле икән. Геологларга йөкләнгән меңләгән вазифаларның берсе... Әлбәттә, скважинаның төрле катламнары арасында берниндн дә циркуляциягә юл калдырылмасын, шәпләп катырылсын. Хәзер инде бөтен скважиналарны да өстәге тамагына хәтле цемент белән ныгытып катыралар икән. Бик вакыт! Ә сыйфат соңыннан, карротаж һәм опрессовка вакытында, беленәчәк.

Баш өстебездә күк гөмбәзе ап-аяз. Йолдызлар җемелдәшә. Көньяккөнчыгыш тарафта караңгы урман сырты артыннан, кызу мичтә йөзе килеп, һәйбәт пешкән ак күмәч рәвешендәрәк, акрын гына ай калкынып килә. Күңелле булып китте.

Әле теге эшче янына барып сүз катам, әле бусы янына барам. Эшләре ярыйсы ук тыгыз булса да, көр тавыш белән җавап кайтаралар, тәмләп, ара-тирә әчкелтем сүзләр дә кыстыргалап, сөйләшә беләләр. Кыскасы, кәефләр безнең ал да гөл. Шулай буталып-матавыкланып йөри торгач, вакытның узганын сизми дә каласың. Бактың исә, радиодан хоккей матчы турында репортаж күптән башланган икән инде. Бермәлне культбудкадан берәү башын игән килеш атылып килеп чыкты да күңелсез хәбәр белән чаң сукканлай итте:

— Безнекеләрне кыстылар... Чехлар инде ике шайба тыкты... Эшләр харап!

Өнсез калдык. Авыр тынлыкны бердәм ыңгырашу бозды:

— Ничек инде алай?

— Нәрсә анда алар, мать якасына, безнең нервыда уйныйлар...

Шушы сүгенү җитә калды: кинәт электричество сүнде. Ниндидер сихер дулкыны бәрелде кебек... Дөм караңгы. Күк гөмбәзендә тик йолдызлар җемелдәшә дә бер кырыйдан ай күтәрелеп килә. Культбудкадагылар сукранып тышка атылды. Мондагылар да ыгы-зыгы килә башлады. Электрикны дәшеп алдылар. Ул трансформаторныйда актарынырга тотынды. Берничә минуттан ачыкланды: нәрсәнедер кай төштәдер ток бәргән, яндырган. Бәлкем, югары вольтлы линиянең үзендәдер? Алла белә... Караңгыда әле тегендә, әле монда йомшак кына яктылык көлтәләре кабынып уйнаклады. Мин дә үземнең электр фонаремны алырга дип культбудкага ашыктым. Аннан чыгуыма, каршыма Шәймөратов килеп басты да миңа таба кулын сузды:

— Сиңа фонаригың ул хәтле ук кирәк түгел бугай?

— Мә, рәхим ит... Сез нәрсә, бу караңгыда да эшегезне...

— Тукталырга ярамый. Электрик кайчан рәтли бит. Булдырырмы-юкмы әле... Вакыт кадерле... Ә син, пожалуйста, читтәрәк йөре. Караңгыда әллә нинең бәрүе бар. Сакланганны... үзең дә беләсең...

Тәмәке көйрәтеп, культбудканың тимер болдырында утырам. Күңелдә ачы бер хис, күкрәк тырнала... Нинди уңмас юлга чыктым соң мин бүген? Нидән бу? Әлбәттә, «балык» дигәненә төкерәсе. Алай зур ниятем дә юк иде. Ә тегендә Прагада ничек икән? Безнекеләр бирешерме-бирешмәсме? Әмма иң ачысы: мин бүген монда скважинаны тамагына тикле цемент белән «коендыру»ны күрмим. Мастер чын-чынлап куып җибәргәндәй итте. Ә бит бу кызыклы процессны шул хәтле күрәсе килгән иде. Мин әз генә юк-барга ышанучан кеше. Әллә берәр килешмәгән эшем булдымы?

Ай инде үзенең әфлисун төсен җуя төшкән. Ул, җир йөзенең шушы кичтәге генә бер почмагын көмеш нурлары белән тизрәк яктыртмакчы булып, безгә ярдәмгә ашыга сыман. Дамба буйлап еpактарак Сель-

сковның буровой вышкасы яп-якты утлар челтәрендә балкый. Ул галәмәт зур Яңа ел чыршысы шикелле. Кинәт ул якта төнге тынлыкны зәһәр металл сызгыруы һәм чинавы яргалый башлады. Әйе, андагылар кискен җәһәтлек белән тирән җир куеныннан корыч инструментны суыртып чыгарырга керештe. Ә безнең монда караңгыда бәләкәй фонарьлар яктысы биешә дә, эшчеләрнең кисеп-кисеп әйткән кырыс сүзләре ишетелгәли. Тукта, чү, безнең дә монда кинәт шалтыр-шолтыр гөрелте купты! Скважинага цемент кою башланды... Ниһаять!

Инде хәзер мин караңгылык эчендә эреп, бик тә кирәкле һәм кичектергесез эш белән мәшгуль булганнар хакында уйлыйм. Әйе, бригаданың үзәге нык. Менә хәзер монда эшләүчеләрдән тыш, бурильщик Айрат Нәбиев белән Равил Ибраһимовлар үзләре генә дә ни тора! Һәр кайсы тәҗрибәле, тырыш һәм булдыклы. Ләкин бу бригада шушы нык һәм көчле үзәге белән әле кайчан гына Алабуга бораулау идарәсендә, ул чагында конторада, койрыкта сөйрәлүчеләр арасында булган лабаса. Бригадага Шәйморатов килүгә, хәлләр тамырдан үзгәрә. Былтыр болар ел йомгаклары буенча идарәдә беренче урынны яулап алалар. Ә ясаган экономияләре исә бөтен бер скважина бораруларга җитәрлек була! Шәйморатов шул рәвешле инде өченче коллективны алгы сызыкка чыгара. Ул ирешкән уңышларның сере нидә? Бу хакта мин, ничектер җаен китереп, партком секретаре Рифгат Гыйззәтуллиннан сораган идем.

— Үз эшен нык белә. Кул астындагы кешеләр белән уртак тел таба ала,— диде парторг, бермәл уйланып торгач. Шушындый ук фикерне директор урынбасары Илһам Вахитов та әйтте, тик өстәп куйды:

— Тырыш та, инсафлы да ул Габделхәй...

Буровой хуҗасына бик тә кирәкле сыйфатлар, әлбәттә. Ләкин мастерлар арасында югары белемле инженерлар, ягъни үз эшләрен яхшы һәм тирән үзләштергән кешеләр дә була. Алар да бит тырышмыйча ятмый, кул астындагыларны бик тә инсафлы рәвештә җайлый һәм тыңлата белә. Шулай да, ни генә булса да, узышта Шәйморатов еш кына аларны артка калдырып килә... Димәк, аңарда бүтәннәрдә булмаган башка төрле сыйфатлар бар? Ә ни икән?

Мин культбудкага кердем дә, өстән пальтоны, аяктан итекләрне салып, мастерның койкасына сузылып яттым. Хуҗа рөхсәт итү генә түгел, кушкан да иде: янәсе, барыбер ут юк... Башымда уйлар...

Куәтле яктыдан кинәт уянып киттем. Ни күрим, Шәйморатов каршы якта икенче каттагы сәкегә, әллә шүрлеккә димме, үзенә урын хәстәрләп маташа. Астагы катта исә ике начальник — Попов белән Фирсов, аркаларын терәшеп, «мәрткә» киткән. Фирсов — идарәнең техника бүлеге башлыгы. Ул шактый соң, караңгылык куергач килеп төште. Әлмәттән бораулар һәм кайбер бүтән төрле инструментлар алып кайтышы икән. Аларның бер өлешен ул иртәгә вертолетта теп базага илтергә тиеш. Ике башлык та нык арыганнар, күрәсең. Ә буровойда соңгы араларда үтә тыгын...

Мин койкадан сикереп тордым да мастерга текәлдем.

— Нәрсә, әллә бетте дәме инде? Арумы?

— Ару. Ә син беләсеңме, күрше, безнекеләр чехлар белән уенны тәки тигезләгән бит. Өч тә өч!.. Вахтадан буш торган бер-ике егет репортажны Сельсков буровоена барып тыңлады. Әйттеләр...

Мин җиңел сулап куйдым.

— Әлмәтлеләр кайда соң? Әллә тайдылармы инде?

— Киттеләр. Мең рәхмәт инде аларга: әйбәт булыштылар... Мастер баш астына плащын һәм сырмасын салгач, акрын гына тавыш белән, миңа әйтүдән битәр, үзе өчен булса кирәк, бер мәл сөйләнеп торды: — Ә хәзер ял: ОЗЦ... Аннары карротаж булыр, опрессовка. Анысы да үткәч, монтажниклар килер дә станокны төп-төгәл алты метрга күче-

реп куяр. Бусы да эшләнгәч, ике-өч көннән яңасын башларбыз... Булды бу: рәхәтләнеп «мәрткә» китим әле бер! Иртәгә өйгә. Анда инде мунча, ә мунчадан соң бер-ике савыт салкын сыра... Эх, әттәгенәсе!

Габделхәй бездән ике йорт аша гына яши һәм мин күршемнең йомшак ягын бик беләм: мунча һәм сыра ярата ул.

Тышта — утырып мәрҗән тезәрлек. Буровойда бернинди дә хәрәкәт сизелми. Җан иясе дә юк. ОЗЦ — ожидание затвердевания цемента (цемент катканын көтү). Димәк, берничә сәгать ял итәргә мөмкин.

Мин папиросымны җәһәт кенә сүндердем дә кире культбудкага кердем. Төн уртасындагы әңгәмәне дәвам иттерәсем килде. Ләкин Габделхәй шул арада гырлап йокыга да киткән иде... Әйе, шулайдыр: аның җилкәсеннән чираттагы тавы төшкән. Хәер, бер аның гынамы?

## «Бар иде минем бер алашам...»

Анда-монда сибелешеп, дамба сыртында ятабыз һәм эч пошканнан комда сызыклар сызгалыйбыз. Күзләребез күктә. Әмма вертолетның күренергә исәбе дә юк.

— Мөгаен, ул мөртәт Идел аръягына сызгандыр әле? Бүген разведкада вахта алмаштыралар бугай,— дип сызлана безнең арадан берәү.

— Ләкин диспетчер иң әүвәл безгә диде бит...

Элгәрерәк Алабугада ике контора иде: берсе эксплуатация скважиналары әзерли, икенчесе — разведка бораулавы. Күптән түгел аларны берләштерделәр, һәм бораулау идарәсе туды. Бригаданың бер өлеше кайдадыр Казан тирәсендә, хәтта Иделнең уң як төбәкләрендә «кара алтын»ның яңа хәзинәләрен эзләүдә. Әгәренки вертолет шунда очкан булса, кимендә биш-алты сәгать көтәсе: тик Казанның үзенә кадәр дә турыдан ике йөз чакрымнан артыграк бит.

Попов, түземе шартлап, урыннан куба да киеменә сыланган комны коя:

— Килә калса, тоткарларсыз, мин бик тиз әйләнермен...

Ул кызу-кызу дамба буйлап атлый. Без аунап яткан мәйданчыктан буровой нибары ярты чакрымнарда гына. Поповның нияте изге: ул рация аша диспетчерны тагын бер кытыкламакчы...

— Сез анда текәрәк тотыгыз! — дип кычкыра Рәшит Ширәев, тез өстенә калкынып. — Югыйсә, безгә монда кичкә хәтле казынып ятарга туры килмәгәе. Ул чагында мунчасы да, бүтәне дә... аллаһы әкбәр! Дөрес бит?

— Аның каравы, хатының... ул сиңа шатлыктан... Син ничә көн өеңдә булмадың? Әһе, алайса, өстәлгә шәбен куяр... — дип, үзенчә тирән мәгънә белән күз кыскалый берсе һәм күн тужуркасының куен кесәсеннән тузып, майланып беткән карта колодасы тартып чыгара. — Нәрсә, җәмәгать, башлыйбызмы? Нервыларны сакларга кирәк монда...

Бусы инде буровиклар һәм монтажчылар арасында була торган хәл. Вакытны ничек үткәрергә беләләр. Хәтта юлда автобуста әлдерткәндә яисә катерда барганда да шуны онытмыйлар, уйный бирәләр. Тик вертолетта очкан чакта гына тотынмыйлар: вакыт кысанрак. Хәер, разведка халкы анысына да җайлашкан, чөнки аларга, гадәттә, ярыйсы ук озак очасы.

Шәйморатов та, уенчыларга кушылырга ниятләп, дамба сыртының түбәндәрәк өлешенә, кояш җылысына шумакчы булып итенде, ләкин мин аны, плащ итәгеннән эләктереп, тоткарладым: «Сөйләшеп утырулары күңеллерәк булыр»,— дидем. Апрель комы салкын әле, җитмәсә, Кама ягыннан, боз сулышын сиздереп, җил дә исеп куйгалый. Әле-

ге шау-шулы картачылар төркеменнән читкәрәк тайпылып, без дә дамбаның кояш җылыта төшкән яңагына кырын яттык. Ләкин мин сүзне каян һәм ничек башларга белмим. Бераздан җеп очын Шәйморатов үзе тоттырды.

— Өйгә кайтып төшү белән үк, иң башта, сад-бакчаны барып карарга ният. Бу кышның зәһәр суыкларыннан соң алмагачкайларның хәле ничегрәк икән анда? Тернәкләнеп китәрдәйме?— дип куйды ул хафалы бер тавыш белән. — Бакчада да казынгаларга вакытлар җитеп килә бит, ә...

Буровикларның коллектив бакчасы нефтьчеләр поселогы белән янәшә генә диярлек, нарат-каен урманы һәм тирән чокырлар арасында урнашкан. Беркемгә кирәге булмаган, ташландык бер бушлык иде. Хәзер анда күзләрнең явын алырдай бакча үсеп чыкты. Суны үзләре тишкән скважинадан суырталар. Һәм, әлбәттә, матур-матур бәләкәй йортлары да бар. Хәер, болары хаҗәт булудан бигрәк, модага иярүгә охшый кебегрәк: һәркайсының өеннән бакчасына нибары биш-алты минутлык кына юл лабаса. Мондый хиреслек беркадәр аңлашыла да: аларның бакчасы бүтән җирләрдәгедән төссезрәк һәм ялангачрак булсынмыни соң?!

— Ә син, Габделхәй, йортның берәгәйлесен салгансың, кызыгырлык,— дим мин. — Җәйләрен кунып ятулары искитмәледер, ә?

— Минем анда әле бер тапкыр да кунып караганым юк шул. Тик көндезләрен генә кайчагында буровойдан кайткач йокы симертергә баргалыйм. Аннары ни... телефон шалтырауларын ишетмәс өчен...

— Нәрсә, еш шалтыраталармыни?

— Була инде... Бездә бит шундыйрак тәртип: концерт карарга китәсеңме яисә кунакка барасыңмы, диспетчерскийда синең кайда батып ятуларыңны белеп торырга тиешләр. Язылмаган закон!

Искә төште... Кайчагында шулай нефтьчеләр клубында ипле генә утыра бирәсең, кино яисә спектакль карыйсың һәм кинәт кискен тавыштан сискәнеп куясың: «Фәлән Фәләневне на выход!». Бу рәвешчә гадәттә берәр хирургны яки гинекологны алып китәләр, рәхәттә оеп утырырга бирмиләр. Димәк, кемнеңдер тормышы куркыныч астында... Кайвакытта, бик сирәк булса да, берәр бурмастерның фамилиясен атап та кычкыралар. Ул да бик ашыгыч кирәк, ул да коткарырга тиешле, чөнки һәр скважинаның тик үзенә генә хас холкы-фигыле һәм язмышы бар... Ә бит бер уйлаганда, берсе икенчесеннән шул кадәр ерак торган профессияләр болар: медик һәм буровик...

— Карале, Габделхәй, кызык өчен генә әйтче: син үз гомереңдә ничәләп скважина борауладың? Сигез ел элек мастер булганыңны беләм мин. Аңарчы күпме дә, мастер булгач күпме?

— Барлыгымы?

Ул шактый озак дәшми-тынмый ята бирә. Күңеленнән исәпли булса кирәк. Җиңел түгелдер, ахры: буровойның авыр хезмәтендә ул бар баскычларны да узган бит.

— Бөтенесе, пажалый, йөз скважинага туладыр. Әйе, ким түгел!— ди ул, ниһаять.— Мастер булып эшләгәндә алтмыш дисәм, аңарчы ун ел эчендә кырыклап бар да бар инде...

Сизеп торам: киметебрәк әйтә әле ул... Әмма әйткән кадәрен дә күз алдына китерүе җиңел түгел: бур белән каты токымнар аша Алабугадан Казанга хәтле ерак ара лабаса!

Юк, ул бораулау эшендә бернинди дә рекорд куймаган һәм аның исеме бөтен республикага яңгырамаган. Ләкин Габделхәйнең җегәрсәләте чәчәк аткан чак. Кем белә, бәлкем, ул үз гомерендә иң зур рекордын куяр: бораулауда иң озак еллар эшләүче һәм иң озын проходка үтүче булыр? Хәтта бер Татарстанда гына түгел, бөтен Союз күләмендә?.. Мин боларны, әлбәттә, үз алдыма уйлыйм һәм күңелемнән ан-

дый хәлнең килерен, булуын телим. Ә Габделхәйнең үзенә бөтенләй бүтән төрле сорау бирәм:

— Тагын шунысы кызык: син буровойга ничегрәк килдең? Күңеленне ни тартты дигәндәй?

Ул җиңелчә елмаеп куя. Күрәсең, искә төшерүләре үк рәхәттер...

— Гап-гади кызыгу аркасында гына... Малай чак иде. Бер заман безнең авыл янына разведчиклар килеп буровой торгыздылар. Бу ни... Әгерҗе районы Рыс авылы... Хәзер анда да нефть таптылар. Мин, мөгаен, үземнең бригадам белән озакламый ул тирәгә барып та чыгармын әле: туган туфракны борауларга... Ә теге заманда разведчикларның беренче борган скважиналары коры булып чыкты. Юкса, безнең авыл халкы нефть чыгуын шул хәтле теләгән иде! Бигрәк тә мин үзем... Еш кына мин алар янына бара торган идем. Күңелне тарта да тора. Чын әкият сыманрак бит: күз алдында әкрен-әкренләп җиде кат җир астына, җәһәннәмнең үзенә төшәләр ләбаса! Уйламыйлар да! Үзләре гап-гади кешеләр, хәтта, әйтер идем, безнең авыл мужикларыннан артык җирләре дә юк... Кайчагында буровойга дәрестән дә качып киткәли идем. Тик алар шул коры килеш ияк сыпырып китеп бардылар. Китсәләр китте, әмма буровой үзе минем күңелдә утырды да калды. Бераз үсә төшкәч, тоттым да төенчекне төйнәп, Әлмәткә, җизни янына киттем. Әлмәт ягы ул чагында гөрли иде. «Җизни, мин әйтәм, давай буровойга урнаштыр әле, югыйсә, хәлләр хәл...» дигән булам. Урнаштырды бу мине. Төрле эштә йөрим. Бар иде минем бер алашам. Мин аңа «Буровик» дигән исем куштым. Буровойга төрле ыбыр-чыбыр ташыйбыз. — Мастер боларны, яшен яшәгән ак сакаллы карт сыманрак, бик тә күптән узган хәлләр рәвешендә исенә төшерә иде. Ә чынлыкта ике дистә ел да узмаган бит әле. «Бервакыт миңа унсигез яшь тулды. Әйе, илле дүртенче ел иде. Киттем туп-туры директорның үзенә. «Шулай да шулай, иптәш директор,— дим, буровойда кара крестьян булып йөрүдән гарык булдым, чын буровик итегез инде, зинһар», дим. Бу башта бер туйганчы көлде. «Ах сине, ди, ничек кыю сөйләшәсең», ди. Аннары чигенде: «Ярар, унсигез яшь тулган икән, закон рөхсәт итә», ди... Шулай иттереп, мин верховой булдым, ягъни вышка хуҗасы. Ул чагында дөньяда миннән дә бәхетле кеше булмагандыр! Чын әгәр...

«Кәртә сугучылар» кинәт хәрәкәткә килде. Һавада вертолет күренгән икән. Ләкин тимер кош Каманың уң яктагы биек яры өслэтә бөтенләй читтән узды.

— Ык тамагына баруы, ахры. Эх, кире кайткан чагында безне дә эләктереп алып китсә иде! — диде уенчылардан берәү.

— Илдар Бакинский кая китеп югалды әле? — Шәйморатов, җирдән калкына төшеп, як-ягына карангалады.— Ул үзенең рациясеннән диспетчерларына әйтеп, вертолетны безне алмага җибәрттерә алыр иде, ичмаса.

Илдар Бакинский — шушындагы участок башлыгы. Мондагы бар скважинага ул хуҗа. Илдар әле бик күптән түгел генә үзенең тупы борынлы вездеходында, безгә ягымлы кул селтәп, дамбадан узып киткән иде...

Габделхәй янә минем янга комга сузылып яткач, мин, күңелемне кичә кич һәм төнлә борчыган нәрсәгә җавап табу нияте белән, ашыгып сорау бирдем:

— Әйтче, Габделхәй, синең бригадада уңганның да уңганы — бораулаучы Харис Фазлыев бугай, дөресме?

— Дөрес. Ул безнең идарәдә генә түгел, трестта да алда бара.

— Хикмәт нидә? Аның уңышының сере, дим?

Шәйморатов уйчанланып бер ноктага төбәлде. Ул, әлбәттә, аңлады мине. Тик җавап бирергә генә ашыкмый.

— Фазлыев — үз эшенең остасы, билгеле. Шул ук вакытта ул эшне

бүтәннәрдән күбрәк ярата шикелле. Аннары аңарда... ничек дип әйдим, нindирәк әчке сизү бар... Талант димме... Әйе, бурильщик таланты!

Инде мин тынып калдым. Ап-ачык итеп әйтте: «Ярату һәм талант». Мин әлеге соравым белән кыек атып туры тидергәндәй булдым. Мастерның бу сүзләре аның үзенә дә карый лабаса! Әйе, шулай: аның да асыл сыйфатлары ич бу һәм алар мастер эшчәнлегендә тагы да калкурак шәйләнә сыман...

Кинәт минем гәүдәне салкын дулкын өшетеп узгандай булды: Габделхәй үз тырышлыгы белән хезмәттә үз урынын тапкан, дәрәҗәгә ирешкән, ул инде хәзер партком члены да... Кинәт аны талантына тулы чәчәк атарга җай китергән урыннан кубарып алып, югарырак чөю сылтавы белән, икенче төшкә күчермәсләрме? Җылы, тагы да дәрәҗәлерәк, әмма аның өчен җайсыз-уңайсыз урында талантын әрәм-шәрәм итмәсме һәм соңыннан тау түбән тәгәрәмәсме? Моңа охшашлы хәл хезмәттә дан казанып, зур орден алуга ирешкән бер мастер белән шушы ук идарәдә бер булып алды бит инде. Юк, кабатланырга тиеш түгел!

Минем озак кына дәшми-тынмый уйчанланып ятуымның серен күршем, әлбәттә, сизми. Ул әле һаман татлы яшьлек елларыннан аерыла алмый, ахры, шыпырт кына сөйләнә бирә:

— Әйе, бар иде минем ул чагында Буровик кушаматлы алашам. Бик акыллы, бик күндәм ат иде... Ә хәзер вертолет дибез, каһәрләп ятабыз үзен... Эх, замана-заманалар! — Ләкин бер мизгелдән мастер дамбадагы реаль халәтенә кайтты, ахры: кинәт йодрыгы белән комга сукты.— Безне алмага киләме инде ул, юкмы, иблис өшкергән нәрсәкәй!

— Син, мастер, иблисне күптән телгә алырлар! — Ни күрик, янәшәдә күн тужуркалы егет басып тора. Авызын ерган.— Әнә карагыз: күренде инде канатсыз саескан!..

Чынлап та, Олы Урман ягыннан, шактый түбән төшеп, болай таба бәләкәй генә чебен очып килә иде кебек. Үзе торган саен зурая бара. Инде гөрелтесе дә абайланды...

Без һәммәбез дә урыннарыбыздан куптык та, дуамалланып, һавада берет-кепкаларыбызны болгарга тотындык...

## Соңыннан...

Ике атналап вакыт үткәч, мин Шәймөратовны Алабугада Беренче май демонстрациясендә очраттым. Әлбәттә, аны бәйрәм белән котладым. Хәер, бәйрәм белән генәме? Аның бригадасы акчалата шәп кенә премия, ә мастер үзе «Татнефть» берләшмәсе җитәкчелеге тарафыннан исемле алтын сәгать белән бүләкләнүе хакында да ишеткән идем инде. Түгәрәк бите җәелгән иде күршемнең...

Демонстрациядә Шәймөратовка идарәнең байрагын илтүне тапшырганнар иде. Габделхәй аны, таза, егәрле кулларында тотып, җиргә салмак, әмма ышанычлы баса-баса, колонна алдыннан җилфердәтеп барды...

Алда исә җәй иде. Галәмәт эссе һәм коры, галәмәт хәтәр җәй. Табигать җәһәтеннән караганда да, хезмәт кайнарлыгы җәһәтеннән килгәндә дә, хикмәтле хәлләр. Эшчәннәр өчен чын-чынлап авыр сынаулы җәй...

Июнь башларында яман давыл котырынып алды. Кама буйларында моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән дәһшәтле туфан... Әллә ниләрне кырды-җимерде, астын-өскә китерде. Кызыл Тау янындагы дамбада урнашкан буровойлар — Вася Сельсковныкы да, Габделхәй

Шәйморатовныкы да — электр энергиясез калды, шулай ук елганың бу як ярындагы байтак скважиналарда нефть суырту тукталды: давыл Боровецк урманында «җен туе» уйнап, исәпсез агачны аударган һәм, шул сәбәпле, урман аша узган югары вольтлы линия әллә ничә чакрымнарда сафтан чыккан иде. «Кама буе нефть һәм газ идарәсе»нең төзүчеләре белән электриклары, ярты ай чамасы диярлек көнне-төнне ялгап, өр-яңа электр линиясе сузып чыкты. Үз-үзеңне аямый эшләүнең матур бер үрнәге булды бу...

Ә буровойдагы хәлләр? Һәр ике буровойда да, дәһшәтле туфан котырган чакта, инструмент тирән забойда була. Куәтле энергия югында инструментны, әлбәттә, күтәртү мөмкин түгел. Берничек тә! Тик бер нәрсә көн кебек ачык: әгәр кыйммәтле вакытны йокымсырап уздырсаң, бу авыш скважиналардагы буровой инструментлар җир катламнары эчендә, инде суыртып ала алмастай булып, кысылып һәм томаланып калачаклар. Күпме хезмәт, күпме тырышулар, никадәр средство — барысы да җилгә очачак... Юк, йоклап калырга ярамый. Бик тиз арада Алабугадагы базадан берничә агрегат китертәләр дә скважиналарда су һәм измә циркуляциясен яңарталар. Туктау юк, тын алу юк,— каты басым астында су белән измәне кудырта бир! Төнлә дә, көндезләрен дә... Ике атна буе!

Бөтен бораулау идарәсе тын кысып көтә кала: ни булыр, җиңә алырлармы-юкмы? Әлеге буровойларга энергия тоташтыргач, һәммәсе дә җиңел сулап куя: җир катламнарының куркыныч кочагыннан хәвеф-хәтәрсез генә котыла тегеләр. Кешеләрнең чыдамлыгы һәм осталыгы табигать стихиясеннән өстен чыга...

Ләкин шушы авыр җәй китергән кыенлыкның баласы гына була әле бу, шәйморатовныкыларны тагын да хәтәррәге, тәмам җелекләрне киптерердәе, алда көтә...

Монысы Алабуга мәйданында була. Эсседән төсе сорыланган август аенда. Бу чыганак әллә ни байдан түгел үзе. Әмма үтә холыксыз, үтә көйсез. Катламнардан газ бәреп чыгуын көтәләр. Шул сәбәпле бораулау технологиясе дә беркадәр катлаулана төшә. Ләкин газ бәреп чыкмый. Кешеләрне афәтнең бүтәне көтә, алар бертөрле тозакка эләккәндәй булалар: тирән забойда инструмент кинәт кысылып кала — яман прихват... Ә бит инде җир куенына бер чакрымнан артык төшкән булалар. Сүгенүдән файда юк. Янә акыл көчен, сабырлык һәм чыдамлыкны җигәсе... Җигәләр — җиңәләр!

Бу бәладән шулай мең мәшәкать белән булса да котылалар котылуын, әмма, шуңа ук ялганып, икенчесе башлана: катлам измәне йота. Җиткерер әмәлләр юк. Скважинаны цемент белән катыралар, янә бораулыйлар, янә измә эзсез югалып кала. Тагын цемент коялар, тагын... — җир куенында мәңге туймас убыр ятамыни!

— Бүтәннәр туктаусыз тирәнгә төшә тора, ә мин, киресенчә, һаман өскә таба чигенәм... дөнья ягтысына таба,— диебрәк шаяртып алды Габделхәй күңелсез генә. Аның бер кичкә генә булса да өенә, семья җылысына кайтып килеше иде. Адымы салмак, авыр. Үзенең гәүдәсе дә салына-шәлперәя төшкән, күзләре чак кына кызарган, карашында коры зәһәрлек тә бар сыман. Йокысыз төннәре аермачык сиздерә...

Әйе, ул скважина үзенең үтә яман холкын күрсәтә иде. Ә бораулаучылар үз характерларын... Ләкин монысында да кешеләр өстен чыкты. Бирешмичә, чын ирләрчә...

Бу хәлләрдән соң инде байтак вакытлар үтте.

Менә мин янә Габделхәй буровоенда. Бу юлы да әллә кайда түгел, Кызыл Тау тирәсендә. Ләкин дамбада да түгел — ун чакрымга сузылган бу дуга-дамбадагы скважиналарның тишәрдәе тишелеп беткән инде. Нефть биреп яталар. Шәйморатов буровое текә янлы, җыйнак кына «бәлеш» сыман утраучыкта калкынып утыра. «Бәлешне» ике-өч

ел әүвәл земснаряд өйдергән. Разведкадан калган нокта... Утрауның итәген калын боз астыннан Кама суы юып-сыйпап ята.

Кыш уртасы. Буран. Ә монда чираттагы скважинага «нокта куйганнар» икән. Габделхәйнең җилдә кызарган түгәрәк йөзен юка сакалмыек баскан. Әмма күршемнең күз карашы нурлы, куанычлы.

— Забой дисеңме? Әнә анда, Кама уртасыннан да ары... Моннан өч ел элгәрерәк шушында сул як ярдагы беренче скважинаны да миңа башлап җибәрергә туры килгән иде, инде азаккысын да безгә бетерәсе булыр. Тагын нибары өч нокта калды. Җәйгә тикле, ныклап тотынсак, Беренче май мәйданы, шулай иттереп, вәссәлам бу як ярда...

Әллә ничә дистә скважина бораулангап һәм шуларның иң зур күпчелеге — шәйморатовныкылар тарафыннан. Җитмәсә, яртысыннан да күбрәге бетмәс мәшәкатьле кыеш скважиналар. Әнә шундый хәлләрдә дә бу бригада идарәдә һаман да алда бара икән. Горурланмаслыкмыни кешегә!

— Аннары кая? — дип сорыйм мин.— Әгерҗе районына туган авылың туфрагын борауларга түгелме?

— Юк шул. Җибәрмиләр әле... Иң башта Суык-су чыганагын, диләр. Бусы кайдадыр Чаллы артында. Шулай булгач, озакламый шаулап-гөрләп торган КамАЗ җирләре аша йөрергә туры килер әле безгә, туганкай...

Мин җиргә биштәрне куям, боз боравымны рәтләргә тотынып, мастерга жумба балыгы турында әйтәм, тәмле ухаиы исенә төшерәм.

— Син зинһар гафу ит инде. Өйдә көтәләр мине. Кичен партком утырышы, диләр. Аннары мәктәпкә ата-аналар комитетына да барасы.

— Җилкәң калын, әйдә, җәмәгать йөген тарта бир! — дип көлемсерим мин, әмма шундук борынны җыерам: — Тик шунысы кызганыч: бу юлы тагын буровоеңда уха белән сыйлап булмый икән үзеңне...

— Үпкәләмә, дим... Мә ачкычны, будкага үзең хуҗа бул инде.

Ул арада яңа вахта да килеп өлгерде. Монда инде гадәти күрсәтмәкиңәшүләр...

Югарыда буровойның корыч конструкциясендә җил ыжгыра. Озакламый җил ыжгыруына куәтле тракторларның шау-гөрелтесе кушылыр: монтажчылар буровой станогын ун метрлар чамасы читкәрәк шудырып, яңа ноктага утыртачаклар. Фидакарь хезмәтнең яңа ноктасына — оеткысына...

Кама аша сузылган юлга күпләп кар салган. Тездән ерасы. Юлның чит-читләреннән чыбык маяклар тезелгән. Эштән бушаган вахта юл буйлап бер җепкә сузылды. Кешеләр, җилдән бөгелә һәм янтая төшеп, тирән карда ава-түнә атлыйлар. Арада мастер Габделхәй дә... Аръякта, «Тын таулар» итәгендә, аларны Алабугадан килгән вахта автобусы көтә. Озакламый, нефтьче пәһлеваннарны кар бураны үз эченә йотып та алды...

Алда ни көтә аларны? Тик бер генә нәрсә көн кебек ачык: аларга — скважиналарга да, кешеләргә дә — үз характерларының ныклыгын әллә ничә мәртәбәләр күрсәтергә туры киләчәк әле...

Шулай, җир-әнкәбез куенындагы «кара алтынга» юллар бер генә дә җиңел түгел. Бик авыр, бик четерекле... Бу хәл бер Кама буенда гынамы соң?

Алабуга — Чаллы, 1972—1974.

## Рахмай Хисмәтуллин

# БӘЙРӘМ БЕЛӘН, ДУСЛАР!

I

Иләмсез зур, авыр масса гөрселдәп таш идәнгә килеп төште. Цехтагы барлык эшчеләр иркен сулыш алып уфылдап куйдылар.

Барлык ыгы-зыгы әнә шул күбенеп үлгән сыерга охшап идәндә җәелеп яткан пешмәгән каучук кисәгеннән башланды. Аны алдагы смена әзерләп җиткермичә, Андерсен агрегаты казанында калдырып киткән иде.

Мондый ыгы-зыгылы вакытта цехның бөтен килеп җитмәгән ягы синең нервыңа тия. Ничек моңарчы игътибар итмәгәннәр соң әле болар? Коточкыч тавыш икән бит монда. Пресслар чыелдый, насослар улый, триер дырылдый, газы да борынны бик әчеттереп, үпкәләрне яндырып керә сыман...

Ритмнан, стабильлектән бер чыккан технологик агым барыбер кысасына кермәде, ул тагын башка узелларны ватарга, җимерергә тотынды. Әнә тагын бер насос киреләнде һәм «ачуланып» бөтенләй яньп чыкты. Запас насосны ходка җибәрү булды, басымнар кинәт бер күтәрелә, бер төшә башлады. Тагын фильтрлар тыгылган иде. Ахыр чиктә агрегатның күчәре сынып чыкты.

Дегазация бүлеге дә газны тигез бирми иде. Идарә пультыннан газ бирүне бөтенләй туктатырга дигән боерык яңгырады...

Цех эчендә утыз алты градуска җиткән көн эсселегенә Андерсен агрегатларының эссесе һәм зәңгәр газы кушылып, янгын вакытындагы кебек мәхшәрле, костыргыч авырсу, тәмсез исле һава эленеп калды.

Андерсен баскычыннан төшеп килгән өлкән аппаратчы Сашаның изүләре чишелгән, беләкләре сызганылган, маңгае, битләре буйлап шыбыр тир ага иде.

— Әгәр гомер буе болай эшләсәң, бик тиз аягыңны сузарсың. Ай-яй-яй, өч сәгать буе бер «сыерны» ват, имеш. Болай булса, яшьләр тормас монда, тормаслар... Илнур, бар әле, Хәмзәне чакыр! Киңәш итешеп алыйк,—диде Саша.

Эшчеләр, ярык тагарак янындагы карт сыман, моңаеп баскычларга утырыштылар. Колаклар чыңлавы һаман туктамады, күңел уйнаклады. Барысы да ачулы, нервылы һәм кемгәдер үчле иделәр.

Алар янына, тирләп, япып-пешеп, смена начальнигы Хәмзә Галимов килеп җитте. Ул, ничектер, арыган, каушаган, бик борчылган иде.

Барысыннан да ныграк ярсып эшләүче Саша сүгенә-сүгенә инженерлардан зарланды:

— Менә шушы чатыр арбаны — Андерсен агрегатын да юньләп көйләп җибәрә алмагач, нигә дип укыталардыр бу инженерларны, Хәмзә туган, ә?! Шушылай маңгайдан тир сыпырып эшләү өченме? Без әнә Илнур соңга калган саен сүгеп кызарткан булабыз, ә ул нишләсен? Ул яшь кеше, чыныкмаган кеше. Мондагы авыр эштән арый ул, ял җитми аңа. Аның урынына ләчтит сатып утырырга яратучы кайбер инженерларның тетмәсен тетәргә иде. Әнә Нурмый Иванычның үзенә өстерәтергә кирәк бу сыерны.

Хәмзә бу сүзләрне, үз адресына да әйтелгәндәй, уңайсызланып тыңлады. Ләкин үпкәләп яисә сүз көрәштереп торыр чак түгел. Һәм эш күрсәтмичә торып кемнедер сүгеп йөрүдән берни дә үзгәрмәсен ул яхшы аңлый. Аны бер генә уй, бер генә теләк алга дәшә, чыбыркылый, ярсыта. Күңеленнән аның йодрыклары төйнәлгән һәм ул ярсулы теләкләр тәкрарлый: «Агрегатлар эшләргә тиеш!» «Берникә дә карамастан эшләргә тиеш!» «Без сынатырга тиеш түгел!».

— Саша дустым! Аңлыйм мин сине, сүзеңдә хаклык юк түгел,— диде Хәмзә, кулын аның җилкәсенә куеп.— Ләкин бүген күп сөйләшеп торыр чак түгел. Давай, хур булмыйк, яңабаштан бөтен узелларны карап чыгыйк. Калган сәгать ярым эчендә агрегатларны башка сменага булса да эшләтеп калдырыйк!

Саша, бик ачуы чыккан булса да, Хәмзә белән килешми булдыра алмады. Дусты бит. Хак сөйли инде.

— Ярар, хуш, егетләр, алайса тагын тырышып карыйк әле,— диде ул, башын иеп.

Хәмзәнең күз алдыннан йөкләмә алу җыелышы йөгереп узды. Чыннан да, ул чагында цех начальнигы Нурмый Иваныч ни өчендер Галимов сменасына артык зур өмет баглап сөйләмәде. Күпчелек башка сменаларны алга куйды. Аларны мактады. «Ну что ж!» дигән иде Хәмзә эченнән генә. «Без дә Кузбасс шахтерының холкын күрсәтербез әле!»

Эшчеләр, Хәмзәнең дәртле итеп эшкә кушуыннан яңа көч алгандай, яңадан тыз-быз эшкә керештеләр. Бер сәгатьтә көч-хәл белән бер агрегатны яңадан эшләтә башладылар.

Әмма эшчеләр дә, Хәмзә үзе дә эт булып арыганнар иде бүген...

## II

...Язгы матур көн булуына карамастан, трамвайга кереп утыргач, сменадашлар бер-берсенә бер сүз дә катмыйча, һәркем үз уенда тирбәлә-тирбәлә кайта бирделәр.

Хәмзә алдындагы утыргычларда саф һавада эшләгән алсу йөзле төзүчеләр үзара сөйләшеп, рәхәтләнеп көлешә-көлешә шау-гөр килеп кайталар иде. Берсенең сүзе Хәмзәнең күңеленә уелып керде.

— Тукта, тукта, дускай, син саный белмисең,— диде ул иптәшенә.— Зарплата плюс 15 процент уральски плюс сандугачлар сайравы да плюс шомырт чәчәкләренең хуш исе... Соңгы икесе инде, туганкай, минем беркем дә тартып ала алмый торган премиальниләрем!..

Үз эшләренең яхшы шартларына куанышып, шаярыша иде булса кирәк алар.

Әйе, бик гыйбрәтле көн булды бүген Хәмзә өчен. Дөрес шул. Аның үз кул астында эшләүчеләре турында һаман да ныклап уйлап

бетергәне юк шул әле. Аларның д., каучук цехын эшләтергә керешеп, проект куәте артыннан куа башлаганнан бирле, Хәмзә кебек үкулларына китап тотып караганнары, юньләп кино-фәлән күргәннәре юктыр. Менә бу сандугачлар тавышын тыңларга бергәләп табигать кочагына да чыкканнары юк. Арыта, техника көйсезлеге җәфалый... ә төзүчеләр әнә саф һавада сандугачлар тавышына иркәләнү өстенә 15 әр процент өстәмә түләү дә алып яталар.

Ә химикларга нигә юк ул?

Бу хәлне җитәкчеләр беләләрдер дип көтеп яту инде бу. Щекино методының кертелүе дә аңлашылып бетми. Бер эшче ике-өч кеше өчен тырышып эшли, ә нишләптер, аның хезмәт хакына бернинди дә өстәмә түләү ясалмый. Бу бит матди кызыксындыруны юкка чыгару. Ахыр чиктә энтузиазм да сүнәр ул.

Әнә Әхмәт белән Ринат каядыр кучәргә чамалап йөри башладылар бугай инде. Комсомол-яшьләр сменасында Хәмзәдән дә өлкән башка берәү дә юк, бу турыда ул дәшми кем дәшсен.

...Әһе, иртәгә Лемаевта планерка бит, тагын тәкъдимнәр сорарлар инде...

Трамвай тәгәрмәчләре борылышта чыелдашып, елашып алдылар, аннары тагын рәхәт тирбәтеп Биклән тавыннан түбән тәгәрәделәр.

Инженерларны тәнкыйтьләгәндә Саша бераз хаклы да, хаксыз да тоелды Хәмзәгә. Уйласаң, бүгенге менә бу бөтен техника алар хыялы, алар исәп-хисабы белән тудырылган бит. Трамвай тирбәтеп алып кайта икән, сине инженер да тирбәтә бит. Алар арасында төрле кешеләр булуы—бусы инде икенче мәсьәлә. Хәмзә үзе, мәсәлән, беркайчан да инженер булырга хыялланмый иде. Әтисе кебек гади шахтер була алса, аңа шул җиткән иде. Әмма тормышның агымнары аны яңа юлларга кертеп җибәрде...

### III

...Әтисе Җәләй ага Хәмзәгә: «Улым, әйдә кайтыйк Татарстанга, туган җирләрне мин бик сагынам»,—дип күпме генә әйтмәде, әмма улының башта артык исе китмәде. Әйе, Татарстанның кайсыдыр бер авылында туган әтисе өчен анда серле сабый чак планнары, дәртле бала чак чишмәләре, якты яшьлек моңнары бардыр. Ә Хәмзә бит шушы Кузбасста туды, шушындагы шахтер малайлары белән аралашып үсте, шушы төтенле шәһәрнең һавасы аның канына сеңде. Инде Хәмзә хәзер үзе әтисе белән бергә шахтада эшли, күмер вата. Илгә бер дигән ягулык чыгара. Чын шахтер булып эшли башлавына да инде аның биш ел тулды. Монда аны ихтирам итәләр, бәйрәм саен яхшы эше өчен бүләкләр бирәләр. Футбол командасында да ул яхшы уенчыларның берсе. Аңа тагын ни кирәк соң?

Ләкин беркөнне туган ягы турында көннән-көн күбрәк сөйләнә башлаган әтисе аны әйтерсең лә сихерләде дә ташлады. Бөтен тирәюнь чәчәкләргә күмелгән июнь көне иде. Хәмзә өйгә кайтып кергәндә әтисе үзе кебек үк укалы түбәтәйләр кигән дус-ишләре белән күңелле генә бәйрәм итеп утыра иде. Әтисе туган ягыннан бер хат та алган икән. Ул ничек итеп аны якташлары сабан туйларына чакырып язганнарын зур горурлык белән кат-кат укып чыкты да түзмәде:

— Эх, улым! Синең бит безнең җырларны да рәтләп ишеткәнең булмады, дөнья кудык шунда. Гомер узган менә. Тыңла әле, улым, бер уйныйм мин сиңа безнең сабан туе көйләрен,—дия-дия, әллә кайчаннан бирле сандык төбендә тын яткан көмеш телле тальянын тартып чыгарды һәм егерме сигез ел буе күмер чапкан, күмер тузаны сеңеп бөртек-бөртек каралган, буын-буын каткан бармаклары белән,

дөньяның иң изге телләренә басарга хокукы барлыгын белдереп, өздереп-өздереп уйнап җибәрде. Уйнады да, җырлады да карт шахтер, үзәкләрне өздереп уйнады. Йөрәкләрне тетрәндереп җырлады. Авыл көенә. Саф, бер риясыз туган як көенә. Меңләгән шахтерларның иң газиз йөрәк моңы сеңеп калган шахта көенә.

Без барасы тал арасы,
Сайрый былбыл баласы.
Туган илем гөл арасы,
Үзем авыл баласы.

Хәтта Хәмзәнең күңелен дә әллә нишләтте бу җыр. Ә инде күңелле генә утырган абзыйларның бу моң астында кинәт дөньяларын онытып, карашларын әллә нинди еракларга төбәгән йөзләренең яктырып, матурланып китүен, энисенең, башкаларга сиздермәскә тырышып, күз яшьләрен сөртүен күреп алгач, йомшады да калды егет күңеле. Матур икән бит этиләр моңы, рәхәт икән бит аны тыңлавы! Хәмзә моңарчы игътибар итмәгән тирән мәгънәләр, яшәү көче, ярсу дәртләр бар икән бит бу моңда.

Шушы көнне Хәмзә үз җилкәсендә ата-анага тиешле бурычны тойды, үз-үзенә аларны туган якларына алып кайтырга сүз бирде...

Ул иң беренче Казанга бер кардәшләренә кайтып төште. Башта бер заводка фрезерлаучы булып эшкә керде. Казан кызы Миңзифага өйләнеп җибәрде. Аннары алтмыш өченче елда алар парлап яшьлек шәһәре Түбән Каманы төзергә китеп бардылар. Әллә өйләнү айнытты егетне, әллә этисенең туган ягы уятып җибәрде, аның тормышында рухи яңару язлары ачылды.

Кузбасста чагында әллә ничә мәртәбә башлап ташланган кичке укуга ул яңадан ябышты. Элек укый алмый, укыйсы килми җәфа чиккән, икеледән, өчледән дә югары күтәрелә алмаган Хәмзә зиһене артканын, укырга дәрте ташып торганын тойды. Ул, комбинат төзи-төзи, кичке урта мәктәпне бик җиңел генә тәмамлады да куйды. Аннары бер күңел уянганда, рух күтәренке чакта сынап карыйк әле дип, Казан химия-технология институтына читтән торып укырга имтихан бирергә барды. Менә тамаша! Бирде бит аны да! Кайчандыр уку дигәндә йөзе чытылган Хәмзә студент булды.

Комбинатта кадровый эшче булып эшли торып, үзәк газ аеру установкасын, изопрен-мономер цехларын сафка кертешә торып, иң яхшы футболчы булып уйный торып, укырга да вакыт тапты. Үзенә нәкъ 32 яшь тулганда инженер-химик-технологлыкка диплом алды. Ул диплом алды! Гади шахтерны туган җире көтмәгәндә, уйламаганда инженер итеп күтәрде.

...Трамвай талгын гына тирбәтә дә тирбәтә Хәмзәне. Авырлыклар аша, ныклы физик хезмәт аша үскәнгәдер, күрәсең, инженерның кем икәнен, нигә кирәклеген бик яхшы аңлап, төшенеп барды. Аларның төрлесен күрде. Яңа гына институт бетереп килгән яшь инженерларның кайбере тәүге көннәрендә эштәге шаблонлыклар, фикерсез катып калганлык очраклары белән килешмичә, авызлыгын чәйнәп өзәргә җыенган тай кебек чыгымлый, үзенә аерым бер иҗат шартлары таләп итә. Ләкин тора-бара, моның мөмкин түгеллеген аңлап, кайсы кая иске, тапталып беткән юлларга сибелә. Бер өлеше, иҗадилыкка нык омтылганнары, тикшеренү институтларына, заводның аерым иҗади бүлекләренә урнашып кала. Икенче берләре уйлап табылган яңалыкларны тормышка ашырырга алына. Линиядә эшли. Бу икенчеләре дә күпмедер дәрәҗәдә иҗат уты, иҗат хисе белән яналар. Боларда да инженер исеменең яме сүнми әле.

Әмма кайсы гына предприятиене алма, анда өченче бер категория инженерлар булыр. Боларның эше сан актарып утыруга, отчетлар

язуга, кирәкле әйберләрнең исемлеген төзүгә, югарыда утырган начальнигы өчен справка сызгалауга кайтып кала.

Ә бит һәр инженер каршында никадәр ачылмаган серләр диңгезе, никадәр чишелмәгән проблемалар тора! Дөнья чиксез серләр белән кайный, мәңге әйләнә. Аның әйләнүе үзе энергия, һава — энергия, атомнар — энергия. Бөтен нәрсәдән энергия тулышып агыла, болгана. Әгәр син инженер икәнсең, бул фидакарь, менә шушы мәңге әйләнүче дөньяның энергиясеннән кешегә файдалы көч-куәт яса, шушы хаосны, шушы туктаусыз хәрәкәтне кешегә иң дәвалы, иң рәхәт юнәлештә авызлыкла! Архимедлардан алып Курчатовларга, Сәгъдиевләргә кадәр булган акыл һәм ачышлар хәзинәсенә синең дә өлешең керсен!

Әйтик, менә бу чит илдән кертелгән Андерсен аппаратлары да улкадәр ис китеп сөйләрлек нәрсәләр түгел. Эшчеләрнең нинди шартларда эшләүләренә игътибар итми торган машиналар. Алар бер 10 — 15 елдан автомобиль янындагы чытыр арбалары гына булып калачаклар.

Ничә тапкыр инде Хәмзә, ап-ак шомыртлы язгы урманның хуш исенә исереп йөргәннән соң, каучук цехына килеп кергәч, борынга килеп бәрелгән авырсу газ исеннән күңеле болганганын тойды. Ә бит эш урынында үзен хуш исле әнә шул язгы урманда кебек хис итә ала. Һәм шулай итәргә тиеш! Ул яшел болыннарны, ямьле урманнарны мәңге сагынып кына яшәмәскә тиеш!

Юкса, киләчәкнең ерак түгел бер баскычында аны һәлакәт сагалавы мөмкин. Химия заводлары тыелгысыз арта торса, атмосфераның тереклек катламы зарарланып, кешелек бөтенләй яшәүдән туктарга мөмкин. Хәзердән үк инде кайберәүләрдә бу газ белән биологик сыешмау, ярашмау бар. Әнә училище тәмамлап килгән Гөлназ дигән яшь-яшь матур кыз шуның аркасында гына яраткан эшеннән китәргә мәҗбүр булды.

Һәм инженер, әгәр ул чын инженер икән, менә шушы каршылыкларны да җиңү өстендә эшләргә тиеш!

Әйе, уйлап табам дигән кешегә менә шушы каучук цехында да әлләә никадәр чишелмәгән проблемалар тулып ята.

...Иртәгә генеральный директордагы планеркада рационализаторлык тәкъдимнәре турында да сорарлар инде...

...Трамвай яңа шәһәргә керде...

## IV

...Кичке аштан соң бүген, нишләптер, арулар бөтенләй онытылгандай булды. Хәмзә, һәр көнне үзен сагынып көткән кызларыннан качып, эш бүлмәсенә кереп бикләнде. Ләкин кызлары, сизенеп алып, ишеккә сарыла-сарыла кычкырып еларга, ялварырга тотындылар.

— Әти, бикләнмә!

— Әти, ач, ач, әти!

— Әти, әйдә, лошадка бул!

— Әти, әйдә, поезд бул!

Бергә сөйләшеп утыруны, бергәләп уен-көлкене яраткан хатыны да артыннан кычкырып битәрли башлады:

— Һәй, әтисе, синнән барыбер академик чыкмас, юкка кереп бикләнеп маташасың. Ач инде! Инженер булуың да бик җиткән. Елатма инде кызларны!

Әмма Хәмзә җавап бирмәде. Ул инде күптәннән эшли башлаган сызымнарын, исәп-хисапларын өстәлгә җәеп салды.

...Әйе, бу Андерсенда уйланып җитмәгән нәрсәләр буа буарлык. Хәтта концентраторда каучук валчыкларының тирәнлеген үлчәү өчен штанга да юк иде бит. Хәмзә тәкъдим итте, эшкә ярады.

Әле менә бу сызымнарда да концентраторда барлыкка килеп җанга тиюче «кәҗәләрне» кимету турында бер тәкъдим. Хәзер әле каучук валчыклары укмаша башлагач, шактый еракта урнашкан дегазация бүлеге операторы кранны ачып концентраторга кайнар су җибәрә. Ләкин дегазация бүлегенә хәбәр итеп, аннан кайнар су килеп җиткәнче шактый кыйммәтле секундлар әрәм була, «кәҗә» ныклап укмашырга өлгерә.

Шунлыктан Хәмзә Андерсен аппараты торган шушы ук бүлмәдәге насос коллекторыннан концентраторга туры торба үткәрүне мөмкин һәм отышлы дип тапты. Болай иткәндә Андерсен янында торган аппаратчы үзе үк ашыгыч рәвештә кранны ача ала һәм алтын минутлар янга кала...

Сызымны укый-укый, Хәмзәнең күзе ватман кырыйларына төште. Кинәт андагы язулар аны көйдереп алгандай булды. Ватман читләренә:

Эх, Нурмый, Нурмый, Нурмый,
Эшең бер тиен дә тормый...—

дип бик күп мәртәбәләр язып тутырылган иде. Эх, шайтан алгыры, тагын шуның белән чәкәләшергә туры килер микәнни инде? Бу сүзләрнең тарихы хәтергә килде...

Беркөнне Хәмзә, «кәҗәләр» белән бик иза чиккән егетләрен, транспортер һаман да көйләнеп җитмәү аркасында каучук брикетларын складка күтәреп ташыган яшь кызларын кызганып, бер-бер хәл үзгәрмәсме дип, цех начальнигы Нурмый Иваныч янына кергән иде. Үзе белән бергә инде ай ярым баш ватып сызган шушы сызымнарын да алган иде.

Нурмый Иваныч Хәмзәнең киңәшләрен ачыктан-ачык шикләнеп каршы алды.

— Да-а... Мин дә цехлар гөрләсен өчен бик тырышам. Ну, слушай, син үзең дә бала түгел бит, аңлыйсың: монда конструкторское бюро што ли? Бездән биш баш өстен торган кешеләр уйлап тапкан агрегатка тот та үзгәртү керт, имеш. Мин моңа һич тә юл куя алмыйм. Под суд што ли безгә бергә?

— Нишләп алай булсын, Нурмөхәммәт Ихсанович! — диде Хәмзә, гаҗәпләнеп,—һәр производство камилләшергә тиеш. Әгәр бу чытыр арбадай агрегатларны үзебез үзгәртә тормасак, безгә монда японнар яисә америкалылар килеп фикер бирмәс. Алар бу машиналар өчен сыгасы алтыннарны сыкканнар инде.

— Да, син, брось, Хәмзә, международныйга тыгылуны! Турысын әйткәндә, слушай, мин синең белемеңә, во-первых, ышанмыйм. Син бит менә абыеңнар кебек,—ул үзенә ишарә иткәндәй булды,—институтларда очно торып укымаган. Син бит эшли-эшли, заочно гына, катыргы өчен генә укыган кеше.—Бу Нурмый Иванычның кайбер цех җыелышларында аны тәнкыйтьләгән өчен Хәмзәгә үчләнүе иде, ахры.—Менә син институтны с отличием бетергән башковитый малай булсаң иде, яисә техник фәннәр кандидатлыгына диссертация якларга җыенсаң иде, менә андыйга ышанырга булыр иде. Аннары, өстән башлап башкалар йөрсә дә другое дело. Так что, давай, пока эш барганда эшлә,—дип, ул сүзен тәгәлләде.

Хәмзә, эченнән генә сүгенә-сүгенә, гомерендә беренче мәртәбә, ишекне шапылдатып ябып чыгып китте.

«Иҗат рухы тәмам кипкән, тәмам корыган бу кешедә,—дип уйлады Хәмзә.—Постыннан бәреп егарга җыена бу малай, дип уйлый инде әллә? Кешеләр ничек шулай салкын җанлы була алалар икән?.. Үз ягына каерырга дигәндә алар бернидән дә тартынмыйлар, премия калҗаларының иң симезләрен эләктерү ягын карыйлар. Үз кешеләрен күтәрергә тырышалар. Әле менә аның пешмәгән бер кадры аркасында каучук «кәҗәләрен» ваткалап гомер уздыралар бит».

Сызым кырыена Нурмый турындагы икеюллыкларны бик күп тапкыр язып чыккач кына, ачуы бераз сүрелә төшкәндәй булды.

...Аннары көн артыннан көннәр узды. Ул бик ямьсез төшенкелекләргә бирелеп алды, янып йөрүләреннән Хәмзә үзе үк көлә башлады. Һе, юләр мин. Чыннан да, бу коточкыч гигант производствоны ул берүзе ничек үзгәртсен инде. Ярар әйдә, сменасы үтсен дә, как-нибудь акчасы килеп торсын. Подумаешь!..

Әйе, кеше күңеле әллә нинди уйларга керүчән, әллә нинди сагышлы чигенүләргә бирелүчән шул ул. Бөркет булып ыргылган күңел кайчак елан булып та шуыша, эреп бала назлаган күңел кешене тиргәп тә ташлый ала бит. Ләкин бу хәлләр нинидер каһәрле минутларда булалар... Ул минутлар үтә. Кеше айный... Реаль дөньяга кайта, үкенә... Соң була...

Хәмзә дә соңыннан үзенең «акчасы килеп торсын әйдә» дигән уйларыннан җирәнеп йөрде. Ләкин сменадашлары цехтагы торгынлыкны хәл итәргә кирәк иде дип исенә төшергәләсәләр дә, ул үзенең тәкъдиме турында сөйләшергә дип һаман беркая бармады. Ай-һай, нечкә нәрсә бит ул зарланып йөрү. Аның башы ике яклы. Бер дуамал җитәкчегә туры килсәң: «Әһә, кеше өстенә гаеп атып, үзеңне акларга, үзеңне өстен чыгарырга тырышасыңмы», дип, шундук үзеңне гаепләп ташларга бер тиен дә сорамавы мөмкин. Шунлыктан Хәмзә, гомумән, кемнеңдер кем өстеннәндер жалоба белән йөрүен түбәнчелек саный һәм аның эш өчен артык файдасын күрми иде. Аннары бит тормышны жалобалар алга этәрми, аның үзенең куәтле дулкыны күп нәрсәне чишеп ташлый. Чүпләрне яр читенә чыгарып ата, кирәген шаулатып агыза.

Беркөнне Хәмзәнең өенә яңа гына аппаратчы булып эшли башлаган кызның анасы килде. «Кызым төннәрен саташып йоклый, кнопкаларга бас, бас тизрәк!—дип төшендә кычкыра.—Бер-бер хәл булмадымы аңа эшендә?»—дип сораштырды ана борчылып.

Ә беркөнне күптән түгел тормышка чыккан яшь киленнең ире Хәмзә янына килеп китте. «Авырлы хатыннарга бу цехта эшләү зыянлы түгелме?» — ди. Ә Хәмзә ничек җавап бирә алсын аңа? Аңа врачлар да җавап биреп бетерә алмыйлар. Күпмедер дәрәҗәдә зарарлы булмый каламы соң инде... Шуңа да бит аларны зарарсыз җиңел эшкә күчерәләр.

Монда күзгә күренми торган басымнар дөньясы. Әгәр дә күңелләрдә дә шундый ук игътибар басымы булмаса, нәкъ менә шул игътибарсызлыгы аркасында ябылмый калган задвижкадан, туктатылмаган стоп-сигналдан, артык бирелгән газ басымыннан дистәләгән кешеләрнең һәлак булуы мөмкин.

Монда басымнар күңелгә, йөрәккә, гомергә тәбәлгән.

Шуңа күрә дә монда иң төгәл күңел тәртибе, иң сыналган тойгылар мәктәбе кирәк.

Шуңа күрә дә Хәмзә кешеләрнең ул басымнар белән идарә итә алу-алмауларын күзләреннән укырга өйрәнде. Блокнотына һәрберсенең психик дөньясын—туган елын, семья хәлен, нинди китаплар укуын, нинди хисләр кичереп йөрүләрен яза барды. Шулай итеп, аның күз алдында әкренләп һәрберсенең холкы пәйда булды...

Хәмзә беркайчан да, беркем дә эшкә эчеп килми торган, соңга калмый торган, корыч тәртипле катгый обстановка тудырды.

Менә шундый чакларда ничек жалоба артыннан йөрисең дә ничек вакланасың...

...Хәмзә тагын сызымнары читенә ярсып-ярсып язылган тәнкыйть сүзләрен укыды. Ул вакытта хисләр өстенлек иткән булган шул. Ә менә бүген ул күңелендә башка дөнья туып өлгергәнен аңлады. Бүгенге Хәмзәне син туктатып кара! Ниһаять, аңарда тормыш үзе корыч ихтыяр көче тудырды... Нурмые булмый хет чурты шартлап ярылсын, иртәгә бөтен комбинат башлыклары каршында цехтагы хәлләрне ярып салачак ул.

Төнге бер иде инде...

## V

...Менә комбинатның иң эшлекле кешеләре җыелган иртәнге кайнар планерка.

Монда артык сөйләүне, буш тәкъдимнәрне өнәмиләр.

Һәркем нервысына йөгән кигезгән.

Һәркемнең, йөгерештән кайткандагы кебек, тыны кысыла сыман.

Өстәл башында генеральный директор Николай Васильевич Лемаев үзе утыра. Аның бөтен кыяфәтендә—җитдилек һәм эшлеклелек. Җитәкче булып ун ел эшләгән чор эчендә беркем дә аның уртак эшкә хилаф килгән бер генә боерыгын да хәтерләми.

Менә өченче тапкыр инде күз өстендә каш булып торган каучук цехыннан смена начальниклары да персональ рәвештә планеркага чакырылдылар.

Әнә, Хәмзә. Ни хәле бар аның? Әллә сүрелгән дәме? Дөнья шулай итә ул: яндыра да сүрелдерә.

Әмма Хәмзә бу юлы сүрелмәде. Карашы Нурмый Иваныч белән очрашкач, йөрәге соңгы чиккә җитеп кысылды. Бер кызарынды, бер агарынды. Кем белә, бу Галимов артыгын таләп итә дип, гаеп итүләре дә бар бит. Нурмый Иваныч та акланып каршы төшми калмас. Әмма әйтәсене әйтми булмый инде.

Ниһаять, Хәмзә сөйлисе сүзе барлыгын кыюсыз гына белдерде. Дистәләгән ашыгыч карашлар аңа төбәлде. Ул сабыр гына торып басты да хезмәт хаклары, эш шартлары, эшне җиңеләйтү турында сөйләп китте. Сүз тирәнгәрәк керә башлагач, директор кырт сорап куйды:

— Ә сез цех начальнигы белән болар турында киңәштегезме?

Хәмзә кызарынып, каушап калды.

— Соң, сөйләшенде инде, бер генә тапкыр түгел.

— Әһе, аңлашылды...

Хәмзә тагын сүзен дәвам итте. Ул Лемаевның аңа игътибар иткән сыман «так», «так», «так!» дип утыруыннан, кайбер урыннарда баш кагуыннан ничектер кыюлана төште һәм бәлки сөйләргә дә ярамас дип шикләнеп йөргән уйларын да, Нурмый Иванычның аның тәкъдимнәрен хупламавын да сөйләп ташлады.

Директор аны игътибар белән тыңлап утырды. Башкалар да, шым булып, гел Хәмзәне генә күзәттеләр. Хәмзәнең кара чәчләре биек маңгаеның дәвамыдай бик җыйнак, түгәрәк булып өскә таба калкып тора.

Тыңлаучылар өчен гадәти булмаган бу сөйләүгә директорның ничек караячагы кызык иде.

Лемаев эченнән: без күтәрергә кадрлар җитешми дибез, бу егет киләчәктә бер дигән җитәкче булачак бит, дип уйлап утырса да, планеркага йомгак ясаганда үзенең мөнәсәбәтен сиздермәде.

— Каучук цехы турында уйланырга кирәк, — дип кенә әйтеп үтте.

Шулай да Хәмзәнең күңеле директорның эчке уен сизгәндәй булды. Йөрәккә кадалырга торган чәнечкеләр эреп юкка чыкты. Йөзендә рәхәт елмаю балкыды.

Чыкканда ул Нурмый Иваныч белән күзгә-күз очрашты. Аның карашы яшеннәр уйната иде...

...Планеркадан соң Хәмзә цехка юнәлде. Ул бүген беренче мәртәбә язгы матур көннең рәхәтлеген тойды. Әнә өй кыекларыннан шат кояш тамчылары сикерешеп төшеп бииләр. Шундый рәхәт дөнья! Каучук цехы аңа бүген әллә ничек бигрәк тә үз, якын булып тоелды. Беренче көннәр, канатланып йөргән чаклар искә төште.

Комбинатта эш сөючәнлеге белән танылган Хәмзәне диплом алу белән шушы иң катлаулы цехка чакырдылар. Ул, эшли башлагач кына, нинди авыр участокка эләгүен аңлады. Башка цехларда уңай һәм тыныч иде, төтенсез иде. Аппаратчылар, ниндидер зур чиста корабта очып барган сыман, төрле приборлар күрсәтүләрен генә язып алып, чарасын күреп торалар. Ә каучук цехында исә, моңарчы күп цехлар буйлап сыек хәлдә күчеп йөргән газ каты брикетларга әверелү сәбәпле, эш авырлаша. Бу процессны әле автоматлаштырып өлгерә алмаганнар, конвейер эшләми.

Шуңа күрә дә бу установкаларны, төрле режимнарга куеп озаклап эшләтеп карый-карый, проект куәтенә ирешү өчен өч ел вакыт бирелгән. Ләкин Хәмзәнең болай озаклап көтәсе килмәде. Ярар, шушы Андерсеннар Кушма Штатларда сәгатенә 4,2 тонна каучук чыгара ди. Ә соң без алардан кай җиребез белән ким? Татарстан нефте бар дөньяга шаулаган кебек, аңардан куәт алучы каучук та ятларныкыннан калышмас!

Бүгенге җыелышта чыгыш ясау шул ашкынуның дәвамы булды.

...Цехка кайтып керү белән Хәмзәне Нурмый Иваныч үз кабинетына чакыртып алды. Ул, креслосында бик эре кыяфәт белән киерелеп утырып, усал тонда сүз башлады. Ул эш дәверендә бик күптән булып үткән җитешсезлекләрне, брак каучук ясаган очракларны чокып чыгарырга тотынды. Ләкин сүзен очлый алмады. Ашыгыч һәм ачулы ярсып, Саша Калинин килеп керде. Бернинди итәгать-фәлән саклап тормыйча:

— Николай Иванович, синең мүкләк Габсаттарың безнең сменага тагын «сыер» калдырып киткән. Башка болай эшләп булмый. Булырбулмас коданны я эштән аласың, я без менә хәзер бөтен сменабыз белән җыелышып Лемаевның үзенә барып әйтәбез,—диде.

Нурмый Иваныч, бурлаттай кызарынып, өнсез калды..

Директордагы планеркадан соң озак та үтмәде, яңа цех начальнигы билгеләнде. Яңа начальник—бөтен җаны-тәне белән оештыру эшенә бирелгән Белов дигән, кечкенә, чандыр гәүдәле, ябык, аксыл йөзле кеше—беренче көннән үк җыелыш җыеп, эшне яхшырту буенча кемдә нинди тәкъдимнәр барлыгын сорашып чыкты. Һәм теше-тырнагы белән Хәмзә тәкъдимен яклады.

...Белов җитәкчелегендә эш уңышлы барды. Хәмзә директорда күтәргән мәсьәләләрнең күбесе уңай хәл ителде. Комбинат буенча хезмәт хакына Урал өстәмәсе кертелде. Каучук ташучы Гөлфияләрне сөендереп, транспортерлар көйләнде.

...Зур бәйрәм, тантана бүген Галимовларда!

Әйе, бу—гаилә бәйрәме. Әтисе Җәләй ага һәм әнисе Хәтирә апа бөтен гомерләре буена хыялланган көн килде. Улларының уңышлары аларга бу шәһәргә юл ачты. Менә, ниһаять, алар туган җирләренә кайттылар. Җәләй ага пенсиягә чыгып, ә хатыны, монда кайткач, улы эшли торган җиргә үк эшкә керде. Үзләренә аерым квартира бирделәр.

Менә аларны куандырып малайлары тагын да зуррак шатлык алып кайтты.

Хәмзә сменасы туган җиргә зур җиңү китерде. Хәмзә сменасы Европа күләм әһәмиятле, ил күләм данлыклы цехны иң беренче булып проект куәтенә чыгарды.

Бу зур батырлык иде. Чөнки шундый кыска срокта, өч ел урынына нибары алты айда проект куәтенә ирешеп, сәгатенә 4,5 тонна каучук бирүне илебез тарихы белми әле. Киләчәктә моны бик җентекләп өйрәнерләр. Яңарган Татарстан бу хәлне үзенең тарихи битләренә алтын хәрефләр белән теркәп, үзенең барлык балаларына:

— Укыгыз, сокланыгыз! Беренче бишьеллыклар чорында минем улларым Березники, Донбасс, Кузбассларда, Магнитогорскиларда дөнья рекордлары куйдылар! Ә бүген инде ул ветераннарның балалары үземә кайтып дөнья рекордлары куялар,—дип сөйләр.

...Әнә алар — Хәмзә абыйларының кул астында бөркет булып очарга өйрәнгән Зөһрә Исрафилова, Илнур Ямалеев, Валя Алексеева, Сергей Гатауллин, Александр Калининнар... Һәрберсе нидер әйтергә, куандырырга тели. Әмма һәрберсе тартына.

Бу Зөһрәләр, күптән түгел генә авылдан килгән кызлар, үзләрен бик тыйнак тоталар. Хәмзә абыйлары алар күңеленә дә күпер тапты. Кызлардан ул «Азат хатын», «Казан утлары» журналларын алып торгалады, алардан татарча чиста сөйләшергә өйрәнеп йөрде. Шулай әкренләп, сизмәгәндә абыйлары бик якын дус кеше, якын сердәш булып китте. Һәм менә өченче көн генә Зөһрә Хәмзә абыйсын матур хәбәр әйтеп куандырды. Ул КамАЗ егете, бетончы Кирамга тормышка чыгачак икән!

Бигрәк тә әйбәт!

Өч бәйрәм бергә булсын!

Хәмзә аны егете белән үзенә чакырды.

Шуңа күрә монда КамАЗга килен бирү туе да!

Монда чорның ике матур дөньясы, ике яшьлек шәһәре карлыгачлары кавыша.

Озакламас Түбән Каманың каучук тәгәрмәчләре белән КамАЗ машиналары да кавышыр!

Әнә Илнур... Бераз кыюлана төшкәч әйтер әле, Хәмзә абый, дияр, мин синең киңәшне тоттым, тырыштым бит, кичке институтка имтиханнарны кичә генә әле уңышлы тапшырдым, рәхмәт, дияр.

Сүзләр күп булыр. Әмма беренче сүзне карт ветеран Җәләй ага алды әле. Ул әнә, иң элек кулындагы шахтерлар тальянын карчыгына тоттырды, чәчәкле тастымалын иплән кенә алдыннан алып куйды. Аннары, тамак кырып, ашыкмыйча гына торып басты.

Алтмыш яшьлек тәбәнәк кенә буйлы картның кырыс кара чәчле башы, саллы ияге, чуеннан коелгандай куәт ташып торган гәүдәсе күзләрне әсир итте. Аның һәр сүзеннән, һәр хәрәкәтеннән зур бер тауны кузгатырлык энергия ташый, ихтыяр, тазалык, ныклы, төпле тормыш рухы бөркелеп тора. Җырларда җырланган меңләгән шахтерлар образы күз алдына килеп басты.

— Кадерле улым!—диде Җәләй ага һәм тирән дулкынланудан туктап калды.

Бүген иртән шәһәр уртасындагы гигант урак-чүкеч сыны янында шәһәрнең данлыклы кешеләре тезелгән иде. Мактау тактасы каршында басып торуы Җәләй аганың күз алдына килде. Мактау тактасында беренче булып аның улы, эшче династиясенең лаеклы варисы, коммунист Хәмзә Галимов рәсеме тора. Җәләй ага өчен бу бик күңелле булды. Улы аның иң тирәндә яткан, иң гадел хыялын тормышка ашырды. Һәр кешегә тәнкыйть һәм сынау күзлеге аша караучы якташлары алдында улы үзен булдыклы итеп танытты. Һәм карт ветеран, меңләгән шахтерлар исеменнән улына рәхмәт әйтә-әйтә, кояшлы урамнар буйлап атлады. Табын янында менә шул хисләрне белдерәсе килде аның. Ләкин... әйтә алмады.

— Туганнарым, кадерлеләрем! Җыелгансыз зурлап безне, рәхмәт сезгә. Сезнең барчагызны котлап бер көй уйнарга рөхсәт бирегез, балалар!—диде ул, дулкынлануын басып.

Яшьләр кул чаптылар. Җәләй ага, баскан килеш, тальян алып бик җәһәт тартып җибәрде...

...Тәрәзәләрдән борынгы да, бүгенге дә булып тоелган, Кузбасс шахталары кебек тирән, Урал таулары кебек биек «Шахта көе» ургылып чыкты. Чыкты да, тамчысы да әрәм булмыйча, матур сандугачлар булып, түбән камалыларның күңелләренә куна барды. Ул җыр гүя үзенең яңа дәвамын, халыкның хезмәт сөючән гүзәл сыйфатларын дәвам итүче Хәмзәләр династиясе җырын сорый иде. Бу минутта кайчандыр татар теле, татар моңы үзенә ят булган чит илнең шахта сүзен үзенең җанында эреткән кебек, бүген әле җырга кермәстәй чит булып тоелган каучук сүзе дә матур җыр яңгырашларына салыныр иде сыман...

Хәмзә бөтенләй бу көннәр турында хыялланмаган иде. Ул бары эшләде, тирен түгеп, тырышып, булсын дип эшләде. Җир тетрәтеп, җир төбенә төште, җир астын айкап күмер чыгарды. Җир өстенә менде, сыек газдан каучук ясады...

Кыйгач кашларын сикертеп бер елмаеп алды да ул, чын йөрәктән:

— Бәйрәм белән сезне, дусларым! — диде...

Зәйни Шаһиморатов

# НӨНӘГӘР КЫЗЫ



Сезнең Нөнәгәр дигән сүзне ишеткәнегез дә юктыр әле? Ә ул Балтач районындагы бер авыл. Нәрсәсе белән мәшһүр соң бу авыл? Татарның югары театр белеме алган беренче хатын-кыз режиссеры Кәшифә ханым Тумашева туган бу авылда. Бу хәл 1903 елның 7 нче январенда булган. Нәрсә биргән соң Нөнәгәр кечкенә Кәшифәгә? Авылдагы абыстай «мәдрәсәсендә» әлпи укырга, бисмилла әйтергә, амин тотарга, намаз укырга өйрәткән. Шулай да язарга өйрәтә алмаган. Чөнки бу елларда кызларның үсәч егетләргә хат язуларыннан курыккан руханилар кыз балаларга язу өйрәтүне тыйган булганнар. Кечкенә Кәшифәне язу язарга өйрәтү бурычы Өркет шәһәре өстенә төшеп калган.

1908 елны булачак артистканың атасы Җамалетдин абзыйның бертуган сеңелесе Газизҗамал апа Рахманова, үзләренең кечкенә кибетләрендә сату итәргә өйрәнчек кирәк булганга, кечкенә Кәшифәне Себергә, Өркет шәһәренә алып китә. Кәшифә бик җитез, елгыр кыз була. Кибеттә дә, өйдә дә бик тиз кул арасына керә. Газизҗамаллар аңа үзләренең киләчәктәге булышчылары итеп карыйлар. Һәм, кибетләрендәге исәп-хисап эшләрен дә алып бара алсын өчен, 1910 елда воскресный школага рус теле һәм арифметика укытырга йөртә башлыйлар. 1912 елда инде Кәшифә Өркет бае Шәфигуллин ачкан «мәдрәсәи исламия» дигән җәдиди кызлар мәдрәсәсендә мөселманча укый. 1914 елны шул мәдрәсәнең рөшди сыйныфларын бик яхшы билгеләре белән генә тәмамлый. Аңа халык шагыйре Габдулла Тукайның «Имтияз алган бала» дигән шигыре басылган Имтияз кәгазе бирәләр. Өркет мәгариф мәдәният җәмгыяте Кәшифәне җәмгыяте хәйрия хисабыннан Төркиягә дарелфөнүндә укырга җибәрмәкче була. Ләкин беренче бөтен дөнья сугышы башланып китүе генә аларга бу ниятләрен гамәлгә ашырырга комачаулый. Һәм заман агышы Кәшифәнең тормышын бөтенләй башка эздән агызып алып китә.

Укып, белем алып авыл укытучысы булу хыялы белән янган Кәшифә, 1917 елгы Февраль революциясеннән соң, Өркеттәге Лятоскович дигән кешенең частный гимназиясенә укырга керә һәм аны 1919 елны экстрен рәвештә бетереп чыга. Ләкин укырга керү белән аның тормышында әле тагын бер үзгәреш булып ала. Кәшифә үзен артык укытырга теләмәгән һәм хәзер инде шактый зур сәүдәгәргә әверелгән апаларыннан китә. Шәмсеҗамал дигән, ире сугышта үлгән эшче хатыннарда яши башлый. Ләкин, шуның белән бергә, тормышның бөтен авырлыгы да аның үз җилкәсенә төшеп кала.

Кәшифәне «мәдрәсәи исламия»дә укыган елларында ук Миңнулла Гыйззәтуллин («Нур» труппасының суфлеры) һәм «Энҗекәй, балдызкай» пьесасының авторы Х. Габидов кебек алдынгы фикерле укытучылар мәдәни-агарту эшләренә тарта башлыйлар. Ул шулар кул астында Габдулла Тукайның «Фәрьяд» һәм башка шигырьләрен яттан өйрәнә, әдәбият кичәләрендә сөйләп йөри. 1917 елның Февраль революциясе алдыннан Х. Габидов аларны «Марсельеза» җырларга өйрәтә. «Озаклამый илдә зур вакыйга булачак, без урамнарга чыгарбыз, флаглар күтәреп шушы җырны җырлап йөрербез!» — ди ул аларга. Һәм, чыннан да, алар революцияне урамда кызыл байраклар күтәргән, «Марсельеза» җырлаган хәлдә каршы алалар. Ләкин Өркеттә власть Октябрь революциясеннән соң да бик озак вакытлар тотрыклы хәлгә килә алмый. Себердә Колчак, шәһәрдә әле аклар, әле кызыллар, әле Калмыков бандалары яки атаман Семенов башкисәрләре.

1919 ел. Гражданнар сугышы бөтен көченә дәвам иткән чак. Өркеткә Колчак тылындагы татар эшчеләре арасында революцион эш алып бару өчен партия тарафыннан җибәрелгән атаклы татар большевигы, элекке каторжан Садыйк абзый Сәгыев килеп төшә. Ул соңыннан Татарстан Верховный Советы Президиумы Председателе булган Гали ага Динмөхәммәтов, Хәйретдин Саттаров, Хафиз Әхтәмов кебек татар коммунистлары белән берлектә легаль татар драма түгәрәге оештыра. Бу түгәрәкнең эшендә Өркет шәһәренең күренекле татар большевиклары һәм Рәхим Тумашев, Ибраһим Габтерәшитов кебек, аларга теләктәшлек итүче алдынгы татар яшьләре дә тартылалар. Кәшифә дә шул түгәрәкнең актив членнарыннан берсе булып китә. Түгәрәк Рәхим Тумашев җитәкчелегендә Г. Гумерскийның «Уйламаганда ике никах», Фатих Әмирханның «Яшьләр», Фатих Сәйфи-Казанлының «Ямьсез тормыш» пьесаларын куя. Кәшифә бу спектакльләрнең барысында да уйный. Хафиз Әхтәмовлар аңа Зауральская дигән сәхнә ләкабе бирәләр.

Ниһаять, 1919 елның 24 декабрендә шәһәр партия комитеты Өркет эшчеләрен кораллы восстаниегә күтәрә. Аларга Черемхово шахтерлары отряды да ярдәмгә килә. Нәтиҗәдә Колчак бандалары җиңелеп кача. Колчак үзе кулга алына. Казаннан чехлар алып киткән Россия алтыны эшчеләр кулына эләгә, һәм Өркеттә Совет власте урнаштырыла.

РКП(б) ның шәһәр комитеты каршындагы мөселман секциясе (җитәкчесе С. Сәгыев) карамагында беренче профессиональ мөселман театр труппасы оештырыла. Труппа Шамил Усмановның «Канлы көннәр», «Беренче адым» дигән әсәрләрен, Евдокимовның «Дәфенсезләр»ен, Габдулла Кариевның «Артист»ын, Галиәсгар Камалның «Беренче театр»ын, Рәхим Тумашевның «Ялгышу» дигән драмасын сәхнәләштерә. Бу әсәрләрнең барысын да Рәхим Тумашев куя. Гали Динмөхәммәтов бу спектакльләрдә дә катнаша. Кәшифә исә Зөләйха, Нәфисә, Наташа, Факиһә кебек баш рольләрне уйный һәм труппаның беренче артисткасы булып китә.



1921 елда губерна политик мәгариф бүлеге Семипалат шәһәрендәге мәдәният йорты каршында профессиональ татар театр труппасы оештыра. Рәхим Тумашев белән Кәшифә Шәрәфетдинова-Зауральскаяны да шушы театрга чакырып алалар. Рәхим Тумашев артист һәм режиссер, Кәшифә апа артистка булып урнаша. Семипалатның Луначарский исемендәге рус дәүләт театры сәнгать эшләре җитәкчесе Леонид Баской татар труппасының да баш режиссеры булып билгеләнә. Труппа аның җитәкчелегендә 1921—24 еллар арасында утыздан артык әсәрне сәхнәгә куя.

Шулар арасында Генрих Гейненең «Әлмәнсур» трагедиясе, Фридрих Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт», Нариман Наримановның «Надир шаһ», Фәтхи Бурнашның «Таһир һәм Зөһрә», «Яшь йөрәкләр», Гафур Коләхметовның «Яшь гомер», Шәриф Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә», Кәрим Тинчуринның «Назлы кияү», Галиәсгар Камалның «Беренче театр», Фатих Әмирханның «Тигезсезләр» дигән әсәрләре бар. Болардан тыш русчадан тәрҗемә ителгән уннарча әсәрләр дә театр сәхнәсеннән тамашачылар хөкеменә чыгарылалар.

Бу спектакльләрнең егермедән артыгын Рәхим Тумашев куя.

Кәшифә ханым Зауральская спектакльләрнең барысында да диярлек катнаша һәм һәр вакыт баш рольләрне уйный. Шулардан Камилә («Хаҗи әфәнде өйләнә»), Нәгыймә («Назлы кияү»), Факиһә («Беренче театр») кебек комик рольләрне искә алмаганда, калганнары барысы да трагик, драматик, героик образлар булалар. Семипалат театрында Кәшифә апаның артистлык таланты ачылып китә һәм чәчәк ата.

Кәшифә апаның чын артисткага әверелүендә тормыш иптәше Рәхим Тумашев һәм Леонид Баской зур роль уйныйлар. Баской, югары культуралы алдынгы рус интеллигенты буларак, Кәшифә ханымның уенын өзлексез күзәтә һәм аталарча кайгыртучанлык белән төзәтә бара, сәхнә кануннарын өйрәтә. Луначарский исемендәге театрның башка артистлары да ярдәмләшүгә һәр вакыт әзер торалар. Рус труппасы белән татар труппасы арасында чын-чыннан иҗади дуслык, тәҗрибә һәм белем уртаклашу гадәткә кереп китә һәм изге бер традициягә әверелә. Алар ярдәмендә татар труппасы артистлары рус театр сәнгатенең реалистик мәктәбен үзләштерәләр.

## Уку еллары

Семипалат театрында уйнау, аерым спектакльләрдә режиссер булып катнашу Кәшифә апада «режиссер булсам!» дигән фикер уята. Ләкин режиссер булу өчен күпне белергә, күп укырга, өйрәнергә кирәк. Кәшифә апа моны яхшы аңлый һәм шул максатка ирешү өчен Рәхим Тумашев белән 1923 елның ахырларында Казанга килә. Кәшифә ханым театр техникумының икенче курсына кабул ителә һәм аны 1926 елда Риза Ишморатов, Хәким Сәлимҗановлар белән бергә тәмамлый. Техникумның үзендә ул режиссер-педагог булып калдырыла. Театр техникумы җитәкчеләре Борис Сималин белән Наум Шульгалар Кәшифә ханымдагы табигый режиссерлык сәләтен күреп алалар. Укыту дәверендә аңарга ассистент һәм режиссер эшләре дә йөклиләр. Мәсәлән,

1929 елда ул, Габдулла Йосыпов белән берлектә, Дауд Юлтыйның «Карагол» драмасын, Всеволод Ивановның «Бронепоезд № 14-69» әсәрен сәхнәгә куя. Е. Яновскийның «Ток һәм доллар» пьесасын Кәшифә апа режиссер-педагог Анна Бородавкина белән бергә сәхнәгә чыгара.

Театр музеен һәм «Тамашачы» журналын оештыручы энтузиаст Кәбәй ага 1929 елны Кәшифә апаны радиокомитет председателе Сәгыйт ага Фәйзуллин белән таныштыра. Сәгыйт ага Кәшифә ханымның режиссер булып эшлисе килүен белгәч, аны радиога диктор итеп тә, режисссер итеп тә урнаштыра. Кәшифә апага, ниһаять, үз көчен режиссерлык эшендә дә сынап карау мөмкинлеге туа. Ул башта татар сәхнәсенең беренче трагигы Мохтар ага Мутин белән бергәләп «Чапаев» дигән радиоспектакль куя. Аннан үзе генә «Галиябану»ны әзерли һәм уйнарга Галия ханым Кайбицкая белән Газиз Әлмөхәммәдовларны чакыра. Бу чорда язучылардан Һади Такташ, Гадел Кутуй, Салих Баттал, Төхфәтулла Ченәкәй, Хәсән Туфан, Габдрахман Минский, Гариф Гобәйләр әдәби-музыкаль монтажлар эшләүдә актив катнашалар. Композитор Василий Иванович Виноградов радиода махсус оркестр оештыра. Бу оркестрда соңыннан татар балет сәнгатенең атасы булып киткән Фәрит Яруллин һәм хәзер Татарстанның атказанган артисты Мөбарәк Батталлар да катнашалар.

1931 ел җитә. Кәшифә апа бу еллар эчендә театр техникумында педагог булып та, радиода спектакльләр куеп та шактый чыныга һәм тәҗрибә туплый. Шул ук елны театр техникумы директоры Хәмид ага Төхфәтуллин Кәшифә апаны Татарстан исеменнән Мәскәүгә театр институтына укырга җибәрә. Аны театр институтының режиссерлык факультетына кабул итәләр. Ул анда: «Мин МХАТ мәктәбен өйрәнергә килдем. Мине Илья Яковлевич Судаков укыткан бүлеккә беркетегез!» — ди. Үтенеч канәгатьләндерелә. Ләкин бер курсны укып бетерүгә, Казаннан Рәхим Тумашевның каты авыруы турында хәбәр килә. Кәшифә апа бер елга академ ял алырга һәм Казанга кайтып китәргә мәҗбүр була. Бу академ ял 1934 елга, Рәхим Тумашев гүр иясе булганга чаклы дәвам итә. Кәшифә апа ике баласын алып Мәскәүгә укуын яңадан дәвам иттерергә бара. Институт директоры, мәшһүр «Чапаев» романының авторы Дмитрий Фурмановның хатыны Анна Никитична Фурманова Кәшифә апаның хәленә керә, аны балалары белән тулай торакка урнаштыра һәм укуын дәвам иттерерлек шартлар тудыра. Кәшифә апа чын мәгънәсе белән Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестендагы Галия кичергәннәрне кичерә һәм, Галия кебек үк, дуслары, танышларының кайгыртучанлыгы белән чолгап алына. 1939 елны ул институтны тәмамлап Казанга кайта. Татар дәүләт академия театрында режиссер булып эшли башлый. Шулай итеп, Кәшифә апа Семипалат шәһәрендә хыялланган максатына ирешә. Институт аңа белемне көрәп бирә, кайбер практик сабаклар аша да үткәрә. Ләкин тәҗрибәле режиссер итеп кенә чыгара алмый. Бусына инде Кәшифә апа театрда үзе казынып ирешергә тиеш була. Һәм ул бу эшкә җиң сызганып керешеп китә.

## Академия театры мәктәбе

Кәшифә апа Татар дәүләт академия театрында 1939 елдан 1953 елга чаклы эшләде һәм шул дәвер эчендә утыздан артык спектакль чыгарды. Талантлы, сәләтле режиссер булып танылды.

Аның Галиәсгар Камал театрында куйган беренче спектакле күз врачы Хәбиб Фәтхуллинның «Күзләр» драмасы була. Иске режим вакытында җәберләнгән, өлешсез калдырылган кешеләрнең совет шартларында ничек уяну, үсүләрен, укып зур профессия иясенә әйләнүләрен

күрсәткән пьеса Кәшифә апаны гашыйк итә. Ул елга якын пьесаның авторы белән эшли, аңа әсәрен камилләштерергә булыша. Башта бик озын, таркау әсәр бара-бара җыйнаклана, образлар тулылана, җанлана, ачыла төшәләр, калкуланалар. Бу чорларда әле күзгә операция ясау үзе бер проблема булып торганга, күпләр пьесаның җитдилегенә дә ышанмыйлар. Аңа гади бер фантастика элементы итеп кенә карыйлар. Кәшифә апа консультация алу өчен Казанның атаклы күз профессоры Адамюкка мөрәҗәгать итә. Адамюк Одессадагы академик Филатов белән багланышка керә һәм «ачарга мөмкин» дигән җавап бирә. Артистларны күз клиникасына операция моментларын карарга алып баралар. Сукырлар җәмгыяте белән багланышка кереп, сукырларның производствода эшләү процесслары белән танышалар. Короленконың «Сукыр музыкант»ын һәм башка язучыларның сукырларга багышланган әсәрләрен укыйлар. Кәшифә апа рольләрне башкару өчен артистлар сайлый башлый. Аңа Хәким Сәлимҗанов, Камал III кебек танылган артистларны тәкъдим итәләр. Кәшифә апа аларга: «Хәким Сәлимҗанов та, Камал III тә — бик яхшы артистлар, бик зур талант ияләре. Мин аларның уеннарына сокланып бетә алмыйм. Ләкин миңа бу юлы мәхәббәт геройлары түгел, борынына шәһәр исе керергә өлгермәгән авыл егете кирәк!» — ди. Һәм әле генә эшче театрыннан күчеп килгән Фоат Халитовны сайлый.

Әсәрнең героинясы Рәисә образын режиссер халыктан, тормышның төбеннән калкып чыккан, саф табигатьле, үтә шагыйранә, үтә кешелекле, чыдам һәм көрәшкә сәләтле оптимист образ итеп күзаллый. Һәм Рәисә ролен Марзия Миңлебаева белән Зифа Басыйроваларга йөкли. Ышанычы аны алдамый.

Спектакльгә музыка яздыру мәсьәләсе кузгалгач, труппа мөдире Мәрьям ханым Чанышева: «Бу Салих ашы. Аңардан яздыр. Ләкин җилкәсеннән төшмә. Шунсыз язмас!» — дигән киңәш бирә. Кәшифә апа һәм пьеса авторы Хәбиб Фәтхуллин Салих Сәйдәшевкә мөрәҗәгать итәләр, аны әсәр белән таныштыралар. Әсәр укылып беткәч, ул бик озак дәшми дулкынланып утыра һәм Фәтхуллинның:— Я? — дигән соравына каршы:

— Мин, бәгырьләрем, әсәрне аңладым. Бу ике бала минем йөрәгемә үтеп керде. Мин музыка язам. Ләкин мине сроклап, бүген-иртәгә дип йөдәтмәгез. Музыка йөрәктә кайнарга тиеш. Ул кайчан кайнар, шунда өлгерер! — дип җавап бирә һәм күздән югала. Спектакльне чыгарыр вакыт якынлашып килә. Ә музыка юк та юк. Артистлар борчыла башлый. Көйләрне өйрәнергә вакыт җитмәс кебек. Ниһаять, Кәшифә апа Сәйдәшне эзләп таба. Бик ныгытып ачуланырга уйлый. Ләкин үзенең:— Я? — сенә, Салихның:— Музыка әзер! — дигән җавабын ишеткәч, бөтенләй ачуын оныта. Алар композиторның театрдагы кабинетына керәләр. Салих пианино янына утырып уйнап та һәм үзенең матур, ягымлы тавышы белән тәмләп җырлап та җибәрә. Әле иркәли, әле елый, әле юата аның музыкасы. Кәшифә апа матур, моңлы музыка тәэсиреннән дөньясын да, кайда утыруын да оныта. Күзләреннән мөлдерәп яшьләре ага башлый. Салих аңа үзенең мөлаем зәңгәр күзләре белән карап ала да:

— Елыйсыңмы? — дип сорый.— Еларсың шул, бәгырь. Әле халык ничек елар. Менә шунда булыр тамаша! — ди һәм үзе дә елап җибәрә. Спектакль чыга. Халык аны ифрат дәрәҗәдә бирелеп карый. Салих Сәйдәшевнең алдан күрүе аклана. Шулай итеп, яшь режиссерның беренче спектакле бертавыштан яхшы дип табыла.

Хуҗа Насретдин мәзәкләре — халкыбыз тарафыннан гасырлар дәвамында тудырылган күмәк иҗат җимеше, халкыбызның үткен сатира, юмор байлыгының җыелмасы. Шушы гүзәл мәзәкләрне туплап тере сәхнә әсәре хәленә китерү мәсьәләсен башта Хәлил ага Әбҗәлилев күтәрә һәм театрның танылган драматургы Нәкый ага Исәнбәткә Хуҗа

Насретдин турында комедия язарга тәкъдим итә. Юк, итеп кенә калмый, хуҗаңны үзем уйныйм! дип, вәгъдә дә биреп куя. Әсәрне сәхнәгә куючы сыйфатында ул Кәшифә ханым Тумашеваны тәкъдим итә.

Хәтерлим әле, бу 1939 еллар иде. Язучылар союзының Габдулла Тукай исемендәге клубы халык белән шыгрым тулган. Залда энә төртерлек тә урын юк. Трибунада Нәкый Исәнбәт, коңгырт чәчле, коңгырт күзле, нурани ачык йөзле Нәкый Исәнбәт. Ул «Хуҗа Насретдин» комедиясен укый. Залда әле кабер тынлыгы хөкем сөрә, әле дөнья шаулатып көлгән тавышлар яңгырый, авторны бүлдереп гөрләтеп кул чабулар, зурлаулар китә. Минем драма секцияләренең бик күп утырышларында катнашканым бар. Ләкин моңа чаклы да, шуннан соң да мондый куанычлы, соклану, канәгатьләнү тойгылары уяткан утырышны күргәнем юк. Бу татар драматургиясе тарихында иң якты сәхифәләрнең берсе булып калды.

Театр әсәрне кабул иткәннән соң, аны куюны кемгә тапшыру турында бәхәс китә. Хәлил Әбҗәлилев Кәшифә Тумашеваны даулавында дәвам итә. Театрның шул чордагы сәнгать эшләре җитәкчесе Евгений Глебович Амунтов әсәрне куярга үзе алына һәм Кәшифә Тумашева белән бергәләп эшләргә була. Ләкин күп тә үтми, Амунтов театрдан бөтенләйгә китә. Эш тулысы белән яшь режиссер өстенә төшеп кала. Кәшифә апа әсәрне сәхнәдә ничегрәк чагылдыру турында уйлый башлый. Хуҗа Насретдинны халык күңелендә яшәгәнчә яңгырату өчен, «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясен куйган алым да, җитди драма алымнары да яраксыз булып чыга. Хуҗа Насретдин үзенә башка форма таләп итә. Күп уйланулардан соң Кәшифә апа мәйдан, халык театрларына, халык әкиятләренә хас күпертелгән театраль алымнар кулланырга, әсәрне пырхылдап очып бара торган кош кебек җиңел, кабарынкы итеп уйнатырга карар бирә. Персонажларда да аның үтә чыккан явыз кешеләр күрәсе килми. Ул Хуҗа Насретдинны тинтәк, аңгыра итеп түгел, Иван дурак яки Шомбай сыманрак, белмәмешкә салынып эшләүче акыллы дивана итеп күрә. Хәлил Әбҗәлилев тә моның белән килешә. Аксак Тимерне дә Кәшифә ханым җитди акыл иясе, сугыш даһие итеп күрәсе килми. Аны да чикләнгәнрәк, урта гасырның бөтен хорафатын үзенә туплаган кеше итеп күзаллый. Нәкый ага, Хуҗа Насретдинны спектакль үзәгеннән читләштермичә тагын да калкурак күрсәтү йөзеннән, Аксак Тимернең монологларын кырка төшә, образны спектакльнең стиленә җайлаштыру юнәлешендә эшли. Аксак Тимерне Җиһангир хан белән алыштыра. Болардан спектакль ота гына.

Кәшифә апа «Хуҗа Насретдин» спектакле музыка белән башланырга, музыка белән бетәргә тиеш, ә музыкасы җиңел, очып бара торган, барабанлы булырга тиеш дип таба. Спектакльгә музыка яздыру өчен көйләренә комедиялелек, оперетталылык хас булган композитор Җәүдәт ага Фәйзине чакыра, музыканың нинди характерда булырга тиешлеген аңлата. Болар композиторны спектакльнең эченә алып кереп китәләр, эшне җиңеләйтәләр. Нәтиҗәдә, халык күңелендә якты эзләр калдырган Хуҗа Насретдин көйләре пәйда була.

Балетмейстер Гай Таһиров спектакль стиленә, рухына хас җитез, йөгерек комик биюләр куя.

Спектакльнең тышкы сурәтен формалаштыру бурычы Петр Тихонович Сперанскийга йөкләнә. Бу вакытта Сперанский Мәскәүгә авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә Татарстан павильонын бизәү эшенә чакырылган, театрдан бөтенләй киткән була. Кәшифә апа белән Хәлил Әбҗәлилевкә Сперанскийны эзләп Мәскәүгә барырга туры килә. Алар аңа, оформление борынгы Болгар шәһәре бистәләрен, сарайларын, кешеләрен, көнкүрешен күзалдына китерерлек булсын, дигән таләп куялар. Сперанский алына һәм тарихи материалларны өйрәнеп, спектакльнең рухы белән органик бәйләнгән тышкы сурәтне тудыра. Костюмнарны тектерү өчен

генә ул Мәскәүдән кайта алмый. Костюмерныйда да аларны ничек тегәргә кирәген белүче булмый. Бигрәк тә чалмаларны чорнау мәсьәләсе үзенең остасын таләп итә. Костюмерныйда эш туктала. Хәлил Әбҗәлилев Кәшифә апага:— Костюмнарны, чалмаларны бары тик Хөсәен Уразиков кына эшләтә ала. Аны спектакль куешырга чакырыйк! — ди. Хөсәен ага риза була. Һәм үзенә генә хас бер оешканлык белән җиң сызганып эшкә керешә. «Хуҗа Насретдин» спектакле шулай итеп аларның уртак иҗат җимешләре булып китә.

Кәшифә апа артистлар белән армый-талмый эшли. Хәлил Әбҗәлилевкә Хуҗа Насретдинның йөреш-хәрәкәтен, Нәҗип Гайнуллинга Җиһангир ханның аксаклык рәвешен табып бирә. Хөсәен агага гына Колый Тархан трактовкасының кайбер яклары бик үк ошап бетми:— Ничек инде ул тархан башы белән шулай комикланып йөрсен? — дигән сорау куя. Кәшифә апа аңа:— Хөсәен ага, алар положениеләре белән генә тархан булганнар. Чынлыкта бик чикле кешеләр. Алар бөтен нәрсәгә лупа аша карыйлар. Шуңа күрә бу спектакльдә эзәне дә дөя итеп уйнарга кирәк! — ди. Әнә шундый эзләнүләр нәтиҗәсе булып мәшһүр Колый Тархан образы барлыкка килә.

«Хуҗа Насретдин»га репетицияләр башлангач, кайбер артист һәм режиссерлар:— Бу безнең театр стиле түгел. Курчак театры. Кәшифә балаган кора! — дип шау-шу күтәрәләр. Ләкин спектакль чыкканнан соң, үзләре үк беренче булып режиссерны уңыш белән тәбрик итәләр. Спектакльне халык зур шатлык, тантана белән кабул итә. Хәлил Әбҗәлилев иҗтиһады белән башланган бу эш әнә шулай уңышка китерә һәм татар театры тарихына алтын хәрефләр белән язылып кала. 1957 елда үткән татар сәнгате һәм әдәбияты декадасында «Хуҗа Насретдин» спектакле югары бәя ала. Хуҗа Насретдин образын иҗат итүче Хәлил Әбҗәлилевкә татар театры тарихында беренче булып СССРның халык артисты дигән олы исем бирелә. Декада спектакльләренә анализ ясаучы театр белгечләре «Хуҗа Насретдин» спектакле турында сөйләгәндә: моны башка төрле куеп булмый. Бу — кабатланмас уникаль спектакль. Ә Хәлил Әбҗәлилев гениаль Хуҗа Насретдин! — дигән бәяне бирәләр.

Әгәр без, театрга шундый зур уңыш китергән «Хуҗа Насретдин» спектаклен башлап иҗат итүчеләр Нәкый Исәнбәт, Хәлил Әбҗәлилев, Кәшифә Тумашева, Хөсәен Уразиков һәм спектакльне тудыруда катнашкан артистлардан — Мәрьям Сульва, Фатыйма Камалова, Мәҗит Илдар, Габдулла Сәгыйтов, Фоат Халитов, Хәким Сәлимҗанов, Галимә Ибраһимова, Марзия Миңлебаева, Рәшидә Җиһаншина, Гөлсем Болгарская, Гөлсем Камская, Нәҗип Гайнуллин, Шакир Мәҗитов, Сәет Булатов, Ибраһим Гафуров, Касыйм Шамил, Каюм Бариев, балетмейстер Гай Таһиров, композитор Җәүдәт Фәйзи, художник Сперанскийлар булды һәм татар сәнгате, драматургиясе шушы изге эшләре өчен нәкъ менә шушы талант ияләренә бурычлы дисәк, һич тә хата булмас.

«Хуҗа Насретдин» спектакле ун елларча сәхнәдән төшми барды. Аның геройларын, берсен-берсе алыштыра-алыштыра, төрле артистлар уйнадылар һәм киләчәктә дә бу шулай дәвам итәр. Ләкин аның беренче тудыручыларын театр тарихы беркайчан да онытмас.

Бервакыт академия театрының шул чактагы директоры Хәмит Алхановны Мәскәүгә чакырып алалар да, үзе җитәкчелек иткән театрда балалар спектакле куйдырмавы өчен, суганлап, борычлап пешереп, шелтә биреп кайтаралар. Алханов Кәшифә апаны чакырып ала да:

— Хет асылын, хет суел, теләсәң нишлә, тик балалар пьесасы тап та бер атнадан уйнат. Мәскәүдән комиссия килгәндә театрның үз спектакле булсын,— ди.

Кәшифә апаның кулында Абдулла Әхмәтнең «Үги кыз» әсәре була. Алар Абдулла Әхмәт белән әсәрне җитлектерәләр. Пьесага шүрәлеләр,

җеннәр, бүреләр, аюлар, күбәләкләр килеп керә. Ниһаять, композитор Җәүдәт Фәйзине чакырып музыка яздыралар. Художник Мәэмүн Сүтюшев калдык-постык декорация кисәкләреннән, кием-салым ташландыкларыннан спектакльнең тышкы кыяфәтен оештыра. Үги кызны Зифа Басыйрова, аның үги анасын Хәдичә Мәхмүдова, убырлы карчыкны Гөлсем Камская уйный. Шүрәлеләр дә, аю, бүреләр дә, күбәләкләр дә үз урыннарында булалар. Спектакль әйтелгән срогында чыга. Халык аны кул чабып каршы ала. Бигрәк тә нәниләр өчен зур бәйрәм була бу. Муса Җәлил мактап рецензия дә яза. Мәскәүдән килгән комиссия спектакльне әйбәт дип таба.

Балалар өчен махсус әсәрләр куюы шуннан соң академия театрының матур бер традициясенә әверелеп китә. Озакламый Кәшифә апага Дәрҗия Аппакованың «Тапкыр егет» комедиясен куярга кушалар. Бу әсәрдә режиссерның күңелен җәлеп иткән, җылыткан нәрсә хезмәт кешесенең өстенлегенә дан җырлау була. Чыннан да, хикмәт хезмәт кешесендә бит! Ул эшләп табып, үз көче белән көн күргәнгә физик таза, акылга сәламәт, тәҗрибәгә бай, тапкыр, курку белмәс була. Хезмәт кешесе юкны бар итүче кодрәт иясе. Ул җенне дә, байны да җиңә. «Ник аның шулай икәнен балаларга шүрәле белән, бай белән очраштырып күрсәтмәскә?» дип уйлый Кәшифә апа. Аннары авторга һәм үзалдына «Шүрәленең көче нәрсәдә?» дигән сорау куя. Алар Шүрәленең көче мөгезендә дип билгелиләр дә, Шәйхулла байдан мөгезен кистертеп, урман өрәген бәлаләргә дучар итәләр. Мөгезсез Шүрәле кая барсын? Аны хәтта урман пәриләре дә кабул итмиләр. Шүрәле мөгезен кайтарып алу өчен Шәйхулла байга хезмәт итәргә, аның капризларын үтәргә мәҗбүр була. Аннан соң тагы Зөһрә кызны алып кайтырга Айга очырып, Шүрәле ролен уйнаучы Әзәл Яһүдинне дөньяда беренче «космонавт»ка әверелдерәләр. Музыка язарга өченче бер ханымны, җырчы Мәрьям Рахманкулованы чакыралар. Музыка матур һәм үзенчәлекле килеп чыга. Көйләрне оркестрга салу эшләрен профессор Михаил Юдин башкара. Биюләрне Гай Таһиров куя. Оформлениесен армас-талмас Сперанский эшли. Былтыр Әхмәтне Ибраһим Гафуров, Галине Зифа Басыйрова, Шәйхулла байны Касыйм Шамил, Байбикәне Фатыйма Камалова, Акбайны Маһинур Шәрипова уйный. Тик менә шул Акбай мәсьәләсендә чак кына конфуз чыкмый кала. Акбай ролен уйнарга тиеш булган Маһинур ханым бу хәбәрне ишеткәч, гаять дәрәҗәдә хурлана һәм Кәшифә апа янына яшькә манчылып йөгереп килә дә:

— Мине эткә әйләндерер өчен генә кайткансыз икән, Кәшифә! Этне уйнарга миннән дә начар кеше тапмагансыз икән! — дип кычкыра.

Кәшифә апа елмая да:

— Нишләп алай дисең, Маһинур? Син генә түгел, «Зәңгәр кош» әкиятендә этне Станиславский үзе дә уйнаган. Артист Боголюбовлар да, Чебаннар да уйнаганнар. Аңа карап алар эткә әйләнмәгәннәр бит! — дигән.

Маһинур ханым аның саен ярсып:

— Алар ир кешеләр! Аларга нишләсәләр дә килешә. Мин хатын-кыз башым белән сәхнәдә бөтен халык күз алдында ничек дүрт аякланып йөрермен?! — дип каршы төшә.

— Бер дә кайгырма, Маһинур! Алар карт этләрне уйнаганнар. Ә син менә дигән яшь этне уйнарсың. Җитмәсә, Карло Гоцци әсәрләрендәге кебек ике аякта гына, сикергәләп кенә йөрерсең! — дигән Кәшифә апа.

Маһинур ханым тынычланган, Акбайны уйнаган, яратып уйнаган һәм спектакльгә менә дигән әкият колориты өстәгән. «Тапкыр егет» зур уңыш белән барган һәм ул Дәрҗия-Кәшифә-Мәрьям ханымнардан торган өч талант иясенең уртак иҗат җимеше булып калган. «Тапкыр

егет»не шул чорларда Габдулла Тукай «Шүрәле»се буенча язылган драма әсәрләренең иң уңышлысы булды дисәк, артык гөнаһ эшләгән булмабыз.

Кәшифә апа болардан тыш Сергей Михалковның «Кызыл галстук», Галиәсгар Камалның «Хафизәләм иркәм», «Беренче театр», «Бүләк өчен» дигән әсәрләрен сәхнәләштерә. Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры», «Җыр дәвам итә», Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану», «Ак калфак», Жан Мольерның «Жорж Данден», Александр Островскийның «Ярлылык гаеп түгел», Константин Симоновның «Көннәр, төннәр», Җаббар Җаббарлының «Сулган чәчәкләр» һәм башка әсәрләрне сәхнәгә куя. Шулар арасында иң күренеклеләреннән берсе итеп Мирсәй Әмирнең сугыштан соң сәхнәгә чыккан «Тормыш җыры» драмасын күрсәтергә кирәк.

Фатыйма Бөек Ватан сугышыннан соң безнең татар драматургиясендә пәйда булган иң олы, иң калку, иң якты героик хатын-кыз образларының берсе. Шушы юлларны язып утырганда «Социалистик Татарстан» газетасы килде. Карасам, анда Хәмзә Кашаповның «Фатыйма арышлары» дигән мәкаләсе һәм «Тормыш җыры» Фатыймасының прототибы Фатыйма Вилдановaның портреты басылган. Фатыйма Вилданова башта укытучы булган. Аннан сугыш вакытында, ирләр китеп беткәч, бригадир булып эшли башлаган. «Фатыйма арышлары» үстереп зур уңыш алган һәм шул уңышны үгезләр, сыерлар җигелгән кызыл олаулар белән кабул итү пунктына озатуны оештырган. ВЛКСМ Үзәк Комитетының һәм Татарстан Верховный Советы Президиумының Почет грамоталары, «Батыр хезмәт өчен» медале белән бүләкләнгән. Бюсты Татарстан дәүләт музеендагы Ватан сугышы чорына багышланган күргәзмәгә куелган. Менә «Тормыш җыры» Фатыймасын Мирсәй ага кайдан актарып чыгарган икән!

Кәшифә апа да, режиссер буларак, әсәрнең рухын, аның сәхнә әчкычын җаны белән тоя. Бу — героик эпоска охшаган шигъри әсәр. Монда кешеләрнең сулауларына кадәр ил язмышы белән бергә берекkән. Режиссер бу әсәрдән көнкүреш спектакле түгел, ә тирән, киң социаль яңгырашка ия булган олы авазлы сәнгать әсәре туарга тиеш дигән нәтиҗәгә килә. Рольләр Фатыйма Ильская, Гөлсем Болгарская, Гөлсем Камская, Фатыйма Камалова, Марзия Миңлебаева, Зифа Басыйрова, Касыйм Шамил, Хәким Сәлимҗанов, Ибраһим Гафуров, Гали Надрюков кебек артистларга йөкләнә. Композитор Җәүдәт Фәйзи, художник Ренат Һибәтуллин җиң сызганып эшкә керешәләр. Шул рәвешчә, заманның бөтен авырлыгын һәм героикасын калку чагылдырган, зур романтик пафос белән сугарылган спектакль барлыкка килә.

Классик әсәрләрне сәхнәгә куйганда, аларда яңгыраган социаль мотивларны тотып ала белү һәм шуларны калкуландырып әтрафлы итеп күрсәтә белү режиссер өчен гаять мөһим сыйфат. Мирхәйдәр Фәйзинең «Ак калфак» драмасын куярга булгач, әсәрнең сәхнәгә чыгуына каршы килүчеләр дә, морза кызларының драмаларын күрсәтеп халык елатудан ни мәгънә? — диючеләр дә табыла. Ләкин Кәшифә апа «Ак калфак» драмасында бөтенләй башка нәрсә күрә. Бу — саф мәхәббәт трагедиясе, ди ул. Хәмдия морза кызы гына түгел, бөтен күнегелгән тормыш тәртибенә, крепостнойлык кануннарына каршы протест тавышы күтәрүче, Добролюбов сүзләре белән әйтсәк, караңгылык патшалыгында ялтырап киткән нур да. Менә ул табигатьнең үзе төсле саф йөрәкле кәтүче Бакый белән крепостнойлыкның үзе кебек мәкерле, шәфкатьсез Шаһтимер морза арасын сайлау алдына куела. Социаль хәле, тоткан урыны аңа Шаһтимерне сайла ди. Ә йөрәге, намусы исемен җырга кушып тәсбих итүче арыслан Бакый ягына тарта. Бакый күрәштә үтерелә. Хәмдиянең Бакый мәете өстендә әйткән әрнүле, ялкынлы сүзләре

шул чорның, шул тормышның газраилларына гаепләү акты булып яңгырый.

Спектакльгә музыканы Сара ханым Садыйкова яза һәм бу аның драма әсәрләренә язган беренче көйләре, композиторлык юлына таба атлаган беренче ышанычлы адымы да була. Бакыйны Дилүс Ильясов, Хәмдияне Галимә Ибраһимова, Шаһтимерне Кәрим Гыйльманов, Сәлим морзаны Хөсәен Уразиков, Җиһанны Гөлсем Болгарская уйный. Сәлим-Уразиковның котырынып күтәрелеп бәрелгән чаклары, Бакый-Ильясовның шатлыктан шашар хәлгә җитеп сәхнәдә тәгәрәп йөргән моментлары, Хәмдия-Ибраһимованың Бакый үтерелгәннән соң аһ-зар елаулары, протестлары, белмим, кемнәрне генә дулкынландырмый, изүче сыйныфларга карата нәфрәт хисе уятмый калды икән? Академия театры сәхнәсендә шаулап баруы «Ак калфак» драмасының Мирхәйдәр Фәйзи томлыкларына кереп басылып чыгуына да тәэсир итте булса кирәк.

Тамашачыларны классик әдәбият белән таныштыру, артистларның, режиссерларның осталыкларын күтәрү максаты белән рус һәм дөнья классиклары әсәрләрен сәхнәгә чыгару академия театрының тарихи һәм изге бер традициясе, тәҗрибә алмашу мәктәбе дә булып тора. Театр җитәкчеләре шул традициядән чыгып Кәшифә апага да үзен Александр Островский әсәрләрендә сынап карарга мөмкинлек тудыралар. Ул 1949 елгы сезонда Александр Островскийның «Ярлылык гаеп түгел» дигән комедиясен сәхнәләштерә. Анда театрның мәшһүр артистлары Хәлил Әбҗәлилев, Хөсәен Уразиков, Нәҗип Гайнуллин, Камал III, Фатыйма Камалова, Галимә Ибраһимова һ. б. лар катнаша. Хәлил Әбҗәлилев белән Хөсәен Уразиковлар образларны ачуда Кәшифә апага ярдәм итеп кенә калмыйлар, Любим Торцов, Африкан Коршунов образларын татар театр сәнгатендә үрнәк булырлык дәрәҗәгә күтәреп башкаралар да. Бу — коеп куйган ансамбльле классик спектакль була да чыга. Һәм Кәшифә апаның үзе өчен дә бөтен бер иҗат мәктәбе булып кала.

Болардан тыш Кәшифә Тумашева В. М. Бейбутов, Евгений Амунтов, Л. М. Литвинов кебек киң танылган театр режиссерлары белән бергәләп күп кенә спектакльләрне сәхнәгә чыгарды. Мәсәлән, опера һәм балет театрының сәнгать эшләре җитәкчесе В. М. Бейбутов белән иҗади хезмәттәшлектә Вильям Шекспирның «Король Лир», Александр Островскийның «Яшенле яңгыр», Евгений Амунтов белән берлектә Шекспирның «Ромео һәм Джульетта», Зур театр режиссеры Лев Маркович Литвинов белән Әнәс Камалның «Иске Казанда», Шакир Шамильский белән бергә Хәмзә Хәкимзадә Ниязиның «Мәйсәрәнең хәйләсе», Ширияздан Сарымсаков белән бергә Әхмәт Фәйзинең «Тукай», Габдулла Йосыпов белән икәүләп Нәкый Исәнбәтнең «Рәйхан», Гамир Насрыйның «Кадерле минутлар», Шәриф Хөсәеновның «Профессор кияве» әсәрләрен куйдылар. Шулардан «Ромео һәм Джульетта» спектаклендә икенче составта катнашкан Фоат Халитов, Марзия Миңлебаевалар белән Ромео һәм Джульеттаны әзерләтә. Алар бу рольләрне беренче составта Амунтов үзе әзерләгән Фатыйма Ильская һәм Камал III ләр белән алмаш-тилмәш уйныйлар. Мәскәүдә үткәрелгән яшь артистлар смотрына барып беренче урынны алалар. Борис Горбатовның «Аталар яшьлеге» әсәре буенча куелган спектаклендә Бейбутов белән берлектә алар шулай ук әсәрнең героинясы Наташа ролен уйнаучы Асия Масагутованы яңа иҗат үрләренә күтәрәләр. Ул талпынып, канатланып киткәндәй итә һәм бөтен колачына җәелеп уйный. Театр сәхнәсендә Наташаның онытылмаслык якты образын иҗат итеп калдыра. Кәшифә апа «Тукай» спектаклендә Касыйм ага Шамил белән бергәләп икенче составта катнашучы Ибраһим Гафуровтан Тукай ролен әзерләтәләр. Тукай яраткан кызны эзләп табып Әминә ролен уйнаучы Галимә Ибраһимова белән очраштыралар. Мондый уртак постановкалар

Кәшифә апаның белемен, тәҗрибәсен киңәйтәләр. Үзенең режиссерлык алымнарын гамәлдә тикшереп, сынап карарга мөмкинлек бирәләр. Әсәрләрне бергәләп сәхнәгә кую академия театрының бүген дә дәвам иттерелә торган тагын бер матур һәм мактаулы традицияләреннән берсе.

Кәшифә апа, әнә шулай итеп, Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә, театр сәнгате корифейлары арасында, кулга-кул тотынышып иҗат итә, аның изге иҗат традицияләрен үзләштерә һәм алга үстерешә, югары квалификацияле режиссер булып таныла.



## Республика күчмә театрында

1955 елда Кәшифә апаны Татар дәүләт академия театрының филиалыннан үсеп чыккан Республика күчмә театрына баш режиссер итеп күчерәләр. Күчмә театр коллективы аны шатланып каршы ала. Кәшифә апа бу театрдагы эшчәнлеген театрны яшь талантлар белән ныгытудан, профессиональ укуны җайга салудан башлый. Театр югары сыйфатлы җитди әсәрләргә мохтаҗ була. Театр тирәсенә Нәкый Исәнбәт, Риза Ишморат, Гамир Насрый, Хәй Вахит, Ш. Зәйни, Г. Минский кебек драматурглар, Җәүдәт Фәйзи, Хәснул Вәлиуллин, Мирсәет Яруллин кебек композиторлар, Әнәс Тумашев, Әнвәр Нагаев кебек художниклар тартыла. Аерым спектакльләр куярга Хөсәен Уразиков, Сабир Өметбаев кебек режиссерлар чакырылалар. Театр 1955—62 еллар арасында тамашачыларына төрле темаларга утыздан артык яңа спектакль күрсәтте. Назыйм Хикмәтнең «Сәер кеше» әсәре, Кәрим Тинчуринның «Сакла, шартламасын» комедиясе, Нәкый Исәнбәтнең «Рәйхан» драмасы, Риза Ишморатның «Үлмәс җыр»ы, Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану»ы, Хәй Вахитның «Яшерен эзләр»е, «Беренче мәхәббәт» пьесалары, Ш. Зәйнинең «Хәзрәт үгетләргә килә», «Тугыз гашыйк», «Таң җыры» дигән әсәрләре, Гамир Насрыйның «Яшел эшләпә»се, Габдрахман Минскийның «Тапшырылмаган хатлар»ы, Шакир Мәҗитовның «Резидәкәй» комедиясе, башкорт язучыларыннан Даут Юлтыйның «Карагол» драмасы, Нәҗип Асанбаевның «Рәйсә»се, әзербәйҗан драматургы Шамхаловның «Кайнана»сы, ниһаять, дөнья классик әдәбиятыннан Жан Мольерның «Жорж Данден» комедиясе шушы елларда сәхнәгә чыгарылдылар.

Сугыш елларында зәгыйфьләнеп аксап калган, сугыштан соң Габдулла Йосыпов, Сөләйман Вәлиев-Сульвалар җитәкләгән чорда аякка баса килгән театр Кәшифә апа эшләгән елларда яңадан иҗат үрләренә күтәрелә һәм чын профессиональ театр хәленә килә. Артистларның талантлы яшь буыны үсеп чыга.

Кәшифә апаның академия театрында һәм күчмә театрны үстерүдә башкарган хезмәтләре партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан югары бәя ала. Аңа 1956 елда Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы белән Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә.

## Һаман сафта

Лаеклы ялга киткәч тә Кәшифә апа үзенең режиссерлык эшен ташламый. Аны әле күчмә театрга, әле Минзәлә театрына спектакль куярга чакыралар. Соңгы елларда гына ул күчмә театрда Т. Закировның «Урман егете» комедиясен, Кадир Даянның «Дулкынлана тирән күл» дигән әсәрен, Минзәлә театрында Д. Аппакованың «Тапкыр егет»ен, Г. Зәйнашеваның «Бәхет кошым» дигән пьесасын, Александр Островскийның «Җариялар»ен сәхнәгә чыгарды.

Кәшифә апа театр техникумында, аннан академия театры каршындагы театр студиясендә, соңрак яңадан ачылган театр училищесында уннарча талантлы артист һәм артисткалар әзерләп чыгарган педагог та. Аңарда белем алган сәнгать эшлеклеләреннән Минзәлә театрының баш режиссеры Мулланур Мостафин, Әлмәт театрының режиссеры Зәкия Туишева, академия театры артистларыннан — Галимә Ибраһимова, Мәрзия Миңлебаева, Ибраһим Гафуров, күчмә театр артистларыннан Газиз Гыйматов, Фердинанд Фарсин, Сания Исмәгыйлова, Люция Фарсина, Гата Нуруллин, Минзәлә театры артистларыннан — Хәдичә Сәлимова, Рабига Шакирова, Мөхәррәм Зәйнуллин, Нәсимә һәм Роза Җиһаншиналар, дәүләт филармония артистларыннан Зифа Басыйрова, Фәйзи Йосыпов, Әзәл Яһүдин, Наҗия Минкиналар барысы да Кәшифә апа шәкертләре. һәм аларның барысына да атказанган һәм халык артистлары, сәнгать эшлеклеләре дигән мактаулы исемнәр бирелгән.

Кәшифә апа әле хәзер дә ару-талуны белмичә җәмәгать эшләрен алып бара. Ул — сәхнә ветераннары советының актив члены. Клублардагы үзешчән сәнгать түгәрәкләренә җитәкчеләр әзерләү өчен ветераннар советы тарафыннан оештырылган драма студиясендә өч ел буена җәмәгать эше тәртибендә укытып килде. Бу студияне бетереп чыккан яшьләр хәзер клубларда гына түгел, Минзәлә, күчмә театрларында артист булып та эшлиләр һәм культура институтының режиссерлык факультетында укыйлар да. Үзешчән сәнгать смотрларында Кәшифә апаны һәр вакыт жюри комиссиясе членнары, консультантлар арасында күрәсең.

Кәшифә Тумашеваның театр сәнгатендә үз алымы, үз стиле, үзенә генә хас кую рәвеше, үз урыны бар. Ул куйган спектакльләр чилепешле булмыйлар. Образлары җанлы, тере, ачык, мезансценалары чигелеп тукылган кебек төгәл, җитлеккән һәм тирән мәгънәле. Ул сәнгатьнең кодрәтен тормышны, алдынгы идеяләрне раслаучы булуында, оптимистик рухында күрә. Аның үз иҗаты да шул сыйфатлары белән көчле булды.

Афзал Шамов

# БЕР КИТАПНЫҢ ТАРИХЫ

Өйдә, китапханәмдә, әллә ни зур да, кечкенә дә булмаган бер китап бар. Ул инде укыла-укыла, кулдан-кулга йөри-йөри шактый тузган, таушалган, кайбер битләре керләнгән, тапланган, хәтта кайбер юлларын танып та булмый. Аның шундый хәлгә килүенә әйләнә-тирәмдәге укучылар гына түгел, ә кулларына эләккән бер китапны актарырга, ертырга яратучы оныкларымның да гаепләре бар. Хәер, нигә аларны гына гаепләргә? Мин аны үз балаларымнан да тиешенчә саклый алмадым. Алар да кечкенә чакларында ул китапны кулларында җитәрлек әвәләделәр. Әле дә аның кайбер битләрендә аларның нәни куллары белән «язылган», бала чак хатирәсе булып калган кәкре-бөкре сызыклар, рәсемгә охшаган да, охшамаган да әкәмәт нәрсәләр ярылып ята.

Ул китапны мин кайчак үземә генә билгеле бер җылы хис белән кулыма алам, шунда, шкаф янында басып торган килеш, яисә өстәл янына барып утырып, аның битләрен ашыкмый гына актарам, кайбер урыннарын, гәрчә кат-кат укылган булса да, кызыксынып укып карыйм, таныш образларны, дусларымны очратам һәм алар мине, үзем дә сизмәстән, узганнарга, ерак елларга алып китәләр.

Бу китап—татар әдәбиятында үзенчәлекле эз калдырган, соклангыч хикәяләр иҗат иткән Мөхәммәт Галинең «Тормыш юллары» исемле беренче зур сайланма әсәрләре җыентыгы. Әдипнең анда «Сабан туенда», «Яңгырсыз елларны», «Пожарныйлар», «Көтүчеләр», «Серле кабер», «Рәхмәтулла тегүче» һәм башка шуның кебек иң матур хикәяләре тупланган. Алар әле бүген дә үзләренең беренче сафлыкларын, нәфисләкләрен, укучыларның күңелләрен дулкынландыргыч көчләрен югалтмаганнар.

Бу әсәрләрнең бергә тупланып матбугатка чыгуында минем дә беркадәр катнашым булды.

1939 ел иде, авыр ел иде, дөнья тарихында шомлы елларның берсе иде. Күк йөзендә кара, куркыныч болытлар айкала. Фашизм дигән котырган ерткыч әле бер илгә, әле икенче илгә канлы тешләрен ыржайта, хәтта инде кайбер илләрне басып та алган, мөстәкыйльлекләрен таптан, изеп, аларга коллык богавын кидергән.

Фашистик Германия белән Италия хәрби интервентлары тарафыннан Испания республикасы канга батырылган. Австрия мөстәкыйльлеген югалткан, Алтын Прага урамнарында,—юк анда гына түгел,— Чехословакиянең барлык шәһәрләрендә, авылларында свастикалы

немец солдатлары йөри. Башка кечкенә илләрнең дә мөстәкыйльлекләре куркыныч астында...

Үзәк Европа төрмәгә, концентрацион лагерьга әверелеп бара. Меңнәрчә, меңнәрчә коммунистлар, революционерлар, азатлык сөюче кешеләр, эшчеләр, интеллигентлар, галимнәр, язучылар төрмәләргә, концентрацион лагерьларга ябылган. Аларның баш очларында фашист палачларының балталары ялтырый...

Берлин, Гамбург, Прага, Вена һәм башка бик күп, бик күп шәһәрләрнең урамнарында китаплар яндырыла, кешелек дөньясын иң яхшы, иң изге хисләр белән буыннан-буынга тәрбияләп килгән әдәби җәүһәрләр утка салына. Гете, Гейне, Шекспир, Бальзак, Золя, Пушкин, Толстой, Горький әсәрләре яндырыла... Һавадан дары исе, янгын исе, булачак дәһшәтле сугыш исе аңкый.

Туган илебезнең чикләре дә тыныч түгел. Советлар Союзы белән дус булмаган, дус булырга теләмәгән кайбер күрше капиталистик илләрнең хәрби көчләре я анда, я монда провокация ясап карыйлар, чикләребезне тынычсызлап торалар.

Чикләребезне генәме соң? Аларны гынамы? Юк, бөтен илне, йөз сиксән миллионлы бөтен совет халкын тынычсызлап торалар.

Казан урамнарыннан,—Казан урамнарыннан гына түгел,—бик күп шәһәрләрнең урамнарыннан, саф-саф булып, «Если завтра война» дигән мәшһүр җырны җырлап, Кызыл Армия частьлары уза. Без аларга өмет белән, бик зур ышаныч белән карап, озатып калабыз. Күңелебез бераз тынычланган шикелле була.

Шулай да тынычланып бетә алмыйбыз. Ил эчендә, халык телендә бер-ике елдан бирле шомлы сүзләр йөри: кемдер халык дошманы булган, кайдадыр шпион тотканнар.

1939 елның апрелендә Татарстан язучыларының икенче съезды булды, яңа идарәгә Муса Җәлил, Шәриф Камал, Таҗи Гыйззәт, Михаил Бубеннов һәм башка иптәшләр сайланды. Шулар арасында мин дә бар идем.

Муса Җәлил идарәнең җаваплы секретаре булып билгеләнде. Союз идарәсенең хәзерге хезмәт бүленеше белән чагыштырганда, председатель дигән сүз бу.

Ул көннәрне Совет Язучылары союзы членнары арасында өлкән яшьтәге язучыларыбыз бик аз иде, хәтта берничә генә иде. Ачыграк итеп әйткәндә, үзләренең иҗатлары белән халык алдында танылган, ихтирам казанган өлкән яшьтәге язучылардан бары Ш. Камал белән М. Гали генә иде. Без аларны карт язучылар итеп саный идек һәм иҗатларын гына түгел, өлкәнлекләрен дә ихтирам итә идек.

Ничәдә иде соң алар? Мөхәммәт Гали 46 ны, Шәриф Камал 55 не тутырган иде. Шуңа карамастан, алар безгә карт булып күренәләр иде. Чөнки без үзебез аларга караганда чагыштырмача яшь идек. Председателебез дә 33 яшендә генә иде.

Бүген мин Язучылар союзы членнары исемлеген кулыма алып карыйм да утызынчы елларда Ш. Камал, М. Гали агаларны карт язучы итеп санап йөрүебезгә гаҗәпләнәм. Кырык-илле яшендәге каләмдәш иптәшләребезне без бүген урта буын язучылар итеп саныйбыз. Бу гаҗәп түгел. Чөнки Союзыбызда алтмышның, җитмешнең аргы ягына атлаган язучыларыбыз да байтак. Шөкер, сиксәнне тутырып килүчеләр дә байтак.

Хәзер менә бу юлларны язганда мин XX гасырның беренче яртысында яшәгән, иҗат иткән һәм вафат булган атаклы язучыларыбызның исемлеген күз алдына китерәм. Татар халык шагыйре Г. Тукай 27 яшендә вафат булды, хәтта 27 не дә тутырмады, Һ. Такташ 31 дә, М. Фәйзи 38 дә, Ф. Әмирхан 40 та, Г. Ибраһимов 50 дә, С. Рәмиев 53 тә, Г. Камал 54 тә арабыздан китте. Күрәсез, берсе дә алт-

мышны тутырмаган, хәтта күбесе иллегә дә җитмәгән. Шуңа күрә ул чөннәрдә безгә Ш. Камал һәм М. Гали агалар карт булып тоелганнардыр да. Аннары аларны карт һәм өлкән итеп саната торган тагын бер нәрсә бар иде. Алар иҗади хезмәтләрен күптән, Бөек Октябрь революциясенә чаклы башлаганнар, шәхси һәм иҗтимагый тормыш авырлыгын җитәрлек татыганнар һәм, ниһаять, совет язучылары, Коммунистлар партиясенең якын ярдәмчеләре дигән мактаулы исемне йөртергә лаеклы булганнар. Бу яклары белән дә алар ихтирамыбызны казанганнар иде.

Бу истәлекне язарга әзерләнгәндә мин, Татарстан язучылары союзы членнарының тулы исемлеген алып, язучыларыбызның уртача яшен табарга тырыштым. Каләмдәш иптәшләребез уртача 54 яшьтә булып чыкты. Бу санны күреп, язучыларыбыз барысы да 54 яшендә дип уйлый күрмәгез, зинһар. Алай дигән сүз түгел бу. Аларның яшьләре дә, картлары да бар. Хәзер Союзыбызга член итеп алынган язучыларыбызның иң яше 27 дә, ә иң карты 79 да.

Яңадан М. Галигә кайтыйк. Югарыда мин М. Гали иҗади хезмәтен Бөек Октябрь революциясенә чаклы ук башлаган дигән идем. Аның «Кунак көткәндә», «Аулак өйдә» исемле беренче хикәяләре 1914 елда «Аң» журналында басылган иде. Димәк, 1939 елда аның иҗади эшчәнлегенә егерме биш ел тулган иде. Шуңа күрә без, идарә членнарыннан өч кеше (М. Җәлил, партия оешмасы секретаре һәм мин), үзара киңәшеп, бу датаны билгеләп үтәргә кирәк дигән фикергә килдек. Идарә утырышларының берсендә тиз арада М. Гали иҗаты турында доклад ясау бурычы миңа тапшырылды. Тик минем докладны тикшергәннән соң гына без бу юбилейны кайда, ничек һәм нинди күләмдә үткәрергә икәнен билгеләргә булдык. Карар чыкканчы һәм юбилейны үткәрү өчен югары оешмалардан рөхсәт алганчы, бу турыда берәүгә дә, идарәнең башка членнарына да, М. Галинең үзенә дә әйтми торырга кирәк таптык. Кем белә, бәлки юбилейны үткәрергә рөхсәт итмәсләр дип уйладык. Ни әйтсәң дә, әдип гомеренең түгәрәк датасы түгел, ә иҗади эшчәнлегенең еллыгы гына. Шуңа күрә, планыбыз барып чыкмаса, М. Галинең күңелен кырырлык итмәскә булдык. «Юбилееңны үткәрәбез, әзерләнеп тор», дип, аны өметләндереп тә, соңыннан берәр сәбәп аркасында аны үткәрә алмасак, әдип өчен моның бик күңелсез булуы мөмкин. М. Гали болай да шагыйранә нечкә күңелле кешеләрдән иде.

Докладны миңа тапшыруның кечкенә генә сәбәбе бар иде. Мөхәммәт абый белән мин күптәннән таныш идем, бер-беребезгә җылы, яхшы мөнәсәбәттә идек. Докладчы билгеләгәндә бу як та истә тотылды. Бу сүзләрдән чыгып, аның идарәдәге башка иптәшләргә мөнәсәбәте салкын булган яисә начар булган икән дип уйлый күрмәгез. Һич тә алай түгел! Мөхәммәт абый, гомумән, ачык күңелле, кешеләргә яхшы, җылы мөнәсәбәтле, игътибарлы, кечелекле кеше иде.

Без еш кына очраша идек. Исәнлек-саулыкны сорашулардан тыш, эш турында, тормышыбыз турында һәм башка мәсьәләләр турында да сөйләштергәли идек. Һәр җыелыштан диярлек сөйләшә-сөйләшә, фикерләребезне уртаклаша-уртаклаша бергә кайта идек. Бер якта тора идек без: ул — Касаткин урамында, мин — Тельманда.

Ул елларда Язучылар союзында җыелышлар күп була иде. Соң башлана, соң бетә иде алар. Кайчак өйгә, гаиләбез янына, төн урталарында, хәтта таң алдында арып-талып кайтып керә идек. Җыелышлар озак дәвам иткәнгә түгел, ә бәхәсле булганга арый идек без. Эшлекле һәм тыныч җыелышларга караганда, шау-шулы җыелышлар, бер-беребезне чамадан тыш тәнкыйтьләүдән торган җыелышлар ул елларда күбрәк була иде.

1939 елда мондый күңелсез вакыйгалар кабатланмаса да, узган елларның шаукымы хисле күңелләребездән тулысынча чыгып бетмәгән иде.

Шундый көннәрнең берендә мин Мөхәммәт абыйны Язучылар союзы идарәсе алдындагы мәйданчыкта очраттым (ул чакта идарә Матбугат йортының бишенче катындагы бүлмәләргә урнашкан иде). Әле дә хәтердә, мәйданчыкта утырырга урындыклар да, диван да юк, бары шактый кыршылган, тузып, җимерелеп барган озынча бер өстәл генә бар иде. Хәл-әхвәл сорашканнан соң, минем сөйләшергә теләвемне, аңа нинди дер йомышым барлыгын аңлап, Мөхәммәт абый аякларын салындырып, өстәл өстенә менеп утырды, мин каршысына бастым. Өстендә соры костюм, ак күлмәк, галстугын матур гына итеп бәйләгән, сакалын яхшы итеп кырган, яңаклары ялтырап, күкселләнеп тора, кулында яз да, җәй дә, көз дә кия торган, без инде күнегеп беткән, бераз искерә төшкән соры фетр эшләпә. Күңеле тыныч, күтәренке булса кирәк. Акыллы соргылт күзләре белән һәр вакыттагыча дустанә карый.

Мин аңа йомышымны кыскача гына сөйләп бирдем.

— Менә нәрсә, Мөхәммәт ага,—дидем,—идарә үзенең эш планына синең иҗатны тикшерү мәсьәләсен кертте. Докладчы итеп мине билгеләде. Аны алдагы утырышларның берсендә тыңларга әзерләнә. Шуңа күрә миңа тәрҗемәи хәлең кирәк иде. Язганы бармы? Булса, шуны бир. Булмаса, тиз арада язып бирә алмассыңмы?.. Тулырак, җентекләбрәк язсаң, яхшы булыр иде. Ярыймы?.. Аннары кайбер китапларың да кирәк. Миндә барысы да юк. Җыентыкларыңа кермәгән хикәяләрең дә бар бит синең. Шуларны берничә көнгә биреп тора алмассыңмы? Озак тотмам, утырышта ук үзеңә кайтарырмын.

Авызымны ачып сөйли башлагач ук Мөхәммәт абый нигәдер миңа, күзләрен зур итеп ачып, гаҗәпләнеп карады һәм шул хәлендә, аптырап, катып калды шикелле. Сүземне әйтеп бетергәч тә җавап бирми торды. Мин тәрҗемәи хәле турындагы үтенечемне кабатларга мәҗбүр булдым.

— Тәрҗемәи хәлем нигә кирәк сиңа?—диде ул, ниһаять.

Мин дә, үз нәүбәтемдә, аның шундый гади сүзләрне аңлап бетермәвенә гаҗәпләндем һәм үтенечемне мөмкин чаклы ягымлырак итеп яңадан аңлатып бирергә тырыштым.

Ничек кенә аңлатсам да, Мөхәммәт абыйның күз карашы үзгәрмәде. Ул, миңа нинди дер каты сүз әйтергә әзерләнгән кыяфәт белән өстәлдән төшеп, ике кулы белән чалбарын күтәреп куйды. Аның борчылган, аптырашта калган яисә ачуы килгән чакларда чалбарын күтәргәләп кую гадәте бар иде. Дөресе, күтәрү дә түгел иде бу. Бары чалбар якасын костюмы аша ике кулы белән ике яктан тотып, күтәргән сыман хәрәкәт ясау гына иде. (Бу гадәте аның бала чактан калган булса кирәк.)

«Кәефе нигә бозылды соң моның? — дип гаҗәпләнеп уйладым мин.—Әллә берәр ярамаган сүз әйттемме икән?.. Кәефен кырырлык, үпкәләтерлек бер сүз дә әйтмәдем шикелле ләбаса...»

Мин инде үзем аптырап калдым. Ни булды соң бу Мөхәммәт абыйга? Әллә минем турыда аңа берәр начар сүз сөйләүче кеше булдымы икән? Нәрсә сөйләүләре мөмкин соң? Аның турында минем беркайчан да, беркайда да начар сүз әйткәнем юк. Әйтерлек сәбәбе дә юк. Әллә инде иҗады турындагы докладны яман ният белән, ягъни әсәрләреннән кимчелек эзләү нияте белән куярга җыеналар дип уйлыймы икән? Нигә алай уйласын? Ниятебез яхшы... Тукта әле, мин аңа доклад турында ничегрәк әйттем соң? «Иҗадыңны тикшерергә телиләр»,—дип әйттем түгелме? Шулайрак әйттем кебек. Тикшерү дигән сүздән шикләнәме әллә?..

Башымнан бер-бер артлы шундый уйлар йөгереп үтте. Шуңа күрә мин ниятебезнең яхшылыгын, изгелеген, мәсьәләне бары аңа ярдәм итү максаты белән генә куюыбызны аңлатып бирергә теләдем.

— Кара әле, Мөхәммәт абый, нигә борчыласың син?— дидем мин аңа. — Без бит моны иң яхшы максаттан чыгып эшләргә җыенабыз... Идарә члennары иҗатың белән тулырак танышырга телиләр, синә кулларыннан килгәнчә ярдәм итмәкче булалар. Үзең беләсең, бәлки яхшы киңәш бирүчеләр булыр... Алдагы иҗат эшендә файдасы тияр...

Сизәм, аны тынычландырырлык сүзләр таба алмыйм, башымда һаман бер уй: «Үпкәләтерлек нинди ярамаган сүз әйттем икән мин аңа?» Шунысы кызганыч, юбилее турында әйтә алмыйм. Әйтми торырга сүз куештык бит.

Мөхәммәт абый миңа шактый тупас җавап кайтарды:

— Кара әле, Афзал, мин бит идарәгә яхшы, ышанычлы кешеләрне сайладык дип уйлаган идем. Яшермим, шатланган да идем. Күрәсең, ялгышканмын икән... Гонаһсыз кешене батырырга җыенасыз...— диде дә, борылып, саубуллашмыйча, кулын бирмичә, бишенче каттан төшеп китте.

Бу сүзләрне ишетеп, мин баскан җиремдә катып калдым. Аның кул бирмәвенә, саубуллашмавына түгел, ә җавабына, тавышының корылыгына, миңа таныш булмаган, моңарчы беркайчан да аңардан ишетергә туры килмәгән тон белән җавап кайтаруына гаҗәпләндем. Йөрәгем «жу!» итеп китте. Менә нигә үпкәләгән, нигә ачуланган, нигә шул кадәр коры тон белән җавап кайтарган икән ул миңа? Син аңа иң изге максатлардан чыгып киләсең, сөйләшкәндә дә аны олы кеше итеп, өлкән әдип итеп, ихтирам итеп сөйләшәсең, басылган әсәрләрен, биографиясен сораганда да түбәнчелекле тон белән сорыйсың, һәрбер сүзеңне чын күңелдән әйтәсең. Ә ул синең яхшы ниятеңне, чын күңелеңнән әйтелгән сүзләреңне бөтенләй икенчегә юрый, сине һәм иптәшләреңне яман ниятле, култыгында таш саклап йөрүчеләр итеп саный...

Башта мин шулай уйладым, Мөхәммәт абыйның тупаслыгына үпкәләдем, шуңа күрә артыннан төшмәдем. Әмма бераздан, сөйләшкән сүзләрне берәм-берәм анализлагач, әдипкә булган үпкәм әкренләп югалды һәм аңа ниятебезне, максатыбызны яхшылап аңлатып бирә алмавыма үкенә башладым. Сөйләшә белмәгәнмен, тиешенчә аңлата алмаганмын, күрәсең, дидем. Шулай да аңлашыр өчен өенә бармадым.

Мөхәммәт абыйны икенче очратканчы күпмедер вакыт узды,— атнамы, ун көнме, әллә аннан да артыгракмы, хәтерләмим. Ләкин бу көннәрне мин чын күңелемнән борчылып үткәрдем.

Ниһаять, мин аны очраттым. Нindидер җыелыш буласы иде. Башланырга берникадәр вакыт бар иде әле. Мин аның янына барып утырдым. Ул мине бик салкын каршы алды, хәтта күрешмәдек тә шикелле. Мин аңа ачыктан-ачык әйттем:

— Аңла, Мөхәммәт абый,— дидем,— әгәр телисең икән, ант итеп әйтәм: иптәшләр синең иҗатың турындагы докладны бары сине ихтирам итеп кенә куялар. Берәүнең дә синең тырнак астыңнан кер эзләргә нияте юк. Белә торгансың ич, быел синең яза башлавыңа егерме биш ел тула. Моннан егерме биш ел элек «Аң» журналында беренче хикәяләрең басылып чыкты бит. Шулаймы?... Менә шуны искә алып иҗатың турындагы докладны тыңларга әзерләнәләр. Башка һичбер максат юк. Ышан... Ярар, доклад дип әйтмик, ул кадәр зурайтмыйк, информация дип кенә атыйк. Шулай ярыймы?

Мөхәммәт абый бер сүз дә әйтмәде, гәрчә урындыкта утырган булса да, чалбарын берничә тапкыр күтәргәләп куйды. Аның тынычсызлыгын, борчылуын күреп, тагын да ачыграк итеп аңлатып бирергә тырыштым.

— Нигә куркасың син, Мөхәммәт абый? Нидән шикләнәсең? Сине тәнкыйтьләргә ниятлиләр дип уйлыйсың икән — бик ялгышасың! Миңа ышанмасаң, әнә Мусадан сора, аның белән сөйләш...

Мөхәммәт абый сүзләремә ышандымы, юкмы — белмим. Ләкин ул көнне дә без җыелыштан бергә кайтмадык. Дөресе, ул минем белән бергә кайтырга теләмәде булса кирәк, мине көтмичә, алдан чыгып китте. Башка вакытларда без аның белән бергә чыга, бергә кайта идек. Әгәр берәребез иртәрәк чыкса, түбәндә, Матбугат йорты ишеге төбендә көтеп тора идек.

Биографиясен язып бирүен сораган көннән бирле мин аның читләшә баруын, очраганда күрмәмешкә салышуын, минем белән очрашырга, сөйләшергә теләмәвен сизә башладым. Бүген дә аның җыелыштан минем белән бергә кайтмавы, кайтырга теләмәве, электәгечә, мине түбәндә, Матбугат йорты ишеге төбендә көтеп тормавы минем белән очрашырга теләмәвен күрсәтә иде. Шулай итеп, һич көтмәгәндә, уйламаганда арабыздан кара мәче йөгереп үтте. Бертөрле дә гаебем булмаганлыктан, бу хәл, бу салкынаю мине шактый борчуга салды.

Шулай да Мөхәммәт абый биографиясен язып китерде. Аның бераз калтыранып чыккан, эре-эре хәрефләр белән язылган биографиясе әле дә архивымда саклана. Почерк белән дә, юлларының кәкре-бөкрелеге белән дә һәм юлларга сыймаган сүз кисәкләрен, иҗекләрне сыйдырырга тырышып, юл ахырын аска таба бөгеп төшерү белән дә бу биография миндәге бик күп кулъязмалардан аерылып тора.

Утызынчы елларның ахырында Язучылар союзы членнарының күпчелеге җәй көннәрендә дачага Түбән Осланга чыга иде. Чөнки әдәби фондыбызның ял базасы шунда иде. М. Гали дә 1939 елның җәендә, үзенең тормыш иптәше Сафия ханым белән бергә, шунда торды. Җәйге айларда язучыларыбызның күпчелеге дачада икәнен искә алып, идарәнең киңәйтелгән утырышын Түбән Осланда үткәрергә булдык. Муса һәм дачага чыкмаган башка иптәшләр дә бу утырышка Казаннан махсус килделәр.

Утырышны әдәби фонд йортының алмагач бакчасында ясадык. (Әдәби фондның бер таш йорты бар иде.) Өстәлләр, урындыклар юк. Җиргә, үлән өстенә генә тезелешеп утырдык. Кайсыбыз кырын яткан, кайсыбыз аякларын бөкләп утырган, тезләнгән — кыскасы, кемгә ничек уңай булса, шулай урнашкан.

Мәҗлестә кеше аз түгел. М. Галидән башка М. Җәлил, Ш. Камал, Т. Гыйззәт, А. Алиш, Г. Кашшаф, Г. Бәширов (ул чакта әле Г. Разин), А. Әхмәт, Г. Гобәй, «Совет әдәбияты» редакторы Т. Имаметдинов һәм башкалар килгән. Көн тәртибендә беренче мәсьәлә: «М. Галинең әдәби иҗаты».

Алдан планлаштырганча, докладны мин ясадым. Хәзер инде, бик күп еллар үткәннән соң, аның иҗаты турында нинди сүзләр, нинди фикерләр әйтүемне хәтерләмим, шулай да докладымның бер моменты күңелемдә ачык сакланып калган: аның иҗаты турында мин мөмкин чаклы уңай караштан торып сөйләргә тырыштым, әдәби кимчелекләрен аз күрсәттем. Миннән соң чыгып сөйләүчеләр дә аның иҗатына уңай бәя бирделәр һәм аңа иҗади уңышлар теләделәр.

Казаннан җыелышка килүчеләр хөрмәтенә тормыш иптәшләребез, бергәләшеп, пилмән пешергәннәр иде. Аны тәлинкәләргә, тирән эчле вак табакларга салып, алдыбызга, үлән өстенә җәелгән ашъяулыкларга китереп куя башладылар. Иптәшләребез, мин сөйләгәнне тыңлыйтыңлый, пар чыгып торган кайнар пилмәнне бик тәмләп ашарга керештеләр. Тик Мөхәммәт абый гына пилмәнгә орынып карамады. Сәбәбен белмәдем. Әллә инде ул әле дә иҗаты турындагы мәсьәләне, яхшы нияттән чыгып, чын күңелдән куюыбызга ышанып бетерми, әллә инде иптәшләрнең җылы сүзләреннән күңеле тулган, дулкынланган иде.

Гаҗәп түгел, күңеле тулуы да бик мөмкин. Чөнки кеше һәм аның хезмәте турындагы уңай сүзләргә кем сусамый!

Утырышның кыска гына бер карары да булды: 1) М. Галинең иң яхшы хикәяләрен туплап, бер җыентык чыгарырга. Аны 1940 елгы планга кертүне Таттосиздаттан үтенергә. 2) Быел М. Галинең әдәби-иҗади эшчәнлегенә егерме биш ел тулганлыгын искә алып, көзге айларның берендә аның иҗатына багышланган тантаналы җыелыш үткәрергә.

Юбилей кичәсе декабрь аенда, язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында үткәрелде. Кызганычка каршы, мин катнаша алмадым. Казанда түгел идем. Иптәшләрнең сөйләвенә караганда, кичә бик матур узган, халык күп булган. Тәнкыйтьче Гази Кашшаф аның әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге турында доклад ясаган. Соңыннан концерт булган. Анда М. Галинең хикәяләреннән өзекләр укыганнар.

Юбилей уңае белән әдип исеменә Мәскәүдән, тугандаш республикаларның Язучылар союзларыннан, редакцияләрдән, уку йортларыннан, дусларыннан, укучылардан күп кенә котлау телеграммалары килгән. Аларны да тантаналы кичәдә укыганнар.

Соңыннан М. Галинең хикәяләре җыентык хәленә китерелеп, әзерләнеп, нәшриятка бирелде. Аны мин рецензияләдем (ул чакта Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли идем), җыентыкка керәчәк хикәяләрне автор белән бергә сайладык, бергә тәртипкә салдык.

Юбилей да узды, Язучылар союзы идарәсе М. Галигә иҗади эш белән тынычрак шөгыльләнергә мөмкин булсын өчен акчалата ярдәм дә күрсәтте, китабы да редакцияләнеп, кул куелып типографиягә төшерелде, Мөхәммәт абый белән арабыз да төзәлде, очрашканда дусларча кулыбызны кысышабыз, җыелышлардан да, сөйләшә-сөйләшә, фикерләребезне уртаклаша-уртаклаша, бергә кайтабыз. Шулай да Мөхәммәт абыйның әлеге биография вакыйгасына, шул уңай белән әйтелгән тупас сүзләргә, аларның дөрес булып чыкмавына кайтканы, бу турыда фикерен әйткәне юк. Бу хакта нәрсә булса да әйтүен һаман көтеп йөрим. Әйтергә тиеш. Ничек инде әйтмәскә! Ә үзем сүз башламыйм, уңайсызланам. Олы кешене, өлкән әдипне уңайсыз хәлгә калдырасым килми.

Ниһаять, китабының беренче корректурасы килде. Аны укырга авторның үзенә бирдек.

Беркөнне иртә белән Мөхәммәт абый, корректураларны тотып, минем янга, нәшриятның 84 нче бүлмәсенә килеп керде (матур әдәбият секторы редакторлары шунда утыра иде). Иптәшләр килеп җитмәгәннәрме, әллә эш белән чыгып киткән булганнармы, белмим, бүлмәдә ялгыз гына идем.

Мөхәммәт абый, гадәттәгечә, кул биреп, ачык йөз белән күреште, күрсәтелгән урынга утырды. Хәл-әхвәлне сорашкач, корректураларны өстәлгә, минем алга куйды, аны җыентыкның редакторына — Гази Кашшаф иптәшкә бирүемне үтенде... Һәм тынып калды.

Корректура тапшырылган, сүз тәмамланган, эшләүче кешегә комачаулык итмәс өчен, саубуллашып чыгып китәсе генә калган. Ләкин ул чыгып китәргә ашыкмады. Өстәлдәге каләм сабын кулында бераз әйләндергәннән соң сүз башлады:

— Афзал, мин синнән гафу үтенергә тиеш бит әле,— диде.

Мин сүзнең нәрсә турында барасын сизсәм дә, аңламамышка салышып:

— Ни өчен, Мөхәммәт абый?— дип сорадым.

Ул, кулындагы каләм сабын әвәләвендә дәвам итеп, күтәрелеп карамыйча гына аңлатып бирде:

— Хәтереңдәдер, әлеге, тәрҗемәи хәлемне сораганнан соң әйткән

сүзләрем өчен... Мин бит аны яман нията белән сорыйсыз дип уйлаган идем...

— Ай, ташлагыз әле шуны, Мөхәммәт абый!— дидем мин, аны тынычландырырга теләп. — Күптәнге вакыйга ич ул. Онытылып та беткән инде. Нигә аның өчен гафу үтенергә?

Дөресе, ул көннәр, ул сөйләшүләр хәтеремнән чыкмаган иде. Онытылуы мөмкин түгел иде.

— Шулай да гафу үтенергә кирәк,— диде Мөхәммәт абый. — Үтенмичә ярамый. Әгәр кешенең хәтерен калдырасың икән, урынсызга, һичбер сәбәпсез калдырасың икән, гафу үтенергә кирәк. Мин дә хәтереңне урынсызга калдырдым. Бактың исә, тәрҗемәи хәлемне иң яхшы теләктән чыгып, мине ихтирам итеп сорагансыз икән...

Без аның белән чын күңелдән аңлашып, дусларча аерылдык.

...Өйдә, китапханәмдә, әллә ни зур да, кечкенә дә булмаган бер китап бар. Ул инде укыла-укыла, кулдан-кулга йөри-йөри шактый тузган, таушалган, кайбер битләре керләнгән, тапланган, хәтта кайбер юлларын танып та булмый. Кайчак мин аны үземә генә билгеле бер җылы хис белән кулыма алам, я өстәлем янына барып утырып, я шунда, шкаф янында, аягүрә баскан килеш кенә битләрен актарам, кайбер урыннарын укыштыргалыйм, таныш образларны, Рәхмәтулла тегүчеләрне, Таз Шәрәфиләрне, Сәйфетдин солдатларны һәм башкаларны очратам, алар белән сөйләшәм, кайгыларын, шатлыкларын уртаклашам. Кай минутларда, китабымны кулыма тоткан килеш, тирән уйга чумам. Бу китап, бу образлар мине, үзем дә сизмәстән, еракларга, узган көннәргә алып китәләр. Шундый минутларда нигәдер миңа ишегем ачылып китәр дә, кулына корректураларын тоткан килеш, ачык йөз белән дусларча елмаеп, Мөхәммәт абый керер шикелле тоела...

Еллар, еллар, без синең шаукымнарыңны, давылларыңны, сынауларыңны онытсак та, дусларыбызның, арабызда яшәгән, иҗат иткән, халыкка, киләчәккә файдалы хезмәтләрен бүләк итеп калдырган өлкән агаларыбызның ачык чырайларын, елмаюлы күз карашларын беркайчан да онытмыйбыз, исебездән чыгармыйбыз, алар турындагы истәлекләребезне бик зур ихтирам белән киләчәккә алып барабыз, туачак буыннарга тапшырабыз.

М. Елизарова

# ПУШКИН КАЗАНДА

Республикабыз тарихында А. С. Пушкин, Л. Н. Толстой, А. И. Герцен, Н. А. Некрасов, Г. Р. Державин, С. Т. Аксаков кебек атаклы рус язучыларының Казанда булулары белән бәйле күп кенә кызыклы сәхифәләр бар.

А. С. Пушкинның Казанга килүе Пугачев җитәкчелегендәге восстание тарихын өйрәнүгә бәйле икәне һәркемгә билгеле. Пугачев восстаниесенең тарихын өйрәнү белән Пушкин шул кадәр мавыгып китә ки, аны инде башкаладагы архив материаллары гына канәгатьләндерми башлый, ул Идел буе һәм Урал ягының восстание булган җирләрен йөреп чыгарга ниятли.

Дусты Нащокинга җибәргән хатында ул: «Бу сәяхәт миңа физик яктан да, рухи яктан да кирәк», — дип яза.

Икенче бер хатында Пушкин: «Аксөякләр арасында хатынымның даны зур, бу хәл күп акча таләп итә, акчаны мин хезмәт белән табам, ә хезмәтем ялгызлыкны сорый...»[1] дип яза.

Ләкин Пушкин үзе өчен бик кирәкле бу сәяхәткә патшаның рөхсәтеннән башка чыгып китә алмый, билгеле. Ул жандармнар шефы Бенкендорфка хат яза:

«Күптән башлаган китабымны тәмамлау өчен миңа бер-ике ай ялгызлыкта булырга кирәк. Китабымдагы вакыйгаларның күп өлеше Оренбург һәм Казанда бара. Менә шуның өчен мин бу ике губернага барып кайтырга теләр идем...»

Бу хатына Пушкин түбәндәге җавапны ала: «Патша галиҗәнабләре Оренбург белән Казанга барырга Сезне нәрсә мәҗбүр итүен һәм бирedә Үзегезгә йөкләтелгән эшне ни сәбәптән калдырырга уйлавыгызны белергә тели».

Хатыныңны Сарай балларына озатып йөрү бик зур эшмени!

Ачуы чыккан Пушкин хатка болай дип җавап бирә:

«Соңгы ике ел буена мин бары тик тарих өйрәнү белән шөгыльләндем, бер генә юл да әдәби әсәр язмадым. Әһәмиятле эшләрдән (бу сүз ачы ирония белән языла.— М. Е.) бушанып китабымны тәмамлау өчен минем бер-ике ай ялгызлыкта булуым бик мәҗбүри...

Авылда нинди китап язуым турында бәлки галиҗәнабкә белергә кирәктер: вакыйгаларының күп өлеше Оренбург белән Казанда барган роман ул һәм менә шуның өчен минем бу ике губернада буласым килгән иде».

---

[1] «Пушкин хатлары», Т. III, 87 бит.

Сарай тормышы шартларыннан туеп беткән һәм Николай патша белән Бенкендорф кушуы буенча барган күзәтүләрдән җәфа чиккән Пушкин, материал җыюдан тыш, рәхәтләнеп бер ял итәргә, иркенләп тын алырга, Петербургның салкын стеналарыннан мөмкин кадәр ераккарак китәргә теләгән иде.

Хәр фикерле шагыйрьне күзәтү астыннан җибәрергәме, юкмы дип озак икеләнгәннән соң, Николай патша Пушкинга рөхсәт бирә һәм аның сәяхәте вакытында күзәтүне дәвам итәргә куша.

1507 чакрымга сузылган Петербург — Казан юлы 19 көн дәвам итә. Почта атлары начар юллардан чаба һәм сәяхәтчене бик йончыта. Пушкин хатынына: «Казанда берләре тирәсендә булырмын», дип яза. Хатны 26 августта Мәскәүдән җибәрә. Ләкин Казанга ул 5 сентябрьнең төн уртасында гына килеп җитә.

Художник Харис Якупов рәсемендә Идел аша чыгып җиткән Пушкинның Казанга юнәлүе сурәтләнә. Ә художник Виктор Куделькин картинасында сентябрьнең 6 сына каршы төндә Пушкинның Казанга килеп керүе тасвирлана.

Шагыйрь Петропавловск тыкрыгындагы (хәзер Рәхмәтуллин урамы) дворяннар кунак йортында туктала.

Кунак йортында Пушкин һич көтмәгәндә үзенең яшьлек дусты, лицейдагы шәриктәше, шагыйрь Евгений Абрамович Баратынский белән очраша. Художник Юрий Лысогорский үзенең картинасында бу очрашуны шактый уңышлы күрсәтә алган.

Пушкин Баратынскийны шагыйрь итеп таный. Дуслары Плетнев белән Дельвиг тә аларның арасын якынайтып тора. 1831 елны Дельвигның үлеме шагыйрьләрне зур хәсрәткә сала. Пушкин Плетневка язган хатында: «Аннан башка без ятим калгандай булдык. Бармак белән сана әле, күпме без? Син, мин, Баратынский, барысы шул... Баратынский борчылуыннан авырый башлады».

Баратынскийның Казан аша Каймары авылына, хатынының әтисе Л. Н. Энгельгард имениесенә кайтып баруы була. Пушкин юлда бик нык йончыган булса да, үткәннәрне искә алып, алар төн буе сөйләшеп чыгалар. Баратынский Казан әдипләренә, шул исәптән шагыйрә Александра Андреевна Фукска да, Пушкинның Казанга килүе турындагы шатлыклы хәбәрне җиткерергә ашыга.

Ә Пушкин йокысыз төнне һәм юлдан аруларын да онытып, Казанны карарга китә. Ул губернаторга һәм шәһәрнең зур чиновникларына күрешә килми, архив документларын да эзләргә омтылмый, аларда күп нәрсәнең бозып күрсәтелүен, чын тарихи дөреслекнең бирелмәвен белә.

Пушкин гади халык арасына китә. Пугачев турындагы дөреслекне гади халык авызыннан ишетергә тели. һәм ул алданмый. Суконный бистәсенең «Кечкенә кыр» дип аталган урамы башында Казан сукночыларына билгеле булган «Горлов кабак» була. Бәйрәмнәрдә анда җырлар җырлана, ярлы халык «тамак чылата».

Казан сукночыларының Пугачев хәрәкәтендәге ролен белгән Пушкин «Горлов кабак»ка китә. Анда шагыйрь белән чын күңелдән сөйләшүчеләр табыла. Художник Равил Нурмөхәммәтов картинасы Пушкинның Казан сукночысы Бабин белән әңгәмәсен сурәтли. Бу вакыйга 1833 елның 6 сентябрендә була.

Бабин Пушкинга 1774 елда Пугачевның Казанны алуы турында кыйммәтле истәлекләр сөйли. Бабин Пугачевның Суконный бистәсен алуы, дворяннар һәм бай сәүдәгәрләр яшәгән шәһәр үзәгенең януы, Пугачев лагереның планы, баш күтәрүчеләрнең туплары торган җирләр турында һәм восстаниечеләрнең мәрхәмәтсезлек белән тармар ителүе хакында сөйли. Бер-беренә орынып утырган агач йортлардан торсалар да, Суконный һәм Татар бистәләре янгыннан зыян күрмиләр. Бу үзе үк баш күтәрүчеләрнең зур ташпулатларда яшәгән байлар белән көрәшүен күрсәткән бер мисал. Бабиннан күп нәрсәләр сорашып белсә дә, Пушкин аның исемен «Пугачев тарихы»на кертми, картның жандармнар тарафыннан эзәрлекләнүен теләми.

Шуннан соң Пушкин тройкага җигелгән җиңел арбага утырып Казаннан ун чакрым ераклыктагы Троицкий тегерменәнә килә. Нәкъ менә шушы тегерməндә, бөтен шәһәр уч төбендә кебек күренгән җирдә, 1774 елны Пугачевның ставкасы була. Казанны алырга әзерләнеп, Пугачев 20 мең кешелек гаскәре белән шушы лагерьда тора.

Художник Лотфулла Фәттах үзенең бер картинасында Пушкинның Пугачев булган урыннарын карап йөргүен сурәтли.

Нокса инешенең Казанкага койган җирендә биек яшел яр буенда утырган Троиц-Нокса авылы тирәсендәге Пугачев лагере урыннарын игътибар белән карап йөргәннән соң ул Царицын авылы янында пугачевчыларның 1774 елның 12—13 һәм 15 июлендә Михельсон отрядларына каршы каты сугыш алып барган җирләрендә була. Пушкин Себер трактына да килә. Бу урыннар да Пугачев исеме белән бәйле. Крестьяннар башлыгы биредә 1774 елның 10 июлендә үзенә каршы җибәрелгән полковник Николай Толстойның «Казан атлы легионы»н тар-мар итә.

Харис Якуповның «Пугачев Казанда» дигән картинасында баш күтәрүчеләр арасындагы төрле милләт кешеләре сурәтләнә.

Шагыйрь кунак йортына Себер трактыннан әйләнеп кайта. Александр Сергеевич патша хөкүмәте тарафыннан Себергә сөрелгән меңәрләгән кешеләрнең шушы юлдан үтүен, дусларыннан берничә декабристның да шул трактта газап чигүен белә иде.

Лотфулла Фәттахның «Пушкин Кремльне карый» дигән картинасы бар. 7 сентябрьдә көндезге сәгать 12 дә Пушкин Казан Кремленә китә. Кремльнең иске стеналары яңартылган, акшарланган була. Ләкин шагыйрь күз алдына күптән узган көннәр килеп баса.

Биредә богаулы «исемсез тоткын» — Пугачев восстаниегә кадәр үк әле төрмәдә газап чигә. Пушкин ялкын чолгаган Казанны, төтен һәм ут эчендәге каралтыларның ишелеп төшүләрен, коралды крестьяннар төркемен күз алдына китерә, Пугачевның Гостиный двор трактиры янына батареялар куюын, аннан торып крепостька, бигрәк тә Спасск монастырена атуын күргәндәй була...

Кремльнең барлык җирен дә карап бетергәч, Пушкин сәгать ярымлап вакытын кунак йортында үткәрә, Казанны карап йөрүдән алган тәэсирләрен яза.

7 сентябрьдә сәгать 2 дән 6 га кадәр Пушкин Казан шагыйре һәм театралы Э. П. Перцов йортында була. Анда төшке ашны ашый һәм шахмат уйный.

Шәһәрдәге интеллигент катлавының үзәгендә торган Э. П. Перцовның Пушкин килгән вакытта Казан губерна управлениесендә хезмәт иткән чагы була. Ул һәртөрле әдәби укулар, үзешчән спектакльләр, концертлар, шәһәр читендә күңел ачуларны башлап йөрүче, оештыручы була. Ул Мәскәү һәм Петербургта еш була, 1820 елларның икенче яртысында башкаладагы әдипләр арасына керә һәм Пушкин белән таныша. Пушкин Перцовның үзенә һәм аның әдәби иҗатына зур хөрмәт белән карый. Бу турыда Баратынский: «Перцов бик акыллы, белемле, хәлиткеч талантлы кеше. Аның шигъри **шаяруларын** безгә Пушкин да мактаган иде», — дип искә ала. Перцов күбрәк сатира яза.

П. А. Вяземский: «Перцовның телдән сөйләгәннәренә караганда язган шигырьләрендә борычы күп тапкыр әзрәк», — дип әйтә. Перцов «шаярулары»н матбугатта бастыру өчен язмый. Мәсәлән, аның бер шигыре халыкка мөрәҗәгать белән башлана:

**Бердәм булып балта ал да**
**Кирәкмәгән читәнне җимер.**

Икенче бер шигырендә дөрес булмаган политика белән халыкны восстаниегә этәрүе өчен патшаны гаепли. 1832 елны Казанда «Заволжский муравей» журналы чыга башлый. Титул битенә:

**Хезмәтемә мактау һәм дан өмет итмим,**
**Яратып һәм кәефләнеп эшем эшлим,—**

дигән эпиграф урнаштырылган бу журналда Перцов та актив катнаша. Соңга табарак, Петербургта яшәгәндә, Эраст Перцов туганы Владимир белән Герценга булыша. Алар «Колокол»га яшерен информацияләр җибәреп торалар. Мәсәлән, «Колокол»ның 1858 ел 1 октябрь санында уннарча яшерен документларның тулы текстлары

басылып чыккач, башында патша Александр II торган Россия яшерен полициясенең 3 нче бүлегендә эшләүчеләрнең ачуы чыга. 3 нче бүлек «Колокол»га бу документларны җибәргән корреспондентны тырышып эзләргә керешә. Ә өч елдан соң, 1861 елның мартында, икенче сенсацион материал басыла: «1861 елның 26 һәм 28 январенда Дәүләт советының берничә сәгатькә сузылган яшерен утырышы булды. Утырышка император, министрлар, югары дәрәҗәле сановниклар — барысы да «үз кешеләр» катнашты». Бу киңәшмәдә крестьяннарны азат итүнең шартлары турында сүз бара. Киңәшмәнең төгәл отчеты бер айдан соң «Колокол»да басылып чыга. Бу материалларны анда Эраст һәм Владимир Перцовлар җибәргән була. 1861 елны кемнеңдер чагуы буенча Эраст кулга алына [1].

Художник Т. П. Радимованың «Перцов өе» дигән этюды бар. (Ул хәзерге Профсоюз урамы, 25 нче йорт). Эраст Петрович Перцов 1804 елны туа һәм 1873 елда, тормыш шартлары авыр булу сәбәпле, үзен-үзе үтерә.

Сәгать 6 лар тирәсендә А. С. Пушкин Татар бистәсенә Фуксларга китә. Карл Федорович Фукска ул вакытта 57 яшь. Шуңа карамастан, ул бик җиңел сеякле, тәрбияле, галим кеше була. Казан университетының профессоры. Ул җирле тарих, әдәбият турында, татар халкының культурасы, көнкүреше турында Пушкинга күп нәрсәләр сөйли. Үзе ул табигать фәннәре һәм медицина белән мавыга торган була. 1821 елда, 45 яшенә җиткәч, Александра Андреевна Апехтинага өйләнә. Хатынының әнисе Анна Петровна Гаврил Петрович Каменевның бертуган сеңелесе була.

Каменев турында Пушкин: «Ул хөрмәткә лаек кеше иде: Россиядә беренче булып классицизмнан читенергә батырчылык итте. Без, рус романтиклары, аның истәлеге алдында баш иярга тиешбез: әгәр шулай иртә үлмәгән булса, бу кеше күп нәрсәләр эшләгән булыр иде»,— дип язып калдыра [2].

Пушкин уңайсызланып калган Александра Андреевнаның кулын дусларча кыса һәм: «Безгә бер-беребезнең кем икәнен әйтеп тору да кирәкми. Шигърият безне күптән таныштырды. Баратынский аннан да элегрәк» [3],— дип әйтә. Карл Федорович кунакка 1774 ел турында белгәннәренең барысын да сөйли.

Карл Федорович Фукс Пушкинны миллионер сәүдәгәр Л. Ф. Крупенниковларга алып бара. Миллионерга ул чагында 76 яшь була. Ә 17 яшендә ул Пугачевка плен төшкән икән. Билгеле, ул истәлекләрдә восстаниечеләргә карата ачудан бүтән ни булмый һәм ул Пушкинны бик аз кызыксындыра, аның сөйләгәннәрен шагыйрь «Пугачев тарихы»на да алмый.

Пушкинның Крупенников белән әңгәмәсе Е. А. Симбирин картинасында сурәтләнә.

Сәгать ярымлап сөйләшеп утырганнан соң Пушкин белән Фукс өйгә кайта. Карл Федоровичны, врач булганга, авыру янына чакырып алалар. Александра Андреевна Пушкин белән ялгыз кала. Бөек шагыйрь хуҗа хатын белән чын күңелдән сөйләшеп утыра. Ул Баратынский, Языков һәм Ознобишиннарның Александра Андреевна Фукска багышланган шигырьләре белән таныша, шагыйрәнең үз шигырьләрен игътибар белән тыңлый. һәм аларга карата җылы фикерләрен әйтә.

Хуҗа хатынга Пушкин шул заманның рус язучылары һәм жандарм-полиция режимы вакытында әдәби хезмәт белән шөгыльләнүнең авырлыгы турында күп нәрсәләр сөйли. һәм ахырдан ул: «Бүген мин күңелемдә ни бар шуны сөйләдем, карагыз аны, бу сүзләр безнең икебезнең арада гына калсын», — дип куя.

Кызганычка каршы, А. А. Фукс шагыйрьнең бу үтенечен ахырга хәтле саклый, «Истә калганнар»ында бу кызыклы әңгәмә турында берни дә язмый.

Кунакчыл хуҗалар Пушкинны кичке ашка да калдыралар. Аш вакытында Перцов та була.

Төнге сәгать бердә генә Пушкин Фукслар белән саубуллаша, чын күңелдән каршы алуларына рәхмәт әйтә, үзенә кунакка чакыра. Фукслардан кайткач та Пушкин йокларга ятмый әле: әйберләрен, кульязмаларын, китапларын рәтләп салып куя, юл дәфтәрен кулына ала.

---

[1] «Наука и жизнь» журналы. 1 һәм 2 саннар. 1965 ел. 46, 66 битләр.
[2] Казанский литературный сборник. «Фукс и его время». 1878 ел. 506 бит.
[3] «Казанские Губернские Ведомости». 1844 ел. № 2 (10 янв.). 99 бит.

Иртә белән ул хатыны Наталья Николаевна (Гончарова)га, Казанда алган тәэсирләрен әйтеп, кыска гына хат яза:

«Фәрештәм, исәнме. 5 еннән бирле Казанда булсам да, сиңа бер генә сүз язарга да вакыт таба алмадым. Хәзер Сембергә китәм, анда синнән хат алырмын дип өметләнәм. Биредә мин китабымның героена яшьтәш картлар белән очраштым, шәһәр тирәләрен, сугыш булган урыннарны карап йөрдем, сораштым, ишеткәннәремне язып бардым, бу якларга килүемә бер дә үкенмим...»

Шунда ук ул А. А. Фукска да рәхмәт хисләрен белдергән язу калдыра:

«Шәфкатьле ханым Александра Андреевна, чын күңелдән рәхмәтемне белдереп сезгә адресымны җибәрәм һәм Петербургка киләм дигән вәгъдәгез ягымлылыктан гына риза булуыгыз түгелдер дип ышанам. Сәяхәтчене якты йөз белән каршылавыгыз өчен, шәфкатьле ханым, тирән рәхмәтемне кабул итегез. Казанда үткәргән шушы аз гына вакыт хәтердә бик озак сакланыр.

Тирән хөрмәт белән Ал-р Пушкин дип белегез» (8/IX-33 ел).

Утыз өченче елның 8 сентябрендә Пушкин Казаннан Лаеш юлы белән Сембергә китеп бара.

Художник Борис Старчиковның «Пушкинны озату» дигән картинасы нәкъ әнә шул вакытларны гәүдәләндерә.

Пушкинның Казан белән бәйләнеше аның соңгы көненә кадәр өзелми. Ул Казан шагыйрәсе А. А. Фукс белән хатлар алыша, үзе чыгарган «Современник» журналын алу өчен аңа билет җибәрә һәм шушы журналга шигырьләр белән катнашырга тәкъдим ясый. А. А. Фукска һәм Казан тарихчысы М. Ф. Рыбушкинга үзенең «Пугачев»ын җибәрә. Пушкинның үз китепханәсендә Казан әдипләре А. А. Фукс, К. Ф. Фукс, Э. П. Перцов, М. Ф. Рыбушкин, И. Д. Деларю китаплары һәм «Казанские известия» журналы һ. б. була.

Алабуга язучысы Надежда Дурованың автобиографик повестен чыгару идеясе белән йөргәндә Пушкин Казандагы танышлары белән хәбәрләшүен тагын да ешлата.

Надежда Дурова «Кавалерист кыз язмалары»н чыгару буенча Петербургта Пушкин белән берничә кат очраша. Үзенең автобиографиясендә Надежда Дурова: «Александр Сергеевич мине бик яхшы каршы алды, язмаларымны укып чыкты, мин аның төзәтүен үтенгәч, төзәтәсе урыны юк дип әйтте һәм язмаларны чыгарганда кирәк булачак ярдәмен тәкъдим итте», — дип язды.

Пушкинның үлеме, илдәге бөтен прогрессив көчләр белән берррәттән, казанлыларны да тетрәтә.

Казан университетының 3 курс студенты Мельников (Печерский) болай дип яза:

«1837 елның февраль башларында словесный факультетның 3 курс студентлары сәгать сигездә рус теле буенча лекциягә җыелдылар. Профессор Г. Ф. Суровцев, гадәтенчә, сәгать суккан вакытта аудиториягә килеп керде. Ул кафедрага менде, урынына утырмыйча, кесәсеннән газета алды, хәтерем ялгышмаса, «Рус инвалиды» иде бугай, аны югары күтәрде дә, тиз генә студентларга күз йөртеп алгач, кычкырып әйтте: «Басыгыз!» Без торып бастык, гаҗәпләнеп профессорга карадык. Дулкынланудан калтыранган тавыш белән ул бер-ике юллык кына хәбәрне укыды. Аның тавышында ачы күз яшьләре тоела иде, аның беренче сүзләрен әле дә хәтерлим: «Поэзиябезнең кояшы баеды — Пушкин юк инде!»

Аудитория бертавыштан аһ итте. Сулкылдап елаган тавышлар ишетелде... Профессор да урынына утырды һәм, кафедрага көмештәй чал башын салып, елап җибәрде...

Берничә минут үтте, ул торды да: «Рус шагыйрьләренең князе табутта. Аның гәүдәсен Петербургтан каядыр еракка алып китәләр. Бәлки әле ул җир куенына кермәгәндер. Пушкин табуты ябылмый торып рус теле турында ничек сөйләмәк кирәк. Лекция булмый бүген...» [1].

---

[1] Н. Агафонов. «Андрей Печерский истәлегенә». Казан, 1887 ел. 55—56 битләр.

*
* *

Бу вакыйга художник Ю. Лысогорский иҗатында уңышлы чагылыш тапкан.

*
* *

Пушкинның Казан — Оренбург сәяхәте 1833 елның 1 октябрендә тәмамлана. Күргән урыннары, «Пугачев тарихы» һәм «Капитан кызы»ндагы вакыйгалар барган җирләр шагыйрь күңелендә тирән эз калдыра.

«Җансыз документларны шул вакыйгаларның шаһите булган кешеләрнең исәннәре сөйләве буенча тикшереп һәм аларның инде картаеп барган хәтерләрен тарихчы күзе аша үткәреп, үзем язачак вакыйгалар барган җирләрдә булдым», — дип яза Пушкин 1836 елда «Современник» журналында.

Болдинога кайткач та Пушкин «Пугачев тарихы»н язарга утыра.

Пушкин бу әсәрендә үз заманы өчен гадәттән тыш кыю фикерләр әйтә.

«Пугачев тарихы» цензура тарафыннан йолкынгалап чыкса да, реакцион тарихчыларның шовинистик карашларына каты удар була. «Тарих»ның гомуми бүлегендә Пушкин «Барлык кара халык Пугачев яклы булды... бары тик дворяннар гына хөкүмәт ягында иде»,— дип яза. Пушкин Екатерина II вакытындагы хөкүмәт аппаратының череклеген ача, восстаниене мәгънәсез рәхимсезлек белән бастырган, шуның белән халык массасының ачуын чыгарган патша генералларының сәләтсезлеген күрсәтә.

Пушкинның бу хезмәтенә үзе цензор булган Николай I патша «Пугачев тарихы» китабындагы «Пугачев бунтының тарихы» дигән бүлекне үзгәртергә куша. «Җинаятьченең тарихы булу мөмкин түгел», — дип әйтә ул. Хөкүмәт өчен яраксыз булган күп кенә урыннарны сыза. Мәсәлән, «данлы бунтарь» сүзен «әсиргә алынган бунтарь» дип басарга куша һ. б.

Белинский «прозадагы Онегин» дип атаган «Капитан кызы»нда да Пушкинның тарихны тирән белүе, гуманизмы, художник-реалист карашы ачык күренә.

**Гомәр Саттаров**

# ИСЕМНӘР-АТАМАЛАР СӨЙЛИ: БОЛГАР-ТАТАР АВЫЛЛАРЫ

Урта Идел-Кама буйларында гасырлар буена яшәү дәверендә болгар бабаларыбыз, һичшиксез, күп кенә физик-географик объектларга (елгаларга, инешләргә, күлләргә, тауларга, кырларга, урманнарга һ. б.) һәм ясалма географик яки административ-территориаль объектларга (шәһәрләргә, авылларга, юлларга һ. б.) үз исемнәрен кушканнар. Шулай итеп, урта гасырларда Урта Идел-Кама (шул исәптән хәзерге Татарстан АССР) территориясе топонимиясенең болгар катламы барлыкка килгән. Әмма, билгеле булганча, болгар теленең бик аз сүзләре генә, башлыча, ялгызлык исемнәре, ел һәм көн исемнәре, сан атамалары һ. б. теге яки бу тарихи чыганакларга теркәлеп, сакланып калган. Борынгы болгар теле үле теллардән санала.

Өстәвенә, Татарстан АССР топонимиясендә урын алган болгар комонимнарын (авыл исемнәрен) барлау, ачу-аныклау һәм аларны системалы итеп тарихи-лингвистик аспектта махсус тикшерү эше дә артта калып килде. Бу исә Татарстан АССР топонимиясенең болгарлар тарафыннан барлыкка китерелгән һәм безгә тарихи топонимик мирас итеп калдырылган субстрат катлам[1]ны (аерата шушы катламга карый торган комонимнарны һәм антропокомонимнарны — кеше исемнәреннән, кушаматлардан яки фамилияләрдән ясалган авыл атамаларын) барлау һәм тикшерү эшен нык кыенлаштыра һәм катлауландыра.

Республикабыз топонимиясенең болгар катламын ничек барларга, нинди методлалым кулланып аларга якын килергә һәм тикшерергә соң? Әле моңа кадәр зур күпчелеге мәгънәләрен сер итеп саклый килгән, фән өчен гаять әһәмиятле мәгълүматларга, мөһим информациягә ия булган тарихи-географик атамаларга — борынгы тел һәм чал тарих шаһитләренә, безгә хәзергә берни дә хәбәр итми, сөйләшми торган «телсез» исемнәргә — нинди тел ачкычы табарга, аларны ничек сөйләтергә? Бу хакта галимнәр озак баш ватканнар. Һәм бу мәсьәләләрне хәл итүдә уртак бер фикергә дә килә язды-лар шикелле. Илебезнең танылган өлкән топонимисты, проф. А. П. Попов, субстрат топонимик катламның формалашу үзенчәлекләрен һәм аны өйрәнүнең юлларын күрсәтеп, болай дип яза: «Әгәр борынгы топонимика күпчелек урында сакланса, һәм аңа яңасы өстәлсә, бу, димәк, элекке халыкның токымнары шушы җирлектә (телләрен башкага алмаштырып, ә кайбер очракта үз телләрен тулысынча яки өлешчә саклап) яшиләр дигән сүз. Шулай итеп, мондый очракта борынгы топонимика субстрат була, аны аңлау өчен, элекке халыкның теле бөтенләй сакланмаса, башка кардәш телләрне һәм шулай ук хәзерге халык телендәге субстрат лексиканы өйрәнү зарур»[2].

---

[1] Субстрат катлам — юкка чыккан җирле халык теленең хәзерге халык телендә сакланып калган калдыклары белән мөнәсәбәтле катлам.

[2] А. П. Попов, Географические названия. Рус телендә, «Наука» нәшрияты, 1965, 150 бит.

Гаять мөһим булган шушы фәнни-методологик күрсәтмәгә таянып, без Татарстан АССР топонимиясенең болгар катламына караган атамаларны барлау, аларның мәгънәләрен ачыклау эшен түбәндәге юллар белән алып барырга булдык: 1) гомум болгар теле ядкарьләренә (без биредә Идел-Кама болгарлары, Дунай болгарлары һәм Кавказ болгарлары телен тулаем күздә тотабыз); 2) борынгы болгар теленә якын торган хәзерге чуваш теленең лексик байлыгына һәм 3) татар теле сөйләшләрендә һәм 4) болгар-татар кабер ташы язмаларында сакланып калган лексик булгаризмнарга таяну.

Болгар дәүләте Алтын Урда князе Булат-Тимер тарафыннан 1361 елда икенче мәртәбә җимерелгәннән соң, болгарлар үзләренең төп яшәү урыны булган Кама сулъягының кара туфраклы, уңдырышлы җирләреннән, туган авылларын һәм шәһәрләрен ташлап, күмәк рәвештә Каманың уңъягына — Казан арты территориясенә күчеп утырганнар. Болгарларның бер өлеше Иделнең уңъягына — Зөя елгасының түбән агымындагы җирләргә күчеп килгән. Менә шушы тарихи сәбәпләр республикабызның Кама аръягы (сулъягы) җирләрендә болгар теле белән мөнәсәбәтле топонимик катламның, бигрәк тә торак пункт исемнәренең югалуы исәбенә, шактый ярлылануына, сирәкләнүенә китергән. Без бу төбәктә болгар топонимик катламы бөтенләй юкка чыккан, эзсез югалган дигән караштан тормыйбыз, әлбәттә. Байтак кына елга (Кондырча, Кондызча, Чирмешән, Яуширмә, Чаллы һ. б.), күл (Биләр күле, Би күле, Балым Хуҗа күле һ. б.), шәһәр (Болгар, Биләр, Тубылгытау, Җүкәтау, Баламир һ. б.) һәм авыл (Пәрәү, Саурыш, Чаллы, Таңкай, Нократ, Ямбакты, Әҗмәр, Иске Рәҗәп, Салман һ. б.) атамалары безнең көннәргәчә сакланган.

Татарстан АССРның Тау ягы (Иделнең уңъягы) территориясендә болгар топонимик катламы шулай ук шактый урын ала. Тарихи чыганакларга караганда, бу җирлектәге: Әтрәч, Тәтеш, Килдеш, Кирмәле, Олы Кариле, Мулла иле, Олы Тархан, Норлат, Мамадыш-Тәүгилде, Сатылган, Тау иле, Әҗәл, Иске Чәчкап, Борындык, Чүти Әҗем, Дәүләки, Коллар, Килдеураз, Шырдан, Салатчы, Борнаш, Күгеш, Күгәй, Айдар, Әлмән, Кармыш, Шәм-Балыкчы, Өтек кебек авылларга XIII—XIV йөзләрдә болгарлар нигез салган. Әмма Иделнең уңъягында, XIII—XIV йөзләрдә болгарлар күпләп күчеп утырганчы ук, чувашлар яшәгән. Чувашларның бабалары үз телләрен акрынлап ташлаулары, онытулары һәм ул заманнарда составына үзләре кергән дәүләтнең башында торган болгарлар телен кулланышка алулары нәтиҗәсендә, хәзерге чуваш теленең борынгы болгар теле белән уртаклыгы, якынлыгы тәэмин ителгән. Проф. А. П. Ковалевский: «Чувашларның бабалары Идел буеның җирле халкы булганнар, аларның Болгар дәүләте составында яшәгәннәре дә, аннан читтә яшәгәннәре дә үз телләрен югалтканнар һәм яулап алучы болгарларның телләрен кабул иткәннәр; моңа карап алар үзләре болгар булып китмәгәннәр, әмма болгар телендә сөйләшә башлаганнар» [1], — дип яза.

Борынгы болгар теле белән чуваш теленең үзара якынлыгы Татарстан АССРның Тау ягы топонимиясенең болгар катламын ачыклауны, шушы катламга караган географик атамаларны барлауны нык кыенлаштыра. Бу җирлектәге географик атамаларның кайсының болгарларга, кайсының чувашларга каравын аеру бик авыр эш.

Казан арты территориясенә XIII—XIV йөзләрдә болгарларның күпләп күчеп утырулары бу җирлектә байтак кына яңа торак пунктлар (авыллар, шәһәрләр, кальгалар һ. б.) барлыкка килүгә китергән. Алар яңа торак пунктларның күбесенә һәм әйләнәтирәдәге байтак кына җир-суларга болгар теленә нисбәтле атамалар кушканнар. Нәтиҗәдә Казан арты җирлегендә шактый киң таралган һәм ишле болгар катламы барлыкка килгән һәм шушы катламга караган байтак кына җирле атамалар безнең көннәргәчә сакланып калган.

Республикабызның Казан арты топонимиясендә болгар катламына караган атамаларның безнең көннәргәчә сакланган булуы һәм бу төбәктә чувашларның компактлы булып яшәмәве әлеге җирлектәге болгар топонимик катламын барлау һәм өйрәнү өчен хәзерге чуваш теле материалында якын килергә, шушы катламга караган атамаларны расшифровкаларга тулы мөмкинлек бирә.

Болгар авыл исемнәренең иң киң таралышы Татарстанның хәзерге Саба районына туры килә. Бу районда исемнәренең килеп чыгышын Идел-Кама болгарлары теленә

---

[1] А. П. Ковалевский, Чуваши и булгары по данным Ахмеда ибн-Фадлана, Рус телендә, Чебоксар, 1954, 6 бит,

якынлыгын нык саклаган хәзерге чуваш теленә бәйләп аңлатып була торган татар авыллары зур күпчелекне тәшкил итә.

*Мамалай* авылы атамасының этимологиясен чуваш мифологиясендә сакланган Мамале-Мамали дигән мәҗүси аллачык[1] исеменә бәйләп аңлатырга мөмкин. Борында мәҗүси йолаларны башкару, мәҗүси аллаларга табыну урыннары изге саналган. Теге яки бу мәҗүси аллачык яки йола исемен йөрткән мондый урын атамаларының шул тирәдә барлыкка килгән торак пунктларга кушылуы, ягъни ойконимлашуы бик мөмкин хәл.

Саба районында *Иләбар* исемен йөрткән ике татар авылы бар. Иләбар атамасының килеп чыгышын чувашларда сакланган мәҗүси Илебәр исеменә бәйләп була. Шушы райондагы Кибәче, Мичән, Пүкәл, Сабай, Саурыш, Теләче, Теләҗе авыллары атамаларының килеп чыгышын озак заманнар мәҗүси булып яшәгән чувашларда сакланган Кибәче, Мичан, Пуккал, Телес, Сабай һәм Савруш исемнәренә бәйләп карый алабыз.

Саурыш авылы исеменең килеп чыгышын авыл картлары болай аңлата: «Имеш, кайчандыр бу авылның арыш басуларын боз суккан. Бары тик урман буенда гына бераз җирдә арыш исән калган. Бу урынны «Сау арыш» дигәннәр. Шуннан чыгып, авылга да Саурыш исеме кушылган». Безнең карашыбызча, бу авылның атамасы Саурыш дигән борынгы болгар мәҗүси кеше исеменнән алынган.

Саба районындагы *Олы Кибәче* һәм *Кече Кибәче* авыллары исемнәренең борынгы заманнарда бу авылларда сугышта кию өчен көбә-кибә күлмәк ясаучылар — кибәчеләр яшәүгә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән булуы мөмкин. Профессор Н. И. Золотницкий Казан татарлары телендә *көбә* сүзенең «вак боҗралардан эшләнгән корыч кием, күлмәк, кольчуга» мәгънәсендә кулланылуын хәбәр итә[2]. Кибәче авылларында тимерчеләр әле дә күп.

Кибәче авыллары атамаларының Кибәче дигән борынгы төрки кеше исеменнән алынган булуы да бар. Кәсеп-профессия терминнарын һәм кешегә хас характер, һәвәслек билгеләрен күрсәтә торган сүзләр ясый торган *-чы, -че* кушымчаларының (көтүче, кибетче, игенче һ. б.) борынгы заманнарда профессияне белдерүче кеше исемнәрен ясауда да катнашулары билгеле. Шуның нәтиҗәсендә төрки халыкларның күбесендә, шул исәптән татарларда да, Сунарчы, Урманчы, Сабанчы, Уракчы, Печәнче, Ындырчы, Япанчы, Аючы, Казанчы, Балыкчы, Бакырчы, Кибәче кебек борынгы кеше исемнәре барлыкка килгән. Хәзерге татар телендә мондый исемнәр кулланылышта йөрми. Татар ономастикасында болардан Сунарчин, Урманчиев, Сабанчиев, Казанчиев, Уракчин, Ямгурчиев, Аючин, Аючиев, Салмачиев кебек фамилияләр һәм Ындырчы, Балыкчы, Япанчы, Бакырчы, Кибәче кебек авыл атамалары ясалган.

Саба районында исемнәре составында *ширмә* топокомпоненты булган Караширмә, Орымширмә, Икширмә дигән татар авыллары бар. Чувашча *сырма* сүзе «елга», «елгачык», *тип сырма* «коры елга», «чокыр» мәгънәсен белдерә. Караширмә атамасы, «кара (тирән) чокыр» мәгънәсен хәбәр иткән хәлдә, чувашларның Хурасырмасына туры килә. Чувашстанның Ишлей һәм Вурнар районнарында Хурасырма исемле чуваш авыллары бар. Шуширмә — Татарстанның Апас районындагы, Ямәширмә — Биектау районындагы, Яуширмә — Чистай районындагы татар авыллары.

Чистай районындагы *Яуширмә* (икенче төрле исеме Кутлушкино. Башлап Котлыкай яки Котлыш исемле кеше килеп утырудан) авылының атамасы Яуширмә дигән елгачык исеменнән алынган. Бу елгачыкның исемен 922 елда Болгарга сәяхәте вакытында Ибн-Фадлан Джаушыр һәм Джаушыз рәвешле теркәгән. Димәк, Идел болгарлары телендә *шыр(шырма)* сүзе, чувашларның *сырма* термины кебек үк, «елга, елгачык, чокыр» мәгънәсендә йөргән булып чыга. Татарстандагы Зур Чирмешән, Кече Чирмешән (Кама аръягында) һәм Чирмешән (Тау ягында) елгалары атамасында урын алган *чирмешән* топокомпонентының барлыкка килүе дә Идел-Кама болгарлары теленә мөнәсәбәтле. Ул «елга + елга» төзелмәсеннән гыйбарәт булган ике өлештән тора.

Саба районындагы *Өтернәс* (русча Утернясь) дигән татар авылының атамасы XVIII йөзгә караган документларда Кутернясь рәвешле язылган[3]. Моңа таянып, Өтер-

[1] Н. И. Ашмарин, Словарь чувашского языка. Вып. VIII, Чебоксары, Рус телендә, 1935, 185—186 битләр.
[2] Карагыз: Н. И. Золотницкий, Корневой чувашско-русский словарь, Казан, 1875, 259 бит.
[3] Д. А. Корсаков, Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII в, Рус телендә, Казан, 1908, 257 бит.

вәс атамасы башта Көтернәс формасында кулланылышта йөргән дип әйтә алабыз. Көтернәс атамасының *көтер* өлешенең этимологиясен татар теленең Минзәлә сөйләшендә сакланган *кутер* (өсте үлән белән капланып сазлыкка әверелгән күл, тирбәлеп тора торган сазлык) [1] сүзенә бәйләп аңлатып була. Өтернәс авылы янында әле хәзерге вакытта да берничә саз бар. Көтернәс авылының Казан ханлыгы чорында булуы мәгълүм [2].

Өтернәс (Көтернәс) атамасы составындагы *нәс* топокомпонентының мәгънәсен ачыклавы кыен. Әлеге топокомпонент Арча районындагы Чикәнәс, Мамадыш районындагы Сәкинәс, Югары Сәкинәс (Сәкинәс елгачыгы буенда) авылларының исемнәре составында бар. Чикәнәс авылы Чикәнәс елгачыгы буена утырган. Чуваш телендә *чике*, татар телендә *чик* сүзе, «чик, кырый, межа, рубеж» төшенчәсен белдерә. Болардан чыгып, Чикәнәс, Шикәнәс һәм Сәкинәс гидронимнарының беренче компонентлары *чикә ~ шикә ~ сикә* (ч ~ ш ~ с тартыкларының тарихи тәңгәллеге тюркологиядә мәгълүм нәрсә) «чик», «кырый», рубеж» төшенчәсен белдерә торган борынгы болгар сүзе *чик (чика)* белән мөнәсәбәтле һәм әлеге гидронимнар «чик елга», «чик буе елгасы» дигән мәгънә белдерә, дип әйтә алабыз. Күрәсең, XII—XIV йөзләрдә Чикәнәс, Шикәнәс һәм Сәкинәс елгалары болгар җирләре белән чирмеш (мари) җирләре арасындагы чик буе елгалары булганнар һәм шуның нәтиҗәсендә әлеге исемнәрне алганнар.

Җөри юлы өстендәге *Баландыш* авылының Казан ханлыгы чорында булуы тарихта мәгълүм. Риваятьләргә караганда, бу авылга балан куаклары күп булган урынга утырганга Баландыш исеме бирелгән. Татарстанның Азнакай районында тагын Баланбүләк дигән татар авылы бар. Әлеге авылларга исем бу урыннарда балан агачларының күп булып үсүеннән чыгып кушылган. Баландыш атамасының Балан өлешен балан агачына мөнәсәбәтле дип карый алсак та, *дыш* өлеше әйбернең, предмет яки билгенең булуын, барлыгын белдерә торган *-лы* яки *-лык* кушымчаларына туры килми. *Дыш* бик борынгыдан ук килә торган архаик сүз яки кушымча булырга тиеш.

Баландыш авылының исеме VI—VII йөзләрдә Әрмәнстанга күчеп утырган болгарлардан калган географик атамаларга бик якын тора. Кавказдагы Карс елгасыннан көнбатыштагы төбәге Ванand дип, Аракс елгасының сулъяк кушылдыгы Вананд-чай дип атала. Скифлар заманында Балан-род исемен йөрткән елга Болгару-чай («Болгарлар елгасы» — Г. С.) атамасын ала [3]. Шунысы игътибарга лаеклы: Кавказ болгарларының Вананд һәм Баланрод атамалары Идел-Кама болгарларының Баландыш атамасына әйтелеше белән шактый якын тора.

Арча районындагы *Кушәр, Иске Шимбер, Яңа Шимбер, Әрнәш* дигән татар, *Бимер* дигән рус авыллары атамаларының килеп чыгышын тюркологиядә болгар теленә якын дип санала торган хәзерге чуваш теле материалында аңлатып була.

Кушәр авыл атамасының килеп чыгышын чувашларда мәҗүси бәйрәм исеме булараk сакланган Кушарга мөнәсәбәтле дип карый алабыз. Кушар (Кушәр) бәйрәме язын аерым бер урында үткәрелгән. Аңа тирә-юнь авыллардагы кызлар һәм егетләр катнашкан. Егетләр үзләренә кыз, ә кызлар егет күзләгән. Кушар бәйрәменә картлар һәм карчыклар килми торган булган. Бәйрәм үткәрелә торган урыннарда барлыкка килгән авылларга әлеге исем күчкән булырга тиеш. Чувашстанда Кушар исемле авыллар бар. Казан артындагы Кушар (Кошар) авылының Казан ханлыгы чорында да булуы билгеле.

Бимер авылы атамасының килеп чыгышын чувашларның мәҗүси исеме Пинер (борын тартыклары *н* > *м* күчеше Пимәр, ә саңгырау «п» тартык авазының яңгырау пары «б»гә күчеше Бимәр әйтелешен барлыкка китерә) белән бәйләп була. Питрәч районында Пимәр дигән татар, Биектау районында Пимәр (Бимер) исемле рус авыллары бар. Алат юлындагы Пимәр (Бимәр) авылы (хәзерге Биектау районына керә) Казан ханлыгы чорында булган.

Пинер исеменең асылында *пин* («мең») сүзе ята. Чувашларда: Пинер, Пиневар, Пинекәй, Пинемер, Пинепи, Пинерук, Пинерчен, Пинеçлү, Пинеç, Пинçтей, Пинече,

---

[1] Татар теленең диалектологик сүзлеге, Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1969, 286 бит,

[2] Е. И. Чернышев. Селения Казанского ханства (по писцовым книгам).— Сб.: «Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья». Рус телендә. Казан, 1971, 286 бит.

[3] В. Т. Сиротенко. Письменные свидетельства о булгарах VI—VII вв. в свете современным исторических событий.— Сб. ст: «Славяно-балканские исследования, Историография и источниковедение», «Наука» нәшрияты, 1972, 217 бит,

Пинехей, Пинеш, Пинешле һ. б. кебек составларында *пин-пине* («мен») сүзе булган хатын-кыз исемнәре кулланылышта йөри.

Биектау районындагы *Ташлы Кавал, Зур Кавал, Кече Кавал* дигән татар һәм *Черкас* дигән рус авыллары исемнәренең мәгънәсен дә чуваш теле ярдәмендә аңлатырга мөмкин.

Алат юлы өстендәге Олы Кавал, Кече Кавал (хәзерге Биектау районындагы авыллар), Нугай юлындагы Кавал (Комлы Кавал) авылларының Казан ханлыгы чорында булулары мәгълүм.

И. А. Износков Лаеш өязендәге Ковали яки Ковал-Кибеч (хәзерге Лаеш районындагы Комлы Кавал) авылында 1642 елларда ясаклы яна керәшеннәр яшәвен хәбәр итә. Ковали атамасы, мөгаен, чыгытай телендәге *кавале* «елга буена сәяхәтчеләрнең сусавын басу һәм ял итү өчен салынган йорт» сүзеннән алынгандыр, ди. Н. И. Ашмарин Кавалның чувашларда сакланган борынгы мәҗүси исем булуын әйтә һәм шул исемгә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән Кавал, Ҫен Кавал (Тәтеш өязендәге чуваш авыллары), Пасарла Кавал (Урмар районындагы чуваш авылы) авыллары һәм Тәтеш өязендәге Кавал авылы янындагы агучы Кавалвар елгачыгы атамаларын мисал итеп китерә.

Питрәч районындагы *Әтрәч* (рус), *Күбәк иле* (рус), *Кибәч* (татар), *Тогаш* (рус) авыллары атамаларының барлыкка килүен дә чувашларда сакланган борынгы төрки-болгар мәҗүси кеше исемнәренә бәйләп аңлатып була. В. К. Магницкий төзегән мәҗүси чуваш исемнәре тезмәсендә Атрясь, Кибәк, Кибәч һәм Тогаш исемнәре бар. Казан артында Әтрәч, Кобяково (Күбәк иле), Кибәч, Тогаш авылларының Казан ханлыгы чорында булулары билгеле.

ТАССР дәүләт музеенда Казан ханы Мөхәммәтәминнең (1487—1496 һәм 1501—1518 елларда ханлык иткән) гаскәр башлыгы Күбәккә моннан 500 еллар элек бакыр эшләре остасы Насыйр бүләк иткән жиз савыт саклана. Аңа чукып язылган текстларда Күбәк исеме ике мәртәбә кабатлана. Димәк, Казан ханлыгы чорында болгар-татарларда Күбәк исеме кулланылышта йөргән. Бу исем, ир бала күбәк-эт кебек талымсыз, авыруларга бирешми торган булсын, дигән теләктән чыгып кушылган.

Балык Бистәсе районындагы *Чаллыбаш, Бикчурай Чаллысы, Казак Чаллысы, Кадрәк Чаллысы, Көчек Чаллысы, Мукшы Чаллысы, Котлыбөкәш Чаллысы, Бирдебәк Чаллысы, Тәберде Чаллысы, Мәмлә Чаллысы, Ури Чаллысы* авылларының исемнәре составында урын алган *Чаллы* топокомпонентының килеп чыгышын чуваш телендә «ташлы» мәгънәсендә кулланыла торган *чулла-чолла* сүзенә бәйләп аңлатып була.

И. А. Износков, Бирдебәк Чаллысы авылының исеме турында сүз алып барганда, бу авылның элек Чаллы дип аталган (хәзерге Шумбут) елга буенда булуын хәбәр итә. Чаллы атамасының мәгънәсе билгесез, ди.

Тәберде Чаллысы авылы янында Чаллы (Шумбут) елгасының сулъяк ярында Казан ханлыгы чорында Чаллы каласы (Чаллинский городок) булган. Татарлар аны Чаллытау дип атап йөрткәннәр.

Югарыда күрсәтелгән авыллар һәм Чаллытау каласы атамасы составында урын алган чаллы компоненты Чаллы елгасы исеменә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән. Бу елгага исә, ярларының ташлы булуыннан чыгып, Чаллы исеме кушылган.

Мамадыш районындагы *Албай, Алгай, Югары Әрнәш, Түбән Әрнәш, Югары Тәкәнеш, Урта Тәкәнеш* һәм *Түбән Тәкәнеш* дигән татар авыллары атамаларының килеп чыгышын чувашларда сакланган мәҗүси исемнәр Албай, Әрнәш һәм Таканашка (Тәкәнеш) бәйләп аңлата алабыз.

Югары Тәкәнеш, Урта Тәкәнеш, Түбән Тәкәнеш авылларының иң борынгысы — Түбән Тәкәнеш. Бу авыл исеменең килеп чыгышын картлар түбәндәгечә аңлаталар:

«Тау башыннан текә инеш аккан. Аны «Текә инеш» дип йөрткәннәр. Шул инешнең исеме безнең авылга бирелгән».

Бу риваять, Тәкәнеш атамасы орфоэпик яктан Текә инеш әйтелешенә якын торудан чыгып, Тәкәнеш «Текә инеш»тән барлыкка килгән дип фараз итүгә (халык этимологиясенә) нигезләнгән. Текә сыйфаты атрибутив функциясендә оронимнар составында урын алса да (мәсәлән, Текәтау, Текәъяр, Текәкыя һ. б.), гидронимнар составында очрамый.

Безнең карашыбызча, Тәкәнеш атамасының нигезендә чувашларда сакланган мәҗүси болгар Таканаш ~ Туканаш ~ Токанаш (Туганиш) исеменең нечкә әйтелешкә ия булган варианты (аллонимы) ята.

Казан крае топонимиясен өйрәнүгә күп көч куйган рус галиме И. А. Износков, чуваш теленә бәйләп, хәзерге Лаеш районына керә торган Анатыш (рус) һәм Сингел (татар) авыллары атамаларының килеп чыгышын узган гасырның 90 елларында ук аңлаткан иде[1]. Лаеш районындагы *Пәрәү* дигән татар авылы атамасының этимологиясен дә болгар теленә якынлыгын нык саклаган чуваш теле материалында аңлатып була. Чуваш телендә *пару, парав* сүзе «бозау» мәгънәсен белдерә. *Парав* (бозау) сүзе башта берәр шәхеснең яки нәсел-ыруның кушаматы яисә кушамат-исеме булып йөрү аша авыл атамасына әйләнгән булырга тиеш. Казан артында Пәрәү авылының Казан ханлыгы чорында булуы мәгълүм. Хәзерге Ульяновск өлкәсенең төньягындагы *Парау* (Боровка) дигән татар авылы да бик борынгы болгар авылларыннан санала. Борында аны Парау иле дип йөрткәннәр.

XIX йөзнең беренче яртысында яшәгән татар шагыйре Габделҗаббар Кандалый Парау авылының исемен «Сәхипҗамалга» поэмасында берничә мәртәбә телгә ала:

Саба җиле исәр булсаң, Парау атлыйг нәфис җайга,
Сәламемне тикергәйсән Сәхипҗамал абыстайга.

Татарстанның төньяк почмагындагы Балтач районының *Ор, Чутай* һәм *Курмала* дигән татар авыллары атамаларының килеп чыгышын да Идел-Кама болгарлары теленә бәйли алабыз.

Тарихта Казан ханлыгы чорында Алат юлында Ор, Орнашбаш һәм Арча юлында Үрсек («Елгачык») дигән татар авыллары булган[2].

Идел-Кама болгарлары телендә «елга» төшенчәсен белдергән *Уар* (уар) сүзе татар теле сөйләшләрендә дә сакланып калган. Алабуга керәшеннәре сөйләшендә әле хәзер дә *ур* сүзе «текә ярлы, сусыз коры елга»[3] мәгънәсендә кулланыла. Татарстанның Сарман һәм Минзәлә төбәкләрендә электә бакчага терлек кертмәү өчен тирән канаучокыр һәм балчык өеме белән әйләндереп алынган киртәне *ур, ур чокыр* дип атыйлар.

*Ур* «елга, чокыр» географик номенклатура термины төрки гидронимиядә һәм топонимиядә эзсез югалмаган. Ул берничә төрки гидроним һәм топоним составында урын ала. Татарстанда: *Ур* — Минзәлә елгасына коя торган елгачык, *Уртамак* — Минзәлә районындагы авыл, *Урсай* — Ык елгасына коючы елгачык, *Урсай, Урсай-Ключ* — Азнакай районындагы авыллар, *Урсала* — Әлмәт районы территориясеннән агып Зәйгә коючы елга, *Урсала, Урсалабаш* — Әлмәт районындагы авыллар. Оренбург өлкәсендә *Ор* елгасы бар. Шушы елга исеменнән *Орск һәм Оренбург* шәһәрләренең атамасы алынган.

*Ор* елгасы исеменең этимологиясе турында Оренбург краен тарихи-географик яктан җентекләп тикшергән галим П. И. Рычков болай дип яза: «Ор — төрки сүз, аның ике мәгънәсе бар. Беренче мәгънәсе «перекоп, линия» (татарларда *ур* — Г. С.), икенче мәгънәсе «устье, отверстие, ворота»[4]. Казакъ топонимисты Ә. Ә. Әбдирахманов Ор елгасының исеме *ор* сүзенең П. И. Рычков күрсәткән беренче мәгънәсеннән алынган булса кирәк дип саный. Шунда ук борынгы төрки телләрдә ор сүзенең *«елга»* мәгънәсендә кулланылу ихтималы булуын искәртә.

Республикабызның Арча районында *ор,* «елга, текә ярлы сусыз коры елга, тирән чокыр» яки «тирән канаулы балчык вал, ныгытма, крепость» географик номенклатура термины буларак, берничә җирле географик атама составында урын ала: *Югары Оры, Түбән Оры, Орбаш, Орнашбаш* — татар авыллары, *Ор, Орнаш* (Орнәс?) елгачыклары. Балтач һәм Арча районнары территориясендә әлеге атамаларның барлыкка килүе һәм безнең көннәргәчә саклануын урта гасырларда (XII—XIV йөзләр) Казан арты җирлегендә Идел-Кама болгарларының яшәве һәм алар телендә тирән ярлы кечкенә елганы, тирән чокырны яки тирән канаулы балчык валлы ныгытманы белдерү өчен *ор* (ур ~ уар) сүзенең кулланылышта йөрүе белән бәйләнешле дип саныйбыз.

---

[1] И. А. Износков. Список населенных мест Казанской губернии с кратким описанием их. Лаешевский уезд. Вып. I. Казан. 1893. 18 бит. Вып. II, Казан, 1895. 34 бит,
[2] Е. И. Чернышев. Күрсәтелгән хезмәт. 288 бит.
[3] Татар теленең диалектологик сүзлеге. Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1969, 455 бит,
[4] П. И. Рычков, Топография Оренбургской губернии, Оренбург, 1887, 2 бит,

*Чутай* авылы атамасының килеп чыгышын этимологик яктан хәзерге чуваш телендә «нур», «яктылык» мәгънәсен белдерә торган *сута* сүзе белән мөнәсәбәтле Чутай мәҗүси болгар исеменнән дип карый алабыз. В. К. Магницкий туплап төзегән мәҗүси чуваш исемнәре тезмәсендә Чутей һәм Чучей исемнәре дә урын алган. Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария»сендә (Казан, 1897 ел басмасы) Читай болгарлардагы кеше исеме буларак телгә алынган. Биредә шуны да әйтеп үтәргә кирәк: Идел-Кама болгарлары белән борынгы заманнарда кан-кардәшлеге булган карачай-балкарларда асыл-ларында *чути* («нур») сүзе яткан Чотай, Чоту, Чотча исемнәре бүгенге көндә дә кулланылышта йөри.

Чутей мәҗүси болгар-татар исеме, Чути әйтелешен алып, республикабыз топонимиясендә авыл атамаларына әверелеп сакланган. Татарстанның Апас һәм Лениногорск районнарында Чути дигән татар авыллары бар. Болгарлардагы Чутай, Чутей, Чути исемнәреннән Казан татарларында Чутаев, Четаев һәм Чутиев фамилияләре һәм Чутай, Чүтәй дигән нәсел кушаматлары ясалган.

Биредә «нур», «якты», «яктылык» мәгънәсен белдерә торган сүзләрнең күпчелек халыкларда кеше исемнәрен ясауда шактый актив катнашуларын әйтеп китү урынсыз булмас. Пакьлек, сафлык, яктылык, намуслылык, матурлык символы булып саналган «нур», «якты» мәгънәсен белдергән сүзләрнең кеше исемнәренә әверелүе яки аларның кушма төзелешле кеше исемнәре составында урын алулары борынгы заманнарда ата-аналарның үз балаларында әлеге яхшы сыйфатларның булуын ихлас күңелдән теләүләре, балаларына исем сайлаганда һәм кушканда шуны мотив итеп алулары белән бәйләнешле.

Тарихка Тау ягындагы (хәзерге Апас районындагы) *Чути* дигән татар авылының Казан ханлыгы чорында булуы һәм аның Якола Чума Кылыч черма исемле елгачык буена урнашканлыгы билгеле[1]. Казан ханлыгы чорында да булуының мәгълүмлеге һәм атамасының борынгы болгар-татар-чуваш телендәге Чути («нур, якты») исеменнән алынуы әлеге Чути авылының Болгар чорында ук барлыкка килгән булырга тиешлеге, ягъни башта болгар авылы булып, Казан ханлыгы чорында исә болгар-татар, соңрак татар авылына әверелүе турында сөйли.

Югарыда анализланган тарихи, топонимик, антропонимик, шулай ук археологик, диалектологик, этнографик һ. б. мәгълүматларны, ягъни үзара тыгыз бәйләнештәге янәшә, чиктәш-арадаш фәннәрнең бер бөтен комплексын тәшкил итүче фактларның тулаем синтезын күздә тотып, Казан арты топонимиясенең үзендә Идел-Кама болгарлары теленә якынлыгын күп саклаганга күрә, башлыча, хәзерге чуваш теле материалында ачыклана торган тарихи катламы урта гасырларда (якынча XII йөздән алып XVII йөзнең беренче чирегенә кадәр) шушы территориядә яшәгән Идел-Кама болгарлары теленә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән дип әйтә алабыз. Казан арты топонимиясенең әлеге үзенчәлекле тарихи катламы чувашларныкы түгел, Идел-Кама болгарларыныкы һәм аларның туган телләренә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән дип әйтү өчен шактый күп яклы һәм дәлилле тарихи-лингвистик һәм экстралингвистик җирлек бар.

Бу очракта хәзерге чуваш теле сүзләре һәм мәҗүси исемнәре, Татарстан топонимиясенең болгар субстрат катламын тикшерү өчен лингвистик чара, бер методик алым, тел ачкычы хезмәтен үти, моңа шактый кулай арадашлык итә. Әмма моңа карап, Татарстан топонимиясенең, бигрәк тә аның Казан арты җирлеге топонимиясенең, лексик-семантик мәгънәләрен хәзерге чуваш теле материалында ачыклап, ачыклап була торган барлык географик атамалары да чувашларныкы, чувашлар тарафыннан кушылган дигән нәтиҗә ясый алмыйбыз. Топонимика фәнендә, ифрат дөрес һәм зарури рәвештә лингвистик факторлардан тыш экстралингвистик (телдән башка) факторларны бик нык исәпкә алып эш итү, аларга таянып фикер йөртү һәм нәтиҗәләр чыгару таләп ителә. Экстралингвистик факторлар исә республикабызның Казан арты регионы (җирлеге) топонимиясенең лексик-семантик мәгънәләре хәзерге чуваш теле материалында ачыклана торган географик атамаларының чувашларга карамавын, чувашлар тарафыннан бирелмәвен, бәлки Идел-Кама болгарларыныкы булуын һәм урта гасырларда алар тарафыннан кушылуын күп яклап дәлилле итеп расլыйлар.

---

[1] Е. И. Чернышев. Күрсәтелгән хезмәт, 289 бит.

Казан арты татарларының төньяк-көнчыгыштагы борынгы күршеләре удмуртларның (вотяклар) татарларны *бигер*[1] (болгар) исеме белән атаулары да жирле финн-угыр халыкларының (чирмешләр, вотяклар һ. б.) болгарлар белән Казан татарларын тарихи-этник яктан бер бөтен (ягъни бер үк халык) итеп санауларын ачык күрсәтә.

Казан арты территориясенә болгарлар X гасырларда ук үтеп керә башлаганнар. Проф. А. П. Смирнов: «Казан елгасы бассейнына болгарлар бик иртә үтеп кергәннәр һәм X—XI йөзләрдә бу районнар Идел болгарлары дәүләте составында булган»[2],— дип яза. «Феодаллашуның көчәюен тагын XII—XIII гасырларда болгар феодалларының Камадан төньякка таба яткан жирләрне экспансияли башлавы белән аңлатырга кирәк. Мишә һәм Казанка елгасы буенда беренче болгар шәһәрләре һәм авыллары шушы вакытларда барлыкка килә»,— диелә «Татарстан АССР тарихы»нда (Казан, 1970, 50 бит). 1236—1240 елларда Болгар халкының шактый өлеше төньякка, Кама аръягына (Казан артына — Г. С.) күчеп китә. Шунысы характерлы: 1360 еллардан башлап (Болгар иле 1361 елда Алтын Урда князе Булат-Тимер тарафыннан яңадан жимерелгәннән соң — Г. С.) борынгы болгар телендә язылган, болгар кабер ташлары юкка чыга. Кама аръягы һәм Болгар шәһәре халкы икенче тапкыр үз урыннарын ташлап китә һәм төньякка — Казан князьлегенә һәм Идел аръягына, Зөя елгасының түбән агымына күчә. Казан арты жирлегендә эпитафик истәлекләрнең күбесенең XIII йөз азагы һәм XIV йөзгә каравы бу территориягә шушы дәвердә болгарларның күпләп килеп утыруы белән, һичшиксез, бәйләнешле. Болгарларның ул вакытта мари һәм удмуртларның бабалары яши торган Кама алды районнарына күчеп утырулары нәтижәсендә, крайның аборигеннары белән икенче мәртәбә очрашу-якынлашуы булып уза. Бу хәл исә халыкның һәм аның культурасының формалашуында шактый тирән эз калдыра. Идел-Кама болгарлары Идел буе халыкларының үсешенә гаять зур йогынты ясаганнар.

Топонимик фактлар белән беррәттән, антропонимик (исемнәр, кушаматлар һәм фамилияләр) яки боларны үзара бәйли торган онамастик фактлар да Казан арты жирлегендә һәм башка урыннарда Идел-Кама болгарлары белән татарларның тыгыз этнолингвистик бәйләнеше, күчемлелеге булуы турында сөйли. Шундый фактларның безнең өчен аерата мөһим булган берсенә тукталыйк.

Татарстанның Алабуга районындагы *Канак* авылының атамасы борынгы болгар һәм аргу телләрендә «каймак», «сөт өсте» мәгънәсендә кулланылган qanaq (кумәклек сүзеннән) ясалган Канак исеменә нисбәтле рәвештә барлыкка килгән. Ата-ана өчен баланың бик татлы, тәмле булуы, «каймак» дигән мәгънә белдерә торган сүзләрне, күчерелмә мәгънәдә «татлы-тәмле, ләззәтле бала» төшенчәсен аңлаткан хәлдә, борынгы заманнарда ук төрле халыкларда кеше исеме итеп кушуга китергән һәм антропонимик универсалий (төрле телләргә бердәй хас күренеш) тудырган.

Татар антропонимиясендә Идел-Кама болгарларының Канак («Каймак») исеме Канак дигән нәсел кушаматына (патронимга) һәм Канаков фамилиясенә әверелеп сакланган.

Зеленодольский районының *Мулла иле* авылында Канак кушаматын йөртүче уннан артык семьядан торган нәсел-ыру бар. Мәсәлән, Гатият Канак, Хәйрулла Канак, Хәсән Канак, Хәмидулла Канак, Шәйхулла Канак, Әсәдулла Канак, Гыйбадулла Канак, Әхәт Канак һ. б. Шушы нәселнең күпчелек вәкилләре Канаков-Канакова фамилиясен йөртәләр[3]. Авылның Канак нәселе семьялары утырган зур урамнарыннан берсе *Канак җыены* яки *Канак урамы* дип атала.

Моның Казан татарларының борынгы бабалары болгарлар телендә «каймак», «сөт өсте» мәгънәсен белдерү өчен кулланылган qanaq сүзе белән мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килүен башка тарихи-лингвистик мәгълүматлар да раслыйлар. Каюм Насыйри «Зөя өязе» дигән хезмәтендә Мулла иле авылы турында: «Бу Мулла иленең асылы бик күптәннәндер. Монда бер Муллагол дигән кеше Болгардан килеп утыргандыр. Алар әүвәл килгәндә берничә кеше булып килгәннәр. Бәгъзысының исемнәре мәгълүм түгел. Аларның берсе Муллагол дигән кеше. Янә алар белән берәү бар икән, Шәехби дигән

---

[1] Удмуртско-русский словарь. 1948. 28 бит.

[2] Отчет Поволжской археологической экспедиции за 1970 г. Архив ИА АН СССР. Ф. I, Р-I, № 212. Л-3.

[3] Норлат авыл Советының 1970 елга хужалык кенәгәсе мәгълүматларына караганда, 52 кеше,

адәм. Ул үзе бер угылы белән килгән. Угылы Теләш исемле галим кеше булгандыр. Мулла илендә дәрес әйткән, мәдрәсә ихъя кылган (булдырган — Г. С.). Бу Шәехбинең атасы Тамты дигән кеше асыл Кытайдан килгән кешедер. Болгар йортында Кытайдан, Һиндстаннан килгән кешеләр күп булгандыр. Болгар тәзек заманда Болгар җирендә ярминкә булып, Һиндстан, Кытайдан сәүдәгәрләр килеп, сату итәләр икән. Шул сәбәпле аннан килгән кешеләр бәгъзы сәбәпләр белән бу җирдә „калганнардыр» [1],— дигән тарихи мәгълүматларны хәбәр итә. Болгар иленең башкаласы шәһре Болгарның 1250—1350 нче еллар арасында халыкара зур сәүдә үзәкләренең берсе булуы турында тарих фәннәре кандидаты Равил Фәхретдинов та яза [2].

Мулла иленә Муллагол белән Болгардан бергә килгән Шәехби бине Тамти-Хытай Әльболгари нәселенең унбер буынын эченә алган шәҗәрәсе шушы авыл зиратындагы кабер ташына язылып сакланган [3]. Хәйрулла бабай Биктаһиров безгә бу шәҗәрәнең хәзерге вакытта 24 буынны эченә алуын хәбәр итте. Бу авылда әле бүгенге көндә дә Болгари кушаматын йөртүче нәсел-ырулар бар. Мәсәлән, Шаһзадә Болгари, Галиәскәр Болгари, Гали Болгари, Гомәр Болгари һ. б.

Болгар теленеке булуы М. Кашгари сүзлегендә (XI йөз) теркәлгән qapaq («сөт өсте», «каймак») сүзенең борынгы болгарларда кеше исеме яки кушамат булып йөрү аша топонимлашып, Казан арты территориясендәге Канак авылы исемендә саклануы, бу җирлектә килеп чыгышы турыдан-туры Идел-Кама болгарлары теленә нисбәтле атама, болгар антропотопонимы урын алуга конкрет мисал булып тора. Шушы гаять мөһим факт исә Казан арты топонимиясенең лексик-семантик мәгънәләрен хәзерге чуваш теле материалында аңлатып була торган атамаларның да борында телләре чуваш теленә якын булган Идел-Кама болгарларыныкы булуын дәлилли, мондый атамаларның республикабыз топонимиясенең болгар катламын тәшкил итүе турында сөйли. Чувашча *каймак* «хайма» [4]. Димәк, Канак авылы исеменең (комонимының) һәм Канак нәселе кушаматының килеп чыгышын чуваш теле материалында аңлатып булмый. Татарстандагы Канак комонимы һәм Канак кушаматы (патронимы) саф булгаризм (Идел-Кама болгарлары сүзе) булып чыга.

Шулай итеп, топонимик һәм антропонимик фактлар, чал тарих шаһитләре буларак, Казан арты җирлегендә һәм Татарстанның башка өлешләрендә Идел-Кама болгарлары белән Казан татарларының тыгыз этнолингвистик бәйләнеше, күп яклы дәвамчан күчемлелеге булуы турында безгә ерак гасырлар аша гаять мөһим хәбәр-мәгълүмат китерәләр. Без карап узган исемнәр-атамалар Татарстан территориясендә, аерата аның Казан арты җирлегендә, Казан татарларының кан-кардәш бабалары Идел-Кама болгарларының йөзләгән авыллары булуы турында ономастик фактлар теле белән дәлилләп итеп сөйлиләр һәм тулаем алганда, топонимика өлкәсендә туган телебезнең «...болгар теленнән килә торган лексик берәмлекләрен „аныклауда» [5] тәүге бер тәҗрибәне хасил итәләр.

---

[1] Қ. Насыйри. Сайланма әсәрләр. Татарстан китап нәшрияты. Қазан. 1956. 146—147 битләр.
[2] Р. Фәхретдинов. Болгар шәһәрләре. «Қазан утлары» журналы. 1972, № 9. 174 бит.
[3] Қ. Насыйри. Күрсәтелгән хезмәт. 147 бит.
[4] Русско-чувашский словарь. М. 1951. 699 бит.
[5] М. З. Закиев. О достижениях и задачах татарской лексикологии, Сб. «Вопросы татарского языкознания», Қазан, 1971, 38 бит.

**Шәмси Хамматов,**

Татарстан журналистлар союзы председателе, «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы

# МАТБУГАТТА КАТНАШУ— ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ ВАЗИФАСЫ

**Мин бит... саф, коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит.**

**Г. Тукай.**

Татарстан язучыларының VIII съездында миңа республикабыз журналистлары исеменнән чыгыш ясарга туры килде. Язучының газета-журнал редакцияләре белән элемтәдә торуы, вакытлы матбугат битләрендә әсәрләр, мәкаләләр бастырып, җитди проблемалар күтәрүе зур политик әһәмияткә ия дигән фикерне үткәрергә тырыштым мин үз чыгышымда.

Газета-журнал, радио һәм телевидение редакцияләре язучыларны ишекләрен киң ачып, аяк өсте торып, якты йөз белән каршы алалар. Шуның өчен кайбер язучыларның: «Без газетаны һәр вакытта да китапка чаклы булган беренче өебез итеп саныйбыз, аның битләрендәге үз түребезне бик якын күрәбез»,— дип әйтүләре бик урынлы.

Совет матбугатының характерлы якларыннан берсе шунда, ул массовый трибунаны сүз осталарына һәр вакыт тәкъдим итеп килде һәм тәкъдим итә. В. И. Ленин язучыларның, публицистларның партия матбугатында катнашырга тиешлеген берничә тапкыр күрсәтте. Газетадагы әдәби материалларның көчен һәм пропагандистик әһәмиятен Ленин язучыларның партия эше, партия җитәкчелеге белән тыгыз элемтәдә булуында күрде.

Большевистик матбугатның данлы традицияләрен дәвам иттереп, совет газета-журналлары, радио һәм телевидениесе язучыларның әсәрләренә киң урын бирә. Язучылар өчен көндәлек матбугат һәр вакытта массалар, тормыш белән тыгыз бәйләнешнең иң ышанычлы чарасы булды.

Партиянең X съезды барган көннәрдә В. И. Ленин Татарстан партия оешмасы делегатлары группасы белән очраша. Алар арасында язучы В. Бахметьев, журналист Вәли Шәфигуллин да була. Делегатлар белән очрашу вакытында Владимир Ильич татар әдәбияты һәм журналистикасының үсеше, газеталарның тиражы һәм полиграфия базасының торышы белән кызыксына [1].

Партия Үзәк Комитеты, КПСС өлкә комитетының даими кайгыртучанлыгы аркасында, бездә матбугат, культура һәм әдәбият-

[1] Карагыз: Ленин и Татария, Казан, Таткнигоиздат, 1970 ел, 300 бит.

ның шундый зур үсешкә ирешүен, Казанның илебездәге полиграфия промышленностенең иң эре үзәкләреннән берсенә әверелүен белсә, Ленин ничек шатланыр иде!

Республикабызда җирле вакытлы матбугатның гомуми тиражы гына да хәзер 2 миллион данәгә якынлаша. Буржуаз пропагандистлар Советлар Союзында рус булмаган милләтләр үз телләрендә белем алуда, китап һәм журналлар чыгаруда чикләнгәннәр, дип юкка гына «кайгырталар». Бер «Социалистик Татарстан» газетасының тиражы гына да быел 160 мең данәдән артып китте. Бу — Россиядә 1913 елда татар телендә чыккан барлык газета-журналлар тиражы суммасыннан да артыграк диган сүз. Безнең республикада ел саен 9 миллионга якын — ягъни 1913 елда дөнья күргән барлык татар китапларыннан дүрт тапкыр артыграк! — китап чыгарыла.

Казанда өр-яңа техника белән җиһазландырылган гаять зур газета-журналлар комплексы төзелү партиянең, өлкә партия оешмасының матбугатны үстерү турында кайгыртучанлыгының тагын бер яңа, ачык мисалы. Без Матбугат йорты дип йөртә торган күп катлы яңа бинада КПСС өлкә комитеты нәшрияты, барлык республика газета һәм журналлары редакцияләре, Журналистлар союзы урнашкан, биредә үк китапханә, уку залы, журналистлар һәм полиграфистлар клубы бар.

Безнең матбугат рухи культура, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләрен яктыртуга зур әһәмият бирә. Менә инде 17 ел рәттән «Социалистик Татарстан» газетасының якшәмбе саннарында «Әдәбият-сәнгать» сәхифәләре урнаштырылып килә. Андый сәхифәләрнең саны 600 дән артып китте.

«Әдәбият-сәнгать» битләрендә бүгенге көндә төп игътибар нәрсәләргә юнәлдерелә соң? Бу — барыннан да бигрәк әдәбият-сәнгатьнең актуаль проблемалары тирәсенә җәмәгатьчелек фикерен туплау. Бу — укучыларыбызга рухи тормышның катлаулы күренешләрен, язучыларыбыз, драматургларыбыз, художникларыбыз иҗатын дөрес аңларга ярдәм итәргә тырышу һәм шул нигездә совет кешеләрен коммунистик рухта, шул исәптән эстетик яктан тәрбияләүдә булышу.

1973 елның гыйнварь аеннан мондый сәхифәләрне «Советская Татария» газетасы да бирә башлады. Башына Максим Горький һәм Владимир Маяковский, Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил рәсемнәрен урнаштыру бу сәхифәләрнең төп юнәлешенә үзенчәлекле ишарә. Алар иҗатта партиялелеккә, патриотизмга, гражданлылыкка, милли һәм интернациональ якларның бердәмлегенә чакыра.

Яшьләргә ярдәм итү, Татарстанның өлкән буын әдәбият-сәнгать эшлеклеләренең бай тәҗрибәсен, осталыгын ачу — газета редакцияләренең иң мөһим бурычларыннан берсе, мөгаен, шулдыр. Әлеге максаттан чыгып, «Әдәбият-сәнгать» сәхифәләрендә республикабыздагы әдәбият һәм сәнгать белгечләренең чыгышларына зур урын бирелә. Алар әдәбият, музыка, сынлы сәнгать, кино һәм театрның иң актуаль мәсьәләләренә багышланган булалар.

Шунысы кызыклы, газетаның әдәбият-сәнгать бите нәшрият басма табагыннан бик азга гына кечерәк. Шуннан чыгып, ел буе чыгарылган 52 сәхифәнең күләмен күз алдына китерү һич кыен түгел. Бу — әдәбият, музыка, театр, киноның күп төрле мәсьәләләренә багышланган мәкаләләрдән, күренекле язучылар, шагыйрьләр, художниклар һәм композиторларның, шулай ук яшь авторларның әсәрләреннән торган ике калын җыентык дигән сүз.

Канәгатьләнү хисе белән тагын шуны билгеләп үтәргә кирәк: язучыларның VIII съезды алдыннан газеталар битләрендә, радио һәм телевидениедә язучылар, тәнкыйтьчеләр, публицистлар әдәби хәрәкәтнең иң мөһим мәсьәләләре турында кайнар бәхәсләр алып бардылар. «Социалистик Татарстан» газетасы битләрендә басылган мәкаләләр, мәсәлән, күтәргән темалары, фикерләренең тирәнлеге белән әдәби эш өчен язучыларның чын күңелдән борчылуларын күрсәтте. Мондый ялкын киләчәктә дә сүнмәсен иде, дигән теләк белдерәсе килә. Алган темпны тагын да куышлырак дәвам иттерү турында уйларга кирәк безгә. Моның өчен без язучы белән матбугатның үзара бәйләнешен тагын да ныгыту юнәлешендә яңа формалар табарга тиешбез. Матбугатта, телевидение һәм радиода киләчәктә дә дәвам иттерелергә лаеклы форма «Язучы һәм бишьеллык» девизы белән эшләү булыр дип ышанырга кирәк. Кистереп әйтергә мөмкин: матбугат язучының активлыгы, гражданлыгы көзгесе булды һәм шулай булып калачак. Ә бу сыйфатлардан тыш совет язучысының һәм публицистының эшчәнлеген күз алдына китерү мөмкин түгел.

Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә матбугат, яңа кеше тәрбияләүдә куәтле чара буларак, бүгенге көнгә, тормышка, коммунизм өчен көрәшнең көндәлек фактлары-

на йөз белән борылды. Ул тагын да җанлырак, дулкынландыргычрак булсын, кешенең йөрәгенә үтеп керсен өчен абруйлы сүз осталарының газета эшеннән читләшмәүләре шарт. Кызганычка каршы, бу куәтле, мактаулы трибунадан һәр язучы да тулы файдалана дип әйтеп булмый әле. Газетада катнашу төп эштән аера, дип раслаучылар да бар арада. Мондый әдәбиятчылар бик күп күренекле совет язучыларының газета һәм журнал битләрендә даими язышуларын, көннең мөһим мәсьәләләрен күтәрүләрен һәм бу эшләрнең аларга классик әдәби әсәрләр иҗат итүгә һич тә комачауламавын ә, киресенчә, ярдәм генә итүен онытып җибәрәләр, күрәсең.

Бүгенге көндә әдәби фронтның алгы сызыгы гигант үзгәрешләр барган, коммунизмның материаль-техник базасы төзелгән урыннан үтә. Укучылар язучылардан зур эшләр һәм кешеләр — яңа тормыш иҗат итүчеләр турында тормышчан итеп язылган, коммунистларча яшәргә һәм эшләргә өйрәтә торган яңа әсәрләр көтә.

Чернышевский әйткәнчә, «тормыш дәреслекләре» булырдай мондый китаплар язу өчен әдип үзенең иҗатын иҗтимагый тормышта, шул исәптән матбугатта актив катнашу белән бергә бәйләргә тиеш. М. Горький, К. Федин, М. Шолохов, Габдулла Тукай, Муса Җәлил һәм әдәбиятның башка бик күп вәкилләренең күпкырлы иҗтимагый эшчәнлекләре моңа рухландыргыч мисал була ала.

Владимир Маяковский үзенең поэтик эшен газетадан башка күз алдына китермәде. Ул: «Минем трибунам — газета»,— дип белдерә, газетага начар мөнәсәбәт күрсәтүче әдипләр турында кәефе кырылып сөйли. Маяковский фикеренчә, шагыйрьнең газетачы булуы — әдәби эшне тормышның көндәлек таләпләренә, халык интересларына буйсындыру һәм коммунизм төзү эшенә зур өлеш кертү дигән сүз [1].

Мәгълүм булганча, күренекле әдипләр, җәмәгать эшлеклеләре язучыларның газетадан читләшүләрен нык гаепләделәр. «Газетадан читләшүче шагыйрь — ят кеше. Газета өчен эшләмәүче шагыйрь — өлгереп җитмәгән кеше» [2],— дип әйтә танылган шагыйрь А. Безыменский.

Халык шагыйре Габдулла Тукай, газеталар чыгаруга, культура учреждениеләре оештыруга күп тырышлык кую белән бергә, язучының иҗтимагый ролен дә югары күтәрде. Ул болай дип язды:

«Бөтен көтепханәләрне, матбагаларны вә газеталарны ябып бетерсәләр, бу көннән яңа киемнәремне ертып ташлап, ялан аяк чыгып йөгерәчәкмен... Мин бит... саф, коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә...»[1]

Әдәбият һәм журналистика, әдәби һәм публицистик сүз — партиянең үткен идеология коралы. Барометр кебек, алар совет кешеләренең тормышындагы, уй-фикерләрендәге, омтылышларындагы үзгәрешләрне бик сизгер чагылдыралар. Төрле чаралар, төрле ысуллар белән әдәбият һәм публицистика бер үк мөһим вазифа башкара — укучылар алдында чынбарлыкның дөрес сурәтен тудыра, халыкның хезмәт тәҗрибәсен гомумиләштерә, коммунистик аңлылык тәрбияли, яңа җәмгыять төзүгә рухландыра.

Публицистика, җәмгыять тормышын һәрьяклап чагылдырып, идеологик һәм политик көрәшнең мөһим тармагына әверелә. Шуңа күрә зур политик, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, кагыйдә буларак, күренекле публицистлар да.

Дөнья культурасы тарихына Максим Горький пролетариатның даһи язучысы буларак кына түгел, шулай ук күренекле публицист, редактор һәм журналист буларак та керде. «Һөнәр турында әңгәмәләр»ендә ул 1930 елда болай диде: «...үземә килгәндә — мин үземне беркайчан да «бары тик әдәбиятчы» гына итеп санамадым һәм санамыйм, бөтен гомерем буена — теге яки бу өлкәдә — иҗтимагый эшчәнлек белән шөгыльләндем һәм бүгенге көнгә кадәр аңа күңел тартылып тора» [2].

А. В. Луначарский М. Горькийны «гаять зур эшче хәбәрче» дип атады. Иҗтимагый-политик эшчәнлекне пролетар язучы җәмгыятькә хезмәт итүнең аерылгысыз өлеше итеп карады. Совет әдәбиятының теоретик базасына нигез салу һәм аның идеялелеге өчен көрәшү белән бергә, М. Горький совет матбугаты үсеше проблемаларын һәр вакыт игътибар үзәгендә тотты, массаларны политик тәрбияләүдә, идеология дошманнарына каршы көрәштә публицист, журналист, хәбәрче тоткан рольгә зур бәя бирде. Ул әдәбиятчы эшчәнлеген публицист эшчәнлегеннән беркайчан да аерып карамады. Аның өчен публицистика гомуми әдәби эшнең

[1] Карагыз: В. Саянов. «Мәкаләләр һәм истәлекләр». Ленинград. 1958 ел. 200 бит.
[2] «Литературная газета», 5 май, 1933 ел.

[1] Г. Тукай. Әсәрләр. 4 том. Казан. 227 бит.
[2] М. Горький. Әсәрләр. XXIV том. 310 бит.

бик тә мөһим өлеше: үз чорының алдынгы язучысы публицист булмый кала алмый. «Әдәбият», «публицистика», «журналистика» төшенчәләрен М. Горький янәшә куйды һәм язучыларны тормыш белән тоташтыручы күпер булып хезмәт иткән журналистикадан аеруга каршы чыкты.

Әдәбиятчыларны һәм публицистларны вакытлы матбугатта актив катнашырга өндәп, Максим Горький моның газета һәм журналлар өчен генә түгел, язучыларның үз иҗатлары өчен дә файдалы булуын күрсәтте. 1928 елда Кызыл Армиянең Үзәк йортында башлап язучы кызылармеецлар һәм хәрби корреспондентлар алдында чыгыш ясап, ул болай диде:

«Газетада эшләп башлап язучы нәрсәгә дә булса өйрәнә аламы?

Өйрәнә ала. Күпләгән яхшы язучылар нәкъ менә газетадан үсеп чыктылар» [1].

Матбугатка Горькийча караган әдипләрне башка әдәбиятлардан да күп санарга мөмкин булыр иде. Бу җәһәттән безнең культура тарихыбызда Галимҗан Ибраһимов шәхесе аерылып тора.

Партиянең Татарстан өлкә комитеты 1922 елның маенда Галимҗан Ибраһимовка «Татарстан» газетасына (хәзерге «Социалистик Татарстан») шефлык итү эшен тапшыра. Күренекле язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимов газета редакциясенә яшь журналист кадрлары әзерләүдә, эшче-авыл хәбәрчеләрен тартуда, матбугатка өлкән буын әдипләрен җәлеп итү, аларның чыгышларын оештыруда ныклы ярдәм күрсәтә, тормыш таләпләренә җавап бирә торган публицистик мәкаләләр белән өледән-әле үзе чыгыш ясый.

Матбугаттагы чыгышларында Г. Ибраһимовның тормышны тирән белүе, хезмәтне олылавы, коллектив куәтенә ышануы бөркелеп тора. Ул язучыларны «тормыш эчендә» кайнарга чакырды. «Мин әдип, мин шагыйрь дип, үзеңне аерып куйма, үзеңне коллективның бер кисәге, механизмның бер винты дип бел, бергә әйлән, бергә тормыш эчендә кайна, бергә ян, шатлан...» — дип язды Г. Ибраһимов 1924 елны «Пролетариат әдәбияты» турында дигән хезмәтендә.

Вакытлы матбугат бик күп язучыларны тәрбияләп үстерде. Гомәр Бәширов — шундый әдипләрнең берсе. Аңа газеталарда, журнал редакцияләрендә эшләү тормыш серләрен өйрәнергә ярдәм итте. Ул газетада эшләү чорын һәр вакыт горурланып

[1] М. Горький. Әсәрләр. XXIV том. 310 бит.

искә ала. «Мине язучы итеп большевистик матбугат тәрбияләп үстерде» [1],— дип язды ул. һәм Г. Бәширов «Социалистик Татарстан» газетасының 50 еллык юбилее уңае белән язылган мәкаләсендә: «Газетада эшләү миңа матур әдәбиятка килү өчен бик кирәкле һәм әһәмиятле бер баскыч булды» [2], — дип белдерде.

Вакытлы матбугатта эшләү өлкән әдип Мирсәй Әмиргә дә иҗади талантын үстерүгә ярдәм итте, әсәрләрендә публицистик рухны көчәйтте. М. Әмир, РСФСР Верховный Советы депутаты буларак, дәүләт эшлеклесе сыйфатында матбугатта актив катнашты. Ул хәзер дә газета-журналларны публицистик мәкаләләре белән бизи. «Күп еллар буена төрле редакцияләрдә эшләү сәбәпле, миңа әдәби иҗатымны журналистлык хезмәте белән тыгыз бәйләнештә алып барырга туры килде. Шуның аркасында минем... язылган әсәрләремдә публицистика йогынтысы көчле» [3], — дип яза Мирсәй Әмир.

Матбугат органнарында даими рәвештә хезмәттәшлек итүче прозаик, шагыйрь, драматург — теләсә кайсы редакция өчен көтеп алынган кеше. Алар газетаның колачын киңәйтәләр, эчтәлеген баеталар, аны кызыклырак һәм сугышчанрак итәргә булышалар. Газета да әдәбиятчы өчен бик файдалы мәктәп булып хезмәт итә. Әдип монда мөһим темалар күтәрергә, көн мәсьәләләренә игътибар итәргә өйрәнә, чынбарлык белән тирәнрәк таныша, әдәби осталыгын чарлый. Шуның белән бергә, Ленин әйткәнчә, популяр язучы «укучыга җитди һәм кыен эшне эшләргә **ярдәм итә,** аны җитәкләп алып бара, аңа беренче адымнарны ясарга булышлык итә һәм мөстәкыйль рәвештә алга барырга **өйрәтә**» [4].

Минем журналистларның I Бөтенсоюз съездында (1959 ел, ноябрь) һәм III съездында (1971 ел, декабрь) илебезнең күренекле язучыларының, публицистларының матбугатка карата әйткән сүзләре хәтеремдә нык саклана.

Алексей Сурков журналистларның I съезды трибунасыннан болай дип сөйләде: «...әдәбиятчы булган кешеләр илебез тарихының һәр зур борылышында газета аша тарих пульсын тою, халык тормышы пульсын тою өчен газетага килделәр. Язучы

[1] А. Гыйниятуллина. Татар совет язучылары, Казан. 1958 ел. 54 бит.
[2] «Социалистик Татарстан» газетасының «Журналист» листовкасы, 1968 ел. 12 март.
[3] М. Әмир. Сайланма әсәрләр, Казан, 1966 ел, 6 бит.
[4] В. И. Ленин, Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 5 том. 317 бит.

публицистикасы, очерклар, фельетоннар — я яхшы, кызыклы газета аларсыз яши алмый — язучы һәм журналист профессияләрен аерылгысыз итә»[1].

Журналистларның III съездында Борис Полевой журналист исемен горур йөртүен, бу профессиясенең бәхетле, кызыклы профессия булуын әйтте.

«Минем әдәбияттагы урыным бераз үзенчәлеклерәк: журналистлар мине — язучы дип, ә язучылар журналист дип атыйлар. Мин бу квалификациягә бик тә шатмын һәм шуны әйтәсем килә: тормышымның иң яхшы һәм бәхетле еллары... үзебезнең совет журналистикасында үтте»[2].

Күргәнебезчә, язучыларның иҗади эшчәнлеге совет матбугаты белән тыгыз бәйләнгән. Газетадан ераклашу, аннан аерылу әдип өчен тормыш, халык сулышын сиземләүне югалту булыр иде.

Республикабызның күренекле әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре вакытлы матбугатта актив катнашалар. Аның битләрендә күплэгән хикәяләр, очерк, тәнкыйть мәкаләләре, яңа китапларга, спектакльләргә, күргәзмәләргә, музыкаль әсәрләргә рецензияләр күрергә мөмкин. Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Бәширов, М. Горький исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Сибгат Хәким, Г. Тукай премиясе лауреатлары Габдрахман Әпсәләмов, Фатих Хөсни, Мирсәй Әмир, Хәсән Туфан, Гариф Ахунов, шулай ук танылган язучылар Афзал Шамов, Шәйхи Маннур, Гази Кашшаф, Зәки Нури, Риза Ишморат, Нәби Дәүли, Мөхәммәт Садри, Габдрахман Минский, Атилла Расих, Әхсән Баян һәм башка бик күпләр — газета һәм журналларның актив авторлары. Безнең заман язучысының бурычлары эчтәлеге белән дә, колачы белән дә бик нык үсте. Язучылар — коммунизм төзү чорының ялкынлы трибуннары, һәм алар үткен художник күзе белән якты киләчәкне күрергә өйрәтәләр, шәһәр һәм авыл хезмәтчәннәрен билгеләнгән максатка ирешү өчен көрәшкә тупларга өндиләр.

*

* *

Хезмәт кешесенең тормышы бик тә кызыклы. Чәчәкләргә күмелгән язгы болын кебек, Советлар иленең игелекле җире новаторлар казанышы, коммунистик иртәгәбезнең үсентеләре белән тулы. Бу кабатланмас гүзәл үсентеләр, яңа, прогрессив күренешләр әдәбиятчы һәм журналистлардан тормышка тагын да тирәнрәк үтеп керүне, җентекләп уйлануны таләп итә. Еш кына без бишьеллыкның гигант төзелешләрен торгызучылар, җирнең йөзен үзгәртүче кешеләрнең кызыклы эшләре турында эчпошыргыч итеп язабыз. Хезмәт батырлары турында без дулкынландыргыч итеп сөйләргә, материаль байлык тудыручыларның шатлыкларын, омтылышларын, хыялларын калкурак ачарга тиешбез. Моның өчен язучыларга һәм журналистларга барыннан да элек тормышны яхшы белергә, халык массаларының — коммунизм төзүчеләрнең иҗади эшен өйрәнергә, алар белән тыгыз элемтәдә торырга кирәк. Әдәбиятчыларның бурычы — гасырның бөек идеяләре, Коммунистлар партиясе идеяләре белән рухланган бүгенге көн кешесен бөтен тулылыгы белән күрсәтү.

Әдәбиятыбыз кеше шатлыгы, кеше бәхете турында җырларга һәм, шуның белән бергә, сәнгать төре буларак, үзе дә кешеләргә шатлык, зур эстетик ләззәт бирергә тиеш. Язучының осталыгын, аның сурәтләү чараларын, стиль ачыклыгын һәм тел байлыгын үстерү мәсьәләләре шуңа күрә бик кискен куела да.

Без гүзәл чорда яшибез. Ул барлык кешеләргә: иҗат работникларына да, эшчеләргә дә, колхозчыларга да үзенең катгый таләпләрен куя. Газета һәм журнал, радио һәм телевидение редакцияләренә ул кичектергесез, әле моңарчы кагылмаган тема һәм проблемалар булып ишек шакый. Аларны күтәрү һәм хәл итү өчен матбугат белән язучы үзара тыгыз иҗади элемтәдә хәрәкәт итәргә тиешләр. Шагыйрь, язучы безнең көннәрдә вак-төяк көнкүреш низагларын теркәүче түгел, ә алдан байрак тотып баручы булсын. Югыйсә, кызганычка каршы, бездә әле барысы турында да язарга яратучы, әмма тормышның мөһим мәсьәләләре, әдәбиятның партиячел бурычы турында тирәнтен уйланып тормаучы әдипләр дә юк түгел.

Тагын шундый бер кимчелек күзгә ташлана. Өлкән буын язучылар үрнәгендә, күп кенә яшь шагыйрьләр матбугатта теләп катнашалар. Әмма әдәби яшьләребезнең бер өлеше бары тик шигырь генә язарга омтыла, анда да кайнап торган тормыштан читтә кала. Тормыш шагыйрьнең очерклар, публицистик мәкаләләрне дә яхшы яза белергә тиешлеген раслый. А. Пушкин, М. Лермонтов, Д. Бедный, В. Маяковский, Г. Тукай,

---

[1] Журналистларның I Бөтенсоюз съезды (стенографик отчет). М. 1960 ел. 123 бит.

[2] СССР Журналистлар союзының III съезды (стенографик отчет), 1972 ел. 200 бит.

М. Гафури, Ф. Бурнаш, Һ. Такташ, Г. Кутуй һәм М. Җәлилләрнең публицист каләме белән дә оста эш итүләрен кем генә белми.

Өлкән әдип Габдрахман Әпсәләмовның публицистик эшчәнлеге күп яшь язучыларга үрнәк була ала. Ул, каты авыру булуына карамастан, редакцияләрдән заказ көтеп ятмыйча, бүгенге тормыш таләпләренә җавап бирә алырлык язмалар белән еш чыгыш ясый. Әгәр дә яшь әдипләр газета-журнал өчен рецензияләр, очерк, фельетон, мәкаләләр язсалар, бик шәп булыр, бу аларның әдәби иҗатларын һәм авторитетларын киметмәс, ә, киресенчә, аларны халыкның тормыш тәҗрибәсе белән баетыр гына.

Партия һәм яшьләр газеталары, журналлары, радио һәм телевидение яхшы очерк һәм публицистик мәкаләләрнең аз булуын бик яхшы тоялар. Билгеле булганча, публицистика — бүгенге көн тарихы, ул тормышка актив үтеп керә, вакыйгалар эчендә турыдан-туры катнашучылар, коммунистик җәмгыять төзүчеләрнең ярдәмчесе булып хезмәт итә. Яхшы публицистика матбугатның, бигрәк тә газетаның йөзен билгели, диләр. Шуңа күрә дә Татарстан язучылар һәм журналистлар союзлары үз сафларында ялкынлы публицистлар тәрбияләү җәһәтеннән зур кайгыртучанлык күрсәтергә тиешләр.

Совет укучысы фельетонны хөрмәт итә. Ул, публицистиканың бер жанры буларак, язучыларның игътибарын тартырга тиеш. Кызганычка каршы, газеталарда фельетон бик сирәк күренә, еш кына аның темасы вак була, сатирик энәсе юньләп кадамый, укучы аннан канәгатьләнү тойгысы алмый. Татарстан язучылары арасында фельетон сәнгатенең һәйбәт осталары бар. Аларның фельетоннары укучыларны еш рак сөендерсен, аларның чыгышлары совет кешеләрен эштәге җитешсезлекләрне, үсешебезгә комачаулык итүче һәр нәрсәне ничек тизрәк бетерү турында уйланырга мәҗбүр итсен иде.

Очерк — язучының газетадагы эшләреннән иң мактаулысы һәм хөрмәтлесе. Әмма ул күп нәрсәдән хәбәрдар булуны, фикер киңлеге һәм осталык таләп итә.

Вакытлы матбугатта очерк язып үзен танытхан язучы, журналист Гариф Галиев «Очеркның кадерен белегез» дигән мәкаләсендә болай дип яза:

«Минем үз гомеремдә газета-журнал битләрендә йөздән артык очеркым басылды... Шуларның иң күп өлеше «Кызыл Татарстан» редакциясенең командировкалары нәтиҗәсендә барлыкка килде һәм шуның битләрендә басылып чыкты... Редакция мине, язучы буларак, тормыш белән даими рәвештә бәйләп торды. Дөрестән дә, уйлап карасаң, республикабызда мин булмаган район бөтенләй юк, ә мин булмаган авыл сирәк» [1]. Очерк остасы Г. Галиев сүзләреннән безнең күп язучыларыбызга, бигрәк тә яшь әдипләргә җитди нәтиҗә ясарга кирәк.

Бу фикерне әдәби иҗат юлын «Кызыл Татарстан» газетасында очерклар язып башлаган Гомәр Бәширов сүзләре дә куәтли. «Очерклар язу,— ди ул,— мине, гомумән, күп нәрсәгә өйрәтте. Дөресен генә әйткәндә, мине әдәбиятка очерклар алып керде» [2].

Очерк — оператив жанр. Аның вазифасы — тугызынчы бишьеллык батырын, коммунизм төзүче совет кешесенең үсешен күрсәтү. Әмма бу мөһим жанрда әле язучы һәм журналистларның бик азы гына иҗат итә. Республикабыз матбугатында экономик очерк бөтенләй юк диярлек. «Советская Татария» яки «Социалистик Татарстан» битләрендә производствоны үстерүдә замандашыбыз ирешкән казанышлар турындагы очеркны укыгач, кайберәүләр, нинди очерк булсын бу, дигән шик белдерәләр. Әмма мондый очерклар бик кирәк. Бу — чор сулышын чагылдыру дигән сүз, чөнки хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү, техника прогрессы өчен көрәш, производство мәсьәләләре белән кызыксыну — коммунизмның материаль-техник базасын төзүдә иң мөһим шартлар. Газета очеркларына карата даими әдәби тәнкыйтьнең булмавы бу иң массовый һәм сугышчан жанрның үсешен тоткарлый.

Публицист актив, оператив булырга тиеш. Бу — сугышчан уяулыкта тору дигән сүз. Язучының тормышка үтеп керү чаралары максатчан булсын өчен, аның бик тә сизгер булуы кирәк. Язучы партия куйган бурычлар белән күзгә-күз очрашырга тиеш. Әйе, очерклар бик кирәк! КамАЗ турында — КамАЗ масштабындагы, игенче хезмәте турында — колач җитмәс кырлар киңлегендәге, фән турында микроскоптай үткен күзле, ерактан күрүче очерклар безнең матбугатны бизәсен иде.

Шуны басым ясап әйтергә кирәк, КПСС Үзәк Комитетының мәгълүм карарыннан соң әдәбият-сәнгать мәсьәләләре матбугат, радио һәм телевидениенең игътибар үзәгенә куелды. «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе, мәсәлән, күренекле тәнкыйть-

---

[1] «Социалистик Татарстан», 4 апрель, 1968 ел.
[2] Г. Бәширов, Сайланма әсәрләр, II том, 1965 ел, 359 бит.

челәр, әдәбият белгечләре, язучылар белән «Түгәрәк өстәл янында сөйләшү» үткәрде. Анда әдәби тәнкыйтьнең торышы һәм аны тагын да яхшырту, хәл итәсе мәсьәләләр турында кызыклы фикерләр әйтелде.

Әдәбият-сәнгать тәнкыйтенең үсеш юллары турында газета-журналларда дистәләрчә мәкаләләр басылды. Шулай да без тәнкыйтьчеләребезнең матбугат битләрендә ешрак һәм кыюрак чыгыш ясауларын теләр идек. Архивларда гына утырмыйлармы алар? Очраклы сорау түгел бу. Чөнки кайбер тәнкыйтьчеләребезнең акрын кыймылдавы аркасында җирле нәшриятта чыгарылган китапларның күбесе игътибардан читтә кала. Әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең яшь һәм урта буын вәкилләре арасында үз адресына бер генә сүз ишетмәгәннәре дә бар.

Миңа Мәскәүдә КПССның XXIII съезды узган көннәрдә Кыргызстаннан халык язучысы Чыңгыз Айтматов белән очрашырга туры килгән иде. Безне — бер төркем журналистларны, партиянең XXIII съезды делегатларын, шул исәптән язучы, Ленин премиясе лауреаты Чыңгыз Айтматовны — журналистларның Үзәк йортына чакырдылар. Без анда КПССның XXIII съезды таләпләре яктылыгында матбугат алдында торган бурычлар турында фикер алыштык. Ч. Айтматов әдәбият-сәнгать өлкәсендә партия политикасын үткәрүдә матбугат һәм журналистларның нинди урын тотуы, газета белән язучының иҗади дуслыгы турында дулкынланып сөйләде.

«Урыннарда әдәби политика,— диде ул,— нигездә газеталар тарафыннан уздырыла. Теге яки бу әсәрнең язмышы, җәмәгатьчелек күз алдында аңа булган бәя газета алган юнәлешкә, аның мөнәсәбәтенә бәйле». Ул әдипләрнең иҗаты, аның әсәрләре турында газета аша сөйләшү нигезле, төпле булырга, шунлыктан редакциядә әдәбиятны белгән журналистлар, авторлар эшләргә тиеш, диде. Шул вакытта «газетаның әдәби политикасында, аның сәнгать әсәренә булган карашында конъюнктурщина, бер читтән икенче читкә ташлану кимрәк булыр. Газетаның ачык, даими линиясе барлыкка килеп, газета нәрсә яклы һәм нәрсәгә каршы чыга — газета үзе һәм аның укучылары бу турыда белеп торырлар» [1].

Бу фикердән, әлбәттә, безгә, журналистларга, редакцияләргә җитди нәтиҗә ясарга кирәк.

Хәл итәсе башка мәсьәләләр дә бар. Без балалар әдәбиятына игътибарны арттыру ягында. VIII съезд алдыннан «Социалистик Татарстан» газетасында басылган мәкаләсендә, радиотапшыруда, съездда ясаган докладында язучы Ләбибә Ихсанова балалар әдәбияты үсеше турында кызыклы мәсьәләләр күтәрде. Бездә бу өлкәдә эшләүче тәҗрибәле язучылар бар. Әмма матбугатта балалар әдәбиятының бүгенге хәленә тирән анализ ясаган, аның киләчәк үсеш юлларын күрсәткән мәкаләләр күренми диярлек.

Язучыларның эшче һәм авыл хәбәрчеләре арасында да үз эшчәнлекләрен активлаштырулары, алар алдында докладлар белән ешрак чыгулары, газета редакцияләрендә әдәби түгәрәкләр оештыруга булышулары, сәләтле эшче-авыл хәбәрчеләренә үз көчләрен әдәбиятта да сынап карарга ярдәм итүләре сорала.

*
* *

Язучының партияле, дөрес сүзе матбугат битләрендә тагын да көчлерәк ишетелсен, коммунистик идеаллар тантанасы хакына совет кешеләрен фидакарь хезмәткә рухландырсын өчен газета-журнал, радио һәм телевидение редакцияләре барлык чараларны күрергә тиешләр.

Билгеле булганча, язучы һәм журналист профессияләрен аерып карау кыен. Алар — коралдаш туганнар. Аларның коралы — ялкынлы большевистик, партияле сүз. Язучыларның һәм журналистларның иҗади союзлары һәр вакыт иңгә-иң торып эшләргә тиешләр. Моннан матбугат та, әдәбият та отачак!

Партиянең халык белән иң мөһим эшләр турында сөйләшә торган чарасы — матбугат, радио һәм телевидениедә эшләү — язучы өчен дә, журналист өчен дә мактаулы вазифа.

---

[1] «Советская печать» журналы, № 5, 1966 ел, 15—16 битләр.

Флүн Мусин

# РЕАЛИЗМ ЮЛЫННАН

*Татар прозасында роман һәм повесть тарихыннан*

Алтмышынчы еллар башыннан совет әдәбият белемендә һәм тәнкыйтендә жанрлар мәсьәләсенә игътибар артты. Романны өйрәнүгә аеруча зур игътибар бирелә башлады. Бу мәсьәләгә багышлап зур-зур бәхәсләр үткәрелде, күп санлы мәкаләләр һәм монографик хезмәтләр язылды.

Роман жанрына булган мондый гомум игътибарны нәрсә белән аңлатырга соң? Төп сәбәпләрнең берсе, минемчә, романның бөтен әдәби процесста уйнаган роле белән бәйләнгән. Бу жанрның тууы һәм җитлегүе еш кына теге яки бу милли әдәбиятның реализм юлыннан үсү процессы итеп карала, ахыр чиктә, роман язмышы реализм язмышы булып алга баса. Совет власте елларында формалашкан күп кенә яшь әдәбиятлар практикасы бу яктан аерума игътибарга лаек. Аларның һәркайсында хәзер роман жанры нык ап формалашты һәм әдәби хәрәкәтне әйдәп барган көчкә әверелде яки әверелеп килә. Роман ул әдәбиятларның идея-эстетик җитлеккәнлеген күрсәткән фактор булып тора.

Илебездәге яшь әдәбиятлар практикасы Көнбатышта киң таралган бер фикернең — хәзерге вакытта роман кризис кичерә һәм хәтта «үлемгә» йөз тотып бара, дигән фикернең нигезсез булуын, киресенчә, социалистик җәмгыять шартларында бу жанрның яңа киңлекләргә чыгуын һәм яңа үрләр яулавын күрсәтә. Бу хәл социалистик реализмның мөмкинлекләре чиксез булуын раслый.

Роман турында барган сөйләшүләрдә бу жанрның туу тарихы шактый актуаль төс алды. Әйтергә кирәк, бу мәсьәләне тикшерү дә үзмаксат түгел, ул реалистик прозаның формалашуын ачыкларга хезмәт итә.

Зур тарихы булган әдәбиятлар тәҗрибәсе аларда проза жанрларының тууы һәм җитлегүе төп өч төрле эстетик фактор белән бәйләнгән булуын күрсәтә. Сүз фольклор, язма әдәбият традицияләре һәм чит әдәбиятлар йогынтысы хакында бара. Бигедә язма әдәби традицияләр үзгә бер әһәмияткә ия булган. Бердән, алар укучының эстетик зәвыкларын тәрбияләүдә мөһим роль уйнаган, икенчедән, фольклорның иң яхшы традицияләрен иҗади үстерә һәм камилләштерә килгән, өченчедән, алга киткән башка әдәбиятлар тәҗрибәсен үзләштерү өчен нигез булып торган.

Проза жанрларының формалашуы өчен, барыннан да элек, чәчмә хикәяләү традицияләре кирәк булган. Татар әдәбиятындагы чәчмә традицияләрнең тарихы өйрәнелмәгән. һәм ул махсус тикшеренүне сорый торган зур һәм катлаулы мәсьәлә.

Татар прозасы үзенең тирән тамырлары белән борынгы дәверләргә үк китә. Дөрес, борынгы әдәбиятта әдәби төрләрнең һәм жанрларның әле синкретиграк хәлдә булулары, анда хикәяләү формаларының да бергә укмашыбрак яшәүләренә китерган. Нәтиҗәдә, бер үк әсәрдә һәм чәчмә, һәм тезмә хикәяләү алымнарын табарга мөмкин. Әйтик, безнең борынгы дастаннарны еш кына саф шигъри әсәрләр итеп каравы кыен. Мәсәлән, Кол Галинең «Йосыф вә Зөләйха»сыннан (1233) башлап, күпчелек поэмалар һәм дастаннар «кыйсса» яки «хикәят» сөйләү рәвешендә язылган һәм алар

сюжет-композиция төзелешләре ягыннан еш кына шигъри повестьларны яки романнарны хәтерләтәләр. Кайбер поэтик әсәрләр, әйтик, Сәйф Сараиның «Гөлстан биттөрки»се (1391) чәчмә һәм тезмә формаларда язылган. Мәхмүт бине Галинең «Нәһҗел-фәрадис» әсәре (1358) исә тулысынча чәчмә хикәяләрдән тора. Мөхәммәдьярның «Төхфәи Мәрдан» һәм «Нуры содур» поэмалары (XVI йөзнең беренче яртысы) шигъри хикәяләр тезмәсен тәшкил итәләр. Мәгълүм ки, бу әсәрләрнең байтагысы борынгы гарәп яки төрки дөньясында туган сюжетларны эшкәртү нәтиҗәсендә язылган.

Мондый сюжетлардан файдалануда да кызыклы гына үзенчәлекләр күзгә ташлана. Мәсәлән, XV йөздә яшәгән Саяди исемле шагыйрь, шундый читтән килгән сюжетларның берсен файдаланып, «Бабахан дастаны»н яза. Әмма ул поэманың жанрын үзгәртми. Ә инде XIX йөздә яшәгән Әхмәт Курмаши, борынгы мәхәббәт поэмаларыннан файдаланып, «Бүз егет» (1874) һәм «Таһир илә Зөһрә» (1876) исемле чәчмә әсәрләр иҗат итә. Басылып чыгу белән, бу әсәрләр татар укучылары арасында киң таралыш таба һәм аларның иң яраткан китапларына әйләнә. Борынгы шигъри сюжетның соңрак чәчмә әсәргә әйләндерел бирелүе һәм укучылар арасында зур популярлык казануы һич тә очраклы хәл булмаска тиеш. Киресенчә, бу факт соңгырак дәверләрдә татар әдәбиятында чәчмә хикәяләүнең тагын да көчәя төшүен күрсәтә шикелле. Чыннан да, XVI йөздән башлап бездә чәчмә хикәяләү активлаша бара. Бу хәл төрле-төрле сәбәпләр белән аңлатыла. Аерым алганда, бу чорларда дипломатик хәбәрләшүнең, канцелярия эшләренең шактый активлашуы, тарих китаплары, һәртөрле елъязмалар, васыятьнамәләр, сәяхәтнамәләр, шәҗәрәләр күп язылу чәчмә хикәяләүнең яшәү һәм үсү җирлеге булып торалар. Менә бер гыйбрәтле факт. «XVII—XVIII гасыр татар тарихи чыганаклары» исемле хезмәтендә тарихчы М. Госманов шул дәверләрдә язылган тарихи китапларда һәм шәҗәрәләрдә әдәби башлангычның шактый көчәя төшүен искәртә һәм бу хәлнең конкрет тарихи сәбәпләр белән бәйләнгәнлеген әйтә.

Татар әдәбиятында чәчмә хикәяләүнең (һәм, димәк, прозаның да) үсешенә тагын китап басу эше зур гына йогынты ясаган булырга тиеш. Мәгълүм ки, бездә бу эш 1800 елдан башлана һәм басма китап бик тиз арада татарлар арасында зур популярлык казана [1].

Билгеле булганча, басма китап ярдәмендә проза яңа баскычка күтәрелә, сәнгатьтә яңа үрләр яулый. Күренекле инглиз әдәбиятчысы Ральф Фоксның: «Роман... ул китап басу станогы җимеше булып тора» [2], дип белдерүе бер дә очраклы хәл түгел. Чыннан да, дөнья әдәбиятындагы беренче басма китаплар роман һәм повестьлар булган. Татар телендә чыккан беренче басма әсәр дә повесть була («Сәйфелмөлек», 1807). Китап басу эшенең әдәби жанрлар үсешенә йогынтысын күрсәтү өчен, тагын бер мисал китерәсе килә. Басма китапның юклыгы XIX йөз азәрбайҗан әдәбиятында драманың беренче планга чыгуына сәбәпче була, ә прозаның үсеше тоткарланып кала [3].

Реалистик проза жанрларының формалашуы, башка күп кенә әдәбиятлардагы кебек, бездә дә мәгърифәтчелек реализмы дәверенә туры килә. Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм аның әдәбиятта чагылышы турында шактый фикер әйтелгән. Бу мәсьәлә белән беренчеләрдән булып Г. Ибраһимов якыннан кызыксына. Дөрес, ул вакытта бездә «мәгърифәтчелек» термины фәнни кулланышта булмаганлыктан, Г. Ибраһимов ул чор әдәбиятын «җәдит әдәбият» дип атый һәм аның асылын түбәндәгечә билгели: «Бу икенче дәвернең әһәмияте, кагъбәсе: иске каткан кадимлекне җимереп, (буржуазный) Европа мәдәниятен, бөтен капитализмны, эксплуатациясе, икътисади тигезсезлеге белән бергә бөтен көенчә татар дөньясына кертү, кыскача әйткәндә, бездә мәдәни капитализмны җирләштерергә тырышу — ягъни шул рухны, шуңа эшләүче кешеләрне дөньяга чыгарудыр» [4]. Күренә ки, биредә татар мәгърифәтчелек әдәбиятының асылы һәм үзенчәлеге бик оста тотып алынган. Аннан соң М .Гайнуллин, И. Нуруллин, К. Фасеев хезмәтләрендә татар мәгърифәтчелек әдәбияты турында бай мәгълүмат табарга мөмкин. Әмма бу очракта безне, мәгърифәтчелек әдәбиятының үзеннән дә бигрәк, аның прозадагы аерым жанрларга нинди йогынты ясавы күбрәк кызыксындыра.

Билгеле булганча, татар реалистик про-

---

[1] Бу хакта Ә, Кәримуллинның «У истоков татарской книги» исемле хезмәтендә тулы мәгълүмат бар,

[2] Ральф Фокс. Роман и народ, Рус телендә, Госполитиздат. 1939 ел. 36 бит.

[3] «Литературный Азербайджан» журналы, 1974 ел. 2 сан. 112 бит.

[4] Г, Ибраһимов, Татар әдәбиятында өченче дәвер, «Татарстан хәбәрләре», 1922 ел, 7 март,

засының беренче карлыгачы итеп Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла»сы (1886) санала. Проза жанрларын формалаштыруда К. Насыйриның роле исә тиешенчә бәяләнми кебек. Хәтта XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы татар әдәбиятындагы иҗат методларын махсус рәвештә өйрәнгән И. Нуруллин да: «Каюм Насыйриның бөтен әдәби продукциясе көнчыгыш легендаларын, экиятләрен һәм кыска анекдотларын тәрҗемә итүдән яки эшкәртүдән гыйбарәт»[1], дип кенә үтә. Дөрес, бу фикерен ул К. Насыйридан критик реализм вәкиле ясарга тырышучылар белән бәхәсләшкәндә әйтә. Әмма, бәхәс рухына бирелеп, ул икенче читкәрәк ташлана, К. Насыйриның мәгърифәтчелек реализмы вәкиле буларак ролен дә инкарь итә кебек. Әгәр мәсьәләгә тарихи конкрет килсәк, К. Насыйри безнең алга мәгърифәтчелек әдәбияты формалашу өчен ныклы җирлек әзерләгән, аңа юл ачкан әдип булып килеп басар. Әмма биредә бер нәрсәне истән чыгармаска кирәк. Мәгълүм булганча, мәгърифәтчелек реализмының аны башка методлардан, әйтик, классицизмнан, аерып торган төп новаторлык сыйфаты тормыш прозасына, «җир» кешесенең көндәлек мәшәкатьләренә йөз белән борылуда чагылды. К. Насыйриның әдәби иҗаты исә нигездә Көнчыгыш халыкларының традицион легендаларын яки язма әсәрләрен татар укучысына аңлаешлы итеп эшкәртеп бирүдән гыйбарәт. Ул әсәрләрдә сурәтләнгән вакыйгалар һәм геройлар беренче карашка XIX йөзнең икенче яртысындагы татар чынбарлыгыннан бик ерак торалар.

Иң элек мондый иреклә тәрҗемәләрнең яңа заман әдәбияты формалашкан вакытта бик законлы һәм типик күренеш булуын әйтергә кирәк. Әгәр башка әдәбиятлар, әйтик, ул дәвердә безгә иң якын булган рус һәм төрек әдәбиятлары тарихына гына күз салсак та, без аларда мәгърифәтчелек прозасының беренче адымнары иреклә тәрҗемәләрдән башланганын күрербез. Рус һәм төрек язучылары башлыча француз мәгърифәтчеләренең әсәрләрен тәрҗемә иткәннәр.

Ф. Әмирхан сүзләре белән әйткәндә, «күп гасырлар шәрык тәэсире белән килгәннән соң, акрын гарәп тәэсире астына»[2] керә башлаган әдәбиятыбызның башында торган, татар халкын Европа, беренче чиратта, прогрессив рус культурасына якынайту юлында армый-талмый эшләгән К. Насыйри исә әдәби иҗат эшчәнлегендә башлыча Көнчыгыштан килгән традицион сюжетларга йөз тоткан. Бу хәлне ничек аңлатырга соң? Хикмәт күренекле мәгърифәтченең аеруча үтемле әдәби чаралар һәм формалар эзләвендә булса кирәк. «Әбугалисина кыйссасы» һәм «Кырык вәзир кыйссасы» кебек көнчыгыш дөньясында зур популярлык казанган һәм татар укучыларына да байтактан таныш булган әсәрләр К. Насыйрига үзенең идея-эстетик карашларын тормышка ашыру өчен киңрәк мөмкинлек биргәннәр. Чөнки бу әсәрләрдә кеше акылына, гыйлемгә дан җырланган, аларның дөньядагы бар нәрсәне үзгәртеп корырлык, гаделлек урнаштырырлык көч булуына басым ясалган. Ә бу, билгеле булганча, мәгърифәтчелек идеологиясенең һәм философиясенең нигез ташын тәшкил итә.

Икенче яктан, К. Насыйрины без яңа заман татар прозасына нигез салучыларның берсе итеп карарга тиешбез. Соңгы елларда әдәби формаларның тууына нигез булып торган башлангыч эстетик җирлекне ачыклауга игътибар артты. В. Шкловский, М. Бахтин, В. Кожинов, С. Аверинцев кебек әдәбият галимнәре, әдәби жанрлар үзләренең тамырлары белән мифка, эпоска һәм халык иҗатының башка борынгы төрләренә барып тоташалар, диләр. Әдәбиятның борынгы эстетик җирлеген ачыклауга игътибар артуның сәбәпләрен галимнәр XIX йөз ахыры һәм XX йөз башларында культура антропологиясенең (ягъни культура тарихын өйрәнүнең) зур уңышларга ирешүе белән бәйләп аңлаталар.

Көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятларына караган бу гомум тенденция заманында татар культурасы һәм татар әдәбиятында да чагылган. Мәсәлән, XIX йөздә бездә дә милли культурабызның үткәне белән кызыксыну, аны өйрәнү теләге үсә һәм мәгърифәтчеләр шул теләкне тормышка ашырырга алыналар. Бер яктан, халыкның тормышын җиңеләйтүнең төп юлын мәгърифәттә күреп, алар изелгән массаларга аң-белем бирүгә зур көч куялар. Икенче яктан, безнең мәгърифәтчеләргә туган халкыбызның күпгасырлык үткәне белән тирәнтен кызыксыну, аны тулырак күзалларга омтылу хас була. Алар халыкның культура тарихын өйрәнүгә аеруча зур игътибар бирәләр. Чөнки әдәби ядкарьләрдә

---

[1] И. Нуруллин. Путь к зрелости, Рус телендә. Казан. 1971 ел. 25—26 битләр.
[2] Ф. Әмирхан. Әдәбиятка ганд. «Әльислах» газетасы, 1908 ел, 19 май.

һәм фольклор әсәрләрендә халыкның күңел байлыгы, якты идеаллары ачык чагыла. Бу байлыкны мәгърифәтчеләр массаларның милли аңын һәм горурлыгын үстерүдә, аларны азатлык өчен яңа көрәшләргә хәзерләүдә иң мөһим чараларның берсе итеп карыйлар. Бу хәзинәне җыю һәм пропагандалау эшенә беренчеләрдән булып Хәлфиннар алына. Биредә Ибраһим Хәлфинның (1778—1829) хезмәте аеруча зур була. Бу башлангычны Ә. Ваһапов, С. Кукляшев, М. Мәхмүдов, Х. Фәезханов һәм башкалар дәвам иттерә [1].

XIX йөзнең икенче яртысында татар халкының күпгасырлык культура мирасын өйрәнү эшен Ш. Мәрҗани белән К. Насыйри яңа баскычка күтәрәләр. Аларның бу өлкәдәге эшчәнлеге энциклопедик төс ала. Язма әдәбият һәм фольклор, мифология һәм этнография — болар Мәрҗани белән Насыйрины бердәй кызыксындыралар. Алар бигрәк тә борынгы дәверләргә — Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорларына караган ядкарьләрне җыю һәм өйрәнүгә дикъкать итәләр. Шушы күпгасырлык рухи хәзинә белән якыннан танышу мәгърифәтче әдипләрнең иҗатларына да эз салмый калмый, билгеле.

Бу хәл проза жанрлары формалашуда аеруча ачык чагыла. Хәзерге әдәбият белемендә әлеге жанрларның, беренче чиратта романның, башлангыч формалары рәвешендә ике төрле структура карала башлады. Рус прозасында шундый форма итеп әкият алына һәм аның реалистик романга да йогынты ясавы күрсәтелә. Мәсәлән, В. Шкловский А. С. Пушкинның «Капитан кызы» сюжет төзелеше буенча тылсымлы әкиятне хәтерләтүен әйтә [2].

Соңгы вакытта көнчыгыш әдәбиятларындагы романның башлангыч «моделе» итеп дастан карала башлады. Бу хәл дастанның әлеге халыклар иҗатында эпик хикәяләү традицияләрен гасырлар дәвамында үзендә туплап килүе белән бәйләп аңлатыла. Нәтиҗәдә ул көнчыгыш әдәбиятларында яңа заман романы формалашу һәм үсеп китү өчен җирлек булып торган. Совет төрки әдәбиятларында роман жанры формалашуда да дастанның роле зур булуы күрсәтелә (мисал өчен М. Пархоменко һәм В. Оскоцкий хезмәтләрендә). Сүз уңаенда соңгы вакытта бу әдәбиятларда дастан жанрын кабат терелтергә омтылыш көчәюен әйтергә кирәк.

Татар әдәбиятында реалистик проза жанрлары ничегрәк формалаша соң? Инде әйтелгәнчә, бу процессның башында К. Насыйри тора. Аның иҗатында үткәндәге язма әдәбият (дастан яки кыйсса) һәм фольклор (әкият) традицияләре бергә очрашалар һәм үзара берләшеп яңа төсмер алалар. Биредә шунысы игътибарга лаек: К. Насыйри әле борынгы легендалар һәм әкият дөньясыннан аерылырга теләми генә түгел, бәлки, киресенчә, еш кына үзе теләп шушы стихиягә бирелә. Шул ук вакытта бу әдип иҗатында үткәндәге язма әдәбиятыбызның үзенчәлекле бер традициясе — новеллизм үзен нык сиздерә. Аның «Кырык вәзир», «Кырык бакча» һәм «Фәвакиһел җөләса фил әдәбият» кебек әсәрләре «хикәят»ләр яки кыска новеллалар тезмәсеннән гыйбарәт.

К. Насыйридан соң әдәбиятка килгән мәгърифәтче әдипләр (М. Акъегет, Р. Фәхретдинов, З. Һади һ. б.) иҗатында исә әдәбият һәм фольклор традицияләренә мөнәсәбәт башкарак төс ала. Биредә инде бу традицияләр йогынтысы, эчтәлектән бигрәк, формада күренә. Чөнки хәзер әсәр эчтәлеге заман тормышына нигезләнә. Мәгърифәтче әдипләр язган әсәрләрдә нинди дә булса бер гыйбрәтле хәл яки вакыйга турында «хикәят» сөйләү, «кыйсса» сөйләү өстенлек итә. Әйтерсең лә әдипләр бары шушы хакта гына уйлаганнар, ә жанр аныклыгы турында рәтләп кайгыртмаганнар. М. Акъегет үзенең «Хисаметдин менла»сын «милли роман яки хикәя» дип исемләгән. Автор әсәрнең жанрын ачык билгеләмәгән һәм, күрәсең, бу эшне кирәк тә тапмаган. Аннан соң революциягә кадәр бездә «повесть» дигән жанр төшенчәсе гомумән гамәлдә булмаган. Без хәзер повесть дип йөртә торган әсәрләрне я «хикәя», я «әсәр» дип кенә атаганнар. Г. Ибраһимов хәтта үзенең совет чорында язылган «Тирән тамырлар»ын да «озын хикәя» дип атаган.

Мәгърифәтчеләрнең жанр төрлелегенә һәм аныклыгына әллә ни игътибар итмәүләре бер дә очраклы хәл түгел, моның тарихи объектив сәбәпләре бар. Бу хәл ахыр чиктә мәгърифәтчеләрнең гомум идея-эстетик карашлары һәм омтылышлары белән бәйләнгән. Бу яктан В. И. Ленинның бер фикере зур методологик әһәмияткә ия. «Без нинди мирастан баш тарта-

---

[1] Бу дәвер татар мәгърифәтчеләренең күпкырлы фидакарь эшчәнлеге турында С. Михайлованың «Формирование и развитие просветительства среди татар Поволжья» исемле хезмәтендә (Казан, 1972) шактый бай мәгълүмат тупланган.

[2] В. Шкловский. Тетива. О несходстве сходного. Рус телендә, Мәскәү, 1970 ел, 219 бит.

быз?» исемле хезмәтендә ул болай яза: «Мәгърифәтчеләр халыкның бер сыйныфын да үзләренең аерата игътибар предметы итеп аерып куймадылар, алар гомумән халык турында гына түгел, бәлки гомумән милләт турында сөйләделәр»[1]. Алар «гомуми рәхәт яшәүгә чын күңелдән ышандылар һәм аны чын күңелдән теләделәр»[2]. Бу хәл мәгърифәтче әдипләр иҗатының бөтен якларына, шул исәптән аларның хикәяләү алымнарына да мәгълүм эз сала. Аларның жанр аныклыгына бик аз игътибар итүләрен яки бу мәсьәләгә шактый формаль карауларын шуның белән аңлатырга кирәктер. Гомумән, мәгърифәтчеләр иҗатында еш кына традицион хикәяләү алымнары өстенлек итә. Традицион хикәяләү алымнары дигәндә, барыннан да элек, әкиятләрдән килә торган хикәяләү алымы күз алдында тотыла.

Яңа заман прозасы формалашкан вакытта хикәяләү алымнарының әкияткә аеруча якын торуы тагын сурәтләү объектларының уртак булуы белән дә бәйләнгән. Эш шунда ки, мәгърифәтчелек прозасындагы кебек, әкияттә дә төп игътибар кешенең шәхси тормышына юнәлдерелә. Бу яктан әкият халык иҗатының башка төрләреннән шактый аерыла. Мәсәлән, әкият белән риваять арасында кызыклы гына аерымлыклар яши. Моны ачыклау өчен, бер үк образны гәүдәләндергән ике әсәргә — «Хан кызы Алтынчәч» риваятенә һәм «Алтынчәч» әкиятенә игътибар итик. Риваятьтә хан кызы Алтынчәч конкрет тарихи җирлектә күрсәтелә. Героиня образында заманның мөһим иҗтимагый идеаллары, ватанчылык, патриотизм идеяләре чагыла. Бу идеалларны һәм героиня язмышын яктыртканда риваять тарихи дөреслектән читләшми. Болгарлар җиңелгәч, яу башлыгына кол булмас өчен, Алтынчәч тау тишегенә кереп югала.

Әкияттә инде патша кызы Алтынчәчне сурәтләүдә хыял, фантазия стихиясе хакимлек итә. Нәтиҗәдә образ конкретлыктан ахыргача арындырыла һәм тагын да гомумирәк төс ала. Алтынчәч мифик көч — дию кулына эләгә. Әгәр легендада героиня образы, инде әйтелгәнчә, халыкның иҗтимагый идеалларын чагылдыру чарасы булып торса, әкияттә ул гомум мораль-этик идеалларның җиңеп чыгуын күрсәтү чарасына әверелә. Әсәрдә явызлык белгесе булган дию һәм патша җиңелә, тылсымлы көчләр ярдәмендә Алтынчәч дию тоткынлыгыннан азат ителә. Икенче төрле әйткәндә, әкияттә явызлык, гаделсезлек җиңелә, гаделлек тантана итә. Җыеп әйтсәк, риваять белән әкият арасындагы иң мөһим аерма түбәндәгегә кайтып кала. Риваять авторын кеше иҗтимагый шәхес буларак кызыксындыра. Әкияттә исә герой — гади кешеме ул, әллә патшамы — иҗтимагый җирлектән һәм иҗтимагый сыйфатлардан тулысынча арындырыла, укучы алдына аның шәхси тормышы баса. Әмма герой биредә дә нинди дә булса индивидуальлектән, конкретлыктан азат ителгән. Ул бары гомумилекне, халыкның артык гомум һәм абстракт идеалларын чагылдыру чарасы булып тора. Тормышны һәм кешене сурәтләүдә социаль детерминизмнан качу, гомумилеккә омтылу ягыннан әкият, һичшиксез, мәгърифәтчеләрнең күңеленә хуш килгәндер. Чөнки, алдарак әйтелгәнчә, мәгърифәтчеләр дә еш кына гомумилек алдында баш иялэр.

Боларның һәммәсе мәгърифәтче прозаиклар иҗатына әкияттән, тагын да конкретлаштырып әйтсәк, тылсымлы әкияттән килә торган традицион хикәяләүнең зур гына йогынты ясавына китергән. Әкият әлеге әдипләр иҗатына турыдан-туры да һәм читләтеп тә, ягъни язма әдәбият традицияләре аша да тәэсир иткән. Әкият, язма әдәбият традицияләре һәм мәгърифәтче әдипләр иҗаты арасындагы тыгыз бәйләнешне без инде әсәрләрне башлап җибәрү алымнарында ук күрәбез. Шуңа берничә мисал китерик. Әкиятләрдә: «Борын заманда бар иде бер патша. Аның дүрт улы бар иде» («Ак бүре»); «Әүвәле булган ди бер бик ярлы кеше. Аның булган ди өч улы» («Һөнәрле үлмәс») һ. б. Үткәндәге язма әдәбиятта: «Рузкяр эчендә[1] бер хуҗа бар иде. Малы-туары үкеш иде. Һич угылы, кызы юк иде» («Нәһҗелфәрадис». 1358); «Равиан асар вә пакыйлән дәр несарь[2] шундаг риваять[3] вә мундаг хикәят кылырлар кем, заманы әүвәлдә бер олуг вә мәшһүр падишаһ бар иде. Малы вә хәзинәсе вә гаскәре бик күп иде, бунча солтанәтлек[4] илә дөньяда һичнәрсәгә ихтыяҗы юк иде. Ләкин дөньяда угылкыздан фәрзәнде[5] юк иде» («Таһир илә

---

[1] В. И. Ленин, Әсәрләр, 2 том, Казан, 1954, 520 бит.
[2] Шунда ук, 499 бит.

[1] Рузкяр эчендә — бер заманда.
[2] Равиан асар вә пакыйлән дәр несарь — төрле әсәрләр турында хикәят сөйләүчеләр.
[3] Шундаг риваять — шулай сөйләрләр.
[4] Солтанәтлек — олылык.
[5] Фәрзәнд — бала.

Зөһрә кыйссасы». 1876) һ. б. Мәгърифәтче әдипләр әсәрләрендә: «Россия уртасында Идел нәһереннән[1] озак дәгел бер татар авылы мәүҗүттер. Карьянең әһалисе ике йөз кадәр өй булып, атыны фак итмәктән чикенә-йөрез[2] анчак хикаябезне җиңел аңлатмак өчен, атыны «Н» хәрефе илә ишарә итәбез... Иштә «Н» көендә урта җәмигътан ерак дәгел бер кечек ханә бар... Бу ханәдә менла хадыны тел Зөлхая вә угылы Хисаметдин менлә атлы адәмнәр торырлар иде» («Хисаметдин менла». 1886); «Б» карьясе мәшһүр бер карья улдыгы кеби, кәндәсендә (үзендә) һәм исеме ерак җирләргә җитмәк мәгъруф бер имам бар иде. Кырык яшьләрендә улан бу имамның гаиләсе Гайшә исемле хатыны илә Әсма исемендә бер данә кыздан гыйбарәт иде» (Р. Фәхретдинов. Әсма яки гамәл вә җәза. 1903); «Башкорт авылларының берендә бере Миңлешаһ вә икенчесе Сәфәргали исемле яңа җитеп килә торган ике егет бер-берләре илә бик дус булып гомер кичерәләр иде» (З. hади. Яңа әсхабе кәһәф. 1908) һ. б.

Күрәсез, әкияттә дә, язма әдәбиятта да һәм мәгърифәтчеләр әсәрләрендә дә хикәяләүне башлауда бер үк алым күзгә ташлана. Әмма биредә мәгърифәтче әдипләрне һич тә әкият һәм үткәндәге әдәбият традицияләрен механик рәвештә күчереп алучылар итеп карарга ярамый. Әкият алымын файдалануга иҗади килү инде язма әдәбият әсәрләрендә күзгә ташлана. Бу әсәрләрнең авторларына әкият алымы әйтерсең лә бер үрнәк схема булып торган. Һәм алар бу схемага җан өрергә һәм аны конкретлаштырырга теләгәннәр. Мәгърифәтче әдипләр исә бу өлкәдә тагын бер адым алга атлыйлар. Аларның әсәрләрендә хикәяләүне башлап җибәрү тагын да конкретлаша һәм детальләшә төшә. Монда шунысы дикъкатьне җәлеп итә: автор игътибары, геройларның үзләреннән бигрәк, алар яшәгән мохитка юнәлдерелә. Әдипләр бу мохитның киңрәк күренешен бирергә тырышалар.

Шулай да мәгърифәтче әдипләр хикәяләүне башлаганда әкияттән килә торган традицияләргә теге яки бу дәрәҗәдә турылыклы булып калалар. Мәгърифәтче әдипләрнең әсәрләрендә авторның үзен актив тотуы, әледән-әле укучыларга мөрәҗәгать итеп, вакыйгалар агышына туры-дан-туры катнашуы да күпмедер дәрәҗәдә әкияткә барып тоташа булырга тиеш. Менә берничә мисал. Әкияттә: «Ярар. Бу кыз шулай, сандугач тавышына гашыйк булып, сандугачны тотып алу юлын эзли торсын, ә без бу сарайның хуҗасына килик» («Өч күгәрчен»); «Ярар. Егет белән Күңгә күренмәс Сылу-Көмеш шулай бара торсыннар, без карчыкка килик» («Күңгә күренмәс Сылу-Көмеш») һ. б. Әдәбиятта: «Н» карьясенә кайтамыз, хөрмәтле укучыларым. «Н» ханәләре кечек вә саламнан вә бәгъзеләре агач тактасы илә ябылмыш улдыкларыны язмыш идек» («Хисаметдин менла»); «Бу адәмнәремезне шунда калдырып, хикәямезнең башка җәһәтенә тәкмил идәлем» («Бәхетле кыз») һ. б.

Әмма биредә әкият алымына иярү һич тә үзмаксат түгел. Аннан соң мәгърифәтче әдипләрнең әсәрләрендә автор еш кына үзен бермә-бер активрак тота, сурәтләнгән вакыйгалар һәм укучы белән тагын да тыгызрак бәйләнештә торырга омтыла. Әдипнең бу актив позициясе һәм миссиясе әсәрләрдә төрле алымнар һәм чаралар ярдәмендә тормышка ашырыла. Укучылар һәм әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалар белән һәрвакыт тыгыз бәйләнештә булырга, моны адым саен сиздереп торырга тырышудан тыш, авторлар еш кына публицистик чигенешләргә һәм монологларга мөрәҗәгать итәләр. Нәтиҗәдә әсәрләр тирән публицистик пафос белән сугарыла. Татар мәгърифәтчеләре иҗатында публицистик башлангычның көчәюенә китергән тагын бер мөһим сәбәп булса кирәк. Бу уңайдан күренекле рус язучысы А. И. Герценның бер фикере хәтергә килә. Ул болай яза: «Иҗтимагый иректән мәхрүм ителгән халыкта әдәбият вөҗдан һәм ачу авазын ишеттерү өчен бердәнбер трибуна булып тора»[1]. Самодержавие шартларында татарларда да әдәбият әнә шундый функцияне үти. Әдипләргә бер үк вакытта художник та һәм публицист та булырга туры килә. Әсәрләрендәге күп санлы публицистик чигенешләрдә һәм монологларда алар шул чор татар тормышының актуаль мәсьәләләрен күтәрәләр, үзләрен аеруча борчыган уйлары белән уртаклашалар.

«Зур гөнаһлар» романындагы үзәк геройлардан Габделгафурның мәдрәсәдә укуын сурәтләгәндә, З. Бигиев, публицистик чигенеш ясап, Казан мәдрәсәләрендәге тәртипсезлекләрне тәнкыйтьли, аларның

[1] Нәһереннән — елгадан.
[2] Чикенә-йөрез — чигенәбез.

[1] А. И. Герцен. Сочинения, Т. 3, Рус телендә, Мәскәү, 1956 ел, 443 бит.

яшь шәкертләрне акрын-акрын «зур гөнаһларга» китерүләрен әйтә. Аннары кабат Габделгафурга әйләнеп кайтып, аның ничек шушы гөнаһлы юлга басуын сурәтли.

Публицистик чигенешләрдә һәм монологларда З. Һади әле авылдагы наданлык һәм әхлаксызлык күренешләренә борчылуын белдерә, әле мондый күренешләрнең сәбәпләре турында уйлана. Бу сәбәпне автор, мәгърифәтчеләргә хас булганча, башлыча гаилә эчендәге һәм мәдрәсәдәге тәртипсезлекләрдән эзли.

Р. Фәхретдиновның «Әсма» повестенда исә хикәяләүгә әледән-әле милли әдәбият язмышы турында публицистик уйланулар, зур техник казанышларны тудырган кешеләрнең акылына сокланулар үтеп керә.

Мәгърифәтчеләр әсәрләрендәге әлеге чигенешләр һәм монологлар, аларда чагылган фикерләр һәм идеяләр, икенче яктан, аларның «табигый кеше» һәм «табигый тәртип» идеалларына барып тоташа, шул идеалларга һәм теләкләргә сәнгатьчә ирешү максатына хезмәт итә.

«Табигый кеше» һәм «табигый тәртип» идеалларының тормышка ашуын күрсәтүне төп максат итеп кую мәгърифәтчелек реализмы әсәрләренең сюжет-композициясенә дә мәгълүм эз сала. Төп конфликт гаделлек белән явызлыкның бәрелешенә корылып, әсәр мәҗбүри рәвештә гаделлекнең тантана итүен сурәтләү белән тәмамлана. Бу яктан да мәгърифәтче әдипләрнең әсәрләре еш кына халык әкиятенә бик якын тора. Кайчак авторлар бу якынлыкны, бәйләнешне үзләре үк билгеләп үтәләр. Мәсәлән, З. Һади «Яңа әсхабе кәһәф» повестен «Әсхабе кәһәф» исемле борынгы әкияткә ияреп язуын белдерә.

Кабатлап әйтсәк, әкияттә дә, мәгърифәтчеләр әсәрләрендә дә еш кына уртак бер максат алга куела. Ул—явызлык белән көрәштә гаделлекнең җиңеп чыгуын күрсәтү. Геройлар да авторларны башлыча шушы көрәш ноктасыннан кызыксындыралар. Табигый, гадел геройлар белән явыз геройлар бер-берсенә капма-каршы куела, алар арасында нинди дә булса идея яки рухи бәйләнеш булуы мөмкин түгел.

Әкият белән мәгърифәтчеләр әсәрләре арасында байтак уртак моментлар табарга була. Сүз биредә башлыча тылсымлы әкиятләр турында бара. Аларның типик сюжет схемасы түбәндәгегә кайтып кала. Башта гаделлек тарафдарлары булган герой алдына авыр бурыч куела. Ул патша кызын яки үзенең туганнарын явыз көчләрдән (еш кына диюдән) коткарырга, я булмаса дөньяда булмаган әйберләрне табып бирергә тиеш. Шул юлда геройларга һәртөрле тылсымлы көчләр ярдәмгә килә һәм ул үзенә йөкләнгән эшне башкарып чыга. Икенче төрле әйткәндә, тылсымлы әкият сюжетының нигезендә геройны берсеннән-берсе зуррак сынаулар алдына куеп, аның бу сынауларны тылсымлы көчләр ярдәмендә уңышлы үтүен һәм бөтен теләкләренә ирешүен күрсәтү ята.

Тылсымлы әкият сюжетына караган мондый элементлар яки сыйфатлар тегә яки бу дәрәҗәдә мәгърифәтчеләр язган әсәрләрдә дә күзгә ташланалар. Биредә шунысы игътибарга лаеклы: әкият сюжеты мәгърифәтче әдипләр иҗатында үзен елдан-ел ныграк сиздерә бара. М. Акъегет һәм З. Бигиев әсәрләрендә, мәсәлән, әкиятнең аерым детальләрен генә күзалларга мөмкин. «Хисаметдин менла»да баш геройның «гүзәл вә күркәм» Хәнифә белән очрашып танышуы турында хикәяләү әкияттәге кебегрәк сурәтләнсә дә, торабара автор ничектер әкият сюжетыннан читләшә, хикәяләүне үзенчә оештыра.

Көнбатышның, беренче чиратта, француз детектив яки авантюр романнарына ияреп язылганга күрәдер, З. Бигиевнең «Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә»се үзенең сюжет төзелеше буенча башка әсәрләрдән нык аерылып тора. Детективлыкка йөз тотып, автор әкияттән килә торган традицион хикәяләүдән читләшә төшә. З. Бигиевнең «Зур гөнаһлар» исемле икенче романында да детектив әсәргә хас вакыйгалар һәм ситуацияләр үзәк урынны ала. Автор үзе дә аны укучыга «җинаять һәм хөкем эшләре хәленнән алынып язылган гадәттән тыш гаҗәп бер хикәядер» дип тәкъдим итә. Биредә язучы детектив жанр алымнарын мәгърифәтчелек идеяләрен яктыртуга буйсындыра. Әсәрдәге төп мәсьәлә — ул тәрбия мәсьәләсе. Габделгафур образы аша язучы кешенең киләчәк язмышы яшь чакта алган тәрбиясе белән билгеләнә дигән фикерне үткәрә. Әйтергә кирәк, бу фикер башка мәгърифәтчеләрнең әсәрләрендә дә үзәк урынны ала. З. Һади аны («Җиһанша хәзрәт») «су баштан болгана» дигән халык мәкале ярдәмендә чагылдыра. Һәм моңа дәлил итеп Җиһанша хәзрәт язмышын ала. Р. Фәхретдиновның «Әсма»сындагы героиня, бик яшьли ятим калып, тормышта бик күп авырлыкларга очраса да, тугры юлдан читкә тайпылмый. Бу хәлне әдип Әсманың ба-

лачакта әнисеннән дәрес тәрбия алуы белән нигезли. Кыскасы, Габделгафур, Әсма һәм Җиһанша кебек геройларны шушы сыйфат үзара якынайта. Табигый, бу уртаклык, якынлык геройларны сурәтләү алымнарында да сизелә. Аерым алганда, Габделгафур турында хикәяләгәндә әкияттән килә торган алымнар күзгә ташлана. Вакыйгаларның башланып китүе ягыннан «Зур гөнаһлар» «Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә»дән инде шактый аерыла һәм традицион хикәяләүгә якыная төшә. Ул гадәттәгечә герой яшәгән авылны тасвирлаудан башлана, аннары автор Габделгафурның атасы Нәкәс муллага кыскача характеристика биреп үтә. Әкият герое кебек, Габделгафур да туган йортыннан ерак сәфәргә чыгып китә. Ә инде геройның Казан мәдрәсәсенә кергәннән соңгы тормышын сурәтләүгә күчкәч, автор традицион хикәяләү алымнарыннан читләшә һәм акрынлап детективлыкка бирелә. Маһруй язмышын тасвирлаган урыннарда тулысынча детективлык өстенлек итә.

З. Һади, Р. Фәхретдинов һәм Ш. Мөхәммәдов әсәрләрендә исә халык иҗаты йогынтысының тагын да үсә төшүен сиземләргә мөмкин. Бер яктан, бу әдипләр халык мәкальләренә һәм әйтемнәренә шактый актив мөрәҗәгать итәләр. Аларны без бигрәк тә З. Һади һәм Р. Фәхретдинов әсәрләрендә күп очратабыз. Икенче яктан, әлеге әдипләр иҗатында әкият сюжеты алымнары күзгә ташлана. Биредә тагын шунысы игътибарга лаек: Р. Фәхретдиновның «Әсма» повестенда героиня Әсма һәм аның әтисе Габбас язмышлары тылсымлы әкияткә хас алымнар ярдәмендә күз алдына бастырыла. Геройлар тормыш юлларында очраган кыен хәлләрдән яки явыз кешеләрдән, әкияттәгечә, ансат кына котыла баралар. Хаҗга киткән Габбас юлбасарлар тарафыннан әсир ителә. Әмма бераздан ул әсирлектән кача һәм Маскат шәһәренә юнәлә. Анда һич уйламаганда Россия матросларын очрата. Алар арасында мөселманнар да була. Алардан кызы белән хатынының вафат булуы турында ишеткәч, Габбас «хаҗаз тупракларына йөз сөрмәк нияте» белән Мәккәгә китә. Мәккәдә ул үзенең элекке шәкерте Салих байны очрата һәм аның белән туган илгә әйләнеп кайта.

Габбасның кызы Әсма мондый маҗаралы хәлләргә тагын да күбрәк юлыга. Башта ул «адәм башына хәсрәт, милләт өстенә бәла китереп йөрүче» Хәлидә кулына эләгә. Аннары тагын да явызрак Зәйнүш абыстай кулына барып каба. Моннан соң Әсма әле тагын берничә мәртәбә кулданкулга күчә. Әмма ул һәрвакыт кыен хәлләрдән яки явыз кешеләрдән исән-сау котыла. Шушындый маҗаралы язмышларга дучар булган бу геройлар, тылсымлы әкият персонажларыннан тыш, үткәндәге язма әдәбият геройларын да хәтерләтәләр. Әмма монда бер кызыклы момент бар. Көнчыгышның традицион сюжетларына нигезләнгән язма әдәбият әсәрләрендә үзенең сөйгәне белән кавышу юлында герой башта сынауларны уңышлы гына үтсә дә, соңыннан һәлакәткә дучар була. Әхмәт Курмашиның «Бүз егет» һәм «Таһир илә Зөһрә»сен генә искә төшерик. Әлеге әсәрләрдә бер-берсен яратучы геройлар ахырдан һәлак булалар. Р. Фәхретдинов повестенда исә Әсма, тормыш юлында очраган барлык авырлыклардан һәм каршылыклардан котыла килеп, ахырдан әтисе һәм яраткан егете белән кавыша. Күрәсең, үзенең финалы белән «Әсма» повесте тылсымлы әкияткә якынрак тора.

З. Һади һәм Ш. Мөхәммәдовларның повесть һәм хикәяләре бу яктан Р. Фәхретдиновның «Әсма»сыннан шактый аерыла. Бары З. Һадиның «Бәхетле кыз»ы гына «бәхетле» тәгәлләнә. Бер-берсен яратучы Гайшә белән Габбас ахырдан кавышалар һәм бик бәхетле тормыш коралар. Язучының «Бәхетсез кыз», «Мәгъсүм», «Яңа әсхабе кәһәф» һәм «Җиһанша хәзрәт» исемле әсәрләрендә үзәк геройлар фаҗигале язмышка дучар булалар. Бу язмышларны тасвирлау белән бергә, автор геройларны фаҗигага китергән сәбәпләр турында да уйлана башлый. Нәтиҗәдә әдипнең идея-эстетик карашларында үзгәрешләр барлыкка килә. Бу үзгәрешләр барыннан да элек мохит төшенчәсен аңлауда чагыла. Әдипнең мохитны мәгърифәтчеләрчә семья һәм көнкүреш рәвешендә генә түгел, бәлки киңрәк аңлавы, аңа иҗтимагый-социаль характердагы моментларны да кертүе күренә. Бу әсәрендә З. Һади әле нигездә мәгърифәтчелек реализмы позицияләрендә торса да, аның идея-эстетик карашларында инде критик реализм сыйфатлары бөреләнә башлавы күзгә ташлана. Шушындый ук хәлне Ш. Мөхәммәдовның «Япон сугышы яки доброволец Батыргали агай» повестенда да сиземләргә мөмкин. Сәүдәгәр Батыргалинең ялган патриотлыгын фаш иткәндә, бу әсәрдә дә критик реализм чаткылары ялтырап китә.

Мондый фактлар безнең әдәбиятта мәгърифәтчелек реализмы белән критик реализмны кытай стенасы белән аерырга ярамаганлыгын, киресенчә, алар арасында чик баганаларын куюның бик кыен эш булуын күрсәтә. Чөнки, бер яктан, З. Һади һәм Ш. Мөхәммәдов кебек мәгърифәтчеләр иҗатында критик реализм элементлары күренә башласа, икенче яктан, кайбер критик реализм әсәрләрендә мәгърифәтчелек реализмы традицияләренең дәвам итүе күзгә ташлана. Бу хәл яңа позицияләргә күчүнең һич тә үткәнне бөтенләй кире кагу исәбенә бармавы турында сөйли. Киресенчә, мәгърифәтчелек әдәбиятыннан байтак нәрсә критик реализм әсәрләренә күчә. Бу процесс Ф. Әмирхан иҗатында аеруча ачык чагыла. Барыннан да элек, аның әсәрендә мәгърифәтчеләрнең төп идеяләре — дини фанатизмга һәм кадимчелеккә каршы көрәш, рус һәм Европа культурасына йөз тоту, хатын-кыз ирекен яклау, мәгърифәткә дан җырлау һ. б. үзәккә куела. Чөнки бу идеяләр критик реалистлар иҗат иткән чорда да татар тормышында үзләренең актуальлекләрен югалтмаган булалар.

Ф. Әмирхан мәгърифәтчеләр эстетикасыннан да актив файдалана. Бу бигрәк тә геройны тасвирлауда ачык күренә. Мәсәлән, «Фәтхулла хәзрәт»тә уңай һәм тискәре геройларны сурәтләү принциплары, һичшиксез, мәгърифәтчелек әдәбиятыннан килә. Аерым алганда, бу яктан «Фәтхулла хәзрәт» белән «Җиһанша хәзрәт» арасында шактый зур аваздашлык сизелә. «Хәят» повестенда исә героиняның характеры мәгърифәтчеләргә хас рационалистик рухта тасвирлана. Хәят тәрбия җимеше һәм, беренче чиратта, семья тәрбиясе җимеше булып тора. Бу яктан автор аны рус кызы Лиза белән чагыштырып күрсәтә. Алар икесе ике төрле тәрбия алалар һәм бу хәл кызларның бөтен табигатенә һәм дөньяга карашларына тирән эз сала. Гимназиядә укып, рус әдәбияты белән якыннан танышу Лизаның «җанына нәрсәдер эзләнү оеткысы» сала. һәм ул үз-үзен шактый мөстәкыйль тота торган шәхес булып үсә. Мәликә абыстайда укыган Хәят исә «каршы сөйләү һәм шик итүне күтәрми торган» затка әверелә. Аннан соң героиняларга семьядагы тәртипләр җитди йогынты ясый. Әгәр Лизалар семьясында «һәркемнең үз теләге, үз тойгылары бик күп урында, бик күп нәрсәләрдән алда» тотылса, Хәятләр йортында инде «һәр кеше, үз теләге вә үз тойгыларына буйсынудан бигрәк, борынгыдан эшләнеп килгән кагыйдәләргә буйсынырга, вә шулар билгеләп куйган юлдан чыкмый барырга» тиеш була. Мәгърифәтчелек реализмыннан килә торган мондый сыйфатларны Ф. Әмирхан әсәрләреннән тагын да китерергә мөмкин.

Кыскасы, XX йөз башы татар әдәбиятында кайда мәгърифәтчелек реализмы тәмамланып, кайда критик реализм башлануын өзеп кенә әйтүе кыен. Чөнки анда бу ике методның сыйфатлары еш кына үзара бәйләнгән хәлдә яшиләр. Әйтергә кирәк, мондый хәл рус әдәбиятына да хас була. Рус әдәбият белемендә бу шул замандагы экономик һәм иҗтимагый-политик үсеш үзенчәлекләре белән бәйләп аңлатыла. Мәсәлән, Көнбатыш Европадагы күп кенә әдәбиятларда төрле методларның чикләре ачык булуның төп сәбәбен галимнәр ул илләрдә иҗтимагый формацияләрнең бер-берсен җитлеккән хәлдә алыштыруларында, шуңа күрә алар арасындагы чикләрнең бик ачык тәсмерләнүендә күрәләр. Россиянең экономик һәм иҗтимагый-политик үсеше исә башкарак шартларда бара. Әйтик, XIX йөзнең уртасыннан ул ныклап капитализм юлына басса да, рус җәмгыятендә әле феодализм калдыклары да көчле була. Бу хәл рус әдәбиятында төрле методларның чикләре Көнбатыштагыча ачык булмауга, киресенчә, аларның бер-берсе белән тыгыз мөнәсәбәттә торуларына китергән.

XX йөз башында татар тормышы иҗтимагый-политик яктан тагын да чуаррак һәм буталчыграк була. Капиталистик тәртипләр һәм массаларның революцион хәрәкәте үскән бер вакытта иске феодаль-патриархаль тәртипләр дә үз позицияләрен бирергә җыенмыйлар иде әле. Нәтиҗәдә шул чордагы татар әдәбиятының идея-эстетик йөзе дә бик чуар һәм буталчык төс ала. Конкретрак әйтсәк, безнең ул дәвердәге әдәбиятта методлар алмашыну аларның бер-берсен тулысынча инкарь итү һәм кире кагулары аша түгел, бәлки берсе икенчесенә таяну, яңаның искедән актив рәвештә файдалануы аша барды.

Заман тормышы татар прозасының жанрларына да җитди эз сала. Биредә бер нәрсә күзгә ташлана: М. Акъегет белән З. Бигиевтән соң байтак вакытлар бездә романнар күренми тора. Дөрес, роман язуга әледән-әле омтылышлар ясала, ләкин алар еш кына тормышка ашмый калалар. Аннан соң М. Акъегет белән З. Би-

гиев әсәрләре дә, гәрчә авторлар аларны «роман» дип атасалар да, чынлыкта бу жанр таләпләренә тулы җавап бирүдән ерак торалар. «Хисаметдин менла»ның хәзер еш кына повесть дип йөртелүе бер дә очраклы түгел. Моңа охшаш күренешләр белән без шул чордагы рус прозасында да очрашабыз. Анда да XX йөз башында роман язарга алынып та, бу эш я хыялда гына калган яисә тәгәлләнмәгән очраклар еш була. Икенче яктан, рус романын тикшерүчеләр «гасырның ахырына якынлашкан саен монументальлектән читләшү тагын да ачыграк күренүен, бу хәрәкәтнең торган саен күбрәк язучыларны үз эченә алуын, аның хәтта монументаль формаларның иң зур остасы Л. Толстой иҗатында да чагылуын»[1] әйтәләр. Дөрестән дә, XIX гасырның 80—90 елларында Толстой иҗатында кече жанрлар — повесть һәм хикәя өстенлек итә. Рус прозасында кече формаларның хакимлеге XX йөз башында да дәвам итә. Әдәбиятчылар бу хәлне ике фактор белән бәйләп аңлаталар. Бердән, рус прозасы бу чорда заман тормышына йөз белән борыла, аның яңа таләпләренә оператив рәвештә җавап бирергә омтыла башлый. Икенчедән, әдәбиятның жанр табигатенә шул тарихи чор үзе җитди эз сала. Мәгълүм ки, XX йөз башы — Россия тормышында тирән революцион кузгалышлар белән бәйләнгән күчеш дәвере ул. Һәм бу чор җәмгыять үсешенең бермәбер катлаулануы һәм хәтта буталчык төс алуы белән аерылып тора. Табигый, бу дәвер тормышын сәнгатьчә аңлау һәм аның турында, роман жанры таләп иткәнчә, бөтен бер мәгънә бирү эше дә шактый кыенлаша. Ул чынбарлыкны гомумиләштерүдән битәр, анализны, ныклап өйрәнүне, ачыклауны сорый.

XIX гасыр ахырындагы һәм XX йөз башындагы татар прозасында кече жанрларның өстенлек итүенә дә шушы факторлар сәбәпче булган, күрәсең. Бу чорда прозаиклар күбрәк повестька игътибар итәләр.

Мәгърифәтчелек реализмыннан критик реализмга күчү татар прозасының һәм эчтәлегендә, һәм формасында мөһим үзгәрешләр китереп чыгара. Бу чорда әдәби иҗатның җирлеге шактый яңара. Әгәр мәгърифәтчеләр, Г. Ибраһимов әйткәнчә, «күбрәк мулла-мәзин белән, озаклап чәй эчә торган кадим фикерле карт-коры белән, иске-яңа хәлфәләр, яхшы-начар остабикә белән, иске-яңа сәүдәгәрләр белән»[1] эш итсәләр, хәзер исә әдипләр акрынлап җәмгыятьнең нигез көчләренә — эшче һәм крестьян массаларына йөз белән борыла баралар. Шул ук вакытта әдәби иҗатның тормышны танып-белү көче үсә, ул заман чынбарлыгын бөтен катлаулылыгында чагылдырырга омтыла башлый. Бу хәл, үз чиратында, әсәрләрнең эчке структурасы катлаулана төшүгә китерә. Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» һәм «Безнең көннәр»е, Ш. Камалның «Акчарлаклар»ы бу мөһим үзгәрешләрне үзләрендә аеруча ачык гәүдәләндерделәр. Реалистик роман һәм повесть жанрларын үзләштерү юлында иң кызыклы адымнар булу белән бергә, бу әсәрләр татар әдәбиятында критик реализмның җитди уңышларын да тәшкил итте.

[1] История русского романа. Т. 2, Рус телендә, 1964 ел, 350 бит.

[1] Г. Ибраһимов, Әдәбият мәсьәләләре, 141 бит.

# ТЫЙНАК ГЕРОЙЛАР

Бөек Ватан сугышы темасы татар совет әдәбиятында киң яктыртыла. Совет солдатының батырлыгын, аның героик характерын төрле яклап ачып бирү әдәбиятыбызның гүзәл традициясенә әйләнде. Язучыларыбыз совет солдаты батырлыгының чыганакларын билгеләү, психологик анализ ярдәмендә аның күңел байлыгын ачу өлкәсендә шактый эш башкардылар. Байтак әсәрләрдә, мәсәлән, Г. Әпсәләмовның роман һәм повестьларында, башлыча, баталь картиналар тасвирлана. Аның геройлары алгы сызыкта сугышалар, үлем лагерьларында дошман белән аяусыз көрәш алып баралар. Алар зур масштаблы эшләр башкарырга сәләтле кешеләр. Дәһшәтле көрәш кырында халку гәүдәләндерелгән геройлар белән рәттән, кайбер язучылар фронтның көндәлек тормышында үз бурычларын намус белән үтәүче, тыйнак эшчәнлекләре белән бөек җиңү эшенә хәлдән килгәнчә өлеш кертүче солдатларны тасвирлыйлар. Бу яктан Әмирхан Еники әсәрләре аерым бер урын алып тора. Язучы үзенең хикәяләрендә турыдан-туры сугыш картиналарын бирми. Аның «Бала», «Бер генә сәгатькә», «Кунакчыл дошман», «Кем җырлады» һәм башка хикәяләрендә сугыш темасы үзгә төрле яклары белән яктыртылды. Әмма язучының моңарчы Бөек Ватан сугышына багышланган күләмле әсәр биргәне юк иде әле. Олы әдиптән укучылар, әлбәттә, мондый әсәрне көттеләр һәм ялгышмадылар.

Язучының «Без дә солдатлар идек» повесте дөньяга чыкты[1]. Повесть дип аталса да, «Фронт дәфтәреннән» дигән искәрмә аны мемуар әсәрләргә якынлаштыра.

Китапта автор унбиш кешелек каравыл взводының көндәлек тормышын тасвир иткән. Взвод турыдан-туры сугыш хәрәкәтләренә катнашмый. Алгы сызыкта да түгел. Алар тормышында алгы сызыкка хас булган вакыйгалар да юк, зур геройлыклар да күрсәтмиләр кебек. Взвод бары тик боеприпас складлары янында каравыл хезмәтен үти, посттан бушаган араларда снарядларны машинага төяп тора.

Бер караганда, мондый хезмәт җиңел дә кебек. Ләкин бу беренче карашка гына. Солдатларның үзләре, көндәлек хезмәтләре һәм яшәешләре белән якыннанрак танышкан саен, без алар җилкәсенә төшкән сугыш йөгенең никадәр авыр булуын аңлый барабыз. Автор укучы алдында акрынлап бу карусыз, сабыр кешеләрнең хезмәтләрен, яшәү рәвешләрен, эчке дөньяларын ача. Гаҗәеп бер интернациональ семья ул взвод. Монда хезмәткә алынган казакълар Өметбаев, Байәхмәтов, үзбәк Ишмәмәт, руслардан Шумилов, сугышта яраланган һәм «нестроевой булып фронтка кире кайткан солдатлар» Хафиз Акшалов, Дорды Ходайбирдин, татар Тәхфәт абзый, чуваш Емелькин һәм башкалар бар. Һәрберсе үз йөзләрен, гадәт-холыкларын саклаган хәлдә, алар аерылмас бербөтенне тәшкил итәләр.

Взвод һөҗүм итүче армия артыннан бара. Әсәрдә бәян ителгән вакыйгаларда ул Латвия җирендә була. Бирегә халык хутор булып яши. Шуңа бәйле, автор совет кешесенең коллективист булуын, колхоз строен үзенеке итеп кабул итүен кечкенә генә эпизодта ышандырырлык итеп бирә алган.

«Чын гаҗәпләнү белән солдатлар:

— Боларны колхозга ничек оештырырлар икән?— диештеләр.— Барысын да бер урынга җыярлар микән?

Билгеле, алар фикеренчә, бу җирләргә яңадан Совет власте кайткач колхоз да булачак, булмый калуы мөмкин түгел».

[1] Ә. Еники, Без дә солдатлар идек, Татарстан китап нәшрияты, 1973 ел.

Менә шушы коллективизм хисе төрле милләт солдатларыннан торган взводны бергә туплый, бер гаиләдәй яшәтә дә инде. Ләкин сугышчан бердәмлекне сурәтләгәндә Ә. Еники һәр кешенең үзенә күрә бер аерым, үзенчәлекле характер икәнлеген зур осталык белән күрсәтә.

Менә «Ишмәмәт мөлдерәп туларга торган күзләре белән миңа моңсу елмаеп кына карый. Бик тә нечкә, йомшак бәгырьле кеше ул безнең Ишмәмәт. Чак кына җылырак сүз әйтсәң, әнә шулай эри дә китә... Әмма үзе бик чыдам, бик күндәм, кая гына куйсаң да тора һәм алты сәгать түгел, ун сәгать тора ала, тавышын-тынын чыгармый».

Менә гаҗәеп нечкә күңелле Төхфәт абзый. Малай чагында әтисе җырлаган «Агач башы» көен хәтерләп җырлый. «Хәер, язмыш кешене кайларга гына ташламасын, күкрәгендә шул бер йөрәкне йөртә инде ул». Бу эпизод кешенең үз иленә, халкына, аның рухи хәзинәсенә мәхәббәт белән каравын, аңа никадәр тугры булуын күрсәтә.

Менә тиктомалга кызып китүче чуваш Емелькин. Ул куян тоту турында да зур нәрсә итеп сөйләргә ярата.

Менә «төш күрергә» һәм аны юрарга яратучы зур-таза гәүдәле казакъ Байәхмәтов. «Ул инде төшендә Сталинны да берничә тапкыр күрде, Рузвельтны да күрде, хәтта Гитлерны да күрүдән курыкмады». Казакъ солдатлар төш күрүнең тәмен беләләр, чөнки шуңа карап сугышның кайчан бетәсен, күпмегә сузыласын юрыйлар.

Тыныч шартларда, устав буенча, солдатлар постта икешәр генә сәгать торалар. Әмма сугыш уставның бу таләбе белән исәпләшми. Кеше җитешмәгәнлектән, карт солдатлар «көзге караңгы төннәрдә дә, кышкы салкын бураннарда да» алтышар сәгать тора. Шуның өстенә, складларны алгы позициягә күчергәндә, посттан азат солдатлар вагон бушаталар, машина төйиләр. «Ә боеприпас дигәнең ул әрҗәләргә тутырган конфет түгел, боеприпас ул тимер дә корыч, аларның (мәсәлән, авыр снарядларның) берсе-берсе сиксән кило тартканнары бар, абзыкаем! Менә шуларны инде безнең гарип-гораба солдатларыбыз кара тиргә батып, көчәнә-көчәнә күтәреп төшерә яки күтәреп мендерә». Ә аннан соң солдат постка китә. Чөнки шулай кирәк. Җиңү өчен кирәк.

Әмма хезмәт никадәр авыр булмасын, сугыш кешенең бәгырен никадәр генә туңдырмасын, кеше һәрвакыт кеше булып калырга тиеш. Ишмәмәт белән Емелькин шул турыда бәхәсләшәләр. Емелькин постта торганда куянны атарга җыенган. Ишмәмәт: «Җан иясен үтерергә ярамый, гөнаһ булады кү...»— ди. Бу сүзләргә артык кызып киткән Емелькин турында ул: «Минаның кальбен аяп әйтәм, кальбе ташка әверелмәсен...»— дип кисәтә.

Повесть битләрендә Ә. Еникигә хас юмор да үзенә урын таба. Ял вакытларында солдатлар икенче фронт ачуны кичектереп килгән союзниклар адресына да ачы сүзләр әйткәлиләр. Менә Емелькин посттан кайткач ашарга утыра.

«Рәхмәт төшкере, бүген дә борчак икән, — диде.— Каян алып җиткерәләр бу борчакны, әллә Әмерикәдән килә инде?! Солдатлар көлешеп алдылар. Арадан берсе: — Юк, булмас, — диде. — Борчак Американың үзенә дә җитми торгандыр...

— Нишләп?

— Нишләп дип, моңарчы бит алар немецка каршы борчак кына атып яттылар».

Ә. Еники саф күңелле, тырыш, чыдам казакъ агайларның коллектив портретын бирә. Менә алар, посттан бушаган арада, латыш хуторыннан бер сарык сатып алып «казакъча бер мәҗлес кылып» утыра. Ә. Еники бу мәҗлесне бөтен нечкәлекләренә кадәр тасвирлый. Биредә казакъ халкының кунакчыллыгы, олыларга хөрмәт белән каравы һәм башка гүзәл милли сыйфатлары ышандырырлык итеп күрсәтелә.

Взводка йөкләнгән вазифалар боеприпаслар склады янында каравыл тору белән генә чикләнми дип әйткән идек инде. Ә. Еники, киеренке ситуацияләр сайлап, солдат характерының яңадан-яңа якларын ача, аларның батырлыкларын сурәтли. Алты солдат һәм бер сержант боеприпаслар эшелонын алгы сызыкка озатырга билгеләнәләр. Авыр снарядлар, төрле сугыш кирәк-яраклары белән тыгызлап тутырылган эшелон немецлар тупка тоткан урынны үтәргә тиеш. Боларның барысын да һавага очыртырга бер снаряд кыйпылчыгы җитә. Бу участокта күпне күргән Дорды кебек солдатлар да бераз шикләнәләр. «Иптәшләр, җаннары учларында булса да, болай тып-тыныч кына утыралар. Тик Байәхмәт кенә авыз эченнән үгез шикелле һаман нидер мөгрәнә — белгән догаларын укып маташа, ахрысы. Кемдер әледән-әле тамак кыргалый, Емелькин булса кирәк, снаряд төшеп шартлаган саен: «Ух, гад!» — дип куя. Ә менә Ишмәмәтнең бе-

тенләй өне-тыны юк, бу галәмәт башланганнан бирле шулай тавышын чыгармый».

«Чынлабрак уйлаганда безнең хәл искиткеч мөшкел иде, без кыл өстендә, без һәлакәтнең өстендә генә торабыз...» Куркынычны үз эчләреннән генә кичергән солдатлар тыштан тып-тыныч. Кинәт паникага бирелгән Шанаевка иярү генә түгел, аны үзләре үк тынычландыралар. Иң куркыныч минутларда алар иңгә-иң торалар: «...солдат психологиясенең гаҗәеп бер сере бар — нәкъ менә иң куркыныч, иң киеренке чакта ул иптәшләреннән аерылырга һәм теләсә кая ташланырга яратмый», — ди автор.

Шулай итеп, интернациональ взвод тагын бер сугышчан заданиене үти — эшелонны исән-сау билгеләнгән пунктка илтеп җиткерә. Рус, татар, чуваш, кыргыз, казакъ солдатлары арасындагы дуслык, туганлык мөнәсәбәтләре аларга авыр солдат хезмәтен җиңеләйтергә булыша. Үзара ярдәм, сугышчан туганлык һәрвакыт күп милләтле Совет Армиясенең рухи көч чыганагы булды. Унбиш кешелек хәрби коллектив тормышында да бу бик ачык чагыла.

Шулай тәрлесен күреп, уттан-судан үтеп, солдатлар җиңү юлы буйлап баралар. Җиңүгә үзләреннән өлеш керткән каравыл взводы солдатлары.

Автор үзе Тукай клубында ясаган бер чыгышында «Без дә солдатлар идек» повестен гади итеп язарга тырышуын әйткән иде. Ләкин әсәр тыштан караганда гына гади тоела. Повестьның көче — аның эчке агымында. Әсәрдә сурәтләнгән һәр характер зур эстетик мәгънә алып килә.

**Р. САЛИХОВ.**

# РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИН ПОВЕСТЬЛАРЫ

Татарстан китап нәшрияты Рафаил Төхфәтуллинның илле еллыгына туры китереп хикәяләр һәм повестьлар җыентыгын туплап чыгарды[1]. Китапка бер нәсер, ике хикәя, өч повесть («Авылдашым Нәби», «Йолдызым», «Агымсу») кергән. Бу әсәрләр, бигрәк тә укучыларга яхшы таныш булган повестьлар, үзенчәлекле каләм остасының иҗади йөзен шактый тулы чагылдыралар. Биредә без тик «Тамчылар ни сөйли» исемле повесть-поэманы гына күрмибез. 1965 елда ул аерым китап булып чыккан иде. Кыскасы, җыентыктагы повестьларны күздән кичереп, әдип иҗатына хас булган кайбер сыйфатларны билгели алабыз. Китапта урнаштырылган сүз башы да бу бурычны беркадәр җиңеләйтә төшә. Ул «Ир язмышы — ил язмышы» дип атала. Тәнкыйтьче Фәрвәз Миңнуллин тарафыннан язылган. Мәкалә, җыйнак кына булса да, укучыларны җитәкләп ир уртасы әдипнең образлар дөньясына алып кереп китә, прозаның характерлы яклары белән таныштыра. Без дә, күз җиткән кадәр, кайбер үзенчәлекләренә тукталып китик.

Р. Төхфәтуллин каләменә поэзиядәге кебек, уй-хисләр муллыгы, лирик ягымлылык, йомшак лиризм хас. Шуның белән бергә, Р. Төхфәтуллин әсәрләрендә бу хисчәнлек кичерешләр тыйнаклыгы аша чагыла. Бу җәһәттән аның прозасы С. Хәким поэзиясен хәтерләтә. Р. Төхфәтуллин да күңел дөньясын ачканда турыдан ярмый, бик сак эш итә, еш кына фикерен әйтеп тә бетерми, тик художество чаралары белән ишарә ясап, сиздертеп кенә куя, укучының уйлау, анализлау, күз алдына китерү, нәтиҗә ясау сәләтенә таяна. Ләкин мондый тыйнаклыктан, саранлыктан рухи дөнья һич тә ярлыланып калмый, киресенчә, хисләрнең олылыгы, кадерле-якын булуы, аларга бик сак кагылырга кирәклеге аңлашыла. Р. Төхфәтуллин бик тирәндә, күңел түрендә яшеренеп яткан хисләрнең тыйнак тибрәнешен укучы йөрәгенә барып җитәрлек итеп сурәтли белә. Аның прозасында поэмаларга хас булган лирик чигенешләр дә әһәмиятле урын ала.

Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир, Габдрахман Әпсәләмов романнарында без Бөек Ватан сугышы елларының кайнар сулышын, каты көрәш дәверенең киеренке-катлаулы хисләрен тоябыз. Рафаил Төхфәтуллин да илебез тормышындагы билгеле бер чорның уй-фикерләрен, билгеле бер катлау кешеләренең тойгы-кичерешләрен сурәтли. Ул башлыча сугыш һәм сугыштан соңгы елларны, ягъни үз буынының йөрәге аркылы үткән дәверне, шул вакыттагы авыл тормышын гәүдәләндерә, игенчеләрнең яки бу-разнадан производствога, нефтькә килгән

[1] Хикәяләр һәм повестьлар. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1973 ел.

гади хезмәт кешеләренең рухи матурлыгын күрсәтеп бирә.

«Авылдашым Нәби» повестеның баш герое югары җитәкче постлар да биләми, бүгенге әдәбият-сәнгатьтә, җырларда мактала торган романтик профессия кешесе дә түгел. Ул — колхозда атлар караучы. Хәзер инде колхозларда бу профессия үзе үк бетеп бара. Төс-кыяфәткә дә чын ясау түгел. Өстәвенә, бер күзе дә зәгыйфь. Ләкин шулай да без аны яратабыз, якын, кадерле ул безгә. Гомер-бакый җәмгыятьне туйдырып килгән игенче хезмәтен күңел биреп башкаруы, колхоз өчен көчен аямавы, коллектив җанлы булуы, шәхси бәхетне ил уңышлары белән бәйләнештә каравы, күркәм сабырлыгы якынайта аны безгә. Нәби үзе дә эшкә сәләтлелекне, булдыклылыкны бик олылый, югары куя. Кешеләрне ул эш белән сыный, уңганлыгына карап бәя бирә.

Повестьның рухын билгеләүдә Нәби характерының тагын бер ягы, кереш сүзендә Фәрваз Миңнуллин әйткәнчә, «хисләренең сафлыгы, тирәнлеге» бик мөһим роль уйный. Автор шушы гади хезмәт кешесенең олы тойгыга сәләтле булуын, гомер буена аңа кер кундырмый саклавын күрсәтә. Яшьлегендә Нәби Зөһрә исемле гүзәлне күреп гашыйк була. Ләкин аңа өйләнә алмый, чөнки бу вакытта инде ул үзенең тормышын башка берәү белән бәйләгән була. Мәхәббәт, сагыш һәр әсәрдә диярлек урын ала. Бирядә исә аның повесть сюжетына ясаган йогынтысын күздән кичерү кызыклы. Әдәбият практикасында сюжет җебен, вакыйганы тудырган сәбәпне озак кына яшереп бару еш очрый. Ул җеп очы гадәттә нинди дә булса мөһим вакыйгадан үрелгән була. «Авылдашым Нәби» повестенда исә ул функцияне кешенең психологик халәте башкара. Әсәрнең ахырына кадәр автор Нәбинең әлеге бер үк вакытта газаплы да, ләззәтле дә булган мәхәббәт тойгыларын, моннан килеп чыккан эчке драманы яшереп бара, ара-тирә моңа тик береэ ишарә ясап кына үтә.

«— Аккош ярыннан калса, таш кыяга атылып төшеп, башын да бетерә әле,— дип кенә куя Нәби үзе дә».

Менә бу тирән хис, әсәрнең ахырына кадәр яшерелеп килгән тойгы, мавыктыручанлык функциясен башкару белән бергә, сюжет үсеше дәвамында үзенә бертөрле моң булып агыла, вакыйгаларга мәгънәлелек өсти, геройлар күңелен, шул ук Нәбинең, аның тормыш иптәше Сәрвәрнең рухи дөньясының башка бик күп катлаулы яклары ачарга мөмкинлек бирә. Нәбинең чын гүзәллекне әнә шулай олылавы, изге, мөкатдәс дип санавы, башкалардан да шундый ук олылау таләп итүе, хәтта бу мәсьәләдә нечкә хискә пычрак куллар белән тыгылучы өшәкә бәндәләр белән җитди бәрелеш-конфликтка да керүе бездә соклану тудыра. Кеше күңелендә матурлыкка, гүзәллеккә никадәр зур һәм хөрмәтле урын саклануын күрсәтә.

Шул ук вакытта Нәби үз характерындагы икенче бер даими сыйфат — семьясына, тормыш иптәшенә турылыклы булуы белән дә укучыда тирән ихтирам уята. Ул, таңга калдырырлык, акыл җуйдырырлык матурлыкны зурлаган хәлдә дә, семья мөнәсәбәтләренә бервакытта да күләгә төшерми. Хәтта хатыны гүр иясе булгач та хисләр сафлыгына кер кундырмый, мәрхүмә күңелен рәнҗетердәй сүз әйтүдән дә саклана.

«— Юкса, болай бит... Сәрвәр апагызның рәнҗеп ятуы бар. Ни генә әйтмә, болай әйбәт тордык, ачысын-төчесен бергә татып гомер иттек...» — ди. (87 бит.)

Автор Нәбине үтә дә бала җанлы итеп сурәтли, икенче балалары туу ихтималын белгәч, ул бөтенләй үзгәрә, «бу вакытта аның сыңар күзе һәм күз кырыйларындагы ваквак җыерчыклары болай гына карауга күреп тә булмый торган эчке бер бәхетле елмаю белән балкый, хәтта авыз эченнән генә ишетелер-ишетелмәс ниндидер бер көй дә кузгалып куя иде». (55 бит.)

Картаймыш көнендә ул олы мәхәббәтнең балалар күңелендә дәвам итүенә куанып яши, бәхетне әнә шунда күрә: «Менә бит ул бәхет дигәнең...» (88 бит.)

Сәрвәрдә исә Нәбинең хис-мөнәсәбәтләре башка төрле кичерешләр кузгата. Сугыш нәтиҗәсендә тол калган чит хатыннар аның бәхетенә, гаиләсе бөтен булуга кызыгып карыйлар.

«— Бигрәк тә изге сәгатьләрдә кавышкансыз икән, Сәрвәр җаным... Без генә инде менә шулай корырбыз»,— диләр. (41 бит.)

Ләкин автор шушы тышкы иминлеккә эчке драманы контраст китереп куя. «Нәби үзе янда булган белән дә... күңеле башкада булгач...»

«— Сылудыр шул... Зөһрәсе,— диде. — Без генә менә шулай бер сөйкемсез сөяк булдык инде, улым». (39 бит.) Сәрвәрнең бу сүзләрендә сабырлык та, эчке әрнү дә ишетелә.

Әнә шулай, әсәргә үзенә бер төрле моң сибеп бара торган мотив геройлар психи-

касын шактый тирәнтен һәм күп яклап яктыртырга мөмкинлек бирә.

Нәбинең рухи дөньясы турында сүз алып барганда, бер принципиаль мәсьәләгә кагылмый үтеп булмый. Ул да булса аның интеллектуаль байлыгы. Юньле-башлы белеме дә булмаган кешегә карата «интеллектуаль байлык» төшенчәсе урынсыз күренүе ихтимал. Андый хәзинәне күп кенә әсәрләрдә сурәтләнгән белем иясләрендә дә еш күрмибез бит әле. Ләкин шулай да без андый төшенчәне Нәбигә һәм әдипнең башка геройларына карата кулланырга булдык. Автор Нәбинең фикерле булуына, уйлануына, күзәтүчән, тормыш турында фикер йөртүчән, төпле нәтиҗә чыгаручан булуына басым ясый. Ул, мәсәлән, сугыштан соңгы елларда хуҗалыкны үстереп җибәрердәй реаль чаралар күрәсе урында кайбер район вәкилләренең бушка шапырынуларына, игенчеләрдән нигезсез антлар бирдертүләренә каш җимереп карый. Төптән уйланырга, киңәшергә, реаль чаралар турында фикер йөртергә кирәк дип саный. «Акылга акылны куша торгач, чын бер акыл килеп чыгар иде»,— ди. (43 бит.) Нәбидә, системалы гыйлеме булмаса да, халык акылы, халык зирәклеге тупланган.

Р. Төхфәтуллин геройлары, гади колхозчылар, эшчеләр, еш кына иҗади эзләнәләр, тормыш күренешләрен анализлыйлар, якын һәм ерак киләчәкнең үзләренчә реаль һәм фантастик картиналарын төзиләр. Р. Төхфәтуллин үзенең геройлары теленнән шактый житди, мөһим фикерләр әйттерә.

Бу җәһәттән «Агымсу» повестенда сурәтләнгән нефть остасы Борһан ага сүзләре, кешенең табигатькә якынлыгы, ясалма рәвештә аны табигатьтән аеруның тискәре нәтиҗәләре турындагы фикерләре (377—378 битләр) игътибарга лаеклы.

Шул ук вакытта автор кайбер район җитәкчеләренең, ягъни халыкны җитәкләрлек үткен зиһенле булырга тиешле бәгъзе кешеләрнең гамәлдә, киресенчә, тик кушканны гына формаль үтәүләрен тәнкыйтьли.

Кыскасы, геройларны характерлауда интеллект дәрәҗәсе шактый әһәмиятле роль уйный. Моннан бер нәтиҗә. Әгәр дә интеллектуаль зирәклек башлыча физик хезмәт кешеләренең рухи дөньясын да шулай матур итеп бизи икән, акыл хезмәте әһелләрен сурәтләүче әдипләр алдына бу өлкәдә тагын да зуррак бурычлар килеп баса, әдәби практика интеллектуаль дөньяны ачуның зур мөмкинлекләре булуын раслый. Табигый, моның өчен беренче нәүбәттә әдипнең үзенә, җәмгыятьнең рухи тәрбиячесенә, фикер иясе булу кирәк.

Инде Р. Төхфәтуллин прозасында геройларның психологик анализына тукталып үтик. Фәндә-тәнкыйтьтә, иҗат практикасында моңа әле төрле мөнәсәбәт яшәп килә. Кайбер тәнкыйть хезмәтләрендә, мәсәлән, әсәр геройларының үз рухи дөньяларына, күңел омтылышларына контроль ясамаулары аларның уңай сыйфаты дип бәяләнә. Р. Төхфәтуллин концепциясе бу мәсьәләдә беркадәр аерыла төшә. Аның геройлары өчен үзләренең күңел тормышы, рухи халәте һәр вакытта да иркен-мәшәкатьсез үтеп керерлек, ачык дөнья булып кала. Аны күрер өчен интегеп казыну-чокыну да таләп ителми, тик рухи тибрәнешләр, зирәклексизгерлек кенә кирәк. Р. Төхфәтуллин үзенең геройларын психологик зирәк итеп, үз күңелләрендә нәрсәләр кайнаганлыгына хисап бирерлек итеп сурәтли. Тормышта без производство максатлары, бурычлары белән, шуны уңышлы үтәү өчен барган көрәшләр белән көн саен очрашып торабыз, максат куюның, шуңа ирешүнең нәрсә икәнен ачык беләбез. Андый бурыч-максатларны, үсә төшкәч, «Агымсу»дагы Хәйдәр дә куя. Шуның белән бергә ук Хәйдәр үзалдына икенче бер максат та куя — характерын яхшырту, камилләштерү, ботак-сатаклардан арындыру. Ул, яшь чагында егылып имгәнгән малай, физик һәм рухи яктан көчле булырга омтыла. «Күңелең китек, эчең ялкын булса да, иптәшләрең алдында сер бирмә, үзеңнә көчлеләрдән дә көчлерәк итеп хис итә һәм күрсәтә бел икән!» — дип уйлый. (278 бит.) Мәхәббәт, гашыйк булу рухи үсеш теләген тагын да көчәйтеп җибәрә. Ул һәр яктан, шул исәптән күңел байлыгы һәм матурлыгы белән дә сөйгәненә тиң булырга тырыша: белемен күтәрә, тырышып музыка өйрәнә, вузга керергә әзерләнә. Бу өлкәдәге үзгәрешләрне ул даими күзәтү астында тота. Анда эчке анализ, үз характерын, эш-гамәлен, психик халәтен анализлау көчле. Автор аны «эчке контроль», «эчке хөкем» дип атый.

«Шулай да эчке контроль дигән нәрсә кинәт кенә сорап куя:

— Җә, Надяны лаеклы каршылау өчен көчеңнән килгәннең барысын да эшләдеңме соң әле? Тиң була алырсыңмы син аңа?

Күңел шунда ук җавап бирә:

— Алдашасың юк, чын-чынлап көчле кеше булырга ерак әле сиңа. Төптәнрәк уйлый-хисаплый башласаң, һаман да мәгънәсезгә үткән вакытың күпме... характерында

да үзгәрешләр, ай-һай, бик аз сизелә...» (364 бит.)

Эчке хөкем, шулай итеп, геройга масаерга ирек бирми, кылган гамәлләреннән сабак алуны, нәтиҗә чыгаруны таләп итә.

Менә шушы эчке контроль, психологик анализ герой характерының динамикасын бик ачык итеп күз алдына китерергә булыша. Хәйдәр производство өлкәсендә генә үсми, эчке яктан да үзгәрә. Ә характерны динамикада күрсәтү — ул матур әдәбиятның мөһим таләпләреннән берсе.

Бу мәгънәдә хикәяләү формаларының да очраклы гына сайланмаганлыгы күренә. Р. Төхфәтуллин иҗат иткән дүрт повестьтан тик берсе — «Тамчылар ни сөйли» генә автор исеменнән хикәяләнә, анда да әле барлык вакыйгалар да баш герой карашыннан үткәреп бирелә, ә калганнары һәммәсе дә герой авызыннан сөйләтелә: «Авылдашым Нәби» — журналист исеменнән хикәя ителә, «Йолдызым» — Гөлзифа истәлекләренә, «Агымсу» — герой дәфтәрләренә корылган, ягъни вакыйгалар турында сөйләү дә, күңел дөньясын тасвирлау да герой кулына тапшырылган.

Ләкин гаҗәп хәл: үз геройларының эчке контролен шулай ышандырырлык, такт белән сурәтләгән язучы бер урында, героеның күңел дөньясын характерлаган чагында, сәер генә психологик төгәлсезлек җибәреп куя. Гөлзифа турында ул, өлкән әдипкә охшатыбрак, болай ди: «Моңарчы әле аның кием-салым турында, гомумән, кызларча ничек тә купшырак — чибәррәк булу турында уйлап та бакканы юк иде». (127 бит.) Автор сугыш чорының үтә кырыслыгы, купшыланырга-бизәнергә вакыты да, материаль мөмкинлеге дә булмавы турында әйтергә тели. Әйе, барына канәгать итәргә туры килгән, киемнең дә затлылыгыннан бигрәк ныклыгы, эшкә уңайлылыгы югары бәяләнгән. Затлылык төшенчәсе үзе заманча булган. Болар һәммәсе дә шулай. Ләкин шулай булган хәлдә дә биредә бик мөһим бер психологик фактор исәпкә алынмаган: авыр шартлар хыялны чикләми бит, хыял үз иркендә кала. Җиткән кызлар тормышында исә матурлык хыялы тагын да зуррак урын ала. Матурлыкка омтылу, ана булырга омтылу кебек, аларның канына сеңгән, чөнки ул игътибарны җәлеп итү чарасы. Гәрчә автор монда Гөлзифаның эш интереслары белән яшәвен күрсәтергә теләсә дә, үз матурлыгына битараф, сүлпән карый башлаган кызның эштә дәртле булуына ышанасы килми. Кешене бер өлкәдә сүрәнлек басса, ул сүрәнлек башка якларга да тарала. Психологик төгәлсезлек, шулай итеп, образны ярлыландыруга китерә.

Ә бит без тулаем Гөлзифа образын, аның характерын башкачарак күз алдына китерәбез. Уңганлыгы, тырышлыгы өстенә, ул егетләр йөрәген яндырырлык чибәр дә. Әсәрдә юкка гына аңа урта бармактай өч егет (Давыт, Мөнир, Җиһангир) күз атып йөрми бит! Гөлзифа Давытка чыга. Гөлзифа характерын язучы күбесенчә Давыт характеры фонында ача. Әдәбиятыбыз тарихында хатын-кызны ир-атка караганда активрак, көчлерәк натура итеп сурәтләгән әсәрләр күренеп-күренеп киткәли («Кыйссаи Йосыф»та — Зөләйха, «Тапшырылмаган хатлар»да — Галия, «Чирмешән ярларында» җыр-романында — Мәгъзия). Ләкин шулай да андыйлар еш очрамый. Хатын-кызлар күбесенчә ир-атка караганда йомшаграк характерлы итеп биреләләр. «Йолдызым» повесте бу ягы белән алдарак телгә алынган әсәрләр традициясен дәвам иттерә.

Давыт — башлы, уңган егет. Комбайнда дәртләнеп эшли, кайбер җайланмалар да кертә, ягъни иҗат оеткысы да бар аңарда. Ләкин шулай да Гөлзифа белән чагыштырганда аның буыннары сыеграк булып чыга. Тормышның беренче каты бәрелүеннән соң ук аптырап, йомшап кала, авылдан кыяклау ягын карый.

Сугыштан соңгы еллар авылындагы кайбер күләгәле күренешләргә, изге һәм бөек игенче хезмәтенә хөрмәт җитмәүгә автор да тирән борчыла. Бу мотив, ягъни игенченең җирдән аерылуы мотивы башка әсәрләрдә дә (А. Гыйләҗев. «Берәү» һ. б.) үзенең чагылышын тапты. Әдипләр моны нормаль процесстан тайпылу дип бәяләделәр.

Ләкин шул кыенлыкларны, гаделсезлек очракларын Гөлзифа да башыннан кичерә бит. Аңа әле михнәт шулпасын күбрәк тә татырга туры килә. Ләкин ул, Давыт кебек, сыгылып төшми. Аның җиргә, туган авылына мәхәббәте көчлерәк, характеры ныграк булып чыга. Һәм менә шушы характерлар контрастлыгы әсәргә үзенчәлекле кичерешләр гаммасын китереп кертә. Авырлыкларга, гаделсезлекләргә Гөлзифа сабырлык белән карый, дидек. Ләкин сөйгәне Давыт «тормышның һәртөрле кыек-китеген, ачысын-төчесен йөрәгенә артык якын ала, хәстә-сырхауга якын бик авыр кичерә иде. Аның шулай эчтән сыза башлавын Гөлзифа бик тиз сизеп ала да үзенең дә җан тынычлыгы югала, күңелнең әллә кай җирләре әрни башлый иде. Давытны борчуга салган

сәбәпнең үзе түгел, ә менә иренең моны шул кадәр авыр кичерүе, сызуы хафага сала иде Гөлзифаны». (169—170 битләр.)

Иҗтимагый хәлләрнең кеше күңеленә тәэсир итүе — табигый күренеш. Биредә исә йогынты шактый катлаулы, буынлы-буынлы төс ала, ягъни иҗтимагый тормыш күренешләре бер кеше күңеленә икенче кеше күңеле аркылы тәэсир итә.

Р. Төхфәтуллин балалар психологиясен, аларның уй-кичерешләрен, хыял-омтылышларын бик зирәк һәм поэтик үтемле итеп сурәтли белә. Нәни геройларның куанычшатлыклары да, кайгы-көенечләре дә сабыйларның үз дөньясыннан килә: зурларның исе дә китмәстәй хәлләр аларда давыллы кичерешләр кузгата яки, киресенчә, мөһим күренешләрнең мәгънәсе сабыйлар аңына барып җитмичә кала. Менә Хәйдәр, сугыш чоры малае, солдат әтисе алып кайткан шикәр шакмагын акбур дип кабул итә. (280 бит.) Биредә баланың дөньяны үзенчә танып-белүе белән бергә, чорның үз психологиясе дә күренеп кала. Бу күренеш олылар күңеленә дә зур йогынты ясый.

Р. Төхфәтуллин психологик халәт-кичерешләрне катлаулы төсмерләре, каршылыклары белән күрсәтергә ярата. Хисләрнең төрле юнәлештә агышыннан, тойгыларның капма-каршы якка көчешеннән уңай геройлар да азат түгел. Гөлзифа, мәсәлән, зурлап мактауларга, бер яктан уңайсызлана, әле уңышны күңелдәгечә үстереп булмады, дип уйлый, икенче яктан горурлана да, исеме Давытларга, Зөлхәбирәләргә барып ишетелүгә шатлана. Кайчак тойгы-кичерешләр бик үк логик эзлекле дә булып чыкмый, герой, кеше күңелен күреп-белеп җиткермәү аркасында, артык беркатлылык та күрсәтеп куйгалый.

Поэзиядә шагыйрьләр, прозада Ф. Хөсни, Ә. Еники, Р. Төхфәтуллин һәм башка әдипләр күңел дөньясының тагын бер бик мөһим үзенчәлекле ягына — акыл белән хис көрәшенә еш кына мөрәҗәгать итәләр. Ләкин нишләптер бу бәрелеш төшенчәсе тойгы ягы өстенлек алган чакта кулланылмый. Хис ташкынын тыеп, буып тормау, иркенләп, үз дигәненчә агарга ирек бирү табигый күренеш дип карала. Тойгы кушканча хәрәкәт итү процессында геройның бик матур сыйфатлары, рухи байлыгы, гүзәллеге ачылып китә. Шуның белән бергә тик хисләр тавышына гына колак салу геройны кайчак трагик финалга да китереп куйгалый.

Акыл белән хис бәрелеше төшенчәсе гадәттә тойгы агымына акыл каршы төшә башлаган, контрольлек итәргә керешкән мәлдә килеп керә. Мондый чакта акыл — салкынлык сыйфатлары белән, хис — кайнарлык сыйфатлары белән характерлана, ягъни акыл өчен салкынлык, хис өчен кайнарлык хас дип бәяләнә. Салкын акыл ялкынлы тойгыны үз контрольлегенә алып, тыеп тора башлый.

Инде бу бәрелештә акыл ягы өстенлек алса, мондый хәл кешенең җитдиләнүе, уйнак тойгылардан арынып, акыл утыртуы дип санала. (Һ. Такташ. «Мәхәббәт тәүбәсе».) Хис белән йөрәк конфликтын шушындый яктылыкта сурәтләүне әдәбиятта еш кына очратабыз.

Р. Төхфәтуллинда бу мөнәсәбәт башкарак төсмерләрдә чагыла. «Йолдызым» повестенда Мөнир Гөлзифага тыныч, битараф кына карый алмый. Якын, кадерле ул аңа. Ләкин шул ук вакытта хисләренә дөрләп кабынырга да юл куймый. Чөнки ул, өченче кеше, Давыт белән Гөлзифаның бер-берсен өзелеп яратуларын белеп, күреп тора. Араларына керергә, бәхетләрен җимерергә теләми. Бу факт, әлбәттә, Мөнирне уңай яктан характерлый, аның олы җанлы булуын күрсәтә.

Ләкин моңа карап кына автор хиснә акылны баш итеп кую гел уңай нәтиҗә генә бирә дигән берьяклы караш үткәрми. Давыт Гөлзифага лаеклы булып чыкмый, ул аны ташлап китә. Мондый хәлдә Мөнирнең үз хисләрен тезгенләү мәсьәләсе дә башка төс ала. Элегрәк олы җанлылык булып күренгән вакыйга ахыр чиктә мәхәббәттәге пассивлыкка әйләнә. Мөнир мондый нәтиҗәгә килә: «Хисләреңә һәр вакыт акылны гына баш итеп кую һаман да дөрес кенә булып бетми икән шул ул, һай, дөрес кенә булып бетми икән». (210 бит.) Моны ул ир уртасы булгач, акыл утырткач әйтә. Хискә иркенләп үсәргә ирек бирмәү анда үкенү тудыра.

Без моны күңел диалектикасын эстетик үзләштерүнең бер күрсәткече дип карый алабыз.

Кыскасы, җитди бәрелеш-көрәшләр белән тулы реаль тормышта яшәүче кеше халәтенә нинди психологик төсмерләр хас булса, шуларның билгеле бер ситуациядәге балкышын автор төкми-чәчми, тулысынча күрсәтергә тырыша. Әсәрдә бу кичерешләрнең тегесе дә, монысы да табигый чыга, тормыш шартлары белән аклана.

Гөлзифа образын, аның эшен, җиргә мәхәббәтен, рухи халәтен автор лирик-романтик буяуларда сурәтләгән.

Әсәр «Йолдызым» дип атала. Нәрсә аңлата ул исем? Беренчедән, күктәге йолдызны, Гөлзифаның тик үзенеке генә булган, «бары тик яхшыга, бары тик яктыга гына өнди, шуңа чакыра» (94 бит) торган йолдызны; икенчедән, Гөлзифаның Йолдыз исемле кызын; өченчедән, омтылган идеалын аңлата. Давыт белән Гөлзифа югары белем алу, берсе инженер, икенчесе агроном булып, мул иген уңышы үстерү турында хыялланалар. «Әнә шул хыялны тормышка ашыру өчен тырышырга кирәк, Гөлзифа»,— ди Давыт. (145 бит.) Әйтүен әйтә, ләкин максатына барып җитә алмый. Гөлзифа исә, бик зур авырлыкларны җиңеп, яшь баласы, әнисе белән шәһәргә күчеп, югары белем ала. Ул беләме белән дә, хезмәт урыны белән дә күтәрелә, шуның белән янәшә үк колхозның да экономикасы ныгый, яхшыра бара. Бер урында Давыт Гөлзифаның үзен дә йолдызым дип атый. Дөресен әйткәндә, Гөлзифа укучылар өчен дә якты йолдыз булып әверелә. Бу образга, аның эшлеклелегенә, уңганлыгына, сабырлыгына, түземлелегенә, максатка омтылышындагы ныклыгына сокланып карыйбыз.

Ә. Еники, Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, М. Әмир, Р. Төхфәтуллин әсәрләрендә Бөек Ватан сугышы һәм аннан соңгы чор кешеләренең рухи дөньялары, ягъни хәзерге буын укучыларының зур өлешенә шактый таныш халәт яктыртыла. Зур художниклар шушы таныш материал арасыннан да күңелнең моңарчы гади күз белән күреп җиткермәгән якларын ачып күрсәтәләр, образлы сурәттә укучы күз алдына китереп бастыралар.

**Ф. ХАТИПОВ.**

# НУР ГАЙСИНГА 60 ЯШЬ



*Хөрмәтле Нур ага!*

*40 елга якын иҗат хезмәте дәверендә Сез дистәләрчә шигырь җыентыклары чыгардыгыз. Балалар өчен нәни дөньялар ачтыгыз. Балалар — җирнең чәчәкләре — игелекле булып үссеннәр өчен, Сез аларга шифалы нур иңдердегез. Сезнең «Дуслык бакчасында» мәйдан тоткан «таза Мортаза» образы бик күп укучыларга якын һәм кадерле.*

*1936 елда Казан педагогия институтында укыган чакта басылган тәүге китабыгыз иҗат юлыгызда беренче сынау иде.*

*Укытучы булып эшләү дәверендә сезнең мәктәп тормышы белән якыннан танышуыгыз үз темагызны тагын да тирәнрәк ачуга китерде.*

*Бөек Ватан сугышы башлангач, кулыгызга корал тотып, ил өчен яуга киттегез. Взвод һәм батарея командиры дәрәҗәсендә Сез авыр сугыш юлын үттегез. Коммунистлар партиясе сафына бастыгыз. Бу чордагы иҗатыгыз да укучыларга билгеле.*

*1952—53 елларда армия сафында Ерак Көнчыгышта хезмәт иттегез. «Тайгада очрашу» тәэсиреннән туган шигырьләрегездә үзенчәлекле Себер табигатен, карагайлар шавын, гаҗәп җәнлекләр илен алып кайттыгыз.*

*Хөрмәтле Нур ага!*

*Язучылар союзы идарәсе, «Казан утлары» журналы редколлегиясе Сезне 60 еллык юбилеегыз белән кайнар котлый.*

*Киләчәк әсәрләрегездә тагын да кызыклы, ачылмаган утраулар табып нәниләргә бүләк итәрсез әле.*

*Сезгә сәламәтлек, рухи күтәренкелек, озын гомер теләп калабыз.*

**ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ,**
**«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ.**

# ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

**Радик Исаев**

## ҮРНӘКЛЕ КИЯҮ

хикәя



Безнең авыл ирләренең үз гадәтләре бар. Кичке аштан соң көтү каршыларга дигән булалар да бала-чага шау-шуыннан җай гына чыгып таялар. Аннан, тоз яларга җыелган мал-туар кебек, салмак кына атлап, Сирай бабайларның өй буена киләләр. Халык җыела башлауга, киез итеген киеп, Сирай агай да чыгып утыра.

Бүген дә шунда җыелдылар. Башта көннәрнең торышы турында сүз алышкаладылар. Аннары түбән оч Фәтхинең көтүдән кача торган кәҗәсен тиргәделәр. Балыкчы Галим агайны да телгә алдылар. Имеш, бер зур кушбаш аның җәтмәсен ертып качкан.

Урам уртасыннан кәттә генә атлап Шәрифулла белән Зәбирә үтеп киткәч, патефон тәлинкәсе тагы үзгәрде. Сирай бабай «прибоен» кабызды да:

— Тәки Зәбирә чүплектә яткан Шәрифулланы үрнәкле кияү итте бит,— дип сүзен башлады.

— Ничек үрнәкле? — диде койма буена чүгәләгән тракторчы Хәбип.

— Бәй, быел яңа ел алдыннан бер мәзәк булды бит әле... — диде Сирай агай. — Май кабыгыз, мин сөйләде димәссез. Үземнең дә бу хәлнең шаһиты булырга исәбем юк иде. Сабира апагыз әйтмешли, күрше хакын хаклап, тәки эсвидител булдым бит. Үзегез дә беләсез Шәрифулланың Зәбирәгә ничек йортка кергәнен. Зәбирә бит авылда карап торган бер кыз иде. Чибәрлеген генә әйтмим, эше буенча да ташка үлчим — дүрт Шәрифулланы алыштыра. Хуҗалыгы тагын!.. Өй җиһазлары, йорт-курасы председательнекеннән ким түгел. Кайбер яклары белән узып та китә. Урам коймаларына кадәрен сабынлап юа бит.

Шәрифулласы турында инде авыз ачып сүз дә сөйләрлек түгел. Начарлыгы белән авыл тарихына кереп калган кеше. Хатын-кызлар белән шаяруын әле әйтмәдем. Зәбирә урынында мин булсам, Шәрифулла йөргән урамнан да узмас идем.

— Ярар,— диде Хәбип. — Безнең баш бит ындыр табагы түгел. Кызык урынын гына сөйлә.

— Кызык дип, шул яңа ел алдындагы кичкә килеп җиттек инде. Әбиең белән аш ашап утыра идек. Итәгенә ут капкандай, Зәбирә килеп керде.

— Ни булды? Әллә бер-бер хәл бармы?— мин әйтәм.

— Әлегә берни дә юк. Хәзер генә безгә керәсез дә, мичкә аркагызны терәп тик кенә утырасыз,— ди бу. — Йөзегезгә менә боларны киярсез,— ди. Сумкасыннан битлек алып бирде. Битлекне кигәч, Сабира апагыз миннән, мин аңардан куркып үлә яздым.

Берәр бала-чага уены уйнатадыр дип кердек. Өй эче караңгы иде. Мичендә дөрләп каен утыны яна. Бүлмә ишекләре кара бәрхет белән капланган. Идән уртасында арыш чүмәләсе кадәре әйбер тора. Аның өсте дә каплаулы.

Зәбирә кушканча, мин мич авызының уң ягына, апагыз сул ягына утырды. Безгә сөйләшмәскә кушып, үзе түр якларына чыгып китте.

Тиздән кап-кара киемле, каз шикелле канатлы бер нәрсә каршыбызга чыгып басты. Шүрәле дисәм, ялганчы булырмын. Андый затны күргәнем юк. Әмма шуңа охшаш бер нәрсә инде. Аның артында кулына тәпәч тоткан тагын бер җан иясе күренде.

Илле дүрт ел тормыш итеп, мондый әкәмәтне беренче тапкыр күргәнлектән, тынсыз калдым. Шыпырт кына апагызга да күз салдым. Аның йөрәге шәптән түгел, алай-болай куркып һуштан гына яза күрмәсен, мин әйтәм.

Теге шүрәленең баштa кергәне идән уртасындагы чүмәләнең өстен ачты. Ни күзем белән күрим, лакан эчендә Шәрифулла йоклап ята. Шүрәле заты моның янына килде дә:

— Монысы җәһәннәмгә. Бусын оҗмахка,— ди. — Ә менә бусы, кем эле шайтаның? Кем димен? — дип, Шәрифулланың якасыннан тарткалады. — Әй, син кем, җәһәннәм кисәве?.. — ди.

Шәрифулла уянды. Күзен зур ачып тирә-якка каранды. Каршындагы шүрәлеләрне күргәч, янә күзләрен йомды.

— Адәм баласы, син кем?— диде шүрәле заты, тегенең баш очында тәпәч уйнатып.

— Мин — кеше, фәрештә җаным,— ди бу. — Исемем — Шәркәй. Мөселман затыннан мин... — ди.

— Нигә сине гроб белән куйганнар?— ди шүрәленең берсе.

— Гроб?! Берни белмим!— ди Шәрифулла.

— Әфәндем, мөселманнар исерекне гроб белән куялар бит, — диде тәпәчлесе.

Шүрәле заты Шәрифуллага якынрак килде дә:

— Фу, бу шайтанны әллә инде үзен хәмер кисмәгенә салып куйганнар. Хәзер үк җиденче тәмуг мичена озатыгыз! Бик әйбәт кисәү булыр. Җиде ел яндырырга!— ди.

— Фәрештә җаным. Фәрештә... — дип ялвара башлады Шәрифулла.

— Сөйләнмә, тәмуг кисәве!— дип, Шәрифулланың баш очында тәпәч уйнатты берсе.

— Судсыз хакыгыз юк! Мин претеставать итәм. Совет законнары... — ди теге.

— Монда бер генә закон. Шәригать законы... — диләр моңа.

— Соң, мин бит, белсәң, фәрештә җаным, алтын куллы кеше. Теләсәң, йорт салып бирәм. Самавар торбасы ясыйм. Бал калагына кадәр коям. Берүк яндырып әрәм итмәгез инде,— дип елап ук җибәрде Шәркәй.

— Җиденче мичкә!— дип боерды шүрәле заты һәм Шәрифулланың башына тәпәч белән берне кундырып та алды.

— Хакың юк сугарга. Аллага жалуб язармын,— ди бу.

— Алыгыз ләгыйнне!

Тәпәчле затларның берсе лаканга килеп ябышты. Шәрифулла аңа кизәнде. Теге тәпәч белән тагын Шәрифулланың башына кундырды.

— Жалуб бирәм. Жалуб...

Шул вакыт ак төстәге икенче шүрәле заты килеп керде.

— Нәрсә бара монда, җәмәгать?— диде бу йомшак кына тавыш белән.

— Менә, бер тәмуг кисәвен озатырга дип торабыз.

— Ак фәрештә җаным, зинһар әйтегез үзләренә, судсыз тәмугка салмасыннар,— диде Шәрифулла ялварып.

— Ярый, хәзер уйлашырбыз,— дип, болар чыгып китте.

— Их, хаталандым,— ди Шәрифулла. — Нигә кирәк иде Сәвиянең сәмиен эчәргә. Әллә нәрсәләр кушып ясаганын белә идем бит. Күрәсең, шул башыма җиткән... Тукта, ничек булды соң әле? Зәбирәнең бишлеген чәлдереп чыгып киткән идем. Тәк, кибет янында Фазлый очрады,— ди. — Аның белән бер яртыны кактык. Шуннан мин кайтып киттем. Юк, Баттал бабайларда койма ясаган өчен аласым бар иде бит. Аларга кердем,— ди. — Үзе өйдә булмаса да, бичәсе бер стакан ширбәт суы бирде. Шуннан, Сәвияләргә килеп кердем. Ипи калайлары ясаган өчен расчутлаштык. Калганын белмим,— ди. — Үзе кесәләренә тыгылып карый. Аннан сигара сыныклары чыга. — Кара, үләргә күп кирәкми икән,— ди, ачка үлгәнмен дисәм, кем әйтмешли, кесә тулы сигара. Туңып та үләргә тиеш түгелмен. Өстемдә менә дигән пальто,— ди. — Үткән ел тәрәзә тупсалары ясаган өчен Мәчтүрәдән алган идем,— ди. — Үлгән иренеке булырга тиеш. Мәрхүм, сельпо председателе иде. Сала торгач, минем шикелле дөнья куйды,— ди. — Значит, туңып та үлмәгәнмен... Алайса, үлүемә бер генә сәбәп,— ди. — Теге фәрештә әйткәндәй, хәмер. Ярый, хәзер соң инде. Монда нык торырга кирәк,— ди. — Якты дөньяда рәхәт яшәдем, монда да оҗмах ягын карыйм әле. Аннан тагын күз күрер,— дип сөйләнә Шәрифулла.

Каршыбызга йөзен челтәр белән каплаган бер кызкай килеп керде. Ул сылулыгы, буй-сыннар, аяклар, мин сиңа әйтим. Күрсәң, үлгән кешең терелер. Авыз эченнән генә көйләп йөри тагын.

— Чибәркәй, нишләп монда йөрисең? — дигән булды Шәрифулла, май ашаган песи кебек күзләрен уйнатып.

— Безнең эш беткән инде, абый. Без хур кызлары,— ди бу.

— Хур кызлары? Таныш булыйк, мин — Хафиз,— ди Шәрифулла.

— Әллә корьән Хафизмы?

— Үзе. Менә оҗмахтан урын көтәм.

— Андый кешеләргә урын люкстан гына бирелә шул,— ди кыз, читкәрәк китеп.

— Чибәркәй, исемеңне әйт инде,— ди Шәрифулла.

— Фатыйма,— ди кыз.

— Исемең дә үзең шикелле матур икән. Тагын кайчан күрешербез!— ди бу.

Шул вакыт теге шүрәле кыяфәтле килеп керде. Кыз чыгып китте. Ак фәрештәнең кулында гәзит. Ул кара фәрештәгә карады да:

— Әфәндем, теге ашлык суга торган машинаның исеме ничек әле?— диде.

— Сибагач.

— Туры килми.

— Комбайн,— ди Шәрифулла, аларга таба үрелеп.

— Дөрес. Туры килә. Комбайн. Ә җиһанда оча торган тимер кошның исеме?

— Өй чаклысын әйтәсеңме?

— Шул. Аллаһы тәгаләнең чапанын тишкәне.

— Белмим ул нәрсәне. Аны фиргавен догасы да җиңә алмаган.

— Ракета бит ул, туң башлар,— диде Шәрифулла.

— Беләсең син, әфәндем. Болай булгач, үзеңне ярдәмче итәргә була,— ди ак киемле фәрештә карасына.

— Менә, карале, монда алфавитның беренче хәрефе соралган.

— Башта торганы беренче була инде, әфәндем.

— Шулай да бит. Кайсы хәреф башта тора соң әле?

— Хәтерләмим.

— А хәрефе, диваналар,— ди Шәрифулла.

— Дөрес.

— Хезмәтең өчен,— дип ак фәрештә карасына акча бирә. — Кроссвордны чиштек. Хәзер без...

— Миңа,— ди Шәрифулла, кулын сузып.

Кара фәрештә аңа чукмар белән кизәнә.

— Бу ләгыйн һаман мондамыни?— ди ак фәрештә.

— Суд көтеп ята. Сезнең өмер ничек булыр?

Алар идәнгә аяк бөкләп утырдылар. Ак фәрештә Шәрифуллага карап:

— Мәет, сине күмүчеләр кырык адым киткәч, җавап алырга тиешбез. Шәригать законнары алдауны яратмый. Алдашкан кешегә шунда ук кызган таба ялатабыз. Кем дә кем дөрес сөйли, җәзасы бермә-бер кими. Исемегез?

— Шәркәй дидем бит инде.

— Нинди заттан?

— Мөселман.

— Һөнәрең?

— Авыл халкы бөтен эшкә дә мастер дип йөртә иде.

— Дөньялыкта ничә ел яшәдең?

— Бик аз.

— Бик аз яшәсәң дә, биш кешелек гөнаһ җыйгансың. Монда бары да язулы.

— Биш кешелек булса да, сезнекеннән күп түгелдер әле.

— Телеңә салынма! Семьяң бармы? Хәләл җефетең белән тату яшәдеңме?

— Анда сезнең эшегез юк.

— Безгә ачыкларга кирәк. Хәләл җефетеңә бер суккан булсаң, кулың кайнап торган суда бер көн, ун суксаң, ун көн кайнатылачак.

— Сезнең өчен дә шундый законмы?

— Ай, үтмәс балта белән ясалган нәрсәкәй. Сорауга җавап бир.

— Мин әле егет кеше. Урыным оҗмах түрендә булырга тиеш. Тәртибем дә яхшы. Бригадир рөхсәтеннән башка төкерек тә йотканым булмады.

— Ялган.

— Ант итеп әйтәм. Ай-кояшны күрмим әгәр...

— Җир астында ай-кояш юк. Сорауга җавап бир. Хәләл җефетең бармы?
— Юк.
— Кызган таба!..
Фатыйма керә дә мич алдыннан кызган таба алып Шәрифулла янына бара.
— Яларга!..
Шәрифулла табага төкереп карады. «Чыж» итмәгәч, эт кебек, телен чыгарып ялый башлады.
Бераздан ак фәрештә соравын янә кабатлады:
— Хәләл җефетең бармы?
— Юк. Ышанмасагыз тикшерегез. Шуның өчен бит жалунҗа алып ятасыз.
— Таба!..
Фатыйма икенче табаны алып Шәрифулла янына барды. Шәрифулланың табага телен тидерүе булды, кызган таба май салгандай чыжлады.
— Кәләшең бармы?
— Бар.
— Ничәү?
— Берәү.
— Кем?
— Фазыйла.
— Тагын?
— Юк.
— Никахсызлары?
— Мәчтүрә генә.
Ак фәрештә килеп Шәрифулланың яка астыннан бер кәгазь алды. Шунда ул:
— Бу ятсыз бәндәнең биш хатыны булган,— дип укый башлады.
— Указлы муллаларны да узып киткән бит. Беренче җефете — Фазыйла. Моның тукмавына чыдый алмыйча ташлап чыгып китә. Икенчесе...
— Фәрештә җаным, бу пальто үземнеке түгел. Сельпо председателенеке. Ул хатын-кыз белән шаярырга ярата иде. Мужыт, аның хатыннары бу язуны кыстырганнардыр.
— Зәбирә синең кәләш түгелмени?
— Монысы минеке. Алтын хатын ул. Әгәр монда килеп чыкса, кирәгегезне алырсыз. Елан аягын кискән хатын ул.
— Бу мәсьәләне хәл иттек. Тагын шуны әйт. Дөньялыкта шәраб эчтеңме?
— Анысы нәрсә тагы?
— Шайтан суы.
— Шайтан суы эчкәнем булмады. Менә әкрен тама торганны авыз иткәләдем.
— Әкрен тама торганы нәрсә?
— Бик шәп әйбер ул. Телисезме, хәзер алып киләм. Бирегез акчаларыгызны? Сәвия апаларга гына йөгерәм. Тәк, без монда өч борын, бер чирек алсам, какраз була.
— Син үзеңнең кайда икәнлегеңне беләсеңме?
— Беләм, мин күп эчмәм.
— Шәраб белән дуслыгыңны да ачыкладык. Хәзер без сине кылдин нечкә, кылычтин үткен сират күпереннән чыгарабыз. Чыгалмасаң — мәңгелек җәһәннәм!..
Ак фәрештә мич алдында торган кисәү агачының бер башын лаканга, икенчесен мич казнасына куйды.

Шәрифулла ялкынлап янган мичкә күз салды. Аннан кисәү агачына карады.

— Сәяхәтеңне башла,— диде фәрештә заты.— Әгәр чыга алмасаң, мичтә янганнан соң, менә бу бәндәләр шикелле, үзеңне таш итеп катырабыз.

Имән бармагы белән безгә таба күрсәтте.

— Бу бит кылдин нечкә түгел,— диде Шәрифулла, елмая биреп. — Алтылы тимер чыбык. Моннан гына түгел, судан коры чыга идек әле,— дип, бу лаканнан күтәрелде дә кисәү агачына тотынды. Ут кебек кызган кисәү агачына кулы пешкәч, акырып тәгәрәп китте. Аның белән бергә сулы лакан да идәнгә ауды.

— Чукынчыклар, нишлисез?— дип йөгереп керде Мәхтүмә карчык. — Баздагы бәрәңгегә су агызасыз бит.

Лампаны кабыздылар.

— Шайтаннар! — диде Сабира апагыз.— Көлдереп үтерә яздыгыз. Бер самавар чәй эчеп кергән идем, манма суга төшкән кебек булдым.

Шәрифулла да мәсьәләне аңлап алды. Ул сәке астына ук кереп качты.

Туйганчы көлеп, өйне тәртипкә китергәч, Зәбирә үзебезне өстәл янына чакырып алды. Аннан магнитофонын эшләтеп җибәрде. Бөтен сүзләре тучно-туч язылган. Җитмәсә, теге Әптерәй малае чаршау артыннан гына сурәткә төшереп утырган. Чәй эчеп бетүгә, кәртечкәләрен дә өстәлгә китереп куйдылар.

Үлдек көлеп. Тик менә шунысы — мәчегә көлке, тычканга үлем дигәндәй, Шәрифуллага гына бик кыен булды. Ул, мескен, айлар буена кеше күзенә күренмәде. Бу хәлне халыкка фаш итмәгез инде дип, безгә генә унбер хат язды.

Бу өкәмәткә байтак вакыт үтте инде. Шәрифулланы әйтәм, тәки үрнәкле кияү булды бит. Хәзер эчәргә түгел, магазин урамына да бармый. Әле үзен, беләсез, ферма мөдире итеп тә куйдык. Мөдирмен дип тормый: кулы белгәч, капка да ныгыта, тәрәзә дә куя. Чынмы-бушмы, укырга да китә, имеш, дигән хәбәр дә бар,— дип, Сирай бабай мәзәген тәмамлады.

## ПУДЭШ ПАТЯН[1] ХИКМӘТЛӘРЕ

*
* *

Җор һәм тапкыр Пудэш Патян берчакны азык-төлек складына килеп керә. Анда ревизия бара икән. Тикшерүчеләр язасы актларын ничек очларга белмичә баш катырып утыралар.

— Менә бер пот ыслаган итне карак мәче ашаган дидек. Ә ун литр спиртны кем өстенә язарга?

— Шул ук мәчегә аударыгыз! — дип, җитди сүз кыстыра Пудэш Патян.

— Ә моңа кем ышаныр соң?

— Ә бер мәченең спирт эчмичә бер пот ит сыпыра алуына кем дә булса ышаныр дип беләсезме?!

*
* *

Бер бик фырт егет башына котелок сыман бик сәер кием кигән. Салам эшләпәле Пудэш Патян белән очрашкач, әлеге егет:

— Синең баштагы бу саескан оясын эшләпә дип беләсеңме? — дип сүз кушкан.

— Ә син шул сәер котелок белән капланган нәрсәң баш дип уйлап ялгышмыйсыңмы икән? — дип җавап биргән аңа Пудэш Патян.

*
* *

Бер юан агай Иделдә бата башлагач, аны кыю бер елгачы егет коткара. Ясалма сулыш алдырганнан соң, һушына килгән агай юешләнеп өлгермәгән янчыгыннан егеткә өч сум чыгарып суза. Шуны күрүчеләр шаулап-дулап ачу белдергәндә, алар янына Пудэш Патян килеп чыга һәм:

— Бәйләнмәгез аңа, дуслар! Сүз әйтеп тел талдырмагыз: үз бәясен ул бездән яхшырак белә!..— дип, кешеләрне тынычландыра.

*
* *

Караңгы баскыч төбендә Пудэш Патянга әзмәвер хәтле бер «сабый» егет очрый.

— Таныйсыңмы мине?

— Әлбәттә, таныйм: син — Сенька-химик!

— Каян белдең? Тавышымнанмы?

— Юк, авызыңнан аңкыган аракы исеннән!.. — ди Пудэш Патян.

---

[1] Хәзерге чуваш әдәбиятының фольклор герое турында язмалардан («Чуваш юморы». Чабаксар. 1973).

*
* *

Көннәрнең берендә тегүче янына кергәч, Пудэш Патян бер хатынның чамадан тыш тар итәкле күлмәк тегәргә үтенүен ишетә:

— Заманнан артта калырга теләмим! — ди ханым.

— И- затлым,— ди аңа Пудэш Патян,— шундый тар итәк белән заманны куып җитә алырсыңмы икән син?

*
* *

Бик модный бер яшь шагыйрьнең китабын укыгач әйтә икән Пудэш Патян:

— Сездә уңышлар һәм яңалыклар күп! Әмма шунысы кызганыч — уңышларыгыз яңа түгел, ә яңалыкларыгыз уңышсыз!..

*
* *

— Романымның дүрттән өч өлешен үзем-үзем тәнкыйтьче буларак утка яктым! — дип мактана күп яза алучы бер абзый. — Ничек уйлыйсың, Пудэш Патян: дөрес эшләдемме икән мин?

— Бик үк дөрес түгел.

— Ә ник?

— Тагын бер чиреген яндырасыгыз калган!

*
* *

Сура елгасына балыкка баргач, Пудэш Патян кармагына... бер кысла эләгә. Балыкчыбыз моңа бик гаҗәпләнеп карап торган да:

— Минем сумкада бер савыт сыра барын каян белдең әле син? — дигән.

*
* *

Пудэш Патянның бер артист турында фикер әйтүен сорыйлар:

— Аның кайсы рольдәге уенын иң яхшы дип саныйсыз?

— «Кәҗә» сукканда бик шәп уйный ул!.. — дигән көлке капчыгы.

*
* *

«Иртәгәгә хәтле генә» дип, бик ялварып акча сорап торган бер танышына Пудэш Патян биш сум бирә. Таныш дигәнебез, бик күп вакыт үткәч тә, шул бурычны һич кайтармый икән һәм, җитмәсә тагын, Пудэш Патянның күзенә күренмәскә тырыша — аңардан качып йөри. Бервакыт очраклы гына туры килеп күрешә язгач, теге урам аша кирегә элдертә икән... Кирәк бит: бурычлы кешене милиционер туктата һәм, урамда йөрү кагыйдәләрен бозганы өчен, аңардан нәкъ биш сум штраф ала. Пудэш Патян бу хәлне күреп тора һәм иске танышына:

— Кагыйдәләрне бозарга ярамый! Алган бурычыңны түлисе кешеләрдән качмассың икенче! — дип усал итеп кычкыра.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

*
* *

Театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе артисты *Айрат Гәрәй улы Арслановка* ТАССР Верховный Советы Президиумының 1974 ел, 5 августта игълан ителгән Указы нигезендә *Татарстан АССРның халык артисты* дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисткасы *Гөлсем Сабир кызы Исәнгуловага* һәм Минзәлә драма театры артисты *Әхмәдулла Җиһангир улы Җиһаншинга Татарстанның атказанган артисты* дигән мактаулы исемнәр бирелде.

*
* *

ТАССР Верховный Советы Президиумының шул ук көнне игълан ителгән Указы нигезендә, музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры солисты *Владимир Тимофеевич Степановка* да *Татарстан АССРның халык артисты* дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Тарих фәнен үстерүдәге хезмәтләре, нәтиҗәле педагогик һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен тарих фәннәре докторы, профессор, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы тел, әдәбият һәм тарих институтының археология һәм этнография секторы мөдире *Альфред Хәсән улы Халиковка Татарстан АССРның атказанган фән эшлеклесе* дигән мактаулы исем бирелде.

## СЕЗОН УҢЫШЛЫ ТӘМАМЛАНДЫ

Казан дәүләт курчак театры быел үзенең кырыгынчы театр сезонын тәмамлады. Ул республикабыз районнарында һәм Дагстанда, Киевтә, Башкортстанда, Пермьдә булып, нәни тамашачыларга Е. Череповецкиның «Әй, бу Мыцык», П. Амосова һәм Е. Петроваларның «Атаклы үрдәк баласы Тим мажаралары», Н. Фәттахның «Энҗеле үрдәк», Т. Миңнуллинның «Азат» исемле әсәрләре буенча эшләнгән спектакльләрен күрсәтте.

## СҮЗ ОСТАСЫНА БАГЫШЛАНГАН КИЧӘ

Казанның Максим Горький исемендәге үзәк культура һәм ял паркында нәфис сүз остасы Әзәл Яһудин иҗатына багышланган кичә үткәрелде. «Яшәү рәхәт, яшәү күңелле» дип аталган ул кичәдә Ә. Яһудин татар һәм рус язучыларының юмористик шигырьләрен һәм хикәяләрен укыды.

*
* *

Чиләбе филармониясенең эстрада ансамбле Казан культура сарайларында концертлар биреп китте. Ансамбль җырчылары Борис Болимаков, Людмила Семина, Евгений Устиновлар җырлаган җырлар һәм алты бертуган Геннадий, Иван, Владимир, Виктор, Вячеслав һәм Леонид Карачинцевларның оста итеп биюләре Казан тамашачыларының күңеленә хуш килде.

## ҖӘЛИЛЧЕЛӘР ӨЧЕН

Җәлил шәһәрендә тамаша залы 535 урынлы, меңнәрчә том китап сыйдырышлы зур китапханәле, бик әйбәт спорт залы, төрле түгәрәкләр өчен күп кенә уңайлы бүлмәләре булган яңа техника йорты ачылды. Аны ачуга багышланган тантаналы кичәдә Татарстанның халык артисты Илһам Шакиров катнашы белән зур концерт бирелде.

Тиздән әлеге техника йортында Муса Җәлил музее да оештырылачак.

## «ЯЛАВ» ЖУРНАЛЫНА 50 ЕЛ

Шушы елның август аенда чуваш язучыларының әдәби журналы «Ялав»ның чыга башлавына 50 ел тулды һәм шул уңай белән ул журнал «Почет билгесе» ордены

белән бүләкләнде. Чувашстан язучылар союзы чакыруы буенча, әлеге журналның тантаналы юбилей кичәсендә язучы Вакыйф Нуруллин да катнашты.

## ГЕРОЙ ШАГЫЙРЬГӘ БАГЫШЛАП

Чиләбе шәһәрендә Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренә багышлап, еш кына «Үлемсезләр» дигән тематик кичәләр үткәрелә. Шул кичәләрнең берсе Чиләбе шәһәренең Ю. Гагарин исемендәге паркында үткәрелде. Анда шул көннәрдә Чиләбедә гастрольдә булган Татарстан артистлары Р. Билалова, И. Ишбүләков, Ф. Юсупов, Р. Ильясов, Т. Әхмәтов, Р. Халитов иптәшләр дә катнашып, «Алтынчәч», «Җәлил» операларыннан өзекләр, арияләр башкардылар. Чиләбе тамашачылары моның өчен Татарстан артистларына зур рәхмәт белдерделәр һәм иҗат уңышлары теләп калдылар.

## ҮЗЕШЧӘННӘР СМОТРЫ

Профсоюзларның Татарстан өлкә советы, республика курортлар идарәсе һәм профсоюзлар өлкә советының үзешчән сәнгать йорты Васильевода республика ял йортлары һәм санаторийлары үзешчәннәренең смотрын үткәрде. Анда унбер коллективтан 200 ләп кеше катнашты. Смотрда беренче урынны Васильево санаторие һәм Берсут ял йорты үзешчәннәре яулап алды. Аларга бүләкләр бирелде.

*
* *

Мәскәүнең Кече Бронныйдагы драма театры артистлары Леонид Каневский, Валентин Смирницкий, Григорий Лямпе, Георгий Мартынюк илебез тамашачыларына «Тикшерүне белгечләр алып бара» исемле күп серияле телевизион фильм буенча танышлар. Әлеге артистлар август аенда Казанга килеп, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасында чыгыш ясадылар һәм тамашачылар күңелендә җылы хис калдырдылар.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Драматургларыбыздан Риза һәм Рәисә Ишморатовлар, шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов, ТАССРның атказанган артисткасы Җәвәһирә Сәләхова һәм яшь шагыйрь Марсель Галиев Мөслим районының Уразмәт, Чишмә, Татар Буләр, Мари Буләр, Чакмак, Иске Карамалы авыллары культура йортларында әдәби кичәләр үткәрделәр. Алар кырда эшләүче механизаторлар янына барып та чыгышлар ясадылар.

*
* *

Прозаик Хәсән Сарьян белән шагыйрь Зәет Мәҗитов Куйбышев районындагы авылларда китап сөючеләр белән очрашып, аларны үзләренең яна әсәрләре белән таныштырып кайттылар.

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫ!

Республикабызның төрле почмакларында зур эшләр башкаручы яшьтәшләреңнең тормышы, хезмәте, ялы турында синең, мәгаен, даими рәвештә белеп торасың киләдер. «Татарстан яшьләре» газетасын алдырасың икән, син, һичшиксез, бу теләгеңә ирешерсең.

Шулай ук яшь язучылар, шагыйрьләр, композиторларның яңа әсәрләре, шигырьләре, җырлары белән танышып барырга да каршы килмәссең. Кызыклы язмышлы кешеләр, хезмәттә зур уңышлар яулаган егетләр һәм кызлар турындагы язмалар да сине үзенә тартмый калмаслар. Боларның барысын да син «Татарстан яшьләре» газетасында табарсың.

Үзенең ярты гасырдан артык тарихы, үзенә генә хас традицияләре булган «Татарстан яшьләре» газетасы һаман да яшьлеккә тугрылыклы. Ул яшьләрнең якын киңәшчесе, дусты булып кала бирә. Газетаның «Сезнең хатларыгызны укыйбыз», «Хат юлга чакырды», «Күп беләргә теләсәң», «Классташ», «Кем булырга?», «Сердәш» кебек рубрикалары астында чыга торган материаллар сиңа бик күп сорауларыңны ачыкларга ярдәм итәрләр.

Әгәр син комсомол работнигы икәнсең, «Комсорг мәктәбе», «Секретарьның куен дәфтәренә» һәм башка шундый рубрикалар белән бирелә торган материаллар эшеңдә кулланма булырлар.

Шулай булуын телисең икән, хөрмәтле укучы, «Татарстан яшьләре» газетасын өеңә алдырып даими укып барырга онытма.

Подписка Татарстанда яшәүчеләрдән республиканың теләсә кайсы элемтә, почта бүлекләрендә, «Союзпечать» агентлыкларында кабул ителә. Аңа шулай ук урыннарда җәмәгать тәртибендә матбугат таратучылар аша да язылырга мөмкин.

Ә Татарстаннан читтә яшәүче иптәшләр газетага язылу бәясен түбәндәге адрес буенча җибәрергә тиешләр.

*420066, Казань, улица Декабристов, 12. Областное отделение «Союзпечати». Для подписки на газету «Татарстан яшьләре».*

**Газетаның еллык бәясе 3 сум 12 тиен.**



Драматург НӘКЫЙ ИСӘНБӘТ

Ф. ӘМИНЕВ рәсеме

## Хөрмәтле укучыбыз!

Республикабызның күп кенә районнарында яшәүче хезмәт ияләре 1975 ел өчен «Казан утлары» журналына язылды да инде. Чистай, Лениногорск, Әлмәт, Сарман, Актаныш, Мөслим, Балтач, Минзәлә районнарында журналга язылу гаруча уңышлы бара.

«Казан утлары» журналы редакциясе бу районнарда журнал таратучы иптәшләргә һәм журнал алдыручыларга рәхмәтен белдерә, журналга язылу эше алдагы айларда да шул темплар белән барыр дип өметләнә.

Редакция республикабызның башка районнарында да «Казан утлары» укучыларының саны артыр дип ышана.

Туган илебезнең союздаш республикаларыннан һәм ерактагы өлкәләреннән дә журналга язылырга теләүләрен белдереп күп кенә хатлар килә. Шуны искә алып, журналга язылу тәртибен укучыларыбызның кабат исенә төшереп үтәбез:

«Казан утлары» журналы 73210 номерлы индекс белән бөтенсоюз каталогына теркәлгән. Журналга язылганда әнә шул индексны әйтергә кирәк.

«Казан утлары» журналының еллык бәясе 6 сум.

«Казан утлары» журналына Советлар Союзының барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин.

«Казан утлары» журналына тулы бер елга язылып кую уңайлырак.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210